
# казан утлары

3
МАРТ — 1977




*Галимҗан Ибраһимов.*

*М. РӘХИМОВ рәсеме.*

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

**3**

МАРТ
1977

## Бу санда

С. ХӘКИМ. Яңа шигырьләр . . . . . . . . . 3
Г. АХУНОВ. Идел кызы. Роман . . . . . . . 8
Г. РӘХИМ. Сокланыйк без... Шигырьләр . . . 74
М. ГАЛИЕВ. Кайтавазлар. Шигъри парчалар . . 79

АЙ, КОЯШ ҺӘМ ЧӘЧӘКЛӘР

К. БУЛАТОВА. Чатнап торган аяз кичнең... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 83
С. ГӘРӘЕВА. Тимер елый. Шигырьләр . . . . 84
Р. ВӘЛИЕВА. Мәхәббәт дәфтәреннән. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Ш. ТАҺИРОВА. Тукайга. Шигырьләр . . . . . 88
Э. ШӘРИФУЛЛИНА. Диңгезче малае. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 89

ОЧЕРКЛАР

Х. ЗАРИПОВ. КамАЗ елъязмачысы . . . . . . 91
Э. КАСЫЙМОВ. Ык Тамагында . . . . . . . . 96

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

М. ХӘСӘНОВ. Әдипнең бөеклеге . . . . . . 108
Г. ХАЛИТ. Чынлык һәм гүзәллек гармониясе . . 121
Р. ГАНИЕВА. Галимҗан Ибраһимов һәм Көнчыгыш әдәбиятлары . . . . . . . . . . . 134
А. ӘХМӘДУЛЛИН. Галимҗан Ибраһимов һәм татар драматургиясе . . . . . . . . . . 141
Н. ЮЗИЕВ. Академиянең 250 нче әгъзасы... . . 147
Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Җаваплылык хисе . . . . 151
Г. ӘХӘТОВ. Язучы фразеологиясенең кайбер үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . 157
С. ПОВАРИСОВ. Тел диңгезе . . . . . . . 159
И. АБДУЛЛИН. Әдипнең тагын бер хаты . . . 162
Ә. РӘШИТОВ. Җалита... Җалита. Шигырь . . . 163

КАЗАННЫҢ 800 ЕЛЛЫГЫНА

С. АЛИШЕВ. Тарихтан бер сәхифә . . . . . . 165

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Х. ТӨХФИ** шигырьләре . . . . . . . . . . . 170

КИТАП КҮЗӘТҮ

**М. САДЫЙКОВ, Х. МӘХМҮТОВ.** Татар мәгърифәтчелеге турында яңа хезмәт . . . . . . 173

УКУЧЫ СҮЗЕ

**Ә. Еникигә хатлар** . . . . . . . . . . . . . 178

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Ф. АБДУЛЛИН.** Көрәшче Тимерләр һәм Миңҗамал җиңги. Хикәя . . . . . . . . . . . 181
**МӨМДИ.** Гыйбрәтле диалоглар . . . . . . . 182
Көрд халык иҗатыннан . . . . . . . . . . 184
**М. КОРЮН.** Күп лыгырдау бәласе. Шигырьләр . 187

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 3/XII-1976 ел. Басарга кул куелды 4/II-1977 ел. ПФ 09001. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 84344 экз. Заказ К-410. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1977 ел.

Сибгат Хәким

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

●

Йөрдем озак кичке урамнарда
Очратырга теләп Тукайны,
Уйлар минем уйнап-кайнап торган
Йолдыз тулы күккә текәлде.
Тукай — йолдыз, җылы, йомшак, иркен
Бишенче ел җәе күгеннән,
Бишенче ел тетрәүләрен тыңлап,
Җәйрәп яткан Җаек күгеннән
Атылып чыккан йолдыз, биек, якты
Унҗиденче еллар күгенә
Барып җитми янып сүнгән йолдыз,
Эзе ләкин һаман күренә.
Күп күзәттем йолдыз атылганын,
Эзе — күктә, эзе — акылда,
Сүнгәндә дә йолдыз йолдызларның
Арасына икән атыла.

●

Фронттан бирле салмаган
Итегем аягымда,
Кайттым мин сугыш беткәч тә
Авылга май аенда.
Атладым җайга, янда ат,
Арсаң атта барасы,
Фронтлар арасы түгел
Арча — Әтнә арасы.
Кайттым чик куеп үлемгә,
Җирдәге бар әрнүгә,
Сәер хис: гаҗәп, кешеләр
Җир казый бәрәңгегә.
Ышанмый күңел, уйлыймын
Сугышның утын һаман,
Сәер хис: кешеләр җирдә
Бәрәңге утырталар.

●

Утырып ява да яңгыр,
Төсләр аралаша да,
Салават күпере тоташа
Кырдагы полосага.
Күренми очы-кырые,
Барасым күптер сыман,
Бу күпер — иҗатка яңа
Салынган күпер сыман.
Керәм, кемнәрдер алдыма
Әйтерсең палас сала,
Студиягә кергән күк
Керәмен полосага.
Керәмен, кагыла ботаклар
Бик таныш куллар кебек,
Кемнәрдер кичә полоса
Сузган да куйган кебек.
Һәркайсы таныш, кул биреп,
Күрешәм берәм-берәм,
Ямь-яшел пластинкаларны
Көйләгән өрәңгеләр,
Мәңгелек пластинкалар күк
Өрәңге яфраклары
Әйләнә, бөтен моңнарны
Язганнар як-яктагы.
Озатып кала зирекләр,
Озатып кала чаган,
Буыннар тавышын тыңлап
Узамын полосадан.

●

Тыкрык башында иске йорт,
Тузаннан каплап йөзен,
Тора ул чатта, түбәсе
Яшел мүк — яшел уҗым.
Тыкрык башында иске йорт,
Тузган, тузан, боек, тын,
Тигез, гөр килгән чакларын
Белә идем бу йортның.
Таралган... Ничә яз килеп,
Ничә җәй һәм кыш үткән,
Тагын яз, ишегалдында
Әрекмән дә кычыткан.
Каз бәбкәләре янында,
Ярлы, ишле балалы,
Үстергән безне авылның
Шул киң ишегаллары.
Чатта йорт... Капкасын ачып,
Ул каршы алмый инде,
Йөрим шул капка төбендә,
Йөримен арлы-бирле.
Тынлыкта шунда оядан,
Кыегыннан чорманың,

Сыерчык баласының мин
Ишеттем чырылдавын.
Тыкрыкта, кечке эңгердә,
Тынып шундый чырылдый;
Гәүдәсе, оясы, йорты —
Бөтен нигезе дерелди.
Чырылдый ярсып, охшаган
Башы орчык башына,
Калдырып җаваплылыкны
Сыерчык баласына,
Таралган бу йорт, төрлесен
Төрле якка очырган...
Сыерчык баласы белән
Тик мин генә ул чордан.

●

Кайтты Тукай,
Ялдан кайткан сыман,
Әйбәтләнә төшкән саулыгы,
Үз урынына калып торганнардан
Кабул итеп алды Чаллыны.

●

Тукай теле, аның «Туган тел»е
Әйтерсең бер изге догалык,
Шамаилләр итеп элгән халык,
Әй, бу халык, бөек бу халык.
Ул бер кулы белән һәйкәл салган
(һәйкәлләрен аның сана, ил),
Ул икенче кулы белән үзенең
Шагыйренә язган шамаил.

●

Шагыйрьләрнең Аккош күлендәге
Дачасында (димә: наяннар),
Флокслар белән бергә үсә
Пугачевлар, Гомәр Хәйямнар.
Чәчәкләргә гашыйк Хәсән Туфан
Бакчасында күзге бер таңда
Үзе баккан чәчәкләрне өзә,
Изгеләрчә илтә Тукайга.
һәр ел шулай, һәр ел бер вакытта
Куя чәчәк, Тукай — алласы,
Шунда тәмам кушылып бетә кебек
Тукай белән Туфан арасы.

Кайта ул көтү алдыннан,
Тоеп дөнья киңлеген,
Әйтерсең майда Берлинга
Килеп кергән көн бүген.
Көтүе тәрткән дә башын
Ул атлап барган юлга,
Уйларын гүя тәшенгән
Кабатлап бара шунда.
Көтүе сүзсез буйсынган,
Бер сүзсез күнгән барсы,
Кайта ул көтү алдыннан,
Зур, горур күләгәсе
Яткан кич тыныч кырларга
(Үткән ул уттан-судан),
Көтүен алып бара күк
Җир шары уртасыннан.
Читенә басам-басам дип,
Бата барган кояшның,
Атлый... Шагыйрь башым белән
Атлавыннан көнләштем.
Көнләштем, хәрәкәтендә
Сизелә бөек заманы,
Атлый, кырларның өстендә
Ике канат — кожаны.

●

Бу гомерне рухның күтәренке
Көннәрендә икән син очла,
Үч иткәндәй туры килә шул рух
Дугадагы авыр сугышка.

●

Татарларның үзләреннән алда,
Бөек эшләр көткән таңнарда
Гармуннары килеп керә башта
Тольяттилар, КамАЗ, БАМнарга.

●

Үз җиремдә кыйммәт торам,
Торам алтын мин монда,
Торам кыйммәт — һәр җырымны
Язам алты миллионга.

●

Һәйкәлсез авыл... Солдатлар...
Сагына кем алар кебек?!
Тик һәйкәл юкка авылга
Керми торалар кебек.

●

Кинәт кенә килеп чыгалар да
Есениннар белән Шукшиннар,
Югалалар кинәт — тагын бушлык...
Аңлатырлык сүзләр юк шуңар.

●

Яшәртеп җибәрә иде
Бер шат сәламең элек,
Каралдың яңгырлы көзнең
Борчак саламы кебек .

●

Утыз елдан соң да блиндажда
Кул сәгате... Кәтик килгәнче,
Котелогын тотып батальонның
Кухнясына киткән иясе.

●

Кайда сез, безнең әниләр!
Табып, алларга салып,
Бишеккә салып тирбәткән,
Кабык арбага салып,
Таң белән уракка киткән
Шаулатып тыкырыкны...
Тугыз-ун бала үстергән,
Сабыр һәм киң холыклы,
Кайда сез, безнең әниләр!
Көн арты көн баеган,
Ургансыз, суккансыз ялгыз,
Шул хакта комбайннар
Уйлана бүген кырларда,
Җиремнең саф орлыгы
Агыла бункерга... сагынам:
Зур җанлы, сабыр, олы,
Кайда сез, безнең әниләр!

●

Чаллыда иске нигездә —
Йорт күчкәч, калган шунда —
Утыра ялгызы чия
Кирпечләр арасында.
Яшәдек тигез диган күк,
Бәхет теләп халкына,
Ул чәчәк аткан шушында
Узган көннәр хакына.

1976

Гариф Ахунов

# ИДЕЛ КЫЗЫ

РОМАН

ӨЧЕНЧЕ БАШЛАМ

## I




ел.

Россия давыл кузгаткан диңгез төсле шаулый.

Петроградта, Мәскәү белән Казанда, Урал һәм Себер калаларында, җир читенә урнашкан Владивостокта — митинглар ташкыны.

Бетсен сугыш! Илгә — иминлек! Сигез сәгатьлек эш көне!

Казан йортларының, департаментларның, солдат казармаларының стеналарыннан алтын погонлы патша сурәтләре очып төшә. Өч гасыр буена сузылган Романовлар хакимлеге халыкның бавырына кара таш булып утырган; мылтык һәм табут күтәрүдән чиләнгән җилкәләр, нахакка аккан каннарны күрүдән бозылган йөрәкләр сызлый. Шуңа күрә патша сурәтен ярсып таптыйлар, тилереп-шашып ерталар.

Россия давыл кузгаткан диңгез төсле үкерә.

Хәвефле хәбәрләр, йомгак төсле тәгәрәп, Кама буйларына да килеп җитте, бу якларның да вакыйгаларын үзе белән ияртеп, үсте, зурайды, чынга әйләнде.

Февраль азагында тирә-як крестьяннары Алабуга бояры Стахиевларның аракы заводын таладылар. Барлык аппаратларын ачып, чирекләп һәм чиләкләп алдылар аракыны. Мичкәләп тәгәрәтүчеләр дә булган. Аракы кирәкмәгәне, үч алу нияте белән ярсып килгәне, лом белән, кувалда белән эш иткән. Завод тәмам эштән чыгып, бар булган спирты җиргә аккан, карны, хәтта туң җирне эрстеп, дуен балчыкка хәтле төшеп җиткән. Анысын зирәк акыллы авыл агае юри эшләгән, диләр: еллар иминләнеп, заманалар тынгач, дуен балчыктагы спиртны янә дә сөзеп алмакчылар, имеш.

---

Дәвамы. Башы 1, 2 саннарда.

Дәһшәтле хәбәрләр көнләп түгел, сәгатьләп арта. Чистайның сыра заводын җимергәннәр; Лаеш алпавытының җир-суларын тартып алып, үзен биләмәсеннән куганнар; Алабуга тегермәненнән олавы-олавы белән он төяп киткәннәр. Байлар паникага бирелеп кача, качмаганы Казанның генерал-губернаторыннан бунтчыларны, закон бозучыларны бастырырга гаскәр сорый, имеш.

Олы давылның бер итәге Зартугайга да килеп җитте: ярсып кузгалган ярлылар Таминдар байның аяклы амбарын Иш өстенә ишеп төшерделәр. Еллар буена рәнҗетелгән крестьяннар, кара болыттай кузгалып, Шакир хаҗи йортына таба китте. Авылның күрке булган калай түбәле йорт җилсез тымызык төндә, ярты күкне иңләп, кара күмергә калганчы, япа-ялгызы утырып янды. Күзләрен кан баскан ярлылар карап торып, бии-бии яндырдылар йортны. Күршедәге Әфләтун бакырчы йортына да зыян килде. Шакир хаҗиның ике катлы биек йортыннан бакырчы йортына беләк буе кисәү башлары очып, аны «ә» дигәнче көл иттеләр. Янгында булганнар ахырдан мәзәк итеп сөйләде:

— Авылдашлар, гаеп итмәгез инде, пажарым Шакир хаҗиныкы төсле матур булмады, ходай кушса, икенче юлы, зуррак йорт салгач, яндырырга килерсез,— дип әйтте ди Әфләтун абзый, аннары кара күмергә калган йорт урынына утырып, күз яшьләрен түкте, ди.

Тирә-як авыллардан көн дә саен ишетелеп торган шомлы хәбәрләрнең күпмесе чын, күпмесе уйдырма булгандыр, әмма Солтанның үз күзе белән күргәне моңарчы булмаган өр-яңа заманнарның килеп җитүен аермачык әйтеп тора иде. Таминдар Тураев мәктәбендә, зур сыйныфлар укый торган бүлмәдә, Микулай патша сурәте бар иде. Мөгаллимнәр белән руханилар беренче сүзләрен: «Аллаһы тәгаләнең кодрәте вә патша хәзрәтләренең ризалыгы белән...» дип башлап җибәрәләр иде. Малайлар бер дә бер көнне шул сурәтне стенадан алып, кадак белән күзен тиштеләр, аннары өстенә менеп сикерделәр. Беркемгә берни булмады. Тик учитель Гаврилов кына: «Атавизм! Варварлык! Болай булса, анархизмга тәгәрибез!»— дип, бөтен мәктәпне бер итеп кычкырып йөрде.

Шуннан соң вакыйгалар акыл иярмәс тизлек белән алмашынып тора башладылар.

Зартугайга Шәяхмәт Айдаров кайтып төште.

Бер дистәгә якын җайдак озатуында, озын торыклы алмачуар атта Зартугайның югаргы очыннан килеп керде дә, авыл этләренең тынычлыгын алып һәм Зартугайның буеннан-буена тузан болыты сузып, кайчандыр үз йорты булган җиргә — Габделхәлим сәүдәгәр кибете алдына килеп туктады.

Өзәңгедән аягын алып җиргә сикерде, ут янып торган җирән мыеклы чая егеткә йөгән тезгенен тоттырып, кибет болдырына менеп басты, авылдан урман буйларына шае китеп барган тузан тасмасына карап торды, башыннан папахасын салып, тирләгән, авыр елларның җыерчыгы буразналаган дәү маңгаен ашыкмый гына сөртте, тик шуннан соң гына шпорлы итекләре белән каты-каты басып болдырга менеп җитте. Габделхәлим бай кибетенең ишеген каерып ачып җибәрде.

— Сәлам бирдек купец әфәнделәргә!— Буынтыклы зур кара кулын кылыч сабына китереп куйды.

Прилавка янында басып торган Габделхәлим сәүдәгәрнең йөзе мәет кебек агарды, теле тотлыга башлады:

— М... минем... г... гаебем...

— Калтыранма, Габделхәлим абзый! Гаепсезгә тырнак белән дә чиертмибез!— Хуҗаларча бер эшлеклелек белән, ашыкмый гына киштәләрдәге ситсы товарны, лардагы тозны, мичкәдәге керосинны

карап чыкты. Тавышын әкренәйтеп, пышылдау дәрәҗәсенә җиткезеп, сорады:— Таминдар Тураев өйдәме? Нәбкәй староста? Минҗанныкылар? Ник дәшмисең?!

Бармак белән ымлап кибетчене үз янына чакырды. Куркудан очкылык тота башлаган кызыл малчының иңбашына кулын китереп салды, аның чүгеп куюыннан сабыйларча рәхәт елмайды:

— Сезнең нәсел ярлы-ябагайны талаганда гына батыр икән, җәза күтәрү ягына буыннар йомшак икән сезнең, ә?! Менә нәрсә, Габделхәлим абзый, Таминдар Тураевка әйт, Шәяхмәт Айдаров кайтты, диген, кибетләрен иртәгә үк берсен бер калдырмый ярлылар комитетына тапшырсын. Аңладыңмы? Мал-мөлкәтнең инәсенә дә тимәсен. Шырпытозны, керосин-мазарны яркәм [1] авыл ярлыларына өләшер.

— Каян килгән кәмитет ул? Юк бит ул бездә,— диде бераз хәл җыеп алган Габделхәлим сәүдәгәр.

— Булдырырбыз! Ишеттеңме?

— Ишеттем, энем Шәяхмәт.

— Бик яхшы, ишеткәч. Кисәтеп куям: өләшмәсә, үзенә үпкәләсен. Бүре базына алып чыгып җанын җәһәннәмгә олактырырмын!

«Олактырмый тор. Таминдар бай без түгел ул сиңа, әллә кайчан гаскәр туплап куйгандыр инде. Синең ише әтрәк әләмне буш кул белән күтәп ятмагае, тот капчыгыңны!»— дип уйлады кызыл малчы.

Шәяхмәт шпорлы итекләре белән каты-каты басып болдырдан төште, җиләненең чабуларын җилфердәтеп, алмачуар атына сикереп атланды, каравыл өенә таба чаптырып китеп барды. Артыннан тузан баганасы сузып атлылары чапты.

Ул Зартугайда ун көн чамасы яшәде. Шул вакыт эчендә ярлылардан актив оештырды, яркәм төзеде, комитетка башлык итеп Салагышның укый-яза белә торган кешесе Вәҗине, комитет әгъзалары итеп Шәрифҗан мөгаллимне, бакырчы Әфлатунны, ике авылның икесеннән дә ышанычлы дип саналган тагын биш-алты кешене билгеләтте. Алар, авыл җыенында карар чыгарып, алпавытларның җирен тартып алырга, җирне бүлү эшләрен башкарырга тиеш булдылар.

Шәяхмәт күзгә күренде, кулга тимәде. Солтан аны ни барысы ике тапкыр күреп калды. Беренчесе — кайткан мәлгә. Икенчесе — китәр алдыннан.

Кайткан мәлдәгесе Солтанның күңелен кузгатырлык матур булды.

Абыйсы башта Солтанны җилкәсеннән кочаклап, муенын авырттырганчы кысты.

— Сугышчы! Настоящий сугышчы! Менә кемнәр кирәк миңа! Болар белән мин буржуйларга каршы сугышып карар идем.

Аның өстендә — күн куртка, түшендә — ут янып торган кызыл бант, бер янтыгында наган, икенчесендә кылыч иде. Рессорлы бричкага утыртып Сара җиңгине алып килделәр. Сара җиңги дә үзгәргән: авыл хатыннары төсле бала итәкле озын күлмәктән түгел, аның өстендә ак кофта, кара юбка; чәчен кыска итеп кистергән, шул кыска чәч өстендә өчпочмаклы сары косынка җилфердәп тора. Үзе тагын сәер: әле аягындагы озын кунычлы ботинкасына, әле Солтанга карап, кызарып елмая; ул елмайгач, Солтан да елмаймый булдыра алмый, елмая һәм битенең ут кебек кызыша башлавын тоя. Аларның Гәрәйнур исемле биш яшьлек малайлары бар, ул туганнан бирле читтә йөреп, татарча өйрәнә алмый калган, сакауланып русча сөйләшә. Өйдәгеләр мәзәк ясап аңардан көләләр, аны уенчык курчак итеп йөртәләр.

Солтан каушаган. Ул моңарчы, абыйсы югында, күңелендә җыелып килгән уйларын аның белән уртаклашырга тели, аның белән ялгызы гына буласы килә. Әгәренки күңелдәге яшерми әйтсәң, аның да абый-

[1] Яркәм — ярлылар комитеты.

сыныкы төсле күн куртка киеп, түшенә кызыл бант, янтыкка кара наган тагып, авыл буйлап гайрәт орып йөрисе килә. Менә ул чагында ачуны китергән кешеләр белән сөйләшеп карар иде ул. Әлбәттә, иң әүвәл алмачуар атка атланып Таминдар байлар утарына барып керәсең. Алмачуар аттан төшми генә хезмәтчеләрдән Таминдар бай малае Һашимны чакыртып чыгарасың. Һашим кулын күкрәгенә куеп, гаепле чырай белән анның кыршысына килеп баса; Солтан кара наганны тегенең ике каш арасына китереп тери: «Яхшы чакта әйтеп кал: жаныңмы, малыңмы?» Таминдар бай малае, әлбәттә, малын биреп котылырга тели. Солтан риза түгел: «Жаныңны алам!»— ди. «Ни өчен жанымны?»— «Хәтереңдәме, теге чакта, сезнең утарга Казан — Уфа байлары жыелгач, син минем жаннан газиз кешемне, Нөркәйне тартып алдың, син аны сиртмәле кибиткаларга бикләп йөрттең. Шулай булгачыннан мин синең жаныңны жәһәннәмгә олактырырга хакым бар!» Таминдар малаеның төсе кача, аяк буыннары калтырый, йөзе кара күмер кебек карала. Солтанга ялвара Таминдар Һашимы: «Зинһар, бер юлга гафу ит, Солтанкаем, мин бит белмәдем, белгән булсам, якын да килмәгән булырыем, миңа үзем юше бай кызлары беткәнмени!» Солтан киң күңелле кеше, Таминдар бай малаен гафу итә. Наганны бит ул куркытыр өчен, Һашим Нурия янына бүтән килеп йөрмәсен өчен генә төбәде. Шуңа атып кул пычратамы соң!

Болар барысы — хыял. Гомердә дә буласы юк хыял. Солтанның абыйсы Зартугайда бер булып киткәннән соң күренми дә. Вакытын ул Салагышта, Пәнжәрдә, Әгерҗедә үткәрә. Үзе төсле папахалы егетләр, продотрядчы иптәшләре белән Әгерҗе — Пәнжәр төбәгендә буржуйларны талап йөри, отрядына ирекле сугышчылар жыя. Менә, ичмасам, аның отрядына язылсаң, теге заманнарда абыйсы белән бергәләп сал агызып йөргән кебек, ярлыларның дошманнарына каршы сугышып йөрсәң. Ул чагында Зартугай халкы алдында да, Нурия каршысында да даның үсәр иде.

Әтисе соңгы вакытта бик вакчыл булып китте. Тора да Солтанга бәйләнә, тора да Солтанга бәйләнә. Имеш, аның абыйсы Шәяхмәт, жүнледән жүнсез туган нәрсә, бүтәннәр кебек, игелекле эш эшләми. Теге чакта булды, теге чакта кеше иген иккәндә Кама иделендә брамлыкта йөрде, инде килеп, адәм баласы сукасын-сабанын барлаганда, ул авыл саен тузан туздырып байларга каныгып йөри. Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас!

Солтан авызын ачып, абыйсының юньле кеше икәнен әйтергә генә теләгән иде, әтисе аны эттән алып эткә салып тиргәде.

Нәкъ шул көнне арып-талып Шәяхмәт абыйсы кайтып керде. Отрядын ул авыл буйлап фатирларга урнаштырган, абыйсы һәм энесе белән иркенләп сөйләшер өчен, хәтта Сара жиңгине дә монда алып килмәгән иде.

Озак юл йөрүдән арган, тирләгән атны суытыр өчен капка божрасына бәйләп куеп, хәл-әхвәл сорашырга да өлгермәгәннәр иде әле, Садыйк карт бик төрпә генә сүз башлады:

— Тагын муллаларны, байларны талап йөрдеңме?

— Соң йөрсә? — диде Шәяхмәт, елмая биреп.

— Нишләп каныгасың син аларга? Ил ачтан үлгәндә, ярман сугышы вакытында алар бит әжәткә биреп тордылар. Алар бит авылга бәрәкәт иңдерделәр.

Шәяхмәт аның сүзен ахыргача тыныч, хәтта елмая биреп тыңлады. Тик абыйсының туктарга исәбе юклыгын, бер үк сүзне киндер сүсе талкыгандай тоташ талкып торуын күргәч, түзмәде, чал куна башлаган матур кара мыегын учы белән чуалтып жибәреп, жан түреннән чыккан тавыш белән әйтте:

— Их, абый! Нужели син бернәрсә дә аңламадың әле?

— Нәрсә аңнарга тиеш соң мин?

— Синең энеңә халык зур эш тапшырды. Дошманнардан таптатма илне, Шәяхмәт, безнең изге эшебезне сакла, яме, диде. Ә син байларга тимә, мулла-мунтагайга тимә дип тукыйсың, тисәң бәддога укыйм дип куркытасың. Синең бәддогаңнан, абый, әгәр беләсең килсә, минем бер кылым да селкенми. Беләсеңме, син өзелеп-өзелеп яраткан, койрык асларын яларга әзер торган Таминдар байлар, Сөләйман хәзрәтләр, революция җиңелсә, синең белән ничек сөйләшергә икәнен белерләр! Синең ише бай-бәтчәгә сатылган миңгерәүләрне алар берәм-берәм дар агачына асып чыгачаклар. Күз дә йоммый! Без, большевиклар, сабыр кеше, вакыты җиткәнче аларга тырнак белән дә чиертмәбез. Килер бер көн, мин синең ялгышканыңны күзеңә карап әйтермен. Син мине имансызлыкта гаеплисең; минем иманым бер генә: хезмәт иясе халкының җелеген суырган аждаһаларны җир йөзеннән себереп түкми торып мин көрәштән туктамыйм. Мин шуның өчен гаскәр туплыйм. Ул гаскәр синең бәхетең, Зартугайлар бәхете өчен утка керәчәк. Ул азатлык яулап алачак. Мин үзем белән Солтанны да алып китәр идем, синең бәддогаңнан куркып тормас идем, тик...

— Нәрсә тик?

— Солтанда синең хакың күбрәк. Чөнки ул синең балаң, ә минем энем генә. Син аны карап-багып үстергән, мин аның таза-сау үскәненә сокланучы гына. Тик... тагын бер тапкыр әйтәм, исеңдә тот: дошман көннән-көн явызлана, аның сугышмый гына үләсе килми. Шулай булгачыннан, иртәме-соңмы, кайчан да булса бер Солтанга да мылтык алырга туры киләчәк.

— Үлсәм дә бирәсем юк Солтанны! Бирәсем юк! — Садыйк карт, авызыннан күбекләр чәчеп, күкле-яшелле тавышлар белән кычкырына башлады.— Муеныма бау салыгыз, аркама ике көпшәле мылтык терәгез, бирәсем юк! Мөхәммәтша, олы улым, Ижау забутында мылтык коямы? Коя! Син гаскәр җыям дип, буржуйларга каршы сугышам дип тилереп йөрисеңме? Шул тилелекләрең белән уналтынчы елны йортсыз-җирсез, малсыз-туарсыз калдыңмы? Шунысы да бик җиткән! Солтанны мин туп җәдрәләре чәрдәкләп бетерсен дип үстермәдем!

Аның җилдә җилфердәп торган сирәк сары сакалы дерелти, әллә ничә ямаулы чикмәненең чабулары ачылып киткән, күзләре, акаеп, нәфрәт очкыннары ата иде. Шәяхмәт аның белән бүтән сүз көрәштерергә теләмәде — кызганды абыйсын. Андыйлар илдә байтак шул әле. Гаделлек кем ягында икәнен аларга озак аңлатырга туры киләчәк. Ул Солтанны җилкәсеннән кочаклап, ишегалдына алып чыкты. Йорт нигезенә алып килеп утырткач, ярым шыпырт тавыш белән әйтте:

— Әтиең ялгыша, Солтан. Аның бәхете өчен көрәшеп йөргәнне аңламый. Гаепләп тә булмый аны, энем, гомер буена крестьянны буйсына торган итеп өйрәттеләр, сыртыннан таяк белән камчы төшмәде. Беләсеңме, уналтынчы елны мин аңар мәшәкать тудырдым, җанын борчыдым. Миңа бит сөйләделәр тентү булганны да, аны Салагыш кутузкасына ябып асраганны да... Солтан, син минем яраткан энем, тыңла минем сүземне: илдә азатлык өчен көрәш бара. Эшче-крестьяннар корал тотып буржуйларга каршы көрәшкә күтәрелә. Ул көрәшкә син дә кирәк булырсың әле. Әзер булып тор. Мин сиңа үземә ышанган күк ышанам. Я, энем, бәхетле көннәргә тикле!

Абыйсы Солтанны кочаклап күкрәгенә кысты, каты төкле ияге белән энесенең битен сыдырттырып алды. Солтанның абыйсы белән китәргә теләге шул кадәр дә зур иде, күңеле тулудан ул елап җибәрә язды, елак булып күренергә ярамый иде, шуңа күрә генә еламады.

Шәяхмәт Айдаров портупеяларын рәтләде, абзардан печән күшәп торган озын торыклы алмачуарны энесе белән бергә алып чыкты, ашыгып баскычтан төшеп килгән абыйсы белән саубуллашты, янә дә бер

мәртәбә аның каргышын тынлап тормас өчен, күз яшьләренә дә урын калдырмас өчен ашыга башлады.

Солтан аның егетләрчә бер житезлек белән өзәңгегә аягын китереп куюын, күз ачып йомганчы ияргә менеп атлануын, ярсынып бии башлаган аргамакны авызлыклап аягүрә бастыруын, ачык капка аша ат тоягыннан каты балчык кисәкләре аттырып чыгып чабуын үкенечле бер соклану белән карап калды...

## II

Зартугайда, Салагышта, Кама буеның башка авылларында Габбас муллага бигүк аңлашылып житмәгән хәлләр, үзгәрешләр көн дә саен диярлек булып тора.

Таминдар бай мәктәбе тирәсендә Кысык Минжан белән Нух Галләм «Милли шура»га сайлау турында, кемгә тавыш бирергә кирәклеге турында сүз алып баралар. Халык арасында жирәбәне бәлшәвикләргә бирергә кирәк дигән сүз йөри. Ә ул «бәлшәвик» дигәннәре фронттан кайткан солдат, Салагыш укытучысы Мәрдән Мурзин икән. Салагышка, утыз сигез авылны берләштергән олыс булганга күрә, якын-тирә авыллардан — Зартугайдан, Машик-Пилгадан, Тәмәк-Чүрәкәйдән, Яуморзадан, Саранбайлардан халык жыеп, митингы үткәргәннәр, митингы бик гаугалы килеп чыккан. Халык икегә аерылган. Бер як «Милли шура»га Таминдар байны сайларга кирәк, ди, икенчеләре Мәрдән ягын каера. Таминдар бай куштаннары кызып китеп, укытучы Мәрдәннең инде аяккулыннан эләктереп алганнар, тәрәзәне рамы-ние белән кубарып чыгарганнар, фронтовиклар булмаса, эш харап икән. Ярман сугышыннан тоташ гарипләнеп кайткан Усал Зариф үзе белән фронтовикларны ияртеп килеп кергән дә, агач аягын тукылдатып, бер генә кычкырган, имеш, Таминдар куштаннары шундук койрыкларын кысканнар.

Авылдан-авылга көне-сәгате белән килеп житә торган шомлы хәбәрләргә Алабуга, Чистай, Казан хәбәрләре кушыла. Рәчәй мөселманнары Мәскәүгә жыелганнар: сугышны туктатыргамы, Ярман патшасын жиңгәнче дәвам иттерергәме дип бәхәсләшәләр, ди. Казанда, Чистайда, Мамадышта, тагын кайдадыр мөселман өммәтендәгеләр жыелып сөйләшкәннәр. Үлсәк үләбез, изге динебезне аяк астына салып таптатмыйбыз дип әйтәләр, ди.

Габбас мулла Зартугайга бик озак килә торган гәзитләрне зарыгып көтеп ала: алардан дөнья хәлләрен укый, дөньяга Мулланур Вахитов дигән чая бер егетнең чыгуын, аның Мөселман социалистлар комитеты төзеп, юксыллар, кимсетелгәннәр ягын якларга керешүен, сугышка каршы чыгуын белә.

Шундый шомнар эчендә яз үтә, жәй үтә. Кама иделе быел былтыргы төсле котырынып ташымый, ярларыннан чыгып, авылларны басмый, табигатьнең икенче бер афәте күтәрелә: каяндыр килеп чыккан каты жилләр, давыллар диләнкәсе-диләнкәсе белән урманнарны аударып китә, авыл урамнарында, юл чатларында тузан баганалары күтәреп, капка-коймаларны аударып йөри.

Июнь аеннан соң хәлләр бик кинәт кискенләште. Вакытлы хөкүмәтнең өязләргә жибәргән комиссарлары тиз арада гаскәр чакыртып, бунтчыларны тыя, таланган жирләрне кире кайтарып ала, артык азганнарны корал белән, төрмәләр белән куркыта башладылар. Авылларда ике көннең берендә митингы, жыелалар да акырыналар, жыелалар да акыналар; сугышка халыкны яңадан кузгата башладылар, елау-сыктау башланды, динне, азанны, намазны оныттылар.

Шәяхмәт отряды алып китүдән куркып, Габбас мулла кара айгырны көндезләрен Гафияткә басуга чыгарырга кушты. Айгыр басуда дөнья

бетереп кешнәп йөри, Гафият бөкрәдән башка берәүне дә якын китерми. Анысына эчтән генә сөенә Габбас, әмма ат караучысының кинәттән холкы үзгәреп китүенә аптырый. Ни хикмәттер, Гафият аракыдан бизде. Картаю галәмәте генәме бу, әллә үзенә кирәкле әйбәт көннәр килә, хөррият чыга дип шатланамы? Кайбер көннәрне кара айгырны кырга чыгарып алдыннан мулла белән әрепләшә, каршы сүзләр әйтә, атны абзарда асрарга азаплана. Әллә минем айгырны Шәяхмәт отряды алып китсенгә яркәм Вәҗи котыртамы, югыйсә?..

Көзгә таба, Габбасның җанына борчу салып, яучылар килә башлады. Нурияне димлиләр. Бае бар, ярлы-ябагае бар. Әти кешенең кәефе кырылды. Кияүләп-туйлап ята торган заманмы? Иртән торуга авылда ни буласын беркем белми. Нуриянең үзенең дә уенда ул түгел. Иртән торса, кичкә керсә — күзе Садыйклар тәрәзәсендә. Анда ни калган? Әллә шул авызын ачса үпкәсе күренергә торган Садыйк малае Солтанга күңеле төште микән? Имансыз нәсел бит алар, денсезләр. Кара инде ул Шәяхмәтне — денсезнең дә денсезе. Күзе-башы аларган, үзе төсле әтрәк әләмнәр белән ниләр генә кыланып бетмәде. Кемнәрне генә таламады, кемнәрне генә оясыннан тузгытмады.

Габбас мулланың күңел тыныч түгел иде быел. Юк, мине дә башкалар белән рәттән авыл ярлылары талар, атымны-сыерымны алып китәрләр дип куркудан түгел. Мал-мөлкәткә ул беркайчан да җанын фида кылмады. Габбас мулла өчен иң газиз нәрсә — җан тынычлыгы. Быел әнә шул җан тынычлыгы югалды аның.

Патша төшерелде. Инанган, табынган, алла кебек күргән патша төшерелде. Җир-суларны, мал-мөлкәтне дин әһелләре халыкка вәгазь сөйләгәндә изге дип, хосуси милеккә берәүнең дә кагылырга хакы юк дип өйрәтеп килделәр. Ул иман юкка чыгарылды — Айдар Шәяхмәте беренче башлап хосуси милеккә кул сузды. Аннары барысы да кул суза башладылар.

Нәрсә бу? Шәяхмәтнең теге елларны йорт-җирен тузгыткан өчен байлардан үч алуымы, әллә булмаса, ул аны шулай булырга тиешле дип ышанып, законлаштырып ук эшлиме?

Менә шул сораулар Габбасның җанын бимазалый, төн йокысын качыра иде. Өстәвенә, өйдәге ыбыр-чыбыр, ыгы-зыгы, көн саен булып тора торган буталыш аны ардыртты, миңгерәүләтә башлады. Шәмсениса көн саен иртә баштан алтын-көмешләрен барлый, көмеш тәңкәләрне, асыл ташлы беләзекләрне Хәнифәнең чәч толымына гына тагып калмый, чәч эчләренә дә, толым асларына да тагарга, күлмәк эченнән алтын укалы күкрәкчәләрне кат-кат кидертергә тырыша. Адәм баласы акылын җуйса җуя икән. Ярабби, чәч толымындагы, күлмәк астындагы хәзинә белән күпме яшәп була? Монда бит дөньяның асты өскә килә, илдән бәрәкәт оча, динне, шәригатьне танымыйлар. Мең ел буена килгән мөселман өммәте юкка чыгамыни?

Вакыт-вакыт Габбас мулла тол абыстай Шәмсенисага йортка кергәненә үкенә башлый. Әгәр ул моннан егерме ел элек аңар йортка кермәгән булса, мәдрәсәдә балалар укытып, яки алар нәселендәге крестьянлык гадәте буенча, җир сөреп, чәчү чәчеп, иген игеп яшәгән булса? Болай да бит инде ул шул эшләрнең күбесен үз кулы белән эшләде. Ат җигүдән, кырга барудан, печән чабудан тайчанмады. Болар барысы дөрес, шул ук вакытта аның гошер-фытыр садакасы алуы да, олы абыстай белән бергә ашка йөрүләре дә, хатын белән хатынны аралавы да дөрес. Кунакка кем йөрде? Шәмсениса. Өйдәге барлык кара эшне кем эшләде? Хәнифә. Димәк, шулай булгачыннан, ул хатын алмаган, асрау алган булып чыга түгелме? Ә бит хәзер әнә асрау тоткан өчен яхшы булмас, диләр, яркәм Вәҗиләр әйтә, асрау тотканнарга, елын елга исәпләп, түләттерергә кирәк булыр, диләр. Хәнифәнең ул эшкә барып җитәрлек аңы юк, ләкин бит яркәмнәр, авылның кызыл авызла-

ры аның күзен ачмаслар, күңеленә коткы салмаслар дип кем әйтә ала? Ат караучы Гафиятне ал. Анысы бит — турыдан-туры хезмәтче. Нигә әле ул соңгы көннәрдә сүз тыңламый торган, әрепләшүчән булып китте? Нигә әле ул өйдә генә утырмый, атлар янында гына йөрми, каравыл өенә бара, җыеннарда катнаша, илдә ни барганның барысын ишетеп, белеп, мыегына чорнап кайта. Синең авыл каршысына басып, җавап бирер көннәрең җитмәс микән, Габбас?

Шундый уйлар белән вәсвәсә килеп йөргән бер мәлне, октябрь башларында Габбас мулла йортына тагын яучылар килеп төште.

Мондый очракта сандык төбеннән иң затлы киемнәр алына: алма бизәкле яулык, энҗеле калфак, кәшимир күлмәк, читек-кәвеш — берсе дә калмый. Барысы күз явыңны алырлык чуар, барысы ут янып тора. Тавис коштай бизәнеп килгән карчыкларның яучы икәнен хуҗалар шундук төшенеп алалар. Яучыларның берсе артыгын сөйләми, сүзне җепләп яки куәтләп кенә тора, икенчесенең — киресенчә — теле-телгә йокмый, анысы сусыз юа, җилсез киптерә. Габбас мулла йортына чачаклы-чуклы киемнәре белән балкып килеп кергән яучы карчыкларның берсе, сусыз юып, җилсез киптерә торганы, кендекче Сафура булып чыкты. Түрдәге кәнәфигә бик иркенләп, күлмәкне җәеп утырып алгач, Сафура-җаһил йоласын китереп, озаклап дога кылды.

— Ярабби, бу йортка иминлек бирсен, авыру-сырхау, бәла-каза китермәсен, зыян-зәверле, болгавыр-мәшәкатьле бу заманда җил-давылларны башка якларга борып җибәрсен. Амин. Туктале, мин әйтәм, җир йөзендә Габбас хәзрәт белән Шәмсениса остабикә бар бит, мин боларның, мин әйтәм, хәлләрен белеп чыгыйм, бер исәптән ахирәтем Бибигайшәгә дә күрсәтеп чыгыйм. Ни эшләр бетереп яталар микән, миңа үпкәләмәгәннәр микән...

Шәмсениса абыстай сабыр гына елмайды.

— Бик тә рәхмәт изге ниятеңә, Сафура. Үзем дә сагынганыем әле сине. Син бит, ни генә димә, минем кызым Нуриянең кендек әбисе.

— Карале син, онытмаган бит. Ай, рәхмәт төшкере!

Хәнифә өстәлгә ак самавыр чыгарып куйды. Ризык кертте. Үзе табын янына утырмады.

— Яле, кадерле кунаклар, килегез әле, менә монда киезле урындыкка утырыгыз, юкса, сарыгыбызны җонсыз итәрсез. — Барысы да сабырлык саклап, ашыкмый гына утырышып алгач әйтте: — Я, бисмиллаһы рахман рахим, житешегез.

Сафура башыннан алма бизәкле француз яулыгын салырга оныткан икән, аны салып, бик пөхтәләп кәнәфи өстенә куйды, аның артыннан Бибигайшә дә шуны ук кабатлады.

Сафура өстәл янына иркенләп утырып, бисмилласын әйтеп, бал калагына үрелде. Бибигайшә дә шуны ук кабатлады. Монда алар борын-борыннан килгән бер йоланы да истән чыгармадылар. Баш яучы балны бал калагының очы тияр-тимәс кенә алырга, чәйне дә уртлап кына куярга тиеш. Нәкъ шулай эшләде Сафура-җаһил. Бөтен битенә сузылган, пешкән токмачтай озын борынын тартып, балны мактады:

— Бәрәкалла, бигрәкләр дә татлы икән балыгыз, аны каян алдыгыз? Нинди умарталарда җыйдыгыз, сакларга дип нинди келәтләргә куйдыгыз? Кемнәр бәхетенә шундый татлы булган ул, кайсы кушмаларга тулган ул? Әллә буй җиткән кызыгыз бармы?

— Җитеп үк бетмәсә дә, җитеп килә торган кызыбыз бар.

— Җитеп килә торган кызыгыз ни атлы?

— Җитеп килә торган кызыбызның аты Нурия булыр.

— Бәрәкалла, Нур иясе! Кайчандыр бер буранлы төндә без аны дөньяга китереп, кендеген кисканиек. Менә инде без, Шәмсениса абыс-

тай, ахирәтем Бибигайшә белән, кайчандыр үзебез кендеген кискән Нурияне бәхетле итү нияте белән килдек. Кызы барның капка төбендә җигүле җитмеш аты торыр ди. Җитмеш атның беренчесе үк булмаса к та, җиденче бездер дип беләбез. Сезгә буй җиткән кыз, бездә буй җиткән егет бар.

— Егетегезнең аты кем соң? — диде Шәмсениса абыстай үз нәүбәтендә.

— Атын актыктан әйтербез, башта затын әйтеп күрсәтик.

— Әлхәмделлила, нинди заттан егетегез?

— Нәселләрендә әчкече юк, карак-угры юк, хатын аерып уйнаучылары юк, килен төшә таш була, ашаганы аш була. Егетебез бик тә уңган, бик тә булган, эшләмәгән эше, җитмәгән җире юк.

— Булдыклылыгын ни белән исбат итәсез?

— Егетебез шөһрәтле, мал-мөлкәтле...

... Почмак якта бүлмә тактасы буенда яучылар сүзенә колак салган Нуриянең йөрәге тасырдый иде: башкайларымны кемгә бәйләргә итәләр?

— Ягез, кадерле кунаклар, тыңлап багыйк, мал-мөлкәте безнең чамага тартамы?

— Ташпулаттан өе бар, өе тулы сые бар, янып торган йөзе бар, шомырт кара күзе бар... Сезгә ни кирәк тагын?

— Без, Сафура, читкәрәк киттек. Башта атын белик, — дип, яучылар йоласын үзе дә сизмәстән ашыктыра башлады Шәмсениса абыстай.

— Кыз баланың аты йолдызлар балкышы төсле була, тирә-ягы нур белән тула, ир баланың атында кылычлар чыңлап, дөньялар зыңлап тора. Без, Шәмсениса абыстай, Габбас белән синең йортына Таминдар бай улы Һашимнан илче булып килдек. Без сүзебезне әйттек, инде сез әйтегез.

— Әйе, әә, сез әйтегез сүзегезне, — диде яучыларның икенчесе.

... Почмак якта, бүлмә тактасы буенда, яучылар сүзен тыңлаган Нуриянең йөрәге каты-каты тибеп куйды: әни ни әйтер? Әти ни әйтер?

Таминдар байларга кыз бирү Шәмсенисаның күтеп бетерә алмас бер хыялы иде. Ләкин ул аны әле шулай тиз һәм көтмәгәндә килер дип уйламый иде, кинәт теле тотлыкты, бите бурлаттай кызарып чыкты. Сер бирергә ярамый иде. Чамадан тыш беркатлы булып, гел дә генә Таминдар бай малаеннан яучылар көтеп яткан булып күренмәс өчен ялындыра башлады.

— Рәхмәт, кадерле кунаклар, җылы сүзегезгә: кызыбыз яшь бит әле. Бик яшь кызыбыз... — дип, күгәрчен кебек гөлдерәп кенә сүз башлады Шәмсениса абыстай, өзеп тә куймады, өметсез дә итмәде. Хәзер, аның исәбенчә, яучылар үгетли башларга тиеш иде, ул шуна лаеклы җавабын әзерли башлаган иде, ләкин шул мәлне әллә каян гына Габбас пәйда булды, яучыларның да, Шәмсенисаның да авызын ачтырмаслык итеп өзеп әйтте:

— Кызыбыз яшь, ике елдан килерсез!

Була бит шундый хәл: әседән әлсерәп үләр чиккә җиткән юлчы кое янына килә, бик тирән коедан чыгыр белән әйләндереп су меңгерә, чиләкне кулга тотам дигәндә генә, бавы өзелеп, чиләк коега төшә дә китә.

Әнә шундый хәлдә калдырды Габбас Шәмсенисаны.

Шәмсениса абыстай ирен төне буе тиргәп чыкты. Күз яше белән каргады, надан дип, акылсыз дип, кара мужик дип, тагын әллә нәрсәләр дип исем кушты. Ләкин ул күпме генә ярсынмасын, эшләнгән эш эшләнгән иде шул инде: сукkан белән сукканны кире кайтарып алып булмый, Таминдар байлар аларга бүтән әйләнеп тә карамаячак. Ялгы-

ша иде Шәмсениса абыстай, Һашимның ансат кына Нурияне ычкындырырга исәбе юк иде.

Иртәгесен, ялт итеп торган кояшлы бер көнне, Зартугай урамнарын көмеш кыңгырау чыңына күмеп, авылга кибиткалы пар ат чатыр чабып килеп керде, югары очтан, Сөләйман хәзрәтләр турысыннан түбән очка чаклы төшкәч, ярсып пошкырынган атлар, авызлыкларын чәйнәп, Габбас мулла капкасына килеп туктадылар.

Капка ачарга чыккан Гафият бөкре:

— Таминдар бай малае Һашим килде, кертимме? — дип хәбәр итте.

Аптырап калган Габбас мулла керт дип әйтүдән башка сүз таба алмады. Кыңгыраулы атлар ишегалдына кереп туктады. Шул минуттан башлап кызның этисе Габбас мулла белән үзен кияү итеп тәкъдим иткән Һашим Тураев арасында ярты сәгатькә сузылган баталия башланды.

— Әссәләмәгаләйкүм, Габбас әфәнде, — дип, ике куллап күреште Һашим. Аның өстендә кара төстәге тройка, аягында штиблет, чытыр ак күлмәк якасына ул күбәләк-бант таккан, башына энҗеле кара кәттәши кигән иде.

«Минем өчен тырышкан», — дип уйлады Габбас мулла кунакның сәламен алган чакта.

— Безнең тарафка нинди җилләр ташлады, яшь бай?

— Җылы җилләр. — диде Һашим, елмаеп. — Минем яучыларыма якты йөз күрсәтмәгәнсез икән, шуңа күрә сәбәбен белергә дип үзем килдем.

— Сәбәбе бер генә: кызым яшь.

— Хәтерем ялгышмаса, сез, дин әһелләре, унҗиде яшьне никах өчен иң җитлеккән яшь дип саный идегез шикелле... — диде Һашим.

«Сүзне аяк терәп сөйләшә бу. Бөердән чыгарып сөйләшә», — дигән уй узды Габбас мулланың күңеленнән. Ул Таминдар бай малаенда бер ел эчендә байтак кына үзгәрешләр барлыкка килгәнен дә күрми кала алмады. Һашим калыная төшкән, бите түгәрәкләнгән. Яңак сөякләре дала ягында озак яшәгән кешеләрнеке төсле бүлтәйгән, бите җилдән-кояштан каралган. Энҗеле кара кәттәши белән кыршаулап куелган бу биттә каш-күз, авыз-борын урта бер җиргә җыелып, аерым яшиләр, үзара гел киңәшеп торалар төсле тоела иде.

— Сезнең сүзне көтәм, Габбас әфәнде.

— Мин үз сүземне әйттем.

— Минемчә, аның сәбәбе ул түгел бит.

— Нәрсә соң? Белсәгез әйтегез.

— Әйтергә була, — диде Һашим, ләкин почмак якта нәрсәнеңдер кыштырдап куюына колак салып, өстәде: — Безгә, Габбас әфәнде, аулаграк җирдә сөйләшергә кирәк иде. Чит кеше ишетә торган сүз түгел бу.

Түбән өйгә төшеп бикләнделәр.

— Сез нәрсәдәндер шикләнәсез, миңа калса...

— Дөрес әйтәсез, шикләнәм. Дөньясы бик болгавыр бит. Чат саен мылтыклы, почмак саен — шпион. Кызымны мин билгесез язмышка дучар итәргә теләмим.

— Билгесез дип нәрсәне әйтәсез?

— Бүген сез, Һашим әфәнде, гайрәтле кеше. Дөнья сезнең кулда. Иртәгә большевиклар килеп сезне селкесә? Сез кем булып каласыз? Шыр ялангач бер адәм. Үпкәләмәгез туры әйткәнгә. Без бары тик шулай гына аңлаша алабыз.

Һашим Тураевның кәефе кырыла башлады.

— Сез, Габбас абзый, мин барлык капиталымны кесәдә йөртә дип уйлыйсыз, ахрысы. Мин большевиклар якадан алганны көтеп утыра

дип беләсез. Минем капиталым, әгәр беләсегез килсә, күптән чит ил банкысында.

— Шулайдыр анысы, ышанам. Ә маңгайга бәреп кергән әрсез бер пуля сезнең ул капиталыгызны бөтенләйгә чит ил банкысында калдыруы мөмкин түгелмени?

— Ә нигә мин пуля көтеп ятарга тиеш? Пароходым — Иделдә, озатучыларым янымда.

— Чит илгә сызарга уйлыйсызмыни? Сер булмаса, әйтегез: кайсы илгә?

— Төркиягә, — диде Һашим иренен кысып.

— Алай икән... — диде Габбас мулла, беркавым тын утырды, Һашим аның чырае бик кинәт караңгыланганны күрде.

— Ошамыймы Төркия? Иранга китәргә була, Мысырга. Аннан — Европа. Нурия кайсысын тели — шунда алып барам: Франциягә, Германиягә... Аңлагыз, конца концов, мин монда Нурия аркасында гына утырам, юкса, күптән якорь күтәргән булыр идем.

Һашимның энҗеле кара кәттәши белән кыршаулап куйган түгәрәк битендә күз-кашы, авыз-борыны тагын урталыкка җыелды: мәсьәләне кап урталай аерып ташларга кирәк, юкса, ул шундый дәрәҗәле башы белән надан бер мулла каршында вакланып утыра.

— Сезнең сүзне көтәм, хәзрәт.

Ниһаять, Габбас мулла телгә килде.

— Сезнең җирсәү дигән төшенчәне ишеткәнегез бармы?

— Юк. Нәрсә соң ул?

— Туып-үскән җиреңне, илеңне сагыну ул җирсәү. Туган җирсез тора алмау. Ярый ла Нурия хәзергә яшь, көләч, сез оештырган зиннәтле тормыш аны канәгатьләндерә дә алсын, ди. Ә олыгая башлагач?..

— Олыгайгач кайтырбыз.

— Кайтарсалар кайтырсыз. Инкыйлаб, революция дигәннәре кайтулын биклэп куйса?

— Ә бит сез куркыныч кеше, Габбас Уразаев. Сез — телисезме, юкмы — большевиклар җырын җырлап утырасыз. Мин сезне, башка кеше булсагыз, кораллы отряд җибәреп чүкетер идем, Нурия кызганыч.

— Алай икән... Беләсеңме, энем Һашим, көчләү-җәберләүгә иманын саткан кешеләргә миндә кыз юк.

Һашим Тураев чәчрәп урыныннан торды, ишегалдына чыгып:

— Атлар! — дип кычкырды һәм, көмеш кыңгырауларын чыңлатып, сәгате-минуты белән Зартугайдан чыгып чапты.

Петроградта «Аврора» туплары атып, бөтен илдә Совет власте урнашканчы Габбас муллага бүтән яучылар килмәде.

Давыллы унсигезенче елны илдә гражданнар сугышы купкач, малмөлкәтен югалтканнар качкан ояларыннан чыгып, комиссарларны, укытучыларны суеп йөри башлагач, Кама иделендә үлем баржалары, рельсларда үлем эшелоннары чапкан чакта, бердәнбер кызы Нурия өчен курку, кан калтырап яшәү Габбас мулланың җанын тагын бер мәртәбә тимер кыршау белән кысып алды.

## III

Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы август төнендә, беренче әтәчләр кычкырганнан соң, Садыйк карт, ярсып өргән эт тавышына уянып, карчыгы Мәүдүдәгә дәште:

— Сиңа әйтәм, тор әле...

— И-и-и шушының бер! Тагын нәрсә бар инде? Төн пәрие булдың, чисти.

— Телеңә салынма, эт өрә.

— Өрсә соң. Синең ул йолдыз атылганга да өрә торган саташкан этең бетмәс монда.

Садыйк картның ачуы чыкты.

— Каян килгән йолдыз ди ул мондый карангы төндә.

Капка дөбердәтә башладылар.

— Тор диләр сиңа, ут яндыр. Килеп җиттеләр бугай!

— Нәрсә сөйлисең син? Кемнәр?

— Ананның кәлҗемәләре, белдеңме?! Капкада кеше бар. Арт санынны күтәрә аласыңмы-юкмы? Солтанны уят, мин чыга торам.

Фонарь яндырып баскыч төбенә чыкты, ярсып өргән эткә дәште:

— Актүш, тукта хәзер үк!

Эт, аны тавышыннан танып, аягына килеп сарылды, аз гына шыңшып алгач, хуҗасына ияреп капка ачышырга китте.

— Кем йөри... эт чыкмас төндә? — диде карт, фонарен баш очына күтәрде.

— Әти, ач әле, бу мин, — диде карлыккан басынкы тавыш.

— Бәрәкалла, Мөхәммәтша, син түгелме?

— Мин, әти, ач тизрәк.

Капка ачуга каршысына картузлы, мылтыклы кеше кереп баскач, Садыйк карт иманеп китте, ләкин олы улын аның бөкрәя төшкән җилкәсеннән, саргылтрак мыегыннан һәм аңкып торган машина мае исеннән танып, аңа юл бирде, үзе фонаре белән яктыртып, аның артыннан ярде.

Чоланга кергәч, хәвефләнеп сорады:

— Нишләп төнлә йөрисең? Җитмәсә, мылтык күтәреп?

— Хәлләр әйбәт түгел, әти, өйгә кергәч сөйләшербез, — диде Мөхәммәтша басынкы тавыш белән. — Үзегез ни хәлдә? Әни авырмыймы? Шәяхмәт абыйдан хәбәр бармы? Аклар килеп җитмәдеме әле?

Берьюлы бирелгән шул хәтле сорауның кайсысына җавап бирергә дә белмәстән, әле һаман фонарен тоткан килеш, Садыйк карт чоланда басып тора иде, ишектән Солтан килеп чыкты, йокылы-уяулы, күзләрен угалап торды да, Мөхәммәтшаны танып: абый! — дип кычкырып аның муенына асылынды.

Өчәүләп өйгә керделәр.

Әни кеше мәш килеп йөри башлады, лампа кабызырга шырпы тапмый интегеп бетте, аннары улы янына килеп, аның төнлә кайтып туңган зур кытыршы кулын ике куллап тотып исәнләште, сагышлы, еламсырак тавыш белән әйтте:

— Син... исән икән. Дөньяда ни булганны да белер хәл юк. Синең өчен кайгыруларым...

Аны тынычландырып йокларга яткыздылар. Мөхәммәтша лампа кабызмауларын үтенде. Фонарь утының тонык яктысында кичтән калган ашны ашады, өй алдына чыгып тәмәке тартып керде, шуннан соң гына әтисе белән Солтанны каршысына утыртып, үз хәлләрен сөйләп бирде.

— Ижауда фетнә. Кичә башланды. Завод эшчеләрен башта ак чехлардан коткарышырга дип Казанга озаттылар. Аннары таң вакытында барлык чиркәүләр кага башлады. Паровозлар, заводлар гудок кычкырта, халыкны мәйданга җыйдылар. Баксаң, ак гвардияче офицерлар, советка каршы теш ыржайтып яткан фронтовикларны коралландырганнар, коммунистларны, совет оешмасы башлыкларын асалар, кисәләр, суялар. Ижаута таланган алпавытлар, патша армиясе офицерлары җыйналды, властьны әнә шулар тартып алдылар.

— Безгә дә килеп җитәрме инде ул? — диде Садыйк карт, күкрәген ышкып.

— Килеп җитүе көн кебек ачык. Эти, син урамга бик чыгып йөрмә. Минем заводта икәнне беләләр. Шәяхмәт абыйның кем икәнен әйтеп тә торасы юк. Аның егетлеге, куркусызлыгы турында хәтта Ижау татарлары арасында да сокланып сөйлиләр.

— Шәяхмәт минем менә монда утыра! — дип, Садыйк карт сөякчел каты кулы белән саргайган, җыерчык баскан муенына тукылдатты. — Син, Мөхәммәтша, мине котыртасың килмәсә, Шәяхмәт исемен телгә алма, яме.

Уңайсыз тынлык урнашты.

— Озакка кайттыңмы, абый? — диде Солтан, аның тәрәзә буена сөягән мылтыгын алып.

— Куй син, сыбызгы. Белер-белмәс башың белән мылтыкка тотынма, — диде Садыйк карт. — Син дә, Мөхәммәтша, атаң йортына кайткан чакта мылтыксыз гына да кайта алган булырыең.

— Мылтыксыз ярамый хәзер, эти, — диде Мөхәммәтша, энесе Солтанга күз кысып алып, өстен чишенә башлады. — Мин бер-ике сәгать кенә черем итеп алыйм. Аннары уятырсыз. Фетнә вакытында тәүлек буе йокламадым.

Садыйк карт олы улының саргылт сакал баскан, берничә көн кырынмаган, арган, алҗыган чыраена карап торды да:

— Ярар уятырмын. Берегезнең дә путный сүз сөйләгәне юк. Фетнә дә буталыш, буталыш та фетнә,— диде.

— Әйдә, Солтан, ишегалдына чыгып керәбез,— диде Мөхәммәтша, утны сүндергәч.

— Анда ни калган? — дип сүзгә кушылды әтиләре.— Нәрсә, миннән тел яшерәсез мәллә инде сез?

— Юк ла,— Мөхәммәтша көлеп куйды. — Йомышны үтәми торып булмый бит инде, эти.

Садыйк карт тынычланып, урын өстенә менеп китте, Солтан белән Мөхәммәтша ишегалдына чыгып озак кына сөйләштеләр.

Аксагыз таулары ягыннан салкынча җил тарта башлаган, күлмәкчән генә тәнне калтырата, теш-тешкә тиеп шыкылдый иде.

— Тундыңмы?— диде абыйсы.— Әйдә керик. Мин әйткәннәрне оныта күрмә, яме. Авылны, гамьсез ятып, кырдырып бетерергә ярамас...

Алар йортта хәзер ир затыннан икәү генә: этисе дә Солтан. Мөхәммәтша абыйсы Ижаудагы фетнәне кайтып сөйләгәннән соң өйдә бер кич кунды да янә китеп барды. Солтан уенча, ул фетнә оясына Ижауга китмәгәндер, кызылларга барып кушылгандыр. Солтан хәзер аңлап алды: эшчеләр алар, «ай, җирем, ай, йортым!» дип, авыл крестьяны кебек дөнья малы өчен ут йотмыйлар. Эшчеләр — кыю халык, башын салса салыр, үз дигәнен итми калмас.

Кайчандыр чамадан тыш юаш кеше иде Мөхәммәтша абыйсы, этисенең авызына гына карап торган кеше иде. Хәзер ничек кыюланган. Ул да Шәяхмәттән бер ягы белән дә ким түгел хәзер. Тик менә Солтан гына өйдә ята. Эти-әнисе тота кулны. Җитмешкә җиткән карт белән карчыкны, дөньялар болгавыр чакта, замана кырыкка төрләнгән чакта, бер үзләрен калдырып китү әллә ничек уңайсыз. Әнисе авырудан арынмый. Быел аның баш өянәге кузгалды. Кайчан карама — башын сөлге белән ураган булыр. Ике көннең берендә ырымчы карчык Тайбә килә, тегәрҗеп белән Мәүдүдә түтинең башын үлчи, маңгай турысына корым сыза, җепне урталай бөкли, корымлы төше уртагышка туры килми, башың дүңгән, ди, кара сыер сөтенә кара тавык йомыркасын болгатып эч, көнгә ике тапкыр, иртәнге һәм көндезге намаздан соң ятып тор, ба-

шындагы сөлгене салма, бәйләү белән маңгай турысыннан төйгечлә, чәч арааа ояларга иткән шайтаннар качып бетәр, ди.

Күңел төшенке, эч поша. Көн аралаш килгән ырымчы карчык Солтанның күзенә хәзер убырлы карчык булып күренә. Аның ырымчыны якасыннан умыртып тотып, баскыч күтәрмәсеннән сыдыртып җибәрәсе килә башлый. Әнисенең авыруы көчәюдән куркып кына Солтан ул эштән тыелып килә.

Өй эше дә бик бер төрле: ишегалды себер, бакчага тирес чыгар, утын кисеп, утын ват. Туйдырмас дисеңме! Солтан көн дә саен эшли ул эшләрне, дөньяда бер гаме дә юк кеше төсле йөри, әмма бер колагы гел уяу: дөньяда ни хәбәрләр бар? Кайдадыр Себер ягында әсирлектә яткан чехлар баш күтәргән, ак генераллар белән сүз берләшеп, алардан корал алып, саранча явы кебек, Мәскәүгә ашкыналар икән.

Кама өстендә сугышлар бара. Таң вакытында туптан аталар. Каравыл өе башындагы, зират каеннарындагы каргалар, дәррәү күтәрелеп, ачы тавышлар белән кычкырып оча: нәкъ давыл вакытындагы төсле! Туп атканнан көтүдә йөргән сыерлар куркышып, койрык чәнчеп тирәякка чаба. Картаеп хәлсезләнгән Мамык ләлек чыбыркы аларны урманнардан, чокыр-чакырлардан эзли-эзли әлсерәп бетә.

Июль азакларында таң алдыннан, халык йокыда чакта, ярты күкне нилэп пожар ялкыны күтәрелде. Күк йөзендә комачтай кызыл шәүләләр биешә, авыл урамында куркышып уянган халык умарта күче төсле кайный: кайсы ат җигә, кайсы абзардан сыер-сарыгын алып чыга алмый кара тиргә төшә, ут өермәсе уйнаткан мәхшәр килеп җиткәнче аулак урманнарга китеп кала алмыйм дип коты чыккан халык, паникага бирелеп, ата улны, ана кызны белмичә чабышып йөри, йөгерә торгач, тәмам арый, хәлдән тая, алып чыга алмагач, капка төбенә, яки йорт нигезенә утырып аһ ора иде.

Салагыштан килгән яркәм башлыгы Вәҗи, мөгаллим Шәрифҗан көч-хәл белән халыкны тынычландырдылар: пожарның Зартугайдан егерме биш чакрымнар ары Пәнҗәр янында Кама иделе өстендә икәнен әйтеп бирделәр. Аклар кызылларның бер пароходын яндырганнар, пароходны батырып, кызыл гаскәрнең башлыкларын үлем баржасына төяп, Чистайгамы, Чаллыгамы алып киткәннәр.

Бу хәл Зартугайларның күңеленә янә дә шом салды. Әгәр алар Камада гына торып калмасалар, Иж белән килеп, Салагышка, Зартугайга тикле күтәрелсәләр?

Авылдашларын бәладән коткарырга теләп, Кысык Минҗан урамга чыкты; үгет-нәсихәт сүзләрен бик хәтәр хутка җибәреп:

— Болай булгачыннан булмады инде, җәмәгать!— диде.— Кызыллар юкка көчәнә, үзләре дә башсыз калачак, безне дә кырдырып бетерәчәк. Менә мин әйткәнне диерсез. Корал юк бездә, корал. Агач мылтык белән еракмы китәсең?! Агач мылтык белән әнә зират каеннарындагы каргаларны да куркытып булмый, ә без ничәмә еллар сугышып азау тешен ярган янаралларны куркытмакчы булабыз. Кичә әнә афисәрләр туп атты, пырахуд егерме чакрымга күренерлек булып янды, аннары су төбенә китеп баргандыр. И-ех, аткач, аткач, әнә шулай итеп атарга кирәк тупны, көчлене көчәйтеп коралсыз халык өстенә җибәрмәскә кирәк.

Байлар Кысык Минҗанга яңа йорт салып бирергә вәгъдә иткәннәр— Минҗан шуңа тырыша. Зартугай авылында торып калган Шәрифҗан мөгаллимне, яркәм башлыгы Вәҗине, коралды өч кызыл гвардиячене ул күздән ычкындырмый күзәтә, аларның ни гамәл кылуларын сәгатеминуты белән Сөләйман хәзрәткә җиткезеп тора, ә тегесе аклар якынлашу белән поскан ояларыннан чыккан байлар белән бәйле...

Зартугай белән Салагыш яркәм эшеннән дә, коралды сугышчылар-

дан да, Шәрифҗан мөгаллимнән дә канәгать түгел. Кызыл гаскәргә атын да, икмәген дә бирергә теләмиләр.

Кысык Минҗан дөрләп янган утка керосин сибеп тора:

— Җыелырга кирәк, җәмәгать! Киңәш-табыш итәргә кирәк. Каравыл өе янына җыелып бер сөйләшсәк, оттырмабыз. Авызга су кабып йөрсәк, үзебез дә бетәрбез, йорт-җирләребезне дә яндырып, барлы-юклы ризыкларыбызны да талап алып китәрләр.

Йортлар арасыннан елан кебек ыжылдап узды Кысык Минҗан. Болай да әйле-шәйле килеп йөргән Садыйк карт кебекләр, Минҗан коткысына бирелеп, шимбә көнне иртәнге якта каравыл өе янына җыела башлады. Минҗан моны күрде, теге вакытта, уналтынчы елны оештырган эше төсле файдалы эш булуына эчтән генә куанып, авылның икенче башына йөгерде.

Китте коткы елан агуы кебек таралып!

Шәрифҗан мөгаллим халык арасында кемнендер бик тырышып коткы салып йөрүен сизенгән, ул-бу була калса дип, авылда тәртип сакларга калдырылган кызыл гвардиячеләрне кисәтеп куйган иде.

Халык каравыл өенә тартыла башлауга, алар килеп җитте. Ләкин бу вакытта халык шактый ук ярсынган, кычкырган-бакырган тавышлардан каравыл өе яны гөрләп тора иде. Үгетләү генә ярдәм итәр микән монда?

Яркәм башлыгы Вәҗи дә, мөгаллим Шәрифҗан да, сүз катып халыкны тыңлата алмагач, кызыл гвардиячеләргә әмер бирделәр. Озын буйлы, битен сакал-мыек баскан утыз яшьләрдәге кызыл гвардияче, винтовкасын җилкәсеннән салып, каравыл өе болдырына күтәрелде.

— Иптәшләр, гражданнар!— дип иплән әйтеп карады, ләкин аны тыңларга теләүче юк иде. Шуннан соң ярсулы, гайрәтле тавыш белән:

— Туктыйсызмы-юкмы, анагызны фәлән-төгән-фәсмәтән!— дип, бугаз ертып кычкырып җибәрде.

Халык арасыннан Кысык Минҗанның чыелдык ачы тавышы колакларны чыңлатып узды:

— Нигә ул безнең әниләргә тия? Нигә ул безне мылтык белән куркыта?

— Бәреп төшер килмешәкне!

— Измәсен из!

Төркемнең алдында ук торган кызыл чырайлы, акай күзле бер дистә мужик, авылның таза хәлле кешеләре, ажгырып-шашынып кызыл гвардиячегә ташландылар: кулыннан мылтыгын бәреп төшерделәр, үзен аяк астына салып, кыргыйлар төсле акырышып таптарга керештеләр; алар артыннан авыл кузгалды.

Яркәм председателе Вәҗи күзләрен кан баскан кара төркемгә атылып барып керде, авыр мышнап, соңгы көче белән:

— Иптәшләр, туганнар, акылыгызга килегез!— дип гыжылдады.

Кысык Минҗанның ачы тавышы янә һаваны ярып җибәрде:

— Җәмәгать, халыкны деннән яздыручы яркәм Вәҗи үзе килде! Ычкындырмагыз!

Акылдан шашкан кара төркем Вәҗигә ташланды, күз ачып йомганчы әләктереп, шинелен умырырга, үзен ни әләкте — шуның белән дөмбәсләргә тотынды; яркәм башлыгының ачыргаланып кычкырган җан өшеткеч тавышы ярсынган өернең үкерүен узып, күккә менде.

Инде Шәрифҗанга чират җитте. Шәрифҗан, кулына тоткан кара наганын уңга-сулга селтәп, бик ашыгыч рәвештә артка чигенә, тешен кысып:

— Якын килмәгез, атам!— дип кычкыра иде.

Халык стена булып өстенә ава башлагач, Шәрифҗан, нишләгәненә хисап бирмәстән, наганнан бер-бер артлы ике мәртәбә һавага гөрселдәтте, аның артыннан ук залп белән ике кызыл гвардияче башлап

йөрүчеләргә атып җибәрделәр. Төркем кинәт аңына килде, ахылдап, кычкырып, чинап, бер-берсен таптап, мылтык төтеннәре эченнән як-якка сибелде.

Буталыштан файдаланып, Шәрифҗан Җиде күл болыннары ягына чыгып чапты. Ул анда, күл буе камышлары арасында, көне буе үзен эзәрлекләүчеләрдән качып утырды. Кичен, караңгы төшә башлагач, авылга кайтты, шыпырт кына Садыйклар йортына керде.

Солтан бу вакытта, кирәк була-нитә калса дип, җиңел сиртмәнең күчәрен майлап маташа иде.

— Сабакташ, үзең генәме? — диде тыны кысылган Шәрифҗан.

— Үзем генә. Ә нигә, Шәрифҗан абый?

— Дусым бул, яхшылыгыңны онытмам. Ат җигеп, Вәрзе-Ятчәгә генә илтеп куй.

— Ник?

— Сорама, туганым. Бик тиз барып җитәргә кирәк.

Ун минуттан алар күптән яңгыр күрмәгән урман юлы буйлап тузан туздырып чабалар иде инде.

Вәрзе-Ятчәдә әле авылдан китәргә өлгермәгән ике укытучыны очраттылар. Берсе кулына чемодан, икенчесе талдан үргән кәрзин тоткан бу ике кеше тимер юлга ашыгалар иде.

Шәрифҗан арбадан сикереп төште. Өчесе бергә, кулларын бутый-бутый, сөйләшеп алдылар. Шәрифҗан тынычланып сиртмәгә менеп утырды:

— Шөкер, өлгергәннәр...

Атны авыл башындагы урыс капка төбенә туктаттылар. Алар каршысына бите яраланган, кулына кәрзин тоткан берәү килеп чыкты.

— Мәрдән абзый! — дип кычкырды Шәрифҗан. — Ни булды сиңа?

Мәрдән Мурзин, Салагышның авыл советы рәисе, тынычсыз иде, сорауга җавап биреп тормады, заманаларның нинди икәнен белмисеңмени, дигәндәй, кул гына селтәде, аннары бик коры тотып, Салагыш-Зартугай хәлләрен сорашты, Шәрифҗан бүген Зартугайда нинди мәхшәр барганны әйтеп биргәч, сөмсерләре коелып, башын селкеп торды:

— Күңелем сизгән иде аны. — Шәрифҗанга боерды: — Хәзер үк минем белән китәсең!

— Китә алмыйм, Мәрдән абый!

— Ни өчен?

— Әти-әнине ерткычлар кулына калдырып булмый бит.

— Ә син аларны саклап кала алырмын дип уйлыйсыңмы?

— Мин китсәм, минем өчен аларны...

— Мин сине иптәшләрчә кисәтәм. Аклар иртәгә Ятчәдә, берсекөнгә Салагыш белән Зартугайда булачак. Дошман аяусыз: аса, кисә, суга батыра. Кулаклар, мал-мөлкәте таланганнар качкан өннәреннән чыкты! Гамьсезлек аркасында бик күп асыл егетләр һәлак булды. Уйла, Шәрифҗан. Китсәң, тимер юл ягына ашык.

Мурзин күпме генә үгетләсә дә, Шәрифҗан аның белән китәргә ашыкмады. Моңсу гына аерылыштылар.

— Сакла үзеңне, сакла, Шәрифҗан! — диде Мәрдән абзый.

Солтан авыл советы башлыгының ачынып әйткән сүзләрендә, борын турысына тартылып килгән кашларында Шәрифҗан сабакташ өчен зур борчылу күрде. Юл буе дәшми кайткан Шәрифҗанның бөкрәя биреп утырган кыяфәтенә карап, үзе дә ихтыярсыз аның язмышы өчен борчыла башлады...

## IV

Акларның якынлашуын башта Зартугай аркылы узган әсир кызыл гвардиячеләр колоннасы сиздерде. Ялан аяклы, чабаталы, ертык чикмәнле кешеләрне биеп торган акбүз атларга атланган конвойчылар,

камчыларын селти-селти, авыл аша алып чыгып киттеләр. Бу ак офицерларның халык күңеленә алдан ук шом салу, акларның җиңелмәслегенә ышандыру ысулы иде.

Әсир кызыл гвардиячеләр артыннан ук аклар булып узган авылларда нинди явызлыклар эшләнүе турындагы хәбәрләр килеп җитте:

...Вәрзе-Ятчәнең авыл советы башлыгын, чормадан табып алып, гаиләсе-ние белән үлем баржасына озатканнар.

...Тәкмәк-Чүрәкәйдә авыл активы Харисның күзен чукып чыгарганнар.

...Салагышта яркәм Вәҗинең әнисен таш подвалга япканнар.

Хәбәрләрнең беренче дулкыны узып китәргә өлгермәде, аннан да дәһшәтлерәк икенче дулкыны китереп бәрде:

...Иш буенда җиде кызыл гвардиячене күпер өстенә бастырып атканнар.

...Саранбайларда ак солдатлар унтугыз яшьлек мөгаллимәне мунчага ябып көчләгәннәр.

...Көчек авылында, көчләү-ирексезләүгә каршы сүз әйткәне өчен, Даут мулланың кул-аягын кисеп, гәүдәсен штыкка кадап, кырга чыгарып ташлаганнар...

Шомлы көннәр. Авыл картларының йокысын качырган, хатын-кызның йөрәген алган хәвефле төннәр.

Зартугайга да аклар гаскәре килеп керде. Урамнар буш — халык йортыннан чыгарга ашыкмый. Җәяүле гаскәрне, укалы погоннарны тәрәзәдән карап тору белән чикләнәләр.

Садыйк картларга күкрәгенә алтын тәре таккан, аяк балтырын марля белән ураган яшь кенә подпоручикны квартир керттеләр. Подпоручик янына көн саен дәү купшы мыеклы, юан гәүдәле комендант килә. Садыйк картны каршысына бастырып әмер бирә: подпоручикны яхшы тәрбияләргә кирәк.

Садыйк абзый Солтанны кисәтеп куйды:

— Кара аны, малай, матри, аксак әфисәргә ялгыш тел тидерә күрмә. Ишетсен колагың!

— Ә тидерсәм?

Картның чырае кача.

— Шаяртма, ахмак! Ике дә уйламаслар, көчекне аткан кебек кенә атып үтерерләр!

Солтанның кинәт әтисен үчеклисе, аның куркаклыгыннан көләсе килеп китте:

— Ә нигә соң теге чакта Шәяхмәт абый белән җибәрмәдең? Мең мин хәзер кылыч белән әфисәрләрнең укалы погоннарын турап йөргән булыр идем!

— Ни сөйлисең син, сыбызгы?! Өйнең көлен күккә очыртасың киләме? Я булмаса, минем картаймыш көнемдә дар агачында асылынып торуымны телисеңме?

Иртәгесен аларга ындыр артлатып кына, караңгылы-яктылыда, Вәрзе-Ятчәдән бер кеше килде. Сакланып кына керде, мескен бүреген арткарак чигереп исәнләште, Садыйк картны лапаска алып кереп анда нидер киңәште. Садыйк карт аны ишегалдына алып чыгып тормады, ындыр артлатып кына озатып җибәрде. Кергәндә Солтан аның бик хәтәр каушаган булуын, сирәк сакалы дерелдәвен күрде. Солтанны ул бармагы белән генә ымлап чакырып алды да, ярым пышылдап:

— Бар, Шәрифҗанга кереп әйт, хәзер үк качсын,— диде.

Солтан кергәндә Шәрифҗан кулына балта тотып, кирәк сабымы — нәрсәдер юнып маташа иде.

— Нихәл, сабакташ, ни йомыш белән кердең? — диде. Күңеле гаять тыныч иде. Солтан ни йомыш белән кергәнен әйткәч тә чырае үзгәрмәде.

— Садыйк абзыйга әйт, кайгыртканы өчен рәхмәт, диген. Миңа берни дә булмас, сабакташ. Мин авылдан китмим. Кеше үтергәнем, ат урлап суйганым юк.— Шул сүзләрне әйткәч, ягымлы итеп бер елмайды.

Садыйк картны бу сүзләр генә дә тынычландыра алмады. Солтанны ул Шәрифҗаннарга кабат кертте. Ләкин Шәрифҗанның сүзе нык, аның авылдашлары белмәгән катгый бер карарга килүе сизелеп тора иде.

Офицерлар, озак та үтми, халыкны каравыл өе янына куып китерә башладылар. Урамда калаен тагып чыккан Нәбкәй староста, бер күзенә кара чүпрәк бәйләгән Кысык Минҗан, атларга атланып, халыкны бик тырышып каравыл өе янына җыенга җыялар иде. Садыйк карт тәрәзәдән күзен дә алмастан:

— Йа ходай, хараплар булды шае теге бала...— дип, авыр итеп бер көрсенде.

Солтан урамга чыкты. Әтисе чыкмаска кушып күпме генә үгетләсә дә, канын кызу синең, бер-бер хәл кылмагаең дип, барма, улым, дип гозерләнсә дә, бармый кала алмый иде инде ул. Анда аның сабакташының язмышы хәл ителәчәк. Капкадан чыгуга кара бер көч булып күренгән халык төркеменә таба, каравыл өенә таба чапты.

Мәйданның урта бер җирендә башына ямьшәйгән кепка, өстенә төсе уңган пинжәк, аягына күн итек кигән Шәрифҗан басып тора. Чырае тыныч. Аның белән янәшә — күк биягә атланган, аркасына мылтык аскан, кулына камчы тоткан Кысык Минҗан. Олау килгәнне көтәләр.

Бакырчы Әфләтүн, Шәрифҗан янына ук килеп, шыпыртрак тавыш белән:

— Энем, кесәңдә акча-мазарың юкмы, булса калдыр, әтиләреңә илтеп бирермен,— диде.

Шәрифҗан кесәсеннән өч кисәк кызыл акча — «керенканы» чыгарып Әфләтүн абзыйга бирде, тегесе акчаны куенына яшереп, халык арасына чумды.

Ул арада җигүле ат килде. Атка атланып сакта торган Кысык Минҗан мылтыгын күккә күтәреп, гүя килүчеләрне сәламләгәндәй, атып җибәрде. Мылтык тавышы Аксагыз тауларына бәрелеп кире кайтырга һәм дары төтене таралып бетәргә дә өлгермәде, Нәбкәй староста йортыннан, китель төймәләрен каптыра-каптыра, чал мыеклы, карсак буйлы офицер йөгереп чыкты. Килә-килешкә:

— Кто стрелял?— дип кычкырып җибәрде.

— Я стрилэл. Аристаунай видум бит, эстриләйт имийем пырава,— диде Кысык Минҗан, күзен дә йоммыйча.

— Болван!— дип җикерде аңа ак офицер.— Я веду сто семнадцать человек, и то не стреляю!

Шәрифҗанны атлы арба янына китерделәр. Ул халыкка карап нидер әйтмәкче булды, әйтә алмады — иреннәре тетрәнде, бәхил булыгыз дигәндәй, халыкка карап, бил тиңентен бөгелеп баш иде.

Солтан җигүле ат янында ук тора иде. Шәрифҗан абыйсына карап аның күзенә мөлдерәп яшь тулды. Шәрифҗан иреннәрен кысып Солтанга елмайды. Ул шулай иреннәрен кыскан хәлдә елмаюы белән Солтаннарны үртәргә ярата иде. Искиткеч матур әкиятләр белгән, яшь шәкертләрне берәүдән дә кыерсыттырмаган, сабыр табигатьле Шәрифҗанны алда нинди язмыш көтә? Аклар аны харап итмәсләр микән? Солтанның йөрәге кысылды. Күзен каплаган яшь пәрдәсе аша ул атка атланган Кысык Минҗанны күрде, аның ат өстеннән төшмичә генә Шәрифҗанны чанага утыртырга боеруын ишетте.

— Качарга уйлый күрмә, сабакы! Мылтыкта минем бүре җәдрәсе, бер атуда миеңне агызып чыгарырмын!

Олаучы карт, дилбегә кагып, атка чөңгереп алды. Халык, олауга юл биреп, икегә аерылды. Ләкин олау чаптырып китәргә өлгермәде, халык ачкан тыкрыктан ашыга-ашыга ике офицер, алар белән бергә

кибән чаклы бохар чалмасын киеп алган, кулына таягын тоткан Сөләйман хәзрәт каршы килә башладылар.

Офицерларның берсе, олау янына килеп җитүгә, халыкка карап, татарчалатып:

— Мөселман кардәшләр, хәзрәтнең сезгә әйтәсе сүзе бар, сабыр итеп торыгыз,— диде.

Офицерның йөзе үтә дә таныш икәнен күрде Солтан, ләкин кем икәнен исенә төшерә алмады. Укалы погоннарда гел русча сөйләшүче офицерларны күрергә гадәтләнгән Зартугай халкы, татарча әйтелгән сүзләргә сәерсенә биреп, тынды. Ул арада Сөләйман хәзрәт татар офицеры белән янәшә басып, тамак кырып алды, вәкарь белән сөйли башлады.

— Мөэмин-мөселманнар, илдә адәм әйтеп ышанмаслык афәт бара. Ата улны, ана кызны белми. Мөхәммәт өммәтеннән булганнарның хәләл каны акмасын дисәк, аллаһы тәгаләнең бар һәм бер икәнен онытмыйк. Күңелләребездәге иманны яңартыйк. Ходаның гөнаһлы бәндәсе Шәрифҗан, үзе безнең мәптек-мәдрәсәдә укып чыккан мөэмин-мөселман, безнең балаларыбызны Мөхәммәт өммәтеннән аерырга теләде. Илне бәлшәвикләр тырнагыннан азат итәргә теләгән шанлы гаскәрләр әмере белән, аллаһы тәгаләнең кодрәте белән Шәрифҗанны гөнаһлы юлыннан вә һәм дә мордар үлемнән коткарып калырга була. Моның өчен бер генә нәрсә кирәк: күктән иңдерелгән изге Коръәнне үбеп, сәвит влачыннан баш тартам дип ант итәргә!

Хәзрәт, Коръәнне урталай ачып, Шәрифҗанның битенә үк китерде. Шәрифҗан төбәлеп Коръән битенә карап торды. Анда ул үзе мәдрәсәдә чакта күреп гадәтләнгән чиста язу сәнгатенең гүзәллеген күрде, ун ел буе үзен кол итеп, фани дөньядан яшереп асраган сүзләрне күрде, нык күңел белән әйтте:

— Минем авылдашларыма хыянәт иткәнем юк. Кем дә кем хыянәт иткән, шулар Коръән үбеп ант итсеннәр. Совет властеннан мине берәү дә баш тарттыра алмас.

Сөләйман хәзрәт кара көйде. Татар офицерының йөзенә елмаю чыкты, ләкин ул елмаюын озак саклап кала алмады, тешләре ыржаеп китте:

— Катарсың. Нәселеңне корытырбыз!

Солтан аны елмаюлы йөзеннән һәм ыржайган тешләреннән кинәт танып алды: Галләмов! Мәдрәсә шәкертләренең канын эчкән Нух Галләм ич бу.

— Тоткынны алып китегез! — дип кычкырды офицер Галләмов.

Кысык Минҗан җигүле атка табан иелеп камчы белән орды. Ат кинәт тартылып куйды, ыргып алга сикерде һәм халык ачкан юлдан тузан эченә кереп югалды...

...Габбас мулла, тәрәзә каршысына басып, ахшам намазын укыр алдыннан бүгенге көн вакыйгаларын күңеленнән кичереп тора. Мәчет тәрәзәләрендә кичке шәфәкъ дөрләп яна, каяндыр тоташ бер гүелде булып тавышлар якынлаша иде. Колагын шыңкайтып, аргы очтан килгән иләмсез тавышларны тыңлап торды. Тавышлар үсә, отыры көчәя барды һәм кинәт... Зартугай урамнарын тузан белән күмеп, ат менгән дүрт-биш кеше җан-фәрманга чаптырып китеп бардылар. Алар артыннан күтәрелгән тузан басылырга да өлгермәде, кемнедер берәүне ат койрыгына тагып чабып килгәннәре күренде. Габбас мулла, ләилаһы иллаллаһы дип, тәрәзәдән артка чигенә башлады, ләкин ул китеп өлгермәде, урамдагы тавыш өйдәгеләрне тәрәзәгә ябырылырга мәҗбүр итте. Габбас мулла кызы Нурияне, хатыннары Шәмсениса белән Хәнифәне тәрәзә яныннан куа, аларны кулы белән этә, йөрәк яргыч бу күренешне күрсәтмәскә тели иде. Ләкин хатын-кызларны тәрәзә буеннан

алып китәрдәй әмәл юк иде шул инде. Ат койрыгына тагылган кешенең хатын-кыз икәнен, аның анадан тума ялангач икәнен, капка-коймаларга бәреләсугыла килүен күргән Нурия ачыргаланып кычкырып җибәрде — һушыннан язып, идәнгә ауды...

...Шәрифҗан шул китүдән Зартугайга әйләнеп кайтмады. Берәүләр, аны тере килеш җиргә күмгәннәр, дип, икенчеләре дар агачына асып Камадан агызып җибәргәннәр, дип сөйләде. Өченчеләр, ул качып киткән, үч алыр өчен отряд туплый икән, дип сөйләделәр.

Чын дөресе аклар Зартугай белән Салагыштан киткәннән соң, халык авыллардан авылларга йөри башлагач билгеле булды.

Кысык Минҗан хатыны Мәрзиябану ниндидер йомыш белән Салагыштан Зартугайга килеп чыкты. Кылган гамәлләре өчен җәза алачак көннәре якынлашуын истә тотып, аны Кысык Минҗан үзе җибәргән идеме, әллә Мәрзиябану үзе халыкның алар гаиләсе хакында ни уйлавын белер өчен килгән идеме, ничек булса булды, Мәрзиябану Сөләйман хәзрәтләр өендә, түр башына аяк бөкләп утырып, әфисәрләрнең Шәрифҗанны ничек җәзалауларын сөйләде:

— Йа ходаем, күрмәгәнгә күрсәтмәсен, күргәнгә сабырлык бирсен. Азаплап та карадылар соң мескенкәемне! Башта күлмәк-ыштаннан гына калдырып безнең кар базына ябып асрадылар. Иманнары ук качкан икән ул әфисәрләрнең! Баздан чыккач, күгәреп каткан Шәрифҗаннан сәвит башлыгы Мәрдәнне таптырдылар. Шәрифҗан бер генә сүз әйтә: белмим! Әфисәрләрнең башлыгы Шәрифҗанның ияк астына яныл торган лампа китереп куйды. Ярабби, сакал төкләре чатыр-чотыр яна, Шәрифҗанның чытырдатып йомган күзләреннән яшь ага, дәшми. Өйгә йон яндырган сасы ис таралгач, түзмәдем, ишегалдына чыгып киттем. Минем чыгуым булды, Шәрифҗанны да ишегалдына чыгарып ташладылар. Ике солдат алмаш-тилмәш камчы белән кыйныйлар, берсе кыйнап арый, икенчесе тотына. Ул кадәрле кыйнауга хайван булып хайван түзмәсие, бу түзә: чалкан яткан, беләген тешләгән, тынын да чыгармый. Өйдән әфисәрләрнең башлыгы чыкты, күн итек башы белән аның гәүдәсен әйләндермәкче булды, булдыра гына алмый бит, әйләнми Шәрифҗан. Ачуы чыкты әфисәрнең, ливальвирын тартып алды да Шәрифҗанның башына төбәп атты. Бичара сикереп куйды — торырга итенгән күк, аннары колагыннан шаулап кан ага башлады... Шундый әйбәт егет ие бичаракаем. Мин бит аны малай чагыннан ук беләм. Әле мин Зартугайга кунакка килеп йөргән чакларда, килен булып төшкәч, аларның күршеләренә килә торганыем. Кыш көне ялан аяк килеп керерие, сүзен әйтә алмый ишек төбендә таптанып торырые. Аяклары күгәрчен тәпие кук кып-кызыл булырые. Малай чагында хәерчелек белән рәхәт күрмәде, үсеп җиткәч, үз көнен үзе күрә башлагач, мордар адәмнәр кулыннан шәһит үлем белән китеп барды. Бигрәкләр яшь көе әрәм иттеләр шул бичаракаемны...

Мәрзиябану боларны елый-елый сөйли, яулык почмагы белән ышкый-ышкый күзләрен кызартып бетерә. Тик Шәрифҗан мөгаллимнең үлемендә аның ире Кысык Минҗанның турыдан-туры гаебе барлыгын гына искә алмый: әйтерсең аның ире сөттән ак, судан пакь...

## V

Алабуга пристаненнан бер чакрымнар ары текә тау ышыгына үлем баржасы китереп куйдылар. Күктә август кояшы йөзә, тау кыясыннан бүселеп чыккан кызгылт ташлар төрмә диварларын хәтерләтә иде; мазутка чумган бәләкәй буксир, баржаның яңа урынын ошатмагандай, сыер кебек мөгрәп куйды, һавага төтен төргәкләре чөеп җибәрде.

Канга батырып кыйналган крестьяннарны, чабаталы кызылармеецларны, партизаннарны, Алабуга һәм Бондюг эшчеләрен — үлемгә хө-

кем ителгәннәрнең яңа партияләрен баржага китереп, трюмга ыргыта башладылар.

Төш вакытлары җиткәндә, конвойчы ике солдат кулын артка каерып бәйләгән, гимнастеркасы теткәләнгән, ялан аяклы һәм ялан башлы бер кешене — кызылларның командирын баржа янына китереп туктатты. Яр читенә басма төшергәнче, үлемгә хөкем ителгән адәм маңгаена төшеп азаплаган кара чәч бөдрәләрен кискен бер хәрәкәт белән артка чөйде, чәч бөдрәләре аңа буйсынмады, болыттай тузгып, янә маңгаена таралып төштеләр: тоткын, кунадай киң җилкәсен каймылдаткалап, трапка аяк басты.

Баржада аны солдатлар каршы алды. Тоткын, елга өстендә чыелдашкан акчарлаклар, бортка бәрелеп чупылдаган дулкыннар тавышына колак салып, чак кына юанды — каршы алган солдатларның берсе, битендә яра җөе ярылып ятканы, аның аркасына мылтык түтәсе белән китереп төртте:

— Атлый бир, нәрсә терәлеп каттың?!

Аны каютага алып керделәр. Кояш нуры тулган бәләкәй бүлмәдә штабс-капитан формасындагы берәү диванга җәелеп утырып, кушуч зурлыгындагы кып-кызыл алма ашый, бүлмәгә алманың хуш исе таралган иде. Бик тә гадәти бер эш эшләгән сыман, тоткынга күтәрелеп тә карамастан, ул сургучлы пакетны кулына алды, аны ашыкмый гына бер кырыеннан ертты, алмасын чәйни-чәйни, пакет эчендәге язуны бик тыныч кыяфәт белән укый башлады һәм кинәт — киек җәнлек тизлеге белән — урыныннан сикереп торды.

— А-а-а, менә бу, ичмасам, сюрприз! Күптән көткән идем мин бу очрашуны, Айдаров, күптән! Карак нинди оста урлашмасын — барыбер тотыла. Шулай түгелме?

Ул аякларын аерып, башын үҗәт бер ныклык белән аска иеп басып торган тоткын каршысына килде, аның ияген кулы белән күтәрмәкче, күзенә карамакчы булды.

— Кулың белән кагылма, мәхдүм!— диде Шәяхмәт.

«Танырдыңмы? Танытырбыз! — дип елмаеп уйлады Бохараев.— Үлем якасыннан урап алган инде, ә ул һаман әдәп өйрәткән булып маташа, заразы!»

Штабс-капитан кулына килеп эләккән корбанын, кул ярасы белән түгел, тел ярасы белән җәзаларга нияткылды — тышка бәреп чыга алмаган ярсуы ач яңаклы аксыл битендә, чигә тамырларында сулкылдашты.

«Мине тезләндерергә маташачак бу»,— дип, кәефе китеп уйланды Шәяхмәт.

— Нәрсә, Айдаров, полкыңны җимерделәр-кырдылармы?

— Минемчә, сез грамотный. Кәгазьгә язылганны укый беләсез.

— Укырбыз. Анысын сездән сорап тормабыз,— диде штабс-капитан, борын канатларын киереп.

Ул Айдаровны күптән аулый иде инде. Шәяхмәтнең большевиклар белән бәйле булуын Бохараев жандармерия идарәсендә утырган чакта ук белеп алды. Андагыларның барысыннан алдарак белде. Уналтынчы елны Шәяхмәт Айдаров партия заданиесе белән фронттан Петроградка китеп баргач, Зартугайдагы тентүне, Айдаров йортын чүкеч сугып саттыруны ул оештырды, әтисе Сөләйман хәзрәтне дә шул эшкә җикте. Аннары патша төшерелде. Өстен сыйныфларны җылы урыннарыннан кузгата башладылар. Шәяхмәт Айдаров унҗиденче елның июнендә, Вакытлы хөкүмәт власть башында әле бик нык утырган заманда ук, фронттан кайтып, Пәнҗәр төбәгеннән Әгерҗе тимер юлы депосына хәтле булган арада яркәмнәр, дружинниклар, активистлар оештырды, продотрядлар төзеп, аларны кораллландырды — китте волостьлар буй-

лап алпавыт җирләрен, кулак хуҗалыкларын талау, мал-мөлкәтне крестьяннарга өләшү. Байларның, муллаларның, сәүдәгәрләрнең йөрәгенә шом салып яшәде Шәяхмәт. Революция чыгу белән кызыл гвардиягә ирекләләр туплый башлады. Бохараев ул чакта аңа тырнак белән дә чиертә алмады. Инде менә көткән көн килде, җәза сәгате сукты! Карап карыйк, җәза кутәрүгә буыннар нык микән «большевик иптәшләрнең?»

Бохараев, алмасын ашап бетереп, авызын кулъяулыгы белән сөртте, матур итеп бер елмайды, борын астындагы бәләкәй кара мыегы да ирене белән бергә җәелде.

— Әйтегез әле, Айдаров, сезне шундый почетлы үлемгә ни өчен хөкем иттеләр?

Аның елмаюына каршы Шәяхмәт җитди җавап бирде:

— Сезнең сыйныфны өзелеп яратканга өчен, мәхдүм.

— О-о-о! Сез оптимист. Шушы хәлдә дә юмор әйтә беләсез. Олылыйм, Айдаров!

— Анысы мәҗбүри түгел. Кулны чишәргә боерсагыз — шул җитә, капитан әфәнде.

— Чишегез кулын.

Артка каерылып торудан оеган кулларын, иңбашларын кыймылдатып алгач:

— Тәмәке тартырга да рөхсәт итәрсез дип беләм,— диде.

— Тартыгыз,— Бохараев кесәсеннән көмеш портсигар чыгарды да аны чыртлатып ачты, папирос тәкъдим итте:— алыгыз, американский.

— Рәхмәт. Мин тәмәкегә күнеккән.— Кесәсеннән чигүле янчык алды, тәмәке төреп ут кабызды. Тирән итеп эчкә төтен суыргач, күптән тартмаганга башы әйләнеп китте: каршыда утырган газраиле аңа томан пәрдәсе аша тоник кына булып, юашланып күренә башлады.

— Ну-с, үлемгә ни өчен хөкем иттеләр?

Шәяхмәтнең сакал-мыегы кырылмаган, алҗыган, талчыккан йөзенә беренче мәртәбә елмаю чыкты:

— Син бит аны беләсең, Динислам. Нигә комедия уйныйсың?

Сөләйман хәзрәт улы үз исемен авылдашы авызыннан ишетергә бик теләми иде. Ләкин ул аны ярсып, ачудан буылып әйтерләр дип көтә иде. Шәяхмәтнең һич көтмәгәндә гади генә итеп: «Син бит аны беләсең, Динислам», дип әйтүе аның ай буе үлемгә хөкем ителгәннәр арасында яшәп, кешеләрне ату-асудан тупасланып беткән күңелендә җылы бер тойгы уятты, шуңа күрә аның Шәяхмәт белән допросчы булып түгел, авылдашы булып сөйләшәсе килде.

— Ярый, хуш, мин беләм ди. Ә син үзең? Үзең соң ни өчен дип уйлыйсың? Син әйткәнне тыңлап карыйк.

— Мин әйткәннәр синең йөрәккә сары май булып ятмас, мәхдүм. Инде бик кызыксынасың икән, рәхим ит. Авылдашым хакына, бер үк болыннарда аунап, бер үк чишмәнең суын эчеп үскәнебез хакына әйтәм: үлемгә мин түгел, син хөкем ителгән кеше, Бохараев.

Штабс-капитанның йөзе кинәт чалышаеп китте. Ләкин ул үзен шундук кулга алып өлгерде.

— Минемчә, үлем әлмәгән без тартабыз, Айдаров.

— Вакытлыча.

— Ничек вакытлыча? Әгәр сез сукыр булмасагыз, уйлый алу сәләтен югалтмасагыз, күргәнсездер дип беләм: Казан губернасы тулысынча безнең кулда.

— Кем ул сез?

— Халык армиясе.

Шәяхмәт ирен чите белән мыскылчан елмайды. Бу хәл Бохараевны чыгырыннан чыгара язды.

— Совет власте Казан губернасында фактически юк. Өязләрдә — чехлар, халык армиясе. Мөселман комиссары Вахитов — Казанның Кремль төрмәсендә. Ә аннан, мәгълүмдер ки, юл бер генә якка — кабергә генә илтә! Күп булса бер атна узар, аны, аның белән бергә барлык жидларны стенага терәп атарлар.

— Ә ни өчен атарга тиешләр?

— Халыкның таләбе шундый. Аңлыйсызмы — таләбе! Самардан, Сембердән, Уфадан, Казанның үзеннән сорыйлар. Милләтебезнең алдынгы кешеләре: Алкиннар, Туктаровлар, Мәмлиевләр, Кильдишевләр сорый. Болак арты республикасы җитәкчеләре таләп итә. Хаиннарга — хаинча үлем!

Мулланур Вахитовның гомере кыл өстендә булу Шәяхмәтнең җанын тетрәтте. Ләкин бу минутта, сәяси дошманы алдында утырганда, ул йомшаклык күрсәтә алмый иде. Үҗәт бер ныклык белән соравын кабатлады:

— Ни өчен Вахитовны атарга тиешләр?

— Ни өченме? Өч гасыр буена хакимлек итеп килгән Романовлар тарихи хата ясады, без ул хатаны кабатларга теләмибез. Ишетәсеңме, Айдаров, теләмибез.

— Нинди хата ул?

— Николай Романов монархия дошманнарын үтереп бетермәде. Ул аларны каторгага җибәрде, төрмәләргә тыкты, Себергә сөрде. Кыскасы, Россияне сәяси тоткыннар белән тутырды. Акылы бар аңларга тиеш: янып торган учакны кая гына куйсаң да, нинди генә йозак белән бикләсәң дә, ул учак булудан туктамый. Сүндерергә кирәк учакны, томаларга кирәк. Шул чагында гына тыныч йоклый аласың, пожар чыгудан курыкмыйсың. Рус монархиясенең иң зур хатасы шундадыр ки, ул бик озак ут белән уйнады, уйнап бетергәч, утны сүндерергә онытты.

— Сез... сүндерәсезме?

Штабс-капитан урыныннан торды, киң сары каешлы портупеясен төзәтә-төзәтә, Шәяхмәткә якын ук килеп басты; Айдаров аның саргылт авыру чыраена нур биреп торган яшькелт күзләрендә усал очкыннар биешүен күрде.

— Сүндерәчәкбез. Идел белән Камада — үлем баржалары, тимер юлда — үлем эшелоннары. Син тузгыткан Таминдар байлар, Шакир хаҗилар үз имениеләренә кайтып утырдылар. Зартугай белән Салагыштта син урнаштырган советларның көле күккә очты. Патша вакытында нинди тәртип булган — илдә шундый тәртип. Шулай булгач, большевик Айдаров, син гомер буе юкка көчәнгәнсең булып чыга түгелме?

Шәяхмәт диванга ничек килеп утырган булса, шул хәлендә, гаять тыныч чырай белән, җиргә береккән имән кебек утыра бирде.

— Штабс-капитан, сез яралы аюның нәрсәгә сәләтле икәнен беләсезме?

— Аюның монда ни катнашы бар?

— Сез ирекле илне яраладыгыз. Ил моның үчен алачак. Сез үзегезнең төзүче түгел, җимерүче икәнегезне ачып салдыгыз. Причем — оятсыз рәвештә. Тарих шаһит — халыкның беркайчан да җимерүче артыннан, палачлар артыннан барганы юк, жандарм Бохараев!

Штабс-капитанның чигә тамыры сулкылдап тибә башлады.

— Солдатлар! — дип кычкырды ул. — Бу мерзавецны җан исәбенә кертегез.

— Камчы беләнме, ваше благородие, шомпол беләнме?

— Камчы белән! Илле кайнарны! Исегезгә төшерәм, порка вакытында барабан суксыннар, минем нервыларым кеше ыңгырашканны күтәрә алмый.

## VI

Зартугай урамнарыннан көн дә саен арыган, өшәнгән атлылар уза. Кайчандыр акбүз атларда ашкынып чапкан иреклеләр, ярларына кире кайтып төшкән язгы су төсле, күмәк ташкынга ияреп, кирегә тәгәриләр. Ялан аяклы кызылармеецларны конвой белән атка атланып куган чактагы сыман, күкрәкне киереп, камчы белән селтәнеп бармыйлар, күбесенчә Кама буендагы хурлыклы җиңелүне, үләрен-калырын белми ябырылган кызылларны искә төшерәләр. Башлар түбән иелгән.

Акларның җиңелү белмәс бөек армиясе Кама үзәннәреннән Башкортстанга таба чигенә.

Зартугайның Түбән очына, Иш елгасының текә ярына ук терәп оборона кордылар, авылның яшен-картын ялан кырга куып, окоп казыттылар, окоп саен диярлек пулемет куеп чыктылар. Ләкин көтмәгәндә ашыгу, каударлану башланды. Пулеметлар алынды, сафлар тизелде — гаскәр авылны ташлап чыгып китте.

Аклар белән бергә Югары оч мәхәлләсенең баш мулласы Сөләйман хәзрәт тә китәргә җыенды. Хатыннарын, мал-мөлкәтен Таминдар Тураевлар олавына төяп, ике атын олауга тагып, намазын, мәчетен онытып, бөтен авылны бер итеп йөгереп йөрде.

Габбас мулла йортына, ак күбеккә баткан атын камчылап, Кысык Минҗан килеп керде.

— Син нишләп гамьсез ятасың, Габбас? Сөләйман хәзрәт китте, безнең Салагыш муллалары китте, Таминдар бай шылды. Әллә бер сине башыңнан сыйпарлар дип беләсеңме? Җыен, хәзрәт, баш исән чагында китеп калыйк. Синең кола бия белән минем күк бияне парлап җигик тә аклар гаскәренә ышыкланып китеп барыйк. Җүнлелеккә булмас калу: байбәтчәнең, мулла-мунтагайның берсен-бер калдырмый суеп киләләр ди бәлшәвикләр. Балаларны ботыннан тотып стенага бәрәләр ди. Мордар үлем белән үлгәнче үзебезнең Мөхәммәт өммәте өчен сугышкан аклар гаскәре ягында булуың мең артык...

Габбас мулла аның сүзләрен тәрәзәдән урамга төбәлгән килеш, сакалын учы белән каплап, бүлдерми генә тыңлады. Аннары, бирчәйгән бармаклары белән сакалын аралаштырып, гүя сакалы белән киңәш-табыш иткәндәй, беркавым дәшми торды.

— Син мине кыстама, кем Минҗан. Җигеп чыгарга арбам да әзер түгел, биям дә колынларга тора.

— Үкенерсең, хәзрәт, соң булыр.

— Үкенерсең дип... Ник үкеним икән мин? Сәвиткә каршы гамәл кылганым юк, авыл кешеләрен сатмадым.

— Кем саткан? — диде Минҗан исән күзен акайтып.

— Башыңны җүләргә салма, Минҗан абзый. Шәрифҗан мөгаллим вафаты синең вөҗданыңда.

— Ни сөйлисең син, хәзрәт. Акылыңа кил. Нишләп Шәрифҗан минем вөҗданымда булсын?

— Ә кем алып китте соң аны Салагышка?

— Анысы инде үткәнне казымыйк, хәзрәт. Барыбыз да дөнья коллары, берәүнең дә җаны икәү түгел, муеныңа алтатар терәп әмер иткәч, апкитми хәлең юк.

— Ярар, сөйләштек, юкка вакыт уздырмыйк. Син алып киткәнсең икән, җавабын да үзең бирәсе. Ул беткән башларга ияреп, ирекле баштан Себер китәр хәлем юк. Үлсәм дә, калсам да шушы Зартугайда. Тәкъдирдә ни язган — шул булыр.

Кысык Минҗан корт чаккандай угаланып алды. Аннары авырдан гына күк биясенә чыгып атланды да, тиктомалдан атына камчы белән өрып, аягүрә бастырды, тартып туктатты, башын капкага бәрә язып, мулла йортыннан чыгып китте.

Акларның актык гаскәрләре авылдан уза. Талаңасы әйбер таланып беткән. Ләкин офицерлар аңа гына канәгать түгел, җиңелү хурлыгыннан ярсып, халыкның соңгысына тотыналар.

Солтаннарга бер төркем солдат ияртеп, бодай капчыгы кебек тыгыз, нык гәүдәле фельдфебель килеп керде.

— Лошадь есть?— диде, кулын кабурына куеп.

— Ниту,— диде Садыйк карт.

— Искать!— дип кычкырды фельдфебель солдатларга.

Сарык абзарыннан, салам белән каплап куйган җирдән, сары бияне җитәкләп алып чыктылар.

Садыйк карт, үләрен-калырын белми, атның йөгәненә килеп асылынды.

— Гаспадиннар, кызганыгыз. Ул бит буаз. Сабан җитә, ул бит буаз. Солтан, дим, кая китеп олактың син, эт каешы? Аңлат әле үзләренә, әйтеп бир әле урысчалатып, атның баранчугы була, диген.

Солтан, Алабугада чакта өйрәнә башлаган русчасын хутка җибәреп, шуның янына кул болгауларын да кушып, әтисе әйткәннәрен озаклап аңлатты. Ул арада офицерның сабыры төкәнде.

— Прекратить разговоры!— диде фельдфебель, бияне арбага җигәргә боерды.

Атның тезгенен ычкындырмый азапланган Садыйк картны читкә селтәп аттылар.

— Улыңмы? Илтә барыр. Алмашка ат бирербез,— диде фельдфебель.

Садыйк карт тагын чәбәләнә башлады.

— Малайкы нитругай, малайкы җәлке, малайкы харуший,— дия сөйләнә-сөйләнә, карт урамга чаклы чыкты, улына ялвара башлады.

— Солтан, балакаем, озак йөрмә, тиз кайт. Тиз кайта күр, яме.

Фельдфебель белән аның деңщигын утыртып, Солтан Салагыш юлыннан чигенеп баручы олауларга килеп кушылды. Күңелендә аның хәзер бер генә уй: исән-сау котылса, атны да алып кала алса, өйдән качып китү, акларны куып килгән Азин гаскәренә кушылып, үтерүчеләрдән Шәрифҗанның үчен алу иде.

Ләкин хәзергә качып китү өчен бер генә дә җай юк, басу юлыннан иллеләп олау бара, олаулар яныннан зур кара төркемнәр булып, җәяүле солдатлар атлый. Салагыш белән Пәнҗәр арасындагы урманда солдатлар туктап ук калганнар. Сакалы биленә җиткән бер рус карты:

— Берите лошадей, проклятые, я не поеду! — дип ярсып кычкыра, җыерчыклар телгәләгән кара-кучкыл битеннән яшь агып, сакалына җыела бара иде.

Солтанның җиңел сиртмәсенә утырган фельдфебель ашыкмый гына җиргә төште, солдатлар төркемен аралап кергәч, биленнән кылычын суырып алып, олаучы картның башына китереп чапты.

Солтан чытырдатып күзен йомды. Яралы аюдай үкереп җибәргән тавышка күзен ачса — солдатлар таралышкан, олаучы карт, канга батып, җирдә ята.

Солтан шул якка озаграк карап тора икән, сыртына төшкән йодрыктан сискәнеп, атны куалап алып китте.

Пәнҗәргә җитәргә биш-алты чакрымнар кала сиртмәле арбага сары бәдрә чәчле, зәңгәр сарафанлы яшь кенә бер хатынны утырттылар. Солтан үзенең артында сиртмәдә әлеге хатынның фельдфебельгә ялагайланып дәшүен, иркә тавыш белән гөлдерәп сөйләшүен, аннары чупылдатып үбешә башлавын ишетте. Артына әйләнеп карарга бик өзгәләнсә дә базмады: башына кылыч чабылган олаучы карт күз алдыннан китми иде әле.

Кызыллардан ерак киттеләр шикелле инде. Солтанның артында, сиртмә-арбага көйләнәләр, ахрысы, ешрак мышлый, ешрак тын ала башладылар.

Пәнҗәргә житәрәк атлы олаулар, җәяүлеләр артканнан-арта барды. Чигенүче гаскәр, күрәсең, Пәнҗәрдән пароход белән китәргә исәп тота: авылның ындыр артлары, басу юллары олаулар белән, гаскәр белән тулган. Пристаньда, яр буйларында буксирлар, баржалар, катерлар, хәтта гап-гади балыкчы көймәләренә тикле гаскәр төйи, сугыш кирәк-яракларын тутыра иде.

Фельдфебель, кабурына кулын куйган хәлдә, Солтанга беркая да китмәскә боерып, сөяркәсе белән каядыр китеп югалды. Солтан жирдән чәчелгән печәннәрне җыеп сары биясен ашатты, өйрәнгән гадәте буенча, өйдән кыстырып чыккан ипи кыерчыгының да яртысын атка ашатып бетерде. Калган яртысын үзе ашый-ашый, күршедәге олауларга күз төшергәләп алды. Җирән сакаллы, тула чикмәнле ике рус, Солтан ишетмәсен дип бугай, сак кына сөйләшәләр иде. Ләкин Солтанның сизгер колагы, аннан да битәр алгысыган күңеле сизеп алды: болар качып китәргә җыеналар.

Атларын борып, урам якка таба китә башлаулары булды, Солтан да алар артыннан иярде. Шәһәр читенә чыгуга руслар атларын җан-фәрманга чаптырып киттеләр. Солтан да алардан калмаска тырышты: ни күрсәләр дә бергә күрерләр.

Атлар өстеннән ак күбек оча башлаганчы чаптылар да беркавым юыртып кына бардылар. Каранып алдылар — арттан куа килүче күренми. Болай булгач — котылалар. Алдагылар урман юлы белән уңга борылды, Солтан Саранбайлар авылына элдертте. Авылга керер алдыннан кечерәк бер сазламыкны узарга кирәк иде, Солтан шул хакта кайгырып, буаз бия белән сазламыкны узып булыр микән дип баш ватып кайта иде, жир астыннан чыккандай, аның каршысына берьюлы ике атлы килеп туктады. Берсенең аты бик кечкенә, ишәк чаклы гына иде.

— Давай, прягай лушади,— диде әнә шунысы.

Солтан аның татар икәнен аңлап алып, этисе әйткән хәйләгә керешге:

— Абзый, бия буаз, тояклары да уалган, ул бит атланып йөрергә ярамый,— диде.

Солтан белән бәхәсләшеп тормадылар. Тәбәнәк аттагысы ялт кына жиргә сикерде дә йөгән тезгенен Солтанга тоттырды, үзе әллә ни арада сары бияне туарып үз атының иярен аңа бәйләде, биягә атланды, Солтанга борылып:

— Бәхил бул, егет, үпкәләмә. Заманасы шундый. Мин сиңа начар ат калдырмадым,— диде.

Солтан кәҗә хәтле атка карап, елар чиккә житешеп әйтте:

— Кемнәр соң сез: аклармы, кызыллармы?

— Сиңа ирек алып килүчеләр без!

— Ирек алып килүчеләр!— диде Солтан үртәнеп.— Агы да талый, кызылы да. Кемнең кем икәнен дә белмәссең.

— Давай, егет, авызыңны бик җәймә, җик тә тай,— диде бәләкәй ат калдырган сугышчы.— Ату монысын алып китәргә дә күп сорамабыз. Заманасы шундый.— Ул көчәнеп елмайды, аркылы кызыл тасма таккан көрән бүреген салып тирләгән маңгаен сөртеп алды, аннары олтаны куба башлаган зур иске күн итеге белән сары биянең корсагына тибеп китеп барды.

Солтан сары бияне кызганып бик озак карап торды. Кайтырга кирәк иде — гаскәриләр калдырып киткән кечкенә алашаны сиртмәгә җигеп, моңсулыктан, керфек төпләрен кымырҗытып күзенә яшь килүдән уңайсызланып, тиз генә сиртмәгә менеп утырды. Караса — ат дигәне тәртәнең яртысына гына житкән, хет тагын шундый бер бәләкәй

ат ялгап җик. Кәҗә бит бу, чын кәҗә! Теге сазлыктан ничек чыга инде бу? Аның гаскәриләр калдырып киткән шушы ат кисәгенә шундый да ачуы чыкты, ул аяк өсте торып басты, нишләгәнен белештермичә, сүс дилбегәне баш өстеннән болгап-болгап, җан көче белән атка китереп сукты: әйдә, дөмексәң дөмек инде! Шулай дип уйлап та бетермәде, күз ачып йомганчы сиртмә төбенә авып төште. Бичара ат ыргылып алга сикергән икән. Солтан тагын аяк өсте торып баскалаганчы ат инде сазламыкны чыгып китәргә дә өлгергән.

Сиртмә, казылмаларга менә-төшә, дөберди-дөберди, бәрелә-сугыла чаба. Солтан сүс дилбегәне ике куллап чорнап тотып, сиртмә төбенә ятты. Туктатыр гына хәлләр юк бит бәләкәчне! Атылып урамга барып керделәр. Капка-коймага, урам урталарындагы бураларга бәрелүдән коты алынып, дилбегәне ике кулга чорнап, аяк тәрәп тарта Солтан, ат — кая ул туктау!— шашынып, ярсып, дулап, тилереп чаба! Урамда очраганнар читкә атыла, җир җимертеп чапкан ат артыннан сәерсенеп карап кала. Картлар: «Тукта! Тукта!»— дип дәшә. Ат Саранбайларны да узып китте инде, ялан кырны бетереп озак чапты — әле һаман туктамый.

Юлда атлы арба күренде.

Солтан: «Беттем!» дип күзләрен йомды.

Бичара хайван арбага сикереп тезләрен бәрде, читкә ыргылмак булды. Арбадагы агай, җиргә төшеп, атның башыннан тотып алды. Күзләре акаеп чыгарга җиткән, савырыннан бүрек-бүрек булып ак күбек очкан бичара ат дер калтырап чабудан туктады, Солтан дилбегәне бушаткач, ул бөтенләй тынычланды — тик ара-тирә генә артына борылып ачулы пошкыргалап куя, шалтыратып авызлыгын чәйни иде.

Саклау урманында бер аланга туктадылар.

Башына ямьшәеп, төсләре уңып беткән киез эшләпә, аягына чабата кигән, киндер күлмәге киҗеле ыштаны өстеннән чыгып торган агай Солтанның кайсы авылдан икәнен сораштырды, кем малае икәнен әйткәч, баш селкетеп торды:

— Беләм. Айдарныкыларны беләм. Шәяхмәт Айдаров белән бергә ярман сугышында йөрдем,— диде.

— Кит аннан!— Солтан гаҗәпләнеп агайны баштан аягына кадәр күздән үткәрде, бу аның абыйсы Шәяхмәт белән янәшә дә куярлык түгел, бердән, яшькә бик олы, икенчедән, киеме Шәяхмәт абыйсы белән янәшә куйсаң — кычкырып көләрлек иде.

— Нигә бик гаҗәпләндең?— диде агай Солтанга, каш астыннан карап.

— Шәяхмәтне беләм диден дә... Нишләп, алайса, ул... акларга каршы отряд белән йөри, ә син монда, аклар озатып...

— Дөнья бу, энем. Мин дә абыең төсле арыслан егет идем. Ярман сугышында кантузин булдым, аяктагы яраларны әйткән дә юк. Өйдә әни карчык, хатын авыру, өч бала... Карап кара син менә шуларны.

Агайның капчыгында ипи белән кабыклы бәрәңге бар икән, шуны икәү бүлеп ашадылар. Урманны чыгып җитә язганда җәяүле юлчылар очрады. Салагыш белән Зартугайдан әле аклар китеп җитмәгәнне әйттеләр. Авылга ат белән кайтып йөрмәгез, бер атны да калдырмый талап алып китә баралар, диделәр.

— Атларны яшереп торыйк. Караңгы төшкәнче көтик,— диде юлчы карт. Урман ешлыгына кереп, атларның алдына үлән йолкып алып килеп салгач, карт:— Ай-һай, егет, атың да атың, әллә Шәяхмәт абыең алып кайттымы?— дип сорады.

Караңгы төшкәч, агай үз юлы белән Яуморзага кайтып китте, Солтан, Зартугайга кайту юлын саташтырып байтак вакыт каңгырып йөргәч, Салагышка барып керде.

Урамнар тын, кеше-кара күренми, этләр дә өрми. Аулаграк урамнар аша узып, кырга килеп чыкты Солтан, Зартугай юлын табуга шатланып, дилбегәне чорнабрак тартып җибәргән иде — бәләкәч ат очкын урынына алга ыргылды, бушаткач — тагын тынычланды.

Төн әллә нинди тыныч, аулак, ерактан тонык кына булып ишетелгән туп тавышлары фронтның шактый ерак киткәнен белдереп тора иде. Менә инде Салагыш басулары да артта калды, Солтан үз авылы җирләренә барып керде. Юлның ике ягында — вак әрәмәлек, сирәк урман. Атны үз җаена куеп, әкрен генә үрдән төшеп килә иде, куак төбеннән ниндидер карачкы күтәрелде дә, юлны кисеп, ат каршына чыга башлады. Солтанга ул карангыда шыксыз озын булып, имәндергеч булып тоелды. Ул, сикереп торып, дилбегәне кулына чорнамакчы иде, теге адәм ат башыннан тотып алырга да өлгерде:

— Кем син?— диде әкрен генә.

Солтан Зартугайныкы икәнен әйтте.

— Ә бу синмени әле, Солтан апаем?— дип, әлеге кеше арбага таба килә башлады. Солтан аның теге көнне Вәрзе-Ятчәдә очраткан Мәрдән абзый икәнен таныды.

— Әй, Мәрдән абзый, котны алдың? Каян килеп чыктың болай? Мин эфисәрләрне озатып кайтып киләм.

— Кайсы авылларда булдың?

— Пәнҗәрдән башлап барысында да...

— Аклар кай тирәдә?

— Пәнҗәргә килеп тулганнар. Ындыр артлары да, ишегаллары да, басу юллары да тулык.

— Китәләрме?

— Өлгергәннәре китә. Буксир белән дә, баржы белән дә...

— Әһә. Салагышта булмадыңмы?

— Булдым.

— Анда ни хәлләр? Аклар киткәнме?

— Бер тавыш та ишетелми. Кеше-кара да юк урамда. Бәлки киткәннәрдер.

— Ярый, алай булгач, мин синең белән Зартугайга чаклы кайтыйм әле. Алып кайтырга курыкмыйсыңмы?

— Әйдә, бергә-бергә күңеллерәк булыр,— диде Солтан. Аннары сагая төшеп әйтте:— Авылдан аклар китеп бетте микән соң? Син, авыл советы башлыгы булган кеше, тотып алсалар?

— Төнлә бик ауламыйлар алар. Җан кадерле. Кем белә минем кайсы почмактан килеп чыгасымны? Бәлки мин кесәмдә револьвер йөртә торганмындыр. Бәлки бүре үтерә алырдай аучымындыр...

— Шулаен шулай да, барыбер куркыныч. Шәрифҗан абыйны кыйнап үтерделәр, Вәҗи анасын анадан тума ялангач ат койрыгына тагып йөрттеләр.

— Китче?! И Шәрифҗан... Әйттем бит мин аңа...

Зират янында Мәрдән абзый арбадан төште. Солтанга рәхмәт әйтеп, агачлар арасына кереп китте. Солтан үз урамнарына таба юнәлде.

Солтан капка бастырыгын төшерүгә, ишегалдына әтисе белән әнисе йөгереп чыктылар. Әнисе битен яулыгы белән каплап елый, әтисе тыенкы тавыш белән тиргәнеп, аны туктатырга азаплана иде.

Ниһаять, әтисе аңардан аерылды, арба янына килеп җитеп:

— Солтан синме? Ат исәнме?— диде.

— Исән,— диде Солтан.— Яңаны алмаштырып бирделәр.

Садыйк карт тәртәнең яртысына гына җиткән бәләкәчне бар яктан әйләнеп карап чыкты да, җиргә төкереп, өйгә кире кереп китте, хәтта туарышырга да булышмады.

«Күрерсең әле син аның нинди икәнен»,— дип, үзалдына елмаеп уйлады Солтан.

Икенче көнне этисе, каргана-каргана, бәләкәчне җигеп урманга китте. Берәр сәгатьтән ул камытларын ваттырып, дугаларын сындырып, атны башыннан җитәкләп кайтып керде.

— Ну, эти, ничек?— диде Солтан.

— Юкка рәнҗеткәнмен әрме атын. Җен көчләре бар бу бәләкәчтә. Алай да талканы коры монын, эрәтеннән-җаеннан гына тормасаң, муенын астына килгәнне сизми дә калырсың! Әмма дә ләкин аптырыйм әле мин, әрмеләр сары биянең нәрсәсенә кызыктылар икән? Бу бит аның янында — очкын. Юк, ялкын бу, пажар! Бар, улым, илгә алып чык өйдән, нәләндерик кулга. Шәт, иншалла, әрмеләр кире килсәләр дә кызыкмаслар инде моңа,— диде, атны, суыту өчен, лапаска кертеп, баганадагы боҗрага бәйләп куйды.

Иртәрәк сөенә иде Садыйк карт. Әрме аты аңа насыйп булмады, шул көнне төнлә Солтан аны шыпырт кына лапастан алып чыкты да атланып кызыллар отрядын эзләп китеп барды. Бары тик бер айдан соң гына аның Азин гаскәренә барып кушылганлыгы, халыкның канын эчкән байларны, ак әфисәрләрне кырып бетерми торып кайта алмам, дигән хаты килде.

Садыйк карт киез эшләпәне кулы белән каш өстенә чигереп, арт чүмечне кашып, җиргә карап торды.

«Ярабби, монысыннан да кул арасына кирәрлек әдәм чыкмады. Монысы да, Шәяхмәт коткысына бирелеп, браматлыкка китеп барды. Миңа балалар игелеген күрергә язмагандыр инде...»

Илдә барган сугышларны искә төшереп, еракта-еракта күк күкрәгән сыман туплар тавышы ишетелә иде.

## ДҮРТЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

1919 елның көзендә, заманалар бераз гына булса да тынычланып, Кама буенда мылтык тавышлары тынгач, Габбас мулла ат җигеп Нурияне янә дә Алабугага китерде. Китерүенең сәбәбе гади: Алабуга — алар авылына иң якын кала. Габбасның туганнан туган сеңлесе Зәйтүнә анда балалар укыта, тутасы ягыннан кардәш тиешле Нәҗия Уразаева, буй җиткән кыз, элекке Эпархиальное училище бинасында, хәзер урта мәктәп итеп җиһазланган зур кирпеч йортта укып йөри. Нурия шулар янында әвәләнеп кыш чыгар дип фикер йөртелде.

Болары, билгеле, тышкы сәбәпләр. Әгәренки эчкәрәк, тирәнгәрәк кереп карасаң, хәлләр, әлбәттә, катлаулырак. Зартугай белән Салагышта, гомумән, Кама буйларында булып узган мәхшәр: үтерү-сую, Вәҗи анасын анадан тума килеш ат койрыгына тагып йөртү, гаделлек таләп иткәне өчен Даут мулланың кул-аягын кисеп, үле гәүдәсен штыкка кадап кырга чыгарып ташлау — болар барысы Габбас мулланың җанын тетрәткән, өнен алган иде. Мәк чәчәгедәй алсу янып торган унтугыз яшьлек Нуриясен ул мондый болгавыр заманда Зартугайда асрап ятудан курка, Таминдар Тураевлар, Сөләйман хәзрәтләр аклар гаскәре белән бергә качып киткәннән бирле үзен таянычсыз итеп сизә, җанын кая куярга белмичә, көннәр буе каңгырап йөри, төннәрен берсеннән-берсе ямьсез төшләр күреп, сискәнеп уяна. Төшләре дә бит аның һаман бер тирәдә әйләнә: имеш, аклар яңадан әйләнеп кайтканнар. Алар белән бергә Сөләйман хәзрәт белән аның улы әфисәр Динислам да кайткан. Кара аргамакларга атланып, кылыч айкап, авыл халкын турап-суеп йөриләр, имеш. Габбас уянганнан соң озаклап догаларын укып ята, аңа гына да риза булмыйча, тәһарәт алып,

намазлык өстенә ук менеп утыра, көн саен укып бара торган биш вакыт намазында ул, явыз адәмнәрдән үзең сакла, каферләрнең, дәһриләрнең, имансызларның акылын томала, ходаем, дип, тәңресенә ялвара. Шуларның барысы өстенә Нуриянең боеклыгы... үтерә инә шул боеклыгы. Ә бит ул нинди көләч иде, нинди яңгыравыклы итеп, көмеш кыңгыраудай чылтырап, рәхәтләнеп-рәхәтләнеп көлә торган иде. Айдар Садыйгының Солтаны Азин дивизиясенә китеп барганнан бирле кызы сүзсез калды. Шул хәтле дә көчле булды микәнни соң яратуы?..

Кунакларны Зәйтүнә каршылады. Ак чырайлы, сары ефәк чәчле, озын кара күлмәкле, егерме җиде яшьләрендәге мөгаллимә кунакларның икесенә ике төрле мөнәсәбәт күрсәтте. Абыйсының сәламен алыр-алмас, юка иренен бөреп кенә куйды (ул әле, күрәсең, абыйсының яшь хатынга өйләнүен шушы көнгә тикле гафу итмәгән!), Нурия белән күрешкәндә анын зәңгәр күзләре чиксез бер сөенеч белән тулып, язгы күк йөзе кебек балкыдылар. Шомырт кара ике толым чәче күзге пальто өстеннән салынып торган Нуриянең алсу капкан битләреннән сөеп:

— Йа алла, кемнәр бәхетенә шулай тулып пештең син?!— диде.— Туктале, гөлекәем, өебез дә суык бит әле безнең... Киләсеңне хат белән дә язып җибәрмәгәнсең. Белгән булсам, Серафима Ниловнага иртә баштан ук өебезне яктырып куйган булыр идем. Әйдәле, үскәнем, сал әле бу пәлтәләреңне, иннәреңне баскандыр. Мамык шәлем бар минем, суык дисәң, җилкәңә шәл салырсың. Укырга дип килдеңме? Бик әйбәт, бик яхшы, үз янымда яшәрсең, Нәҗия белән бергәләп укырсыз...

Ул тагын әллә нихәтле ягымлы сүз сөйләде, Нуриянең чибәрлегенә, буй-сынына торып-торып сокланды, шуның белән сеңлесен бик кыен хәлгә китереп куйды. Гел аның янында гына бөтерелүе, этисен санга да сукмавы Нурияне баса, газаплый башлады.

— Нәҗия апам кайда соң?— диде Нурия, килеп туган күңелсезлекне бетерергә теләп.

— Кайтыр, иркәм, Нәҗия дә кайтыр. Аларны урман кисәргә җибәрделәр — бер атнага. Югары сыйныфта укучылар утынны үзләренә үзләре әзерли. Кеше бер дә юк бит, гөлекәем, ир-ат фронтта, яшь-үсмернең киеп чыгам дисә киеме юк. Халыкны кара җәяүгә калдырды бу сугыш...

Ул, капыл исенә төшеп, сүз белән мавыкканга үзен-үзе битәрләп, болын чаклы буш бүлмәне кыеклап кисеп чыкты да аргы баштагы бәләкәй генә иске бер имән шкафтан соры мамык шәл алып, Нуриянең җилкәсенә китереп япты, тик шуннан соң гына:

— Әйдә, абый, чишен син дә... кунып китәрсең,— диде.

— Куныйн мин сездә куналмам, Зәйтүнә. Атны сакларга урын да юк монда... Нуриянең әйберләрен алып керим дә кузгалырмын...— диде Габбас мулла.

Ул көчәнә-көчәнә сандык күтәреп керде, талдан үргән кәрзин алып керде, Нуриягә кирәкле ашау ризыклары салган ипи капчыгын кертеп куйды, аннары өстен чишенмәгән көе генә урындыкка утырып, кызы белән сеңлесе Зәйтүнәнең саулыгына кул күтәреп дога кылды... Һәм кайтырга дип кузгалды.

Нуриянең күңеле тетрәп китте. Әтисен бер чынаяк чәй дә эчмәгән килеш чыгарып җибәрү башка сыймаслык хәл иде. Ләкин бу фатирга ул баш түгел, юка иренен чытырдатып кысып куйган Зәйтүнә апасы баш иде шул. Әмма әтисе ишек төбенә үк килеп җитеп, ишек тоткасына үрелгәч, кызый түзмәде:

— Апам, әти чәй эчеп китсен инде, яме,— диде.

— Чәй эчеп китәр,— диде Зәйтүнә апасы коры гына.

Самавыр кайнаган арада Нурия үзе яшисе бүлмәне күздән кичерде. Бәләкәй иске шкафтан тыш монда баш-башлары тимер шарлы ике иске карават, бер өстәл, кайчандыр байлар өен бизәп торган, хәзер инде

кызыл төстәге атласы тузып тишелгәләгән терәкле өч урындык, стена буендарак галанка мич бар иде. Шушы ике-өч бөртек мебель болын чаклы буш бүлмәдә бөтенләй югалып калган, бүлмәнең бушлыгын бигүк сиздермәс өчен генә анда-санда төртеп куелган сыман тоела иде.

Саргылт битен җыерчык һәм борчу баскан озын сарафанлы бер хатын утын күтәреп керде. «Добрый день!»— дип исәнләште, болар кемнәр дип тә, каян килделәр дип тә сорап тормады, мичен ягып җибәрде дә «досвиданья!» дигән бер генә сүз әйтеп чыгып китте.

Аның шулай үз эченә бикләнгәнлеге, сүзсезлеге Нуриягә үтә дә аңлаешлы һәм табигый иде, Нуриягә ул туганыдай якын тоелып китте.

— Йорт хуҗабыз, Серафима Ниловна,— диде Зәйтүнә, ул чыгып киткәч.— Ире кызыл командир булган, Алабуганы коткарганда дошманнар үтергәннәр. Мәшәкать дип тормый, мичне көн саен үзе кереп яга, бичара. Фатирдашларым утынны күп тотмагайлары дип курка бугай...

Нурия апасының сүзен баш селкеп тыңлады. Габбас мулла, атласы ертылган урындыкка чүмәшкән көе, үз уйларын уйлый иде, ул бер сүз дә дәшмәде. Ул Зартугайга кайтып китәчәк. Нурия монда кала. Алар өчәү генә яшәрләр — үзе дә ике хатыны. Барысы да олы кешеләр. Эчпошыргыч дәрәҗәдә күңелсез кешеләр. Көмеш тавышы белән бөтен өйне ямьләндереп яшәгән Нурия монда кала. Әти кешегә кинәт бик күңелсез һәм моңсу булып китте: ул хәзер көмеш кыңгыравы алып ташланган буш дуга күтәреп кайтып китә түгелме?

Чәйне сүзсез диярлек эчтеләр. Нурия әтисенең, чынаяк тәлинкәсен тырпайган бармаклары өстендә тотып, өф-өф килеп эчүен, тәлинкәне үзенә таба гүя сулышы белән тартып китерүен карап утырды. Кала җирендә дә чәйне самавырдан эчәләр икән, дип уйлады. Шул минутта ук күз алдына Хәнифә түтәсе килде, ул аның көйрәп торган утлы күмерләрне мичтән соскычка тутыруын, мич эссесеннән алсуланган чибәр йөзен, аның янында олы коштай дәү булып, әмма йөргән чагында песидәй йомшак басып йөри торган үз әнисен күз алдына китерде. Солтан авылдан киткәннән бирле җанына җыелган сагышлары янына инде үзенең дә авылдан читкә китү сагышы өстәлде. Әтисе дә кайтып китәчәк бит әле аның. Ул бәлки монда соңгы чынаяк чәен эчә торгандыр. Әнә ничек тырышып, тирләп эчә ул. Чал керә башлаган түгәрәк кара сакалы дерелди, алсуланган ирене очлаеп тәлинкәдәге төшне тотарга тырыша, менә ул аны тотты, ләкин чамалап җиткерә алмады бугай, төш белән бергә шык иттереп тәлинкә кырыен да китеп алды. Менә син, гөнаһ шомлыгы! Башта гаҗәпләнде, аннары кып-кызыл булып кызарды, соң дәрәҗәдә уңайсызланып, Зәйтүнәдән кат-кат гафу үтенде, яңа чынаяк китереп бирергә вәгъдә итте. Зәйтүнә аны кыен хәленнән чыгармады, юка иренен кысып куйган килеш, мыскылчан чырай белән карап торды. «Юк өчен борчылма, абый, бу заманда аннан кадерлерәк әйберләр дә ватыла!» дип әйтсә ни була инде? Әйтми бит, тынычландырмый. Нуриягә әтисе шундый кызганыч булып тоелды, ул хәтта чәй эчүеннән үк туктады, Зәйтүнә апасы аны кат-кат кыстаса да, бүтән эчерә алмады чәйне.

Сүзсез генә аерылыштылар. Әтисе өстен киенеп, ишектән бөкрәя төшеп чыгып китте. Нурия тәрәзә аша аның арба башыннан юл кәҗәнен алып киюен, арбадагы печәнне ястык кебек итеп күпертүен, арбага менеп утыргач, өй ягына таба каерылып бер каравын, аннары атка дилбегә кагып китеп баруын күрде...

Көзге көн сүнеп бетә язды. Өй эченә эңгер иңеп, караңгылык караватөстәлләр, галанка мич яннарына үрмәләде. Әйберләр шәкелләрен югалтып, кара өемнәргә генә әйләнеп калдылар.

— Ә нигә без ут кабызмыйбыз, апам?— диде Нурия зарлы тавыш белән.

— Керосиныбыз юк, гөлием. Электрны нардомда гына яндыралар. Бераз көтик инде.

Бүлмә бөтенләй караңгыланды, дөнья тынды, ялгызлык хисе Нуриянең җанын баса башлады.

Зәйтүнә апасы каяндыр шкаф эченнән шәм табып алып кабызды. Аны калай тәлинкәгә утыртып, өстәлгә куйды. Зартугайда чагында утызлы лампага ияләнгән Нуриягә шәм яктысы тычкан уты төсле генә иде — утсыз утырганнан да күңелсезрәк булып китте.

Нурия үзен гаять бәхетсез сизеп, әтисе кебек, урындык читенә чүмәште, башын иде; әллә нишләп йөрәк сыкрый, кешегә күрсәтмичә генә үксеп елыйсы килә, ләкин бу зур һәм шыксыз бүлмәдә качып елардай почмагы да юк бит аның... Әкрен генә басып йөргән әнисе күз алдына килде. «Сабыр, сабыр»,— ди иде ул аңа. Чәрелдн башласаң да, еламакчы булып борын тартсаң да, бер үк сүзне әйтә: сабыр сабыр! Әллә ниткән догаларыннан, үгетләүләреннән болайрак тәэсир итә иде шул ике сүз Нуриягә. Менә хәзер дә ул әнисенең дәү коштай каршысында басып торуын, сабыр, сабыр дип дәшүен ишеткәндәй булды. Нурия тамагына килеп бөялгән күз яшен түкми калды.

Күңелдән моң түгеп, шәмнең сары яктысына карап бераз утыргач, Зәйтүнә апасы урын җәйде, юлдан килгән кеше арыгандыр дип, сеңлесенең башыннан сыйпап йокларга яткызды. Үзе ул атнасына бер мәртәбә куела торган спектакльгә нардомга җыена башлады.

Нурия уй-сагышлары, үзәк өзгеч эч пошуы белән — гомерендә беренче тапкыр — япа-ялгыз калды. Зартугайдан ук алып килгән мамык мендәрдә үз өйләренең җанга газиз исен тоеп, иләсләнеп ята торгач, бүгенге озын юл, яңа тойгылар, яңа мөнәсәбәтләр авырлыгы аны басты, ул йоклап китте...

Озак йоклагандырмы, юкмы — бер заманны каты итеп төрткәнгә уянды. Өстәлдә сары ут яна, каршысында кыска итеп чәчен кистергән, өстенә кофта-юбка, аягына күн итек кигән бер кыз басып тора. Почык борынлы, мыскылчан чырайлы бу кызның тавышы тәмәке тартудан карлыккан ирләр тавышы кебек тупас иде:

— Тор, буржуй кызы, киерелеп ятма, мин сиңа бер кызык күрсәтәм!

Нуриянең кинәт йокысы качты. Эчке күлмәктән генә килеш, куллары белән үзен-үзе кочаклап, каршысында торган күн итекле кызга карап катып калды:

— Ә син кем?

— Без Нәҗия Уразаева булырбыз!

— Синмени ул Нәҗия апам? Әле бит сине Зәйтүнә апа бер атнага китте дигән иде.

— Ә мин үземә тигән өлешне дүрт көндә кисеп бетердем, мәктәптән яңа смена алырга кайттым,— диде Нәҗия карлыккан тупас тавышы белән.— Ә син тәмәке тартасыңмы?

Нурия бу сүздән «икъ!» дип көлеп куйды, торып өстен киенә башлады.

Нәҗия терәкле урындыкны галанка мич буена аударып куйды да мич капкачын ачып, шунда чүгәләде, газит кәгазе ертып, тәмәке төрде, ут кабызды, ике борын тишегеннән паровоздан чыккан төсле итеп ак төтен агылып чыкты.

Нурия анысына гаҗәпләнергә дә өлгермәде, Нәҗия аның авылдан алып килгән күчтәнәчләрен таптыра башлады, каяндыр үзенең юл капчыгын табып, аннан бөке урынына кәгазь бөтереп тыккан бер шешә алды, шешәне баш турысына чаклы китерде дә:

— Син моның нәрсә икәнен беләсеңме?— диде.

— Әллә керосин алып кайттыңмы, апам?— диде Нурия сөенеп.

— Таптың сүз: керосин! Самогон диләр моны беләсең килсә! Әйдә, Зәйтүнә апа югында берәр чокыр эчеп алабыз.

— Кит, җүләр!— диде Нурия коты алынып.

— Их, син, буружуй кызы! Менә карап тор. Моны авызга бер кабуга бөтен тәнеңә ут йөгергәндәй була! — Нәҗия калай кружкага аксылъяшькелт сыекча салды, башын артка ташлап эчеп җибәрде, Нурия аның йөзе әче миләш капкандагыдай җыерылып килүен, күзеннән шул ук минутта атылып яшь чыгуын күрде. Ул бик кинәт исереп китте, Нурияне килеп кочаклады, чатырдатып кукрәгенә кысты:

— Ә син беләсеңме, буржуй кызы, замана хәзер пыралитарьятныкы! Элек кенә ул хатын-кызны эт урынына да күрмәгәннәр! Хәзер мин үземә-үзем баш. Телим — тәмәке тартам, телим — эчәм. Мине беркем берни эшләтә алмый. Ха-ха-ха! Әйдә, тансавайт итәбез.

Ул Нурияне ду китереп әйләндерә башлады, Нурия башы әйләнеп, куркып кычкырып җибәрми торып, аны әйләндерүдән туктамады.

Искиткеч иде бу хәлләр. Нурия тәмам хәйран калып торган арада Нәҗия Зәйтүнә апасының кайда икәнен таптыра башлады, нардомга спектакльгә киткәнен белгәч, Нурияне бик ашыктырып киендерде, кулыннан җитәкләп спектакльгә алып чыгып чапты.

Шул көннән башлап бу йортта Нурия өчен көтелмәгән, беркайчан да күңелгә килмәгән шау-шулы, өермәле тормыш башланды.

## II

Серафима Ниловна — аз сүзле хатын. Ул көненә бер мәртәбә өйләдән соң мич ягарга кереп чыга. Өстендә бөрмәләп теккән озын сары сарафан, сүзләре дә бер үк: «Добрый день — досвиданья!» Зәйтүнә апалары көннән-көн буе мәктәптә, өйдә керосин булмаганлыктан, язусызу эшләрен ул мәктәптә төгәлләп кайта, Нурия белән Нәҗиягә монда үзләре теләгәнчә яшәргә тулы ирек куелган иде. Өстәвенә, Зәйтүнә мөгаллимәнең олыгаеп барган кыз булуы да ярап куйды. Алабугага килгәч дуслашкан мөгаллимә кызлары белән бергә ул танцы кичләренә йөри, атна саен бер мәртәбә нардомга спектакль карарга бара. Киенепясанып, озын куныччлы сары ботинкасының барлык каптырмаларын шнур белән бәйләп бетереп, өйдән чыгып китәр алдыннан:

— Бер кая да чыгып йөрмәгез, яме, үскәннәрем. Дөньяларның бик чуалчык чагы, усал-унтагайдан, явыз-яманнан үзе сакласын!— дип әйтеп китә.

Авылда туып үссә дә, бик тиз шәһәрләшеп киткән, тез тиңентен кара итәк, зәңгәр блузка киеп, берет-кепканы кыңгыр салып йөри торган Нәҗия, Зәйтүнә апасы иптәш кызлары белән өйдән чыгып китүгә, мич алдына килеп тезне-тезгә чәнчеп утыра да тәмәке кабызып җибәрә, ул да түгел, йөгереп килеп Нурияне урыныннан йолкып ала да тегеләр артыннан чыгып чаба; болар да шул ук спектакльгә барып керәләр, спектакль бетәр-бетмәс беренче булып чыгып йөгерәләр дә Зәйтүнә апалары кайтып кергәндә инде мышный-мышный «йоклап яталар».

Әнә шулай бергә, Зәйтүнә мөгаллимәгә күрсәтмичә генә үз белдекләре белән яшәп ятканда, Нурияның тормышында көтелмәгән бер хәл булды. Күрше фатирда стена аша гына музыка уйнап җибәрделәр. Әллә нинди ят музыка, үз гомерендә беренче тапкыр ишеткән сәер авазлар әсир итте Нурияне. Язын Иш елгасы ташыган чактагы кебек, бозларның дөберди-дөберди кузгалулары сыман, бер мәлгә дөнья гел күкрәп торды. Аннары бозлар агып беттеләр. Кояш чыкты. Кояш җылысыннан өй кыегында тамчылар тама башлады. Шундый матур, шундый нәфис тама тамчылар, шундый мөлаем, шундый рәхәт җылыта кояш, ишегалдына чыккан сыерлар шул җылыга кызына, урамда казлар йөри, күңелне тутырган шатлык-сөенеч күз яше булып тамакка бәялә; әнә

күрше Садыйк абзый малае Солтан ат эчерергә китеп бара, тамчылар һаман тама, һаман тама...

Әтиләре белән кунакка барган җирдә Нуриянең мандолина, скрипка кебек уен кораллары күргәне бар иде, зур кунаклар җыелган чакларда әтисе үз өйләрендә граммофон уйната торган иде, ә менә бу язгы саф авазларның, тымызык тамчыларның, җылы кояш нурларының нинди уен коралыннан чыгуын ул бер ничек тә аңлый алмады. Аңлыйсы килү, белергә теләү — тәкатьсез рәвештә — аның күңелен алгысыта иде.

— Апа җаным, бер генә минутка мине күршеләргә алып кер әле,— диде ул Нәҗиягә.

— Ярамый!— диде Нәҗия. Нык итеп, өзеп әйтте. Атаманлык итү, «буржуй кызын» үз иркенә буйсындыру аңар бар нәрсәдән рәхәт иде, күрәсең.

— Әллә, апам, кеше әйберсенә тияр дип куркасыңмы? Бер генә әйберләренә дә кагылмыйм. Күреп кенә чыгыйк инде шул музыканы...

Ишектән Зәйтүнә апасы кайтып керде. Борынын сузып иснәнеп торгач:

— Нәрсә яндырдыгыз сез монда?— диде.

Нурия кызарды. Нәҗиягә күз сирпеп алды, тегесе бармагын иренеңә куеп, әйтмәскә боерды.

— Яндырмадык,— диде Нурия, тотлыгып.

Зәйтүнә апалары тәрәзә төпләрен, караватт асларын карады, галанка мичнең көлләрен актарып бетерде, нәрсә янганны аңламады. Канәгатьсез калып, өс-башын алмашырга кереште.

Нурия аңар баягы гозерен әйтте. Зәйтүнә апасы юка иренен кысып, сабыр гына тыңлап торды да, мәктәптә балалар өйрәткән көйле тавыш белән:

— Юк, иркәм, сорама да, ялынма да. Күрмәгән-белмәгән кешегә юк-бар йомыш белән керү кызларны бизи торган сыйфат түгел ул. Гомумән, андый уйларыңны башыңнан чыгарып ташла, гөлкәем, яме,— диде.

Нурия күңелсезләнде, боекты. Үз өйләрендә, Зартугайда чакта аның барлык гозерен берсүзсез үтәп килгәнгәдер, ике олы кешедән берьюлы отказ алу аңа авыр иде, бу аңа тормышның бик зур гаделсезлеге булып тоелды.

Шулай да ул музыка коралын күрү бәхетенә ирешә. Бер атнадан соң мәктәп укучыларын, яшьләре олыгая төшкән кызларны зур бер якты бүлмәгә музыка дәресенә дип алып керделәр. Шүрәле куллары төсле озын куллы, нечкә бармаклы Балантаев бүлмәнең аргы почмагында торган уентыклы, кырма аяклы, көзгедәй ялтыравыклы кап-кара өстәлнең капкачын ачып, аны, өй кыегы кебек итеп, таяк белән терәтеп куйды. Тагын бер кечкенә капкачын ачып, гармун телләре төсле аклы-каралы бармакларына басып, төрле-төрле тавыш чыгарды. Нурия баскан җирендә тора алмаслык булып, сикереп китәрдәй булып сөенде. Теге көнге авазлар нич бу. Кояш нурын, тамчылар тамуын менә нинди музыка коралы тудыра икән.

Балантаев тавышларның исемен до, ре, ми, фа, соль дип аңлатты. Бик тә сәер тоелды бу Нуриягә: имеш, ашый торган тоз да соль, тавышның исеме дә соль булсын. Кызык та соң дөнья хәлләре!

Тәнәфес вакытында ул Нәҗия Уразаеваны эзләп тапты. Тыны бетеп, бүгенге яңалыгын хәбәр итте:

— Менә, күрсәтергә теләмәгән идең, белдем инде, күрдем инде, әл-лә-лә, әл-лә-лә!

— Нәрсә белдең, нәрсә күрдең?

— Музыка коралын күрдем. Рояль дип атыйлар икән аны! Хәзер мин, теләсәм, атна саен, көн саен шул рояль янына утырып көй чыгара алам, дәрестән соң туйганчы рояль уйный алам!

Болары — Нажия апасына белгерткәне. Әле бит белгертмәгәне, күңелдә сер булып калганы бар. Солтан сугыштан кайтыр, Нурия рояль уйнарга өйрәнеп куяр. Ул аңа «Кара урман», «Иделкәем алкын» көйләрен уйнап күрсәтер, Солтан таң калып тыңлар, тыңлап кына калмас, аның музыкасына кушылып, рәхәтләнеп бер җырлап җибәрер. Менә булыр әкәмәт, менә булыр шатлык-сөенеч! Ул көннәргә тикле ерак әле, аларны Нурия хәзергә җанын җылытып торган матур бер өмет итеп күңеленең иң-иң түрендә генә яшәтә ала...

Киләсе ял көнендә Зәйтүнә апасы Нурияне Ибраһим Баяновларга алып барырга вәгъдә итте. Баянов Буби мәдрәсәсендә чакта Габбас мулладан сабак укыган икән, остазының кызын үзләрендә күрергә теләгән. Нурия кунакка бик теләп бармады, мөгаллимә апасының «чит кешегә керү кызларны бизәми» дигән сүзләре аның миенә сеңеп калган иде.

Чал кашлы, пенснелы Ибраһим абзый ошады аңа. Башкалар кебек чамасыз мактау сүзләре әйтеп Нурияне оялтмады, табын янында да олылыгы белән басып тормады, киресенчә, төрле мәзәк сүзләр әйтеп, барысын да көлдерде, чәйдән соң күңелгә үтәрлек итеп скрипка да сызып җибәргәч, Нурия аны гомер буе күреп, янәшә яшәгән туганыдай якын итте. Табигыйлек белән киң күңел кешеләрне чын итә шул.

Зәйтүнә апасы Нурияненң Баяновны үз итеп өлгерүен сизде, шуңа күрә әйтер сүзен тартынып-нитеп тормыйча әйтте:

— Сеңлебезнең бер һөнәре артырга тора бит әле, Ибраһим абзый. Нурия музыкага әвәс булып чыкты бит. Менә сез, тәҗрибәле укытучы, ничек карыйсыз бу эшкә?

Әйбәт карый икән укытучы: яратып баш какты, тиздән яшьләр өчен нардомда бальный танец кичәләре оештырылачагын, теләгән кешенең язылачагын белдерде.

Хәбәрнең монысы Нуриягә сөенеч белән бергә борчу да китерде. Аны алырлар микән? Аның буй-сыны танцы итәргә ярарлык микән? Әллә кызларның гәүдәсе, аяклары танцы өчен табигать тарафыннан махсус яратылган булуы кирәк микән?

Нурия соңгы елларда уйланучан булып китте. Мулла йортында бер төрле, авыл урамнарында икенче төрле мөхит белән очрашу, әнисе Шәмсенисаның аны дин-шәригать кануннары өйрәткәнчә яшәтергә тырышуы, ә хөррият чыкканнан соң башланган өр-яңа тормышның сиңең алдыңа үз таләпләрен китереп куюы — әледән-әле уйланырга, тормыш таләбе белән үз ихтыяҗыңны янәшә куеп карарга мәҗбүр итә иде.

Танцы өчен бик тә килешле дип таптылар Нурияненң гәүдәсен. Музыкаль слухына да яхшы бәя бирделәр, ритмы да тел тидермәслек иде кызыбызның, әмма... һай, шул «әмма» дигәне булмаса! Гөнаһ шомлыгы, бар иде шул «әмма» дигәне, әнә шул «әмма» дигәне Нурияненң кулаягын бәйләп куя иде. Бальный танцыларга өйрәнгән өчен акча түләргә кирәк иде. Әтисе килешерме шул хәл белән, әллә катгый рәвештә баш тартырмы?

Нәкъ шул көннәрдә Алабугага Габбас мулла килеп төште. Чыпталы кошовкага ул капчыгы белән бәрәңге төреп салган, поты белән бодай оны алып килгән, кызын үлеп тә сагынган, аның өчен борчылып килгән иде.

Нурия өйдә юк иде, әти кеше кызының хәлен Зәйтүнәдән бик төпченеп сорашырга кереште.

— Укуын әйбәт укый, аш-су кебегенә дә кулы ябыша, туганым абыстай бик тә йорт җанлы итеп, тәрбияле итеп үстергән сеңлемне,— диде мөгаллимә, иренен бөрештереп сүзсез торгач, янә дә сөйләп китте:— Тик менә... музыкага әвәс булып китте Нурияҗкәй. Пианино уйный, бальный танецка язылам дип йөдәтә.

Габбас мулла кызының ир-ат белән бергә кәҗә кебек сикергәләнеп йөрүен бер дә өнәми иде, тик каршы килсә, артта калган кара мулла икән дип әйтүләреннән курыкты, шуңа күрә кашларын җыерып, чыраен сытыбрак торгач:

— Соң... дәресләреңә зыян килерлек булмаса... йөрсен... — диде.

— Йөресен дип әйтү ансат аны. Ул бит түләүле, бушка өйрәтмиләр.

Габбас мулланың бу хәбәргә дә исе китмәде, чаларып килгән күк көрән сакалы эченнән үзалдына елмаеп:

— Соң тансы-мансы миңа кирәк түгел, Нурия белән сиңа кирәк, акча эшлисең бит, түләрсең, — диде.

Боларны тыңлап, тезне-тезгә чәнчеп утырган Нәҗия Уразаева, кыска итеп кистергән чәчен селки-селки, рәхәтләнеп бер көлде.

— Күрдегезме, буржуйлар безне нинди утыртты?! Ха-ха-ха! Кызын танцыга өйрәтергә теләмәгәч, тәки тапты бит җаен, ха-ха-ха! — Ул озаклап, күңеле булганчы көлде, аннары үтә дә чыккан җитди, усал чырай белән Габбас мулла каршысына килеп басты:

— Ничава, мулла абзый! Хәзер замана пыралитарьятныкы! Сез әле минем кулга бер төшәрсез, мин сезне сагайский биетермен! Шундый итеп биетермен мин сезне, үзегез акча түләп чыгып качарлык булырсыз!

Бу шул хәтле көтелмәгәндә килеп чыкты, Зәйтүнә мөгаллимә дә, Габбас мулла да сүзсез калдылар.

Тормыш үзенекен итте: Нурия усаллашып, үҗәтләшеп, рояль уйнарга, дөресрәге, ул кышны көй чыгарырга, теләсә кайсы егетнең күзен ут яндырырлык итеп танцы итәргә өйрәнде.

Нәҗиянең дә һөнәре арта төште: Зәйтүнә апасыннан яшереп тәмәке суыргалый торгач, ул ирләр кебек ботны-ботка куеп, тәмәке төтенен эчкә алып тартырга, җае чыкса аракы йотарга, урысчалап сүгенергә өйрәнде. Нурия өчен Нәҗия гомумән дә акыл ирешмәслек бер могҗиза иде. Әле күптәнмени, ул бит аның канатлы ал алъяпкычын ябып, ап-ак йон оекбаш белән тугызлыдан үргән чабата киеп йөргән чакларын белә, ул бит аның юашның да юашы чакларын күрә иде. Хәзер кара, өстәге кием заманча: блузка да итәк, кыска чәч тә тәмәке! Нәҗия теләсә кайсы малай белән сугыша ала, теләсә кайсы укытучы белән бәхәсләшә ала, ни генә эшләмәсен — һәр вакыт өстен чыга. Табигать биргән сәләте бик зур идеме, өйдә аның дәрес әзерләп сәгатьләр буе утырганын да күрмәссең, ә үзе гел мактаулы билгеләргә генә укып бара. Мәктәптәге иң зур эшләрне ул башлап йөри, Нурия һәм башка кызлар өстеннән ул атаманлык итә.

Нурияне иң-иң аптыраштa калдырганы шул: Нәҗия зарланмый. Баксаң-күрсәң, уку шартлары нинди авыр, укучыларны ашатыр өчен паек җитәрлек түгел, сыйныф бүлмәләрендә кышын биләй киеп утырган чаклары булды. Укучыларның күпчелек өлеше бик ябык, ике-өч кыз бергә килдеме, укуның кыенлыгыннан, ачлыктан, суыктан зарлана башлыйлар, Нәҗия килгәнне күрсәләр, шундук шып булалар, чөнки Нәҗия зарланып йөрүчеләрне «пыралитарьятның» явыз дошманы дип санап, эт урынына сүгә, кайчагында яңакларына менеп төшәргә дә күп сорамый иде.

Менә шушы батыр кыз, кызларның атаманы, язын агачларның каерылары кояш җылысын сизеп бүртә, яшелләнә башлагач, берәүгә бер сүз әйтмичә Алабугадан китеп барды.

Моңа бик сәерсенделәр. Сәбәбен эзләделәр, таба алмадылар. Мәктәп йорты тынды, моңсуланды, атаман кызның истәлекләре белән яши башлады.

Зәйтүнә мөгаллимә мәктәптә татар әдәбияты дәресе алып бара иде. Башта ул Галиәсгар Камалның байлардан көлеп язган шигырьләрен аңлатты яшьләргә, аннары мавыгып китеп, хәзер менә алар укый торган бинаның кайчандыр Епархиальное училище булуын, аны рус бояры атаклы Стахиевның салдыра башлавын, аннары, Стахиев үзе үлгәч, хатыны салдырып бетергәнлеген әйтте. Зәйтүнә мөгаллимә әйтер сүзен тәмләп, җиренә җиткереп әйтә белә иде. Шушы йортта кайчандыр, әле унбиш еллар элек кенә, руханиларның булачак хатыннары укып ятканны, Кама буйларын тетрәтеп кулында тотып торган Стахиевларның дәүләт терәге булган дингә никадәр зур ышаныч баглаганнарын сөйләп китте. Кызлар тын да алмый тыңладылар аны, малайлар да тыңлады.

Зәйтүнә мөгаллимә үзе алып барган дәресләрдә шаулап утырганнарын хәтерләми. Ә менә бүген әллә нәрсә булды. Бер минут эчендә сыйныфның асты-өскә килде, малайлар белән кызлар, һичбер рөхсәтсез, аяклы парталар арасыннан чыгып, тәрәзәгә ташландылар. Мөгаллимә аларны тәртипкә чакырып никадәр азапланмасын, берни булдыра алмады, дәшә-дәшә тамагы карлыккач, үзе дә түзмәде, сыйныф хәтле сыйныфны берьюлы кузгата алырлык вакыйга булганны карар өчен тәрәзә буена килде.

Килде һәм урамдагы тамашага хәйран калып, авызын ачты да ябарга онытты. Тәрәзә каршысында ук бик күп булып атлы арбалар туктаган, арбаларның әле берсеннән, әле икенчесеннән я кәрәк сакаллы поп төшә, яки чалма-чапанлы мулла язгы көпшәк кар өстенә коела иде.

Карый торгач, Зәйтүнә мөгаллимә дин башлыкларын үзенә буйсындырган кешенең кем икәнен дә күреп алды. Бу — Нәҗия атаман иде. Аның өстендә яшькелт бушлат, бушлатны ул яссы каеш белән буып куйган, каешка кара кабуралы наган таккан, аягына күн итек, башына бүрек кигән иде.

Барлык мулла-мәзинне, барлык попны-дьяконны арбаларыннан төшергәч, мәктәп тәрәзәсе буена тезеп куйды. Сафка тезелгәннәрнең каршысыннан йөреп чыкты, башларын иеп торганнарның башларын күтәрде, чатнап чыккан усал тавыш белән:

— Хир-р-р-но! — дип кычкырып үрә катырды, бер-ике, бер-икегә санатты, ике рәт итеп тезде дә мәктәп тирәли бер өч мәртәбә чаптырып әйләндерде, шуннан соң гына олауларына утырырга рөхсәт биреп, урман ягына таба алып китте.

Зәйтүнә мөгаллимә башка муллалар арасында абыйсы Габбас мулла да барлыгын күреп өлгерде, башта ул моңа хәйран калды, аннары Нәҗия атаманның чамадан тыш арттырып җибәреп, Габбас мулла кызы Нуриянең гайрәтен чигерүеннән курка башлады.

Әнә шул көннән соң мәктәп укучылары арасында Нәҗия Уразаеваның милиция эшенә кергәнлеге, укучылар салкында туңып утырмасын өчен Алабуга өязендәге поплардан һәм муллалардан унҗиде кешене җыеп алып килеп урман кистереп ятуы турындагы хәбәр таралды.

Нурия күңелендә Нәҗиягә карата ямьсез бер төен урнашты. Нәҗия аның әтисен, башкалар белән бергә, көн саен балалар сабакка җыелган чакны турып китереп, мәктәп тирәли йөгертеп кенә калмый, башка руханилар белән бергә салкын бер баракта асрый, кызы янына күрешергә дә җибәрми, үзе дә хәзер элекке фатирына кайтып күренми иде.

Габбас мулла бары тик ун көннән соң гына беренче мәртәбә Зәйтүнә мөгаллимәләргә килеп, кызы белән күрешә алды. Ул бәләкәйдән үк урман эшендә эшләп, дөньяның ачысын-төчесен һәм авыр эшләрен эшләп үскән булса да, бу юлы килә-килүгә урман эшенең авырлыгыннан зарланырга керәште.

— Бигрәк кансыз кеше булып чыкты бу Нажия! Сулыш алырга да ирек бирми бит, имансыз! Җелекләребезне киптерә. Көне буе урман кискәненә дә түзәр иең, бихисап сүгенә. Муллаларны мыскыл итеп тәмәке тарта, анысына да күз йомарыең, дингә тел тигезә, мәктәп балалары алдында, тиләләр йортына җыелган кешеләрне тинтерәткән кебек, мәктәп тирәли чаптырып йөри. Урманны бит аны динне мыскыл итмичә дә кистерергә була торгандыр...

Зәйтүнә мөгаллимә башта абыйсын сабыр гына тыңлап утырды. Габбас мулла тагын да җәелебрәк зарлана башлагач, аны кызганудан Нуриянең күзләренә яшь тулгач, түзмәде:

— Бүгенгә җитеп торсынмәллә, абый? Калганын икенче килгәндә зарланырсыңмәллә? — диде.

Габбас мулланың үлеп тә хәтере калды. Өйлә намазы укыйсы барлыгын да онытып, үзалдына каргана башлады. Ачу аның төер булып тамак төбенә менеп утырган, ярсудан тавышы кысылып, нечкә булып, вакыт-вакыт гыжылдап ук чыга иде.

— Совет динне мыскыл итәргә кушмый! Кушмый мыскыл итәргә! Әгәр сез мөгаллимә башыгыз белән шуны белмисез икән, Декретны укып карагыз. Гәзиттән кисеп алып, Көрьән эченә салып куйдым мин ул Декретны. Сезнең кеше җанында тукынырга, дин әһелләрен мыскылларга берегезнең дә хакыгыз юк! Юк! Без монда урман кисеп йөрибез икән, балалар суыкта утырмасынга кисәбез, балалар белемле булсынга.

Бу юлы инде Зәйтүнә мөгаллимә дә тыныч кына кала алмады, корт чаккандай чәчрәп урынынннан торды:

— Туктале, абый, торасың да дин дисең син, динне мыскыл итәләр дисең? Нәрсә, Нажия сезне намазлык өстеннән бәреп төшердеме? Әллә булмаса сәҗдәгә киткән чагында муен тамырыгызга наган терәдеме? Нишләп син, дин дигән булып, Декрет дигән булып, безнең илдә яшәгән теләсә кемнең хезмәт итәргә тиешлеген, ил авыр көннәр кичергән чагында аңа булышырга кирәклеген онытасың?

— Минме онытам?

— Әйе, син онытасың. Крестьян гомер буе атсыз тилмерде. Җирсез тилмерде. Казан губернасында революциягә хәтле 483 мең крестьян хуҗалыгы булган, шуның 158 меңе атсыз...

— Нәрсә син миңа сөйлисең боларны?

— Кемгә сөйлим соң, менә бу шкафка сөйлимме, миңа бер генә претензия дә белдермәгән галанка мичена сөйлимме? Серафима Нилованың әнә ирен үтерделәр, алай да зарланмый, тешен кысып яши бирә. Син әйтәсең, мине мыскыл итәләр дисең. Ә теге заманнарда халыкны ничек мыскыл иттеләр?! Халыкны хакка-нахакка күпме кыйнадылар! Аларны бит муллалар, поплар рөхсәте белән эшләделәр.

— Минем халыкны кыйнарга кушканым юк.

— Кыйнаган өчен каршы килгәнең дә юк.

— Каршы килгәне өчен әнә Даут мулланы тураклап үтерделәр.

— Шул-шул менә! Күбәләктәй газиз җаныгыз өчен кан калтырап яшисез. Ә халык җаны җан түгел сезгә, эт җаны. Шәкертне хәлфә кыйнады — дәшмәдегез, крестьянны староста таяк белән төйде — авызыгызга май каптыгыз, солдатны офицерлар нагайка белән суктырды — полк муллалары фатихасын биреп торды. Ник син ул чагында хакыйкать эзләмәдең, ә?! Бүген сезгә — Алабуга өязе муллаларына бер Нажия кычкырган, сезнең инде шуңар үләр чикләргә җитеп ачуыгыз килә, каннарыгыз кайный, ай-һай-һай, бар икән кадерле җаннар! Ә бит синең өстеңдә әйбәт тун, абзыкаем, башыңда җылы бүрек, аягыңда итек. Син өеңнән алып килгән туклыклы ризык ашыйсың. Ә безгә, халыкны агартучыларга, балаларның күңеленә мәгърифәт нуры салучыларга нәрсә? Ясмык кушкан чи арыш ипие, солы боткасы! Укучылар аны

чүпрәк боткасы дип йөртә. Синең кызың ул ашны ашамый. Син аңа әнә ике мәртәбә бодай оны алып килдең. Менә шулай, абыкаем...

Габбас мулла чал төшкән куе кара сакалын учы белән учлап, мөгаллимә сеңлесен ярсынып тыңлады, каршы сүз әйтмәде. Сүзләре бик саллы, дәлилләре каршы килерлек түгел иде шул.

Тагын ике атнадан урман кисү буенча үз өлешенә тигәнне бетереп, ул Зартугайга кайтып китте. Бик зур рәнҗү төяп кайтты җанына. Утыз чакрымнар кайткач, аның җирән биясе арыды, өшәнде, аңа атын күрше авылда калдырып, башка муллалар белән бергә җәяү кайтырга туры килде. Яшь чагында Буби мәдрәсәсенең суык бүлмәләрендә катып-туңып ятканга ул ревматизм алган иде. Дүрт-биш чакрым кайту белән үк аның аяклары йөрмәс булды. Муллалар, Саранбайлардан ат яллап, аны мең иншалла белән өенә кайтарып җиткезделәр. Шул көннән башлап Габбас мулла сеңлесе Зәйтүнәгә дә, башкисәр Нәҗиягә дә, аның хурлыгына шаһит булган кызы Нуриягә дә җанында рәнҗеш саклап калды.

## IV

Авыл башында зират. Зартугайлар читкә киткәндә дә, читтән кайтканда да зират буена туктап, күңелләрен ныгыталар: олыраклар дога кыла, яшьләр тын гына басып тора. Ата-баба йоласы шулай. Ничәмә-ничә буын Зартугайда гомер кичереп, бала-чага үстергән, йорт җиткезгән, табигатьтән үзенә тиешлесен алып яки алып бетерә алмыйча, күңеленә үкенечләр төяп, теге дөньяга китеп барган, ягъни менә шушында төп йортына, мәңгелек йортына күчкән.

Нурия йолаларга мөкиббән китә торганнардан түгел иде. Әмма шулай да ике ел Алабугада яшәп, совет мәктәбендә белем алып, елларның авырлыгын һәм төрләнеп торуын үз күзе белән күреп кайткач, ул да Зартугай зираты янында туктамый булдыра алмады.

Башка елларны күкрәп утырган зират быел күңелгә шом салырлык дәрәҗәдә үзгәргән: йөзәр яшьлек имәннәр, Зартугай әле кара урманнар арасына килеп утырган чаклардан бирле калган карагайлар шаулаптулышып утырмыйлар, аларның яфрагы сирәк, фәкыйрь ябалдашлы агачлар арасыннан бушлыклар, игене көйгән кырлар күренеп тора. Авылда ачлык. Егерменче елның кайнар җилләре болын печәнен, игентаруны ялмап алган.

Зиратның авылга терәлгән ягына килеп чыккач, күрде: зират капкасы төбенә көтүе белән халык җыелган, зур гына чуар төркем өзлексез кыймылдап, хәрәкәтләнеп тора.

Төркем янына җитеп сорашкач, белде: югары очның Рамазан картлар йортыннан берьюлы ике кеше үлгән: карт үзе, кече малае. Ябык чырайлы, сәләмә киемле кешеләрнең Нуриядә эше юк, юлда очраган Хәсбикамал Әптерие аңа шул хәбәрне әйтте дә үзе зиратка кереп китте.

Габбас мулла өендә Нурияне шаулап каршы алмадылар. Габбас мулла үзе үлгәннәргә ясин чыгарга дип, Хәнифә түти әтисе белән энесенең җеназасын күреп калырга дип югары очка киткәннәр.

Шәмсениса карчык авыл ярлылары гына кия торган ниндидер ала-ма-сәләмә киемнәр киеп, ишегалдында тавыкларга әчетке болгатып йөри иде. Капкадан кергән ят кешегә башта кулын каш өстенә куеп озаклап карап торды, аннары танып алып каударлана башлады: кулына тоткан кош табагын җиргә куярга да, тоткан килеш торырга да белмичә, арлы-бирле селкенә башлады, аннары нигез буена ыргытып, Нуриягә таба лаптыр-лоптыр килеп йөгерде, күлмәк итәгенә абынып егыла язып калды.

— Һай аллам, балакаем, син дә исәнмени әле дөньяда? Әллә ниткән төшләр күреп бетердем. Ике көннең берендә кеше үлгәнне килеп әйтәләр, ятсам да уйлыйм, торсам да уйлыйм, ниләр бетереп йөри икән бу бала, минәйтәм, ашарларына бар микән моның? Менә бит... зиһенем чуалып китте әле. Хәнифә түтәннең әтисе дә гүр иясе булды бит. Авыр туфрагы җиңел булсын, тилмерепләр дә үләргән диделәр бичаракайны. Ач үлемнәрне ходай язмасын, дусыңа түгел, дошманыңа да күрсәтмәсен...— Шәмсениса абыстай кинәт йомшап китеп балавыз сыга башлады, Нурия аны үз сүзләре белән үк юатуны кирәк тапты: «Сабыр, әни, сабыр».

Шәмсениса абыстай аны чәй куеп эчертте, үзенең бу ике елда бик тә картайганын, шушы корылыкның, ачлыкның бик теңкәгә тигәнен сөйләп китте.

— Җылап керә күрше-колан. Бер умачлык он сорап та, ашка салырлык бер бәрәңге сорап та керәләр. Яңа ашлыктан бише белән кайтарып бирермен дип гозерләнәләр. Бирмәсием — ачтан шешенгән кешеләрнең йөрәк бәгъреңә төшәрлек итеп карауларын күрү әҗәл белән бер, бирериең — үзеңә калмый. Әле бит киләсе елны да иген уңамы-юкмы? Аны бит сиңа берәү дә әйтеп бирә алмый. Ачлык бөтен Идел буена килгән. Бездән башлап Әчтерханга чаклы Идел буйлап әллә егерме, әллә утыз мельон кеше ипсисез, ди. Әтиең гәҗиттән укып әйтте. Сәвит хөкүмәте булышасы диләр диюен, Әмрикәдәнме, Франциядәнме эшче-крестьяннар Рәчәйгә икмәк җыясы диләр, аларныкын кем белә, әнә бит теге унсигезенче елларны да Әмрикә булышасы дип торганнарые, булышты бик, әллә ничә илдән гаскәр җибәреп, ярлысын-баен бергә өеп турап йөрделәр. Ходаем, бүтән күрсәтмәсен, адәмнең коты алынып беткән, бер нәрсәгә дә ышанмый хәзер, агы килде — агы таладьы, әллә ниткән кәмитетләр төзеп йөргәннәрие, алары булып алары талады, бездән генә нинәмә-нинә кат ашлык алып чыгып киттеләр бит инде... Ябраббым, бер ходаем, мәрхәмәтеңнән ташлама, без бичара инсаннарыңны ач итмә дип догалар кылам, тәңрегә ялварам. Кешекара керә-нитә калса дип алабута ипие пешереп куйдым, шуны ашатам, үзебезнеке дә юк икәнне тел белән аңлатып бирә алмаганга гаҗизлектән шулай эшлим. — Ул шакмаклы тастымалны сүтеп, кайрак кебек кара, таш кебек каты алабута ипиен Нурия алдына китереп куйды: — Менә, кабып карале, белерсең ни икәнен...

Нурия ипине әйләндереп-әйләндереп карады, тешләп кабып карады, уртын яман ачыттырып, авызында су җыелгач, үрелеп чәй уртлап куйды.

Рамазан карт җеназасыннан Габбас мулла кайтты. Иөзе — кара болыт. Ни дисәң дә Рамазан карт аңа баба тиешле кеше, Хәнифәне буй җиткереп биргән. Берәүне дә рәнҗеткән адәм түгел. Ничәмә еллар солдат хезмәтендә интекте, өй тулы кыз бала булып, җирсез интекте, инде менә бердәнбер ир заты (авыру-гарип булса да ир заты!) бу йорттан китеп барды. Болай булгач әби тиешле кеше Габбас карамагына кала бит әле. Амбардагы арышны бик чамалап тотасы булыр. Алабута кушып пешерергә кирәк. Иртәгә үк хатын-кыз затын өй эче белән алабута җыярга чыгарасы булыр. Бер бездән генә калмаган.

Алабута җыю дигәннәре алай бик ансат эш түгел икән. Саламы белән җыймыйча, орлыгын гына сыдырып җыйганга күрә, Нуриянең ярты көн эчендә бармак аралары суелып чыкты. Әнисенә зарланган иде, Шәмсениса абыстай тавышын әкренәйтеп:

— Сабыр, балам, сабыр, ачтан үлеп булмый бит инде, — диде.

— Амбарда арыш бар бит әле, — дип каршы төште Нурия.

— Тик кенә тор, күрсәтерләр арышыңны! Бу болганчык заманда авызыңа су кабып торганың мәслихәт. Аллам сакласын, арышың ба-

рын белеп алсалар, үтереп чыгарга да күп сорамаслар. Чистай ягында әнә бер пот он өчен өй эчләре белән суеп чыкканнар, ди. Жый әйдә, жыйн, безнең ашарга юкка ышансыннар...

Әле генә танцы кичәләрендә йөреп, нардомда спектакльләр карап, совет мәктәбендә укып кайткан кыз өчен бу сүзләр сәер иде, әнисенең дә, үзенең дә алдакчы булып чыгуларын уйлау Нуриянең күңелен кимсетә, гарьләндерә иде. Әмма ул кайткан көнне үк берьюлы ике кешенең гүр иясе булуын белү, ябыгудан коры сөяккә калган кешеләрне күрү аны дәшми калырга мәҗбүр итте.

Июнь ахырларында, авыл халкы ачтан кырылып бетү куркынычы алдында калгач, Әгерҗе станциясына кукуруз кайтканлыгын хәбәр иттеләр. Авыл саен, җан башыннан билгеләп, норма белән бирәселәр, имеш. Аягына басып торырлык булган, күтәрәмгә калмаган утыз бишләп атны авыл советы башлыклары гамәлгә кертеп, станцага барырга мәҗбүр иттеләр. Алар арасында Габбас мулла аты да бар: арбага Габбас мулла үзе түгел, яшь хатыны Хәнифә утырган иде.

Бу хәл олаучылар арасында мыскылчан сүз дә кузгатып алды. Башына ак киез эшләпә, өстенә өйдә суккан алача күлмәк, дәү төпле киндер ыштан кигән Хатамтай, мәңгелек мәзәкче, ышнада атларны үлән чемченергә җибәргәч, сиртмә арбасыннан төшмичә, битен яулык белән бөркәнеп, өйдән алып чыккан ипи кыерчыгын ашап утырган Хәнифәгә таба баш бармагын төзәде:

— Күрдегезме, яшь остабикә дә атка утырып йөри башлады, мин сиңайтим. Еллар иминләнергә, игеннәр уңарга булсын! Ә бит теге елларны Габделхәлим куписларга кунакка йөргәндә Габбас мулла янына Шәмсениса абыстай киерелеп утыра торганые. Кукуруз апкайтырга булгач, мин сиңайтим, нибуч, яшь корткасын чыгарган. Баксаң-күрсәң, алабута ипие биреп җибәргәндер әле, юкса, Хәнифәне әйтәм, карачкы кебек, битен-башын каплап утырмасые. Ах-ха-ха...

— Ярлы язмышы янаралга чыксаң да ялыныч инде ул, Хатамтай абзый. Мәрхүм Рамазан картның кызы муллага чыкты ни дә, юргага чыкты ни — барыбер ялчы булып гомер итәчәк.

— Шәмсениса остабикә дә хитри: хәзрәтенә яшь катын алам дип өенә асрау китертте. Өч бала тапты Хәнифә, өчесе тин гүр иясе булдылар. Әллә җүнне тормыштан дисеңме? Булмаган кая? Көне-төне кер юып, атка башак болгатып, ындыр табагы чаклы йортны алланың бирмеш көне утын белән ягып җылытып кара әле. Имгәнү түгел, әллә нишләп бетәрсең! Бер генә баласын да вакытында тапмый бит. Я корсак төшерә, я җитлекми туып үләләр.

Авылда аз сүзле булуы белән дан алган тугымчы Ямалтин шакыраеп каткан алабута ипиен тезенә куеп урталай сындырды да тешләп алып, авырдан гына чәйни башлады.

— Син ник дәшмисең? — диде аңа Хатамтай.

— Акыллы эшен бетерер, ахмак кәвешен эзләр, — диде Ямалтин, ипиен чәйни-чәйни.

Әгерҗедән кайтышлый, атлар арыгач, кукуруз капчыкларының күбесен мулла атына төяделәр. Башка атларның буш арба тартып кайтырлык кына хәлләре калган иде. Олаучылар инде үзләре дә эштән чыгып арыганнар, шуңа күрә аларның берсе дә мулланың яшь хатыныннан көлеп теш агартмый, һәркайсы үз уе белән, үз гаме белән мәшгуль, тизрәк өйгә кайтып җитәргә, тизрәк кукурузны киледә төеп, аның оныннан мөлдерәшеп утырган ач балаларга төче күмәч пешереп бирергә хыялланалар иде.

Җаннарга җылы бирерлек кайнар төче күмәч кирәк иде аларга.

... Ачтан интеккән, мәет чыккандай тынып калган авылда утырудан да күңелсез нәрсә бар микән? Бер ай эчендә Нурия эч пошудан ябыгып, олыгаеп киткәндәй булды. Моны әтисе белән әнисе дә сизеп алдылар. Нигә шулай икәнен төпченеп-төпченеп сорашырга тотындылар. Монысы инде Нурия өчен сүзсез саргаюдан да авыррак иде. Ул бит аларга: монда миңа күңелсез, сез бит миңа гомер юлдашы була алмыйсыз, дип әйтә алмый. Аның мәңгегә дип яраткан кешесе әллә кайларда йөри, аның өенә кайтканы да юк, кайда икәнен хәбәр иткәне дә юк. Әллә исән ул, әллә исән түгел. Монда сагыштан саргаеп ятканчы Нурия Казанга китәргә ният кылды. Ләкин ерак юлга ялгызы гына барасы килми. Алабугада чакта бергә укыган иптәш кызын үгетли алса әйбәт булыр иде дә, эттән дә ярлы гаиләдә беренче бала булып белем алган, инде Салагыш мәктәбенә эшкә дә урнашып бетә язган Кәшифәне әниләре Казанга җибәрерләр микән соң? Аннары Казан хәтле Казанга барасың икән инде, өс-башыңны да рәтләп китмичә булмас. Сугыш газапларыннан, ачлыктан интеккән илдә алыйм дисәң әйберсе дә юк бит әле аның. Кәшифә белән икәүләп, кеше-карага әйтми генә, ак йонны бик нечкә итеп эрләп, пардан кофта, пардан перчатка бәйләделәр. Нуриягә әнисенең озын кунычлы сары ботинкасы белән киеп йөрер өчен кара йон оекбаш та кирәк иде, анысын эшкә уңган Хәнифә түтәсе ике көн эчендә бәйләп өлгертте.

Нурия укырга китәргә җыена, әтисе дәшми йөри. Нурия аңлый аны, әтисе аны тагын, Алабугадагы кебек, юк-бар белән, уен-көлке белән, әртислек белән шөгыльләнер дип курка.

Нурия үзе дә икеләнә башлады. Әллә китмәскәме? Чыннан да! Калада аңа ни калган? Салагыш мәктәбенә укытучылар җитми, озакламый Зартугайда да мәктәп ачылыр, диләр. Әгәр Нурия ата-анасы янында яшәп, балалар укытса һәм... сабыр гына көтсә?

Казанга китмәү, Зәйтүнә апасы кебек мөгаллимә булып авылда калу уе көннән-көн күңелендә ныграк берегеп барган бер вакытта аның уй-фикерләрен челпәрәмә итеп ташлаган бер хәл булды. Салагышка Казаннан укытучы булып кайткан Мәрхәбә, аны өйләреннән шыпырт кына чакырып чыгарып, лапас күләгәсендә бер хат тапшырды.

Хат гади бер кәгазьгә төрелгән, тышында берниндн дә язуы юк иде. Нурия бик каушап ачты аны. Ачты да, йөрәгенең тамак төбенә үк килеп җиткәнен тоеп, сулыш ала алмыйча, хатны күкрәгенә кысты. Хат аңардан иде: исән икән, дөньяда бар икән бит аның Солтаны!

— Сиңа ни булды? — диде Мәрхәбә, аның йөзе тораташ булып катканын күреп.

— Бер ни дә... булмады... — Нурия сүзләрен көч-хәл белән әйтеп, очкылык тоткандай икылдап елап җибәрде.

Мәрхәбә хатны тотып карамакчы булып аңа таба үрелде, әмма Нурия хәл алып өлгергән иде инде, кулны пешерердәй кайнар хатны учында кысып тоткан көе, ул үзләренең югары бакчасына йөгерде. Мәрхәбә аның артыннан калмады, укытучы булып, балалар укытырга кайтса да, кызларга хас кызыксыну, белергә теләп ашкыну хисе аңарда да бар иде.

Бакчаның иң аргы почмагына узып, берәү дә күрмәслек куе ябалдашлы сәрби куагының төбенә утырып, башларын-башка куеп, хатны икәү бергә укыдылар. (Шундый сөенечле хат китергәне өчен Мәрхәбәгә дә укырга рөхсәт итте Нурия!)

Солтан Казанга кайткан, рабфакка укырга кергән. Колчак гаскәрен нәҗес пумала белән Япон диңгезенә себереп төшергәч, Солтанга

анда эш калмаган. Сугышта булу, үлем белән кара-каршы очрашу аның күзләрен ачкан. Ул Нурияне сагынуын, яратуын, күрәсе килүен әйткән. Элекке үпкәләрен инде онытып бетерә язган. Укымыйча мулла йортында мәхдүмә булып кына калырга уйлый күрмә тагын, дигән. «Мәхдүмә» дип төртеп әйткән сүз Нурияне гарьләндереп куйса да, сагынып һәм үз итеп язган хат аны сөендерде. Күрәсең, бу сөенеч йөзенә бәреп чыкты бугай, Мәрхәбә аны утырган җиреннән үрелеп кочаклады, әкрен генә чайкалган көйгә:

— И дә бәхетле кеше син, Нуриякәем! Миңа сугыш җирләреннән шундый хат язучы булса... — диде.

— Нишләр идең?

— Минме? — Мәрхәбә дусыннан аерылды, сипкел баскан матур битен балкытып яшькелт күзләре җемелдәштеләр, куллары канат булып югары күтәрелде, матур тыгыз күкрәкләре шалкан кебек калкып чыктылар. — Минме? Аксагыз таулары башына менеп бер кычкырыр идем...

— Нәрсә дип?

— Хатны миңа язмаганнар шул, — диде Мәрхәбә, кулларын түбән төшереп. — Миңа язсалар, кычкыра белер идем мин... — Һәм авыр итеп бер көрсенде.

Нурия аны яратып, якын итеп көлде, аннары кинәт моңсуланып калды.

Ул көннән-көн буе Солтанга хат язды, язган бер хатын ерта барды. Хатның берсе дә аның күңелендә скрипка кылыдай чыңлаган үзәк өзгеч сагышны әйтеп бирә алмый иде. Адәм баласының телендә мәхәббәтнең бөеклеген, сафлыгын әйтеп бирердәй сүзләр яралмаган әле. Хисләрен әйтеп бирә алырдай сүз табудан гаҗиз калгач, ул бүген үк Казанга чыгып китү, Солтанның Казан урамнарыннан атлап баруын күз кырые белән генә булса да күрү хакында хыяллана башлады. Солтанны ул солдат итекләреннән, яшькелт гимнастеркадан, кызыл йолдызлы, очлы башлы шлемнан итеп күз алдына китерде. Кызыл гвардияче Солтан кызу-кызу бара. Зәңгәр күзләре тагын да зәңгәрләнебрәк балкыйлар. Барган уңайга җебеп киткән борынын тартып-тартып куя, ә үзе Нурияне уйлап сагышлана. Нурия аяк очларына басып килә дә аның күзен каплый. Солтан ялт итеп борыла: Нуриякәй-Нөркәй, синме бу? Күземә генә күренәсеңме?

Үзе уйлап чыгарган әнә шул гүзәллектән Нуриянең йөрәге кысыла. Һәм ул, Казанга китү көнен якынайтырга теләп, Кәшифәләргә йөгерә. Ике дус ашыгып-каударланып өс-башларын рәтләргә, зур калада кирәк буласы язу-сызу әсбапларын хәстәрләргә керешәләр.

Кешеләргә сөенеч китерүдән ямь таба торган Мәрхәбә тагын килеп җитә, Нурияне өйләреннән урамга чакырып чыгарып, өр-яңа хәбәр әйтә: аның әтисе Ибраһим Баянов Алабугадан кайткан. Ул хәзер укытучылык эшендә эшләмәячәк. Аны Казанга Җир эшләре халык комиссарының урынбасары итеп алалар. Нарком урынбасары. Ул кечкенә кеше булмаска тиеш! Әгәр онытмаган булса, ул Нуриягә ярдәм итә ала. Нурия аларда бер генә мәртәбә булды шул, анда да әле Зәйтүнә апасы кыстаганга гына барды. Ибраһим Буби мәдрәсәсендә әтиеңнән гыйлем алган кеше дигәнгә күрә генә... Онытты микән, юкмы?

— Син нәрсә тынып калдың? Әллә минем әтинең нарком урынбасары булуы ошамыймы? — диде Мәрхәбә, авызын турсайтып.

— Кара әле, дусым, әгәр мин сезгә барсам, Ибраһим абый, мине дә Казанга алып бар әле дип сорасам, ул бик уңайсыз булыр микән?

— И шушының бер! Җыен тузга язмаганны уйлап чыгара да тора. Нәрсәсе авыр булсын инде аның, я? Син бит минем әтинең муенына атланып бармыйсың.

Икесе дә чыркылдап көлештеләр. Нурия Мәрхәбәләргә бүген кинчкырын кереп чыгарга булды. Хәзер үк нярел китмәве әрсез булып күренмәскә тырышудан иде.

Ышлафырлы яшел күлмәген, әнисеннән алган озын куныччлы сары ботинкасын киеп, чәч толымнарына чулпыларын такмыйча гына (совет чыккач андый нәрсәләрнең модасы бетте!), Баяновларга китте.

Баскычтан йөгерә-йөгерә менде. Ишек шакыды — җавап бирүче булмады. Көтеп торды, тагын шакыды. Мәрхәбәнең әнисе, яулыгын тамак астыннан китереп бәйләгән кырык яшьләрендәге хатын, ишектән килеп чыкты, кулын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә:

— Бәрәкалла, нишләп ишек дөбердәтеп торасың? Ачык бит ул! Әйдә, апаем, әйдә, түрдән уз, Габбас хәзрәт кызы түгелме соң син? — диде.

— Шул ием шул, Маһинур апа... Ибраһим абый кайткан икән, шуны ишетеп килгән идем. Озак тормам мин, йомышымны гына әйтәм дә...

Маһруй җиңги почмак якка таба барылып:

— Әтисе, сиңайтәм, йомыш белән килгәннәр, — диде.

— Исәнмесез, Ибраһим абый, — диде Нурия үзенә таба килгән озын буйлы ир кешегә.

Ибраһим Баянов буй-буй сызыклы ак күлмәгенең сәдәпләрен каптыра-каптыра килеп житте, ул чит-читләре ярты күмәч кыстырган төсле кабарып чыккан яшькелт галифе чалбардан, җиңел чүәктән иде. Үзен бик тыныч тотып:

— Исәнме, апаем, — дип, авыл гадәтенчә, ике куллап күреште. — Миндә йомышың бар идемәллә?

Нурия батырлыгын җыеп, бер әйтүдә пулеметтан сиптергән төсле сүзен сибеп ташлады.

— Мин быел Казанга укырга бармакчы булган идем. Сезне дә Казанга барасыгыз бар икән дип ишеттем. Мине үзегез белән алып китә алмассызмы дип килдем.

— Сез кем буласыз әле? — диде Баянов, күзләрен зуррак ачып. Аның чал кергән кашлары югарырак күтәрелде.

— Мин... танымыйсыз мәллә? Мин бит Габбас Уразаев кызы булам, Зәйтүнә Уразаева сеңлесе. Ул мине сезгә алып барган иде, Алабугада чакта...

— Нуриямени? Бәрәкалла! Сез ике елда бик үскәнсез, чибәрләнгәнсез дә дип әйтимме? — дип, ул Нуриябе бик оялтты, аннары Нуриянең җилкәсеннән әдәп белән генә алып, өстәл янына китереп утыртты, үзе аның каршысына ук килеп утырды:

— Без, әлбәттә, сезне алып барырбыз. Мин бит әле үзем генә түгел, Казаннан кайткан энем Габидулла белән аның хатыны Нурҗиһан Алабугада калдылар. Сез, алайса, иркәм, егерме бишенче августтан да соңга калмыйча, Алабугага килеп җитегез, шуннан без бергә-бергә оешып Казанга сәфәр кылырбыз.

Нурия пружина кебек җыелды, сүзен әйтә алмый чак кына тотлыгып торгач, янә дә пулеметтан сипкән төсле бер тын алуда әйтеп ташлады:

— Ибраһим абый, минем белән бергә Кәшифә дә барсын әле.

— Кем соң ул Кәшифә?

— Бик якын дусым ул минем. Түбән очның Сәлимәттәй кызы.

— Әтисе кем?

— Тугымчы Ямалтин.

Баянов чал кергән кашларын тагын бер мәртәбә түбән төшереп алды: күрәсең, хәлне бизмәнгә салып өлгерде.

— Ярар. Барсын. Алырбыз. Башка дусларың юктыр бит инде?

— Юк, Ибраһим абый, башка дусларым юк. — Баяновның ышанмыйчарак карап торганын күргәч, борын канатларын киереп, ярсынып өстәде: «Валлаһи газим юк, ипидер!»

Баяновлардан чыккач, Нурия җәлт-җәлт атлап, Кәшифәләргә китте. Күңеле аның түгәрәкләнгән, хисләре Казандагы «берәү» белән барып тоташкан иде, әнә шул аны җәлт-җәлт атлата, дөньяны гел япякты төсләрдән генә торгандай якты итеп, матур итеп күрсәтә иде.

Каравыл өе янында, койма аша үрелеп, миләш яфрагы өзеп торган коба сыерның сыртыннан сыйпап узды. Каравыл өенең корыган каенында кара каргалар колак тондыргыч каркылдашып калдылар. Нурия аларга торналар озаткан чактагы кебек матур итеп кул болгады. Өй нигезендә комда аунаган тавыкларны ике якка чәчеп, Кәшифәләр чоланына барып керде.

Кәшифә өйдә иде, кулдан гына күлмәк итәге бөгеп утыра иде. Дусын күргәч, ашыкмый гына торды, килеп, кабартма кебек йомшак, җете ак кулы белән Нуриянең ике кулыннан тотып алды:

— Килдеңме? Кайчан кузгалабыз?

— Егерме бишенче августтан да соңга калмыйча Алабугага барып җитәргә! — дип кенә сүз башлаган иде, почмак яктан башына яулык өстеннән мескен бүрек киеп куйган Сәлимәттәй килеп чыкты:

— Ул ниткән сүз ул «кузгалабыз»? Син, мәхдүмә, Кәшифәне бик кыстама, ул бара алмас быел.

Нуриянең башына кусәк белән китереп ордылармыни! Ул лып итеп букәнгә утырды. Үпкәләгән тавыш белән, көйле итеп, бераз гына артистланыбрак:

— Нишлә-ә-әп инде, Сәлимәттәй? Җибәрермен дигән идең бит? — диде.

— Атасы Ижауга китте, забутка. Минем рөхсәттән башка кыз баланы бер кая да чыгарасы булма, ишетсен колагың, матри, диде. Шулай дип боргычлап куйганнан соң да... юк, мәхдүмә, кыстама.

— Туктале, Сәлимәттәй, бу ничек була инде бу? Мин бит Кәшифәгә ышанып...

— Ике абыйсының берсе әрмедән кайтканы юк. Өйдә мин япа-ялгызым нишләрмен?

— Син, Сәлимәттәй, бик өзеп әйтмә әле, — дип, Нурия аның җаена ятып, барлык артистлык сәләтен эшкә җигеп сөйли башлады: — Мин бит синең үзеңә кыен буласын беләм, мин барысын да күреп торам. Әмма дә ләкин мулла булып мулла, дин башлыгы бердәнбер кызын калага укырга җибәргән чагында, Ямалтин абзый каршы килмәс. Ю-у-ук, каршы килми. Киләме соң! Бу елларны бит аның ашарга табуы да асат эш түгел. Анда безне пайоктан өзмиләр, ай саен онын, ярмасын бирел торалар. Хәзер бит замана көчленеке түгел, укыганныкы! Аннары бит без ике кыз бала икебез генә китмибез, Казанда түрә булып бик зур урында утырган Ибраһим абзый алып бара бит безне.

— Кайсы Ибраһим? Баяннар Ибраһимын әйтәсеңме? Ул бит Алабугада не түгелме соң? Мөгаллим диләр бит аны...

— Казанга күчергәннәр, түрә итеп, үзем алып барам, үзем укытам дип тора лабаса! Беләсеңме, Сәлимәттәй, бу ачлык заманда, бер генә кышны үткәреп җибәрсәк тә...

— Белмим инде, җибәрсәм үземә кыен, җибәрмәсәм, кыз баланың үпкәләп куюы бар... — дип авыр сулады әни кеше, бу инде аның килешүе иде.

Тагын бер атнадан Габбас мулла аларны ат белән Пәнҗәр пристанена хәтле китереп куйды. Пароходның кайчан килере билгеле түгел иде. Пристань буендагы бәләкәй генә йортта төн кунып, икенче көн-

нең азагында гына, авыл советыннан алган белешмәләрен күрсәтеп, Алабуга пароходына көч-хәл белән эләгә алдылар.

Пароход шыплап тутырылган иде.

Капчыклы, әрҗәле, сакал-мыеклы, караңгы чырайлы кешеләр урын өчен талашалар. Әрҗә-капчыклары өстенә чүмәшергә өлгергәннәре гырлап йоклап ук киткәннәр, эләгә алмаганнары дөнья бетереп сүгенәләр; тозлы балык исе, иегән күн исе, адәм тире исе, тагын әллә ниткән исләр барысы бергә кушылып, борыннарны ярып керә иде.

Нурия белән Кәшифә алмашырга бер кат кием һәм юл ризыгы салган кәрзиннәрен күмер капчыклары өстенә куеп, усал чырайлы сәләмә кешеләр арасына кереп кысылдылар.

Пароход, көпчәкләрен шапылдата-шапылдата, үзе артыннан күбекләнеп кайнаган ак су калдырып, алга үрмәләде. Пароход артыннан, әчы чыелдап, балык аулаучы акчарлаклар көтүләре белән иярeп бардылар...

Алабугадан Казан пароходына күчеп утыргач, юл мәшәкатьләре бераз гына булса да онытыла төште. Ибраһим абзыйның наркомзем язулары ярдәм иттеме, чаларган кашлы олы кыяфәте пароход башлыкларына ошап куйдымы, аларга кеше дынгычлап тутырылмаган өске каттан урын бирделәр. Ибраһим абзый белән Габидулла абзый, тавышланырга яратучан Нуржиһан җиңги укырга баручы кызларны кешегә санап, үзләре белән тамак ялгап алырга чакырдылар. Табындагы ризык бик аз күренә иде, безнең кызлар ризыкка үрелергә кыймадылар, үз капчыкларын чишәргә уңайсызландылар, ә менә Габидулла абзый колачына көчкә сыярлык карбыз күтәреп кереп, кызларны сыйлый башлагач, тартынып тормадылар. Мондый затлы ризыкны күптән күргәннәре юк иде.

Габидулла абзый карбыз тураган чакта пычагын кыеграк ышкып, бармак битен әләктереп алды. Нуржиһан җиңгигә шул җитә калды.

— Әллә бер дә кызлар күргәнең юкмы? Иплебрәк кылансаң булмыймәллә? — диде. — Нәрсә монда карбыз кисәсе урында бармагыңны кисеп утырасың?

Бу хәл Нурия белән Кәшифә күңелендә бик уңайсыз тойгы калдырды. Шуңа күрә алар, Казанга җитеп, Нуржиһан җиңгиләр йортына кергәч тә ишек төбеннән узмыйча хуҗаларны аптыратып бетерделәр. Нуржиһан җиңги күтәрелеп-бәрелеп тиргәргә дип чыккач, ботинкаларын парадныйда ук салып, оекчан килеш, аяк очы белән генә басып, түр якка уздылар.

Иртәгесен Ибраһим абзый кызларны партия өлкә комитетына алып барды — ишек төбендә басып торган мылтыклы солдат, кызларның белешмәләрен карап, аларны Баянов белән бергә кирәкле бүлмәгә озатып җибәрде.

Өлкә комитетында аларга фармшкола, пединститут, университет янындагы рабфакны тәкъдим иттеләр. Ибраһим абзый кызларны рабфакка күндерде.

Командировка язуларын күтәреп, тере тиен тоткандай сөенеп, кызлар Нуржиһан җиңги янына кайттылар.

Бүген Нуржиһан җиңгиләренең йөзе якты иде, кызларны ул берәмберәм күкрәгенә кысты, күкрәге аның, килеп капланган чакта, тын бетәрлек дәрәҗәдә зур иде.

— Сез, кызлар, болай итегез: Грузинский урамыннан түбәнрәк төшегез дә Кызыл Армия йортын табыгыз, аннары трамвай юлы белән барып, тар бер тыкрыктан Воскресенский урамга менеп китегез. Бик күп баганалы, урам буе сузылган ак йорт булыр. Нивирситит дигәннәре шул инде. Ишегалдына кергәч, «Рабфак кәнсәләре кайда» дип сорарсыз.

Кызлар ярар дип риза булып чыгып киттеләр, ләкин күпме эзләсәләр дә, университетны таба алмый кайттылар.

Нурҗиһан җиңги ике мәртәбәсендә дә аларны ачуланмады, бүген аның кәефе яхшы, йөзе елмаюлы иде. Борыны янындагы миңе дә кызларга әллә ничек сөйкемле тоела иде. Икенче мәртәбә чыгып китте кызлар. Бактың исә, алар Грузинский белән барып Рыбнорядскийдан арырак төшеп китәләр дә, университетны урталыкта калдырып, Проломныйдан туп-туры Грузинскийга чыгып, саташып йөриләр икән. Кешеләрдән сорасаң: менә алга таба, менә сулга таба, менә артка таба дип өйрәтеп җибәрәләр. Казан каласына беренче мәртәбә аяк баскан кешегә «алга таба» ни дә, «артка таба» ни — каян белсен аны!

Әйләнчек сарык кебек әйләнеп йөри торгач, биек бер койма буйлап Воскресенский урамына менә башладылар. Инде шактый арыдылар, табасы килә рабфакны!

Кемдер Нуриянең битен каплап алды, кыз чырыйлап кычкырып җибәрде. Күзен ачса... каршысында, авызын колагына хәтле җәеп, Солтан басып тора. Ул нинди үскән, тазарган! Әле кайчан гына ул Нуриядән тәбәнәгрәк иде шикелле. Ике ел эчендә... Күр әле бер! Сары каеш, гимнастерка, галифе чалбар, күн итек нинди килешә аңа!

— Я, нигә телсез калдыгыз? Исәнмесез, Зартугайлар! — диде Солтан, калынаеп киткән тавыш белән. Ул, үзенең шундый зур һәм таза булуыннан уңайсызлангандай, кулларын чалбар кесәсенә тыккан килеш, җилкәләрен җыерып куйды.

— Әйдә, булмаса күрешик,— диде Нурия, кызарып.— Бәлки син инде авыл кызлары белән күрешергә дә теләмисеңдер.— Солтанның җанын кайнар бер дулкын яндырып алды. Ул кызларның икесе белән дә ике куллап күреште, икесен бергә үзенә тартып китереп, җилкәләреннән кочаклады да, күңел түреннән чыккан рәхәт бер куе тавыш белән:

— И сагындым да соң үзегезне! — диде.

Ул, әлбәттә, Нурияне сагынганын әйтергә теләде, тик әдәп кагыйдәсенә буйсынып, «үзегезне!» дип әйтте.

Нурия мөлдерәмә тулы хисләрен түгеп җибәрүдән курыккандай, телсез калды. Аның өчен Зартугай хәлләрен Кәшифә сөйләп бирде.

— Садыйк абзый каргана. Синең Зартугайга кереп тә тормыйча Казанга китеп баруыңны яратмаган. Мин аңар төп йорттан бер казык та бирәчәк түгел, ди, мин аны браматлыкта йөрергә дип үстермәдем, ди, Шәяхмәтнең азар-бизәр килеп йөргәне дә бик җиткән, ди...

Солтан Кәшифәнең көйле йомшак тавыш белән туктаусыз сибеп торган сүзләрен, үзе өчен ямьсезлектән бүтән берни дә китермәгән сүзләрне көч-хәл белән тыңлап бетерде дә:

— Ярый, кызлар, мин сезне рабфакка тикле озатып куйыйм да йөгерим, мине наркомземда Ибраһим Баянов көтеп тора! — диде.

— Ибраһим абзыйга бездән сәлам әйт, Казан каласына безне ул алып килде, обкомга да ул алып барды... — дип Кәшифә янә дә көйле тавышы белән тезеп китә башлады. Солтан аны шул урында кырт кисеп:

— Ә син, Нурия, минем хатны алдыңмы? — диде.

Нурия баш селкеде, керфекләре тетрәнде.

Солтан аларны университет ишегалдына кертеп, рабфак канцеляриясенә кадәр озатып куйды, икесен бергә кочаклап саубуллашты, аннары солдатларча кырт борылып, таза нык адымнар белән китеп барды.

Нурия кинәт тынып, моңсуланып калды.

— Нәрсә син әвене янган адәм кебек торасың? — диде Кәшифә.

— Без бит Солтанның адресын да сорамадык.

Кәшифә әкрен генә көлде:

— Яратуы чын булса үзе эзләп тапсын! Кызлар горур булырга тиеш!

Нурия каршы сүз әйтмәде. Алар гаризаларын, командировка кәгазьләрен канцеляриягә кертеп бирделәр. Кичен рус теле белән арифметикадан имтихан тапшырдылар. Кәшифәнең рус теле бик чамалы иде, Нурия янында ул да узды. Гомуми торак булмады. Рабфакның хуҗалык эшләре мөдире, кабарынкы мыеклы, куе тавышлы украин Спивачук сөлге буе исемлектән әле берәү дә кермәгән фатир табып, аларны Воскресенский урамындагы Пассаж дип йөртелгән йортка алып китте. Кызларга алтынчы катта түгәрәк тәрәзәле, чолан сыман гына бер бүлмә кисәге эләкте. Комендanттан ике тимер карават, әченә салам тутырган матрац алып, олаучы бер карттан кайтартып куйдылар. Олаучы ике караватны, ике матрацны берьюлы аркасына күтәреп, алтынчы катка тикле меңгезеп куйды — бер генә мәртәбә дә тукталмады.

Икенче көнне кызлар сөенечләрен әйтергә дип Нурҗиһан җиңгиләренә йөгерделәр. Алар аның тавышланырга яратса да, нечкә күңелле, ярдәмчел кеше икәнен белеп алганнар иде инде.

Чәй янында Габидулла абзый бик җитди кыяфәт белән:

— Әллә булмаса, Нурҗиһан, син дә рабфакка укырга керәсеңме? Теләк булса, сиңа да командировка алып була бит, — диде.

Нурҗиһан җиңги башын артка ташлап, кычкырып көлеп җибәрде.

— Син нәрсә, әтисе, әллә миңа Кәшифәләр, Нурияләр белән бергә букча күтәреп, тырык-тырык нивирсититкa чабарга кушасыңмы?!

Нурҗиһан җиңгинең үзен бик югары куеп, өстән карап сөйләшүе кызларга ошамады. Рабфакта төрле халык укый: үсмерләрдән башлап, олы яшьтәге хатыннарга, сакаллы абзыйларга чаклы бар. Язучы Фатих Сәйфи хатыны Абруй Сәйфи, кайсыдыр наркомның хатыны Сабирова, яшь язучы Ахшамов белән аның йомшак табигатьле, сөйкемле хатыны Галия ханым — барысы да рабфакта. Нурҗиһан җиңги җәелеп көлеп утыра икән, бары тик... заманны аңлап җиткермәгәнгә, ире канаты астында булганга гына көлә. Шулай да кызлар Нурҗиһан җиңгине бер юлга гафу иттеләр: ул бит әле аларны Казанга алып килде, ул бит әле аларны беренче көннәрендә үз фатирына сыендырып асрады, ул бит әле аларга «нивирсититның» кайда икәнен өйрәтеп җибәрде. Чынлап торып уйласаң — шәп кеше ул Нурҗиһан җиңги!

## VI

Пассажның алтынчы катындагы чоланда салкыннар башлануга яшәрлек әмәл калмады. Күпме генә яксаң да, анда җылы тормый, берике сәгатьтән ул салкын ат абзарына әйләнеп кала иде.

Кәшифә белән Нурия кышны уздырып җибәрердәй урын эзләргә тотындылар. Нурия Алабуга кызы Таһирәне очратып, Казанда музыка техникумы барлыгын белеп алды. Халык мәгарифе комиссариатыннан (ягъни Габидулла абзыйдан) командировка сорап, музыка техникумына килде. Яше олырак иде Нуриянең, музыка техникумына егерме ике яшендә түгел, бик күп иртәрәк керергә кирәк иде, әмма композитор Солтан Габәши тәкъдиме белән Нурияне кабул иттеләр. Нурия Пассаж түбәсендәге гүр суыгыннан әнә шул техникумның тулай торагына күчеп котылды. Кәшифәне дә урамда калдырып булмый бит. Аны Шәрык академиясе рабфагында укыган авылдашлары Солтан Айдаров белән Имам Каһарманов үз яннарына сыендырдылар. Икесе дә гражданнар сугышы фронтларында йөреп кайткан, дөньяның ачысын-төчесен татыган бу кешеләр, озын-озак уйлап тормастан, бүлмәнең бер почмагына ширма корып куйдылар да тугымчы Ямалтин кызы шунда көн күрә башлады. Нурия аңардан үлеп тә көнләште: ул көн саен, сәгать саен

Солтанны күреп торачак, аның белән сөйләшә алачак. Нуриягә булсын иде шул бәхет!

Кәшифә күчмәсен, мин күчәм дип барып булмый шул.

Музыка техникумының торагына, кичерәк кенә бер бүлмәгә дүрт кыз: Нурия Уразаева, Фатыйма Чапдарова, Алабуга кызы Таһирә һәм арада иң моңлы бала — җырчы кыз Гөлсем Сөләйманова туры килделәр. Алабуга кызы Таһирә кеше белән аралашуга бик әллә ни әвәс түгел — аның үз уе үзе белән; Фатыйма кияүгә чыгарга җыенып йөри — аның да үз мәшәкате үзенә җиткән; Нуриягә хәзер иптәш булып, сер уртаклашырдай дус булып Гөлсем Сөләйманова торып калды. Гөлсем — үтә дә беркатлы, әчкерсез кыз икән, беренче күрүдә үк ул Нурияне үз итте, зур авыр толымын кулына тотып карап:

— Ничек үстердең, Нурия җаным, бу хәтле чәчне? Әллә чишмәләрегезнең суы бик әйбәтме? — диде.

— И-и-и, кем инде аны үстерәм дип үстергән,— диде Нурия,— Хәнифә түтәй бар безнең, әтинең яшь хатыны, шул көн саен тарап, көн саен үрә торган иде.

— Әтиең бай кешемени?

— Мулла.

— Син, алайса, аны, җан кисәгем, миннән башка берәүгә дә әйтмитор, яме. Бу дөньяның кеме юк — яхшысы бар, яманы... Алла сакласын, рабфагыңнан да, техникумыңнан да чыгарып ташларга күп сорамаслар...

Гөлсем Сөләйманованың әйткәннәре дөрескә чыкты.

Ләкин ул иң әүвәл рабфак яки музыка техникумы җитәкчеләре тарафыннан түгел, нәкъ менә Нурияләр белән бергә укыган рабфакчы Галләмов тарафыннан эшләнде һәм Нуриянең күңелендә ямьсезлеге белән мәңге төзәлмәс бер яра булып сакланып калды.

Галләмов дигәннәре Зартугайдагы мәктәп-мәдрәсәдә шәкертләрне кыйнап, кансызлыгы белән дан алган Нух Галләм иде. Ул ак офицерлар белән бергә Шәрифҗанны җәзалап үтерүдә катнашканнан соң, ак генераллар Кама буйларыннан табан ялтырата башлагач, заманаларның ул көтмәгәнчә үзгәреп китәчәген сизенеп, кызыллар ягына авышкан, әүвәлгечә үк кансызлык белән акларны турарга тотынган һәм, совет власте өчен кан коюы турында документ юнәтеп, Казанга кайткан, университет рабфагында иң дәрәҗәле кеше булып, күкрәк киереп йөри иде. Әнә шул Нух Галләм башта, дәрестә утырган чакларда, Нуриягә язу язып аптыратты, тора-бара хатлар яза башлады. Хатларында ул Нуриягә үлеп тә гашыйк булуын, аңардан башка тора алмавын, аңа өйләнергә теләвен, әгәр Нурия аңа кияүгә чыгарга риза булмаса, урлап Ташкент якларына алып китәчәген яза иде.

Нурия җор табигатьле, мәзәк уйлап чыгарырга, артистланырга оста кыз, башта хатларны үзе укый, аннары көлә-көлә Гөлсемгә укыта, аннары Нух Галләм булып кылана башлый: борын астына бияләй теккәннән калган тире кыйпылчыгын ябыштырып куя, чәчне колак яныннан күпертеп чыгара, кепканы кыңгыр сала, кулдан бәйләгән озын ак шарфны җилкә аша җилбәгәй җибәрә дә, аһылдап, Гөлсем алдына килеп тезләнә:

— Гөлсемкәем-гөлкәем, йөрәк маем, сызып бетәм бит инде, сары кәгазьләр кебек саргаям, зәңгәр каралар кебек зәңгәрләнәм, ашасам ризык җитми, эчсәм чәй төткәзә алмый аптырыйм, синнән башка көнем көн, төнем төн түгел! Никләр азаплыйсың син мине, никләр тәмуг утларына саласың? Ник син мине җылы кочагыңа алмыйсың?! — дип зарлы тыңкыш тавыш белән сөйләп китә Нурия-Нух. Гөлсем аның мәхәббәтеннән баш тарта, Нурия-Нух аның саен ярсый, кайнарлана, сабырсызлана, дәртенә чыдаша алмыйча, сөйгәненең ботларыннан

кочып ала һәм алар икәүләп, дөбер-шатыр килеп, караватка авып китәләр.

Бу спектакльне карап торган кызлар: Фатыйма белән Таһирә эчләре катып, кулларын чәбәкли-чәбәкли көләләр, ду килеп сикереналәр, ачлы-туклы яшәгән тормышларын вакытлыча гына булса да онытып торалар иде.

Бәхетсезлек буласы көнне дә алар шулай шаярыштылар, көлештеләр, дуракланып ду килделәр. Пианино торган суык бүлмәләрдә бармаклар күчән күк катмасын өчен, кара йоннан бармак очларын тишеп калдырып бәйләгән перчаткаларын киеп, музыка дәресенә барып кайттылар.

Аннан кайткач, Гөлсем, Фатыйма, Таһирә, алар белән бергә Нурия паек һәм стипендия алырга бардылар. Нурия баштарак:

— Әйем лә... бүген бармыйм, иртәгә барырмын әле, — дип көйсезләнеп маташкан иде, кызлар аны җилтерәтеп кенә алып чыгып киттеләр. Кызларның көне-сәгате белән стипендия алырга кыстауларының сәбәбе дә юк түгел, чөнки стипендия болай да аз акча, алган көнне үк, кирәк-ярагыңны алып өлгермәсәң, акчаның бәясе төшә дә бетә, бер генә нәрсә дә алырга ярамый иде.

Шуңа күрә кызлар Нурияне җилтерәтеп алып чыктылар, шуңа күрә кызлар, стипендия алуга, тагын бер мәртәбә җилтерәтеп Нурияне паекка алып бардылар. Бишесенә тиешле бер пот онны бәләкәй чана белән тартып алып кайттылар да якындагы лавкаче Ясыйр абзыйга биреп, көн саен иппиләтә алып торырга вәгъдәләшеп кайтып киттеләр.

Аннары ачлык елны Америка эшчеләре җибәргән азыкларның калдыгына төзелгән ашханәгә кереп, ике кашык тары боткасы белән берәр стакан крахмал кисәле ашап чыктылар.

Өйгә кайттылар. Көн кичкә таба авышканлыктан, бүлмә суынып беткән, ягарлык утын да нибары ике көнлек кенә калган иде инде. Фатыйма белән Таһирә бәләкәй чана тартып, печән базарына утын эзләргә чыгып киттеләр. Гөлсем Сөләйманова пианист укытучы белән өстәмә рәвештә әзерләнергә сүз куешкан икән, ул шунда чыгып йөгерде. Нуриягә өйне җылытып, мичкә бәрәңге тәгәрәтеп куярга куштылар. Кызларның һәркайсы карават астында саклый торган капчыкларыннан өчәр бәрәңге алып бирде.

Нурия башта мич артына куеп киптергән чыралыктан бераз чыра телде, аны галанка мичкә бура кебек итеп тезде, ул бәләкәй чакта Зартугайда түбәлек тактаны шулай тезеп киптерәләр, ай буе торганлыктан, такта өй эченә куе булып үлән үсә, Нурия иптәш кызлары белән әнә шул өй эчендә качышлы уйный торган иде.

Коры чырага ут элгәч, мичкә утын агачлары салып чыкты, мич капкачын ачып куйды, табуреткасын идәнгә аударып, мичтән төшкән ут яктысында музыка дәресенә әзерләнә, нотадан җыр чыгара башлады.

Мичтә дөрләп киткән ут аның тез башларын рәхәт җылыта, җырның никтер нотадагыча чыгасы килми, авылда, яшьләр урамда җырлап йөргән, некрутлар гармунга җырлап узган җырлар искә төшә иде. Кинәт кызның күңеле кузгалып, бәләкәй чаклары, тегермән буасы янындагы сазламыктан бака балалары алып кайткан чаклары исенә төште. Бик тә кире, үз сүзле кыз булуыннан ул хәтта оялып та куйды. Бермәлне аларның өенә чыпчык очып кергән иде. Нурия чыпчыкны тотып бирегез дип шыңшый башлады. Әтисе белән әнисе, алар белән бергә Көмеш түтәй, өйдәге әйберләрне аудара-аудара, мышкылдый-мышкылдый, чыпчыкны тотып Нуриягә бирделәр, Нурия аны кулында тотып торды, чыпчык бөтен гәүдәсе белән дерелди, дерелдәве хәтта Нурияның кулына сизелеп тора иде...

Аннары ул Солтан белән аяклы амбар янына килеп, тау түбән йөгереп төшүләрен, саллар өстендә куышып уйнауларын күз алдына ки-

терде — йөрәге рәхәт-рәхәт кысылып куйды. Үлеп тә Солтанны күрәсе килә башлады. Солтанның ун көн инде аларга килгәне юк, нишләп йөри икән ул? Әллә укуын ташлап авылга кайтып киттеме, югыйсә?

Кинәк ишек шакыдылар. Нурия сискәнеп, бер үк вакытта бик хәтәр сөенеп, ишек ачарга йөгерде, «Ул» дигән уйдан аның бөтен тәненә ут йөгергән иде. Ләкин ишекне ачкач, аның чырае бик кинәт карангыланды. Ишек төбендә басып торган Нух Галләм, күн кепка астыннан бүлтәеп чыккан чәчен рәтли-рәтли:

— Көтмәгәниегезме, Нурия туташ? — диде.

Нурия дәшмәде, ачу белән ишекне ябып кереп китә башлады. Кереп житсә, ихтимал, ул ишекне бикләп тә өлгергән булыр иде, әмма Нух аңардан өлгеррәк булып чыкты. Нурия тотынган ишекне ул каерып ачып керде дә, бүлмәдә берәү дә юклыгын шәйләп алгач, ишекнең биге барлыгына игътибар итеп, буш урындыкка килеп утырды.

— Я, ни хәлләрдә яшибез, сылукай-гөлкәй? — диде ул тыңкыш тавышы белән.

Нурия каш астыннан, өнәмичә, дошман күзләре белән аңар карады. Нух Галләмнең елтыравыклы күн курткасы да, шундый ук күн кепкасы да, тезен тезгә чәнчеп утырганда тырпаеп торган сары сафиян итеге дә, хәтта кызлар йөзе кебек чибәр йөзе: сызылып киткән кара кашлары, туры борыны, уймакланып торган бәләкәй авызы да, барысы, барысы аңар күңел кайтаргыч чит иде, дошман иде. Ул хәтта бер генә мәлгә үз-үзеннән аптырап та куйды, тышкы кыяфәте белән бу Солтан Айдаровтан чибәррәк бит, киеме дә коеп куйган, Нурияне бәлки ярата да торгандыр, Солтан әнә ун көн буе килми, ә бу шул ун көн эчендә Нуриягә өч хат язды, көнгә ике-өч кат туктатып хәл-әхвәлен сорашты. Кыен булса, ярдәм итәргә әзер икәнен белдерде.

— Нишләп шулай әрсезләнеп йөрисез сез, Галләмов абзый? — диде Нурия. Нухның үзеннән дүрт-биш кенә яшькә олы икәнен белә торып, карт итеп күрсәтер өчен юри «абзый» диде.

Нух Галләм ирен чите белән генә елмаеп куйды.

— Сез мине мыскыл итәсез, мулла кызы. Итегез, туйганчы көлегез миннән, абзый диегез, бабай диегез, минем сезгә булган ялкынлы мәхәббәтемне алар берсе дә сүндерә алмый. Мин сезне төшләремдә күрәм. Зартугайда беренче мәртәбә күргән көнемнән башлап, сезнең менә бу шомырт кара чәчләрегезне, сезнең зифа буегызны оныта алмыйм. Шушы кадәр хәзинәгә мин түгел, икенче берәү хуҗа булачагын төшемдә күреп, көнләшүдән йөрәгем ярылыр дәрәҗәгә житеп уянам. Ник тилмертәсез сез мине? Ник үртисез? Әйтегез бер сүз: синеке булам, сабыр ит, диегез, биш ел, ун ел, гомер бакый көтәргә риза. Я, ник дәшмисез? Миңа сезнең тавышыгызны ишетү мәңгелек сәгадәт! Әгәр сез миңа өметле бер сүз әйтсәгез, Габбас абзыйга барып, тезләнеп, кулыгызны сорар идем.

— Сез, Галләмов абзый, роман геройлары кебек сөйләшәсез. Кулны сораудан ни файда, йөрәкне сорарга кирәк.

— Сез һаман көләсез. Ә минем йөрәкне мәчеләр тырный.

— Абау, бигрәк ямьсез итеп әйттегез. Мәче! Сез, ичмаса, миңа берәр җыр җырлап күрсәтер идегез. Күңелсез, суык. Тышта җилләр улый...

Нурия әрсез егетнең болай гына чыгып китмәслеген белә иде, шуңа күрә ул юк-бар белән аны юатып, иптәш кызлары Гөлсемнәр, Фатыймалар кайтканын көтә, кызлар кайткач, Нухның әле генә әйткән сүзләрен нәкъ анынча тез чәнчеп утырып, кабатлап күрсәтергә тели иде. Шуңа күрә аның күңеле тыныч, хәтта Нух Галләмгә караган саен көләсе килеп, шаян тойгы белән тулган иде.

Тик ул тагын берничә минуттан үзен нинди язмыш көткәнен белми иде әле.

Нуриянең мыскылчан бер чырай белән, үзеннән рәхәтләнеп көлеп, мич каршында тыныч күңел белән утыруына Нух Галләм үзенчә бәя бирде. Урыныннан торып, ишекле-түрле салмак кына йөренә-йөренә, тагын бер мәртәбә Нуриягә булган хисләрен сөйләп чыкты һәм шул арада, сиздермәскә тырышып, ишекнең келәсен бикләде.

Кеҗә тавышы Нуриянe урыныннан сикереп торырга мәҗбүр итте:

— Сез нишлисез, Галләмов? Ачыгыз хәзер үк!

Нух Галләм, Нуриянең юлына аркылы төшеп, беләкләреннән тотып алды. Кыз күтәрелеп аңа карады, күзләре зур булып ачылды. Мич кызуыннан алсу капкан бите, куркынып ачылган күзләре чиксез матур, дөньяңны онытырдай чын иде. Нух Галләм, кинәт үзендә тыелгысыз рәвештә кайнар бер хис кабынганын сизеп, кызны үзенә тартып китерде. Бер кулы белән чатырдатып кысып, икенче кулы белән кызның биле тирәсендә кармалана башлады. Нурия, җан көче белән чәрәшеп, аның кочагыннан сыдырылып чыкты. Күзен кан баскан, акылын җуйган Нух Галләм Нуриянең изүенә килеп ябышты, күз ачып йомганчы кызның күлмәген урталай ертып төшерде һәм... яшен суккандай катып калды. Аның күз алдында ап-ак йомры иңбаш, шалкандай тыгыз имиләр, озын ак муен пәйда булды. Ләкин күз камаштыргыч гүзәллекне ул секундның күпмедер бер өлешендә генә күреп калды, аңын җыеп өлгергәндә инде ул икенче бер тетрәү кичерде. Нәфрәттән ярсыган Нурия, үзен-үзе белештермичә, башта аның чәченнән умырып тотты, аннары уңлы-суллы яңаклый башлады. Күзеннән чәчелгән ут көлтәсе һәм чалтырап киткән тавыш Нухны аңына китерде: идәндә аунап яткан кепкасын эләктереп, ишекнең келәсен ашык-пошык ачып, ул урамга атылды...

## VII

Кабан күленең уң ярында патша заманнарында ук купец Тирапановлар өч катлы итеп салдырган борынгы кирпеч йорт тора. Бөтен дөнья сугышы, ике революция һәм гражданнар сугышы давыллары кайчандыр фирүзә төсендә булган йортның буяуларын уңдырып, аны ала-кола төскә керткәннәр. Урыны-урыны белән шкатуры коелып, кызыл кирпечләре чыгып калган; алар ил өстеннән узган дәһшәтле сугышларның канлы ярасы кебек, еракта ук күренеп торалар. Булат тимердән гомерлек итеп коелган урам як капкасының да җил-яңгырлардан буявы уңып, тутыгып, күгәннәре кәкрәеп беткән. Майламаганнарына да ун еллар бардыр, ачканда-япканда, әкәмәт ачы тавышлар чыгарып, ярлы кеше зарыдай ыңгырашып кала.

Менә шунда Идел буе авылларыннан, Кама арьягыннан һәм шәһәр бистәләреннән белемгә сусаган татар-чуваш-мукшы балаларын: уңсигез яшен тутырган яшь-җилбәзәкне дә, солдат шулпасы эчеп, окопларда бет симертеп кайткан сакаллы солдатны да, буразнадан гына күтәрелгән авыл мужигын да барысын бергә китереп тутырдылар. «Шәрык академиясе рабфагы» дигән яңгыравыклы зур исем биреп, ач-ялангач халыкны ил белән идарә итү өчен тизләтелгән ысуллар белән укытырга керештеләр.

Солтан Айдаров та шушы казанга килеп эләкте.

Алдынгы булуы белән элек тә бик әллә ни мактана алмаган, дөнья промышленниклары исемлегендә иң арттагы урынны бирәүгә дә бирми килгән Россия гражданнар сугышыннан тәмам бөлеп, җимерелеп килеп чыкты. Завод-фабрик морҗаларының төтене сүнгән, чуен юллары ватык, пристаньнар сәләмә кимәле мужиклар, бәхет эзләп йөрүче сукбайлар белән тулы. Бердәнбер байлык — килер көнгә өмет. Тик шул өмет, еракта яктыт ут кебек, кешеләрне җылытып асрый, соңгы чиккә житеп ачыргаланырга ирек бирми иде.

Ачлык-ялангачлыкта, суык биналарда яшәгән рабфакчылар көн саен күңел юаткыч шаярулар уйлап табалар. Йокысы каты булган берәр егетне караваты-ние белән күтәреп коридорга чыгаралар да караваг башындагы тоташтыргыч тимерләрен алып куялар. Төнлә суыктан туңа башлаган «йокы чүлмәге» иске шинеленең җиңенә аягын тыкмакчы булып кыймылдый башласа, дөбер-шатыр килеп, җимерелеп төшә.

Колчак Хәсән белән Имам Каһарманов Сәйфелмөлекне өстәл өстенә меңгереп бастырганнар да чалбарын тарталар. Малай галифе чалбарына чытырдатып ябышкан, тарткан саен галифедан салам коела. Баксаң-күрсәң, Сәйфелмөлек, авыл гыйбаты, шәһәрчә булам дип чалбарыннан галифе эмәлләгән — күпереп торсынга салам тутырган икән.

Шәһәрчә киенү, шәһәр культурасына ия булу, йогышлы авыру кебек, рабфакчыларның яман чиренә әйләнеп китте, ул аларны тилертә, чатлама суыкта урамга бәрән бүрек киеп түгел, кепканы кырын салдырып чыгара, киез итек әрҗә-чемоданнарга бәйләп куйган килеш карават астында тора, тишек булса да ботинка кияләр. Солтанга да шул чир йокты — Шәяхмәт абыйсыннан калган яшькелт бостон чалбарны, галифе ясыйм дип, кия алмаслык дәрәҗәдә бозып ташлады да инде менә үкенеп йөри...

Көндезләрен дөнья революциясе, совет властеның бурычлары турында ач карынга лекция тыңлап кайталар; лекциядән соң бүлмә-бүлмә җыелып, паек алырга казна келәтенә йөгерәләр. Паек дигәннәре атнасына бер бөтен ипи. Син шуны җиде кисәккә бүлеп, атна буе ашарга тиеш.

Кукмара ягы малае Әхмәтсафа, үз-үзенә бәйрәм ясап, ипине җиде кисәккә бүлә (шул көн җиткәнче ул чалгы пычакны Гали пәкесе итеп кайрап куйган була).

— Менә шулай, ипекәйгенәем, син тагын безне сагынып килдең, без сине тагын чалгы пычак белән җиде кисәккә бүләбез. Бер кисәген бүген, бер кисәген иртәгә ашыйбыз. Сабыр гына ашыйбыз без сине, ашыкмыйбыз. Солы кибәге кушылган булсаң да тәмле син, ясмык тәмнәре дә килә синнән, борчак тәмнәре дә килә, ә бит син үзең арыш ипие дип аталасың! Менә болай итеп тотабыз без сине, ипекәй, менә болай итеп ашый башлыйбыз...

Ашарга тотыну белән Әхмәтсафаның тавышы бетә. Ипине ул ваквак кабып, бик озак чәйнәп, тәмләп ашый. Ләкин рәхәтлекне никадәр озакка сузарга теләмәсен, көндәлек паек барыбер ашалып бетә, ачка киселгән ашказаны әле ашыйсы килеп котырып кына кала, моны инде бүлмәдәгеләр Әхмәтсафаның үз-үзен тирги башлавыннан аңлап алалар:

— Юк, сорама, бирмим. Дүшәмбе паегыңны ашадыңмы? Әйттем бит инде бирмим дип! Нигә ачуымны китерәсең? Әллә бирим микән? Иртәгәсе көнне, сишәмбедә ашамый торасыңмы? Ярар, торсаң бирәбез...

Икенче көн паегы да ашалып бетә. Әхмәтсафа әле туймаган. Аның инде күңел коткысына бирелергә хакы юк, калган биш кисәкне ул шакмаклы тастымалга төрә, чишә алмаслык итеп чиyләп бәйли, чемоданның төбенә үк салып, берьюлы ике йозак белән биклэп куя.

Ашаган ипи кече телләренә йокмаса да, рабфакчылар кайнар суны бактан бер-ике кружка соскач, туклангандай булалар, күңелләре ачылып, яшьлеккә хас шаянлык-шуклык белән мавыгып китәләр. Арада иң күп көлдерә торганнары Колчак Хәсән. Ул барысыннан да өлкән, буйга барысыннан да озын һәм барысыннан да чандыр; ул гражданнар сугышы чорында Колчакта әсирлектә дә булырга өлгергән, үлемнән мәзәк холкы һәм чамадан тыш ихласлыгы аркасында гына котылып калган.

Тамак ялгап алгач, Колчак Хәсән, буржуйлар кебек, йоклап алырга тели: буржуй хатыннары булып түшәк сала, «түшәге» күперебрәк китсен дип, шәрә тактаны и кага, и кага — рабфакчылар эчләре катып, рәхәтләнеп көлә, мендәр урынына да, түшәк урынына да, юрган уры-

нына да хезмәт итә торган озын соры шинелен бөркәнә башлагач, дәгъва куптаралар, ул әле доклад ясарга, профессор булып тарих аңлатып бирергә тиеш.

Колчак Хәсән бердәнбер исән булган терәкле урындыкны үзенә тартып китерә, озын ябык гәүдәсе белән урталай бөгелеп, урындык терәгенә ябыша, күзлекне пенсне сыман иттереп ике бармак белән генә чеметеп борын төбенә кысып куя да бик җитди чырай белән сөйли башлый:

— Один тыща девятсот двадцать первый голодный год, серебра семьсот, медний тәңкә бесшут, сифрләнни, хамудрәнни, ариндатор, спикулянтыр, Әхмәтсафа шантажир, Колчак Хәсән указатель, Солтан Айдар приказатель, адрит-кудрит, яфрак майт, кибени фини китсен кибәннәр арасына Каһарманов...

Егетләр, эчләрен тотып, караватка авалар.

— Көлдермә, үтерәсең, болай да эч эчкә ябышкан, — диләр.

Ачлы-туклы тормыш рабфакчыларны кышын түзеп тора алмаслык хәлгә китерде. Ипидә арыш онының әсәре дә калмады, ахрысы: ул авызга капмаслык тәмсез була, я кайрак кебек ката, я артык чи булып, складтан алып кайтып җиткергәнче бозга әйләнә; тозлы кәбестә шулпасында өшегән ике-өч бәрәңге йөзеп йөри.

Ачлык кайбер егетләрне бозык юлларга да этәргәләде.

Базарда вак сәүдәгәрләрнең, авыл хатыннарының әйберләрен чәлдерү, үз йорты белән яшәгәннәрнең келәтенә керү, Петропавел чиркәвенә төшеп, икона урлап сату шикелле нәрсәләр булгалап, аларны рабфакның комсомол оешмасы гына түгел, партиянең Суконный-Пләтән райкомы бюросы да көн тәртибенә куеп тикшерде. Ләкин шул гадәттән тыш хәл дә кайбер егетләрне өркетә алмады. Шагыйрь булырга хыялланып, поезд барган ритмга такмаклап йөрергә гадәтләнгән Сирин-Батыршин үзенчә нәтиҗә ясады:

— Юк, иптәшкәйләрем, нинди генә югары оешмага куеп тикшермә, урлашу начар нәрсә дип күпме генә лаф орма, кеше социализмда яшиме, капитализмдамы, тамагы ач икән, аның башында бер генә идея: «Каян ашарга табарга?» Совет власте безгә башта ипи бирсен — аннары социализм идеяләрен таләп итсен.

Гражданнар сугышыннан контузия алып кайткан Имам Каһарманов, стажлы коммунист, озын чәчле, бәләкәй гәүдәле шагыйрь белән һич кенә дә килешергә теләми:

— Уйлап кына карагыз, Идел буендагы корылык утыз миллион кешене бер телем ипиисез калдырды. Кулак ипиен җиргә күмеп черетә, үзе төсле капкорсак, үгез муеннар белән советка каршы теш шыкырдата, әнә шул ипине аңардан каерып алырга, рабфакчылардан ЧОН отрядлары төзеп, авылларны айкап кайтырга кирәк.

Аны игътибар белән тыңлыйлар, ләкин авылга чыгарга ашыкмыйлар.

Вак-төяк урлашулар көн саен булып тора. Бу эшкә бер вакыт хәтта Солтан Айдаров та катнашып алды. Иң әүвәл ул, учком рәисе булуыннан файдаланып, завхоз Кәрим абзыйга якынайды. Завхозның эшен тикшерү, аңа контроль ясап тору учкомга йөкләнгән иде. Шунлыктан Солтан үзен продукт тирәсендә хуҗа итеп сизә, әмма каты куллы, гадел холыклы Кәрим абзый хәтта учком рәисе Айдаровка да бер генә телем икмәк тә артык бирми, аның эшен күпме генә тикшермә — һәркайчан дөрескә чыга. Азык келәте тулай торакның аскы катында булып, аның бер ишеге кухняга карый иде. Айдаров әнә шул ишекнең йозагын ачарга өйрәнде. Төнлә белән, бүтәннәр яткач, йозакны кадак белән ача да бер телем ипи, әзрәк кенә тозлы май яки бер-ике уч ярманы кесәсенә салып, яңадан ишекне бикләп чыга. Берсендә шулай ярманы идәнгә ялгыш коеп калдырган. Айдаров бервакыт шулай завхоздан:

— Эшләр ничек, Кәрим абзый, продуктларга кагылучы юкмы? — дип сорады.

— Кагылучы юк анысы, — диде Кәрим абзый, — тик менә бер күсе нэләнде, каһәр төшкере, бакчы, ярманы идәнгә чәчеп киткән, йөзе кара нәмәстәкәй!..

Төн. Утыз биш кешелек бүлмәдә барлык егетләр инде йоклый. Колчак Хәсән белән Шадра Шакир гына йокламый. Солтан аларның аратирә бер-берсенә сүз кушып куйганнарын ишетеп, йоклап киткәннәрен көтеп ята. Бүлмә тәмам тынып, авыр мышнаулар, борын сызгыртулар гына алмаш-тилмәш ишетелә башлагач, ул әкрен генә тора, аяк очларына гына басып коридорга чыга, буш һәм караңгы коридордан капшана-капшана барып, кухняга төшә. Кухняда плитә яна, идәндә бик зур кисмәк тора, кисмәк өстендә чүмәләмә итеп турап куйган бәрәңге агарып күренә. Мич башында кухарка хатын гырлап йоклый. Солтан, кухарканың йокысы катымы икәнне сынау өчен, бер котелокка кайнар су агыза, агызып бетерүе була:

— Әй, син нишлисең монда? — дигән тавышка сискәнеп, кулындагы котелогын төшереп җибәрә яза. Караса — Шадра Шакир. Солтан тиз генә котелогына бәрәңге тутырып ала, икәүләп коридорга чыгалар.

— Ипиләре кайда боларның? — ди Солтан.

Шакир иңбашын сикертә, белмим, ди

Белә шадра шакмак — аның монда төшкәне бар. Юкса, Айдаров артыннан шулай тавышсыз гына керә алыр идемени!

— Син дөресен әйт, шаярып торырга вакыт юк.

Коридорда шкаф тора, ишегендә йозак, өстә ябылып бетмәгән зур гына ярыгы бар.

— Әнә шул шкафта түгел микән? — ди Шакир шыпырт кына, Солтанны җилкәсенә бастырып өскә күтәрә, кулын тыгып карарга куша.

— Шушында! — ди Солтан тыны бетеп.

— Ал тизрәк.

Солтан шкаф башына менеп китә, ике куллап ишекне каера һәм, кулын тыгып, бер бөтен ипи ала да Шакирга суза.

— Инде иплән кенә төш! — ди Шакир.

Ләкин иплән төшү дигәннәре барып чыкмады. Шкаф янында гына буш чиләк тора икән, Солтанның шуңа килеп абынуы булды, чиләк шалтыр-шолтыр тәгәрәп китмәсенме?!

Ул арада кухнядан чәчләре тузгыган кухарка килеп чыкты, күзләрен акайтып Солтанга төбәлде, әллә курыкты, әллә кинәтлектән каушап калды, аны-моны әйтергә өлгермәде, Солтан аны янга селтәп, ишеккә ташланды. Шакирны ул өченче кат баскычында куып җитте, кулында бәрәңгеле котелок, култык астында — бөтене белән икмәк!

Тиз генә кереп яттылар. Шакир ипине карават астына ыргытты. Тавыш-тын юк, куа килүче дә юк. Бераздан Шакир Солтанны ипи ашарга чакырды. Кая ул ашау! Ипи түгел, күмәч бирсәң дә кирәкми! Солтан кан калтырап ята. Болай хур булып йөргәнче ачка үлгәнең артык.

Иртәгесен Солтаннар бүлмәсенә завхоз Кәрим абзый, рабфак мөдире һәм кухарка килеп керделәр. Аларны күргә Солтан сөлге алып юынырга шылды. Әй юына, әй юына, суык судан бите, кулы күшеп бетте — тегеләр һаман чыкмый. Юыну бүлмәсендә көне буе ятмассың бит инде, киредән бүлмәгә кайта. Тегеләр нәкъ бүлмәдән чыгып киләләр.

Рабфак мөдире бармагы белән генә ымлап, Солтанны үзенә чакыра, ияк очына ябыштырылган бер тотам кара сакалын өч бармагы белән чеметеп, Солтанга төбәп карый:

— Иптәш Айдаров, менә бу егетне төнлә кухарка кухняда күргән.— Үзләре белән ияртеп алып чыккан Шакирга күрсәтә. — Ә ул әйтә, Айдаров белән бергә төштем, ди. Моны ничек аңларга?

Солтанның йөрәге жу итә. Рабфактан очырачаклар. Хурлыгы ни тора! Ул бик усал итеп Шадра Шакирга карап куя да:

— Әйе, төшкән идек, — ди.

— Әйттем бит, әйттем бит, — дип чәрелди кухарка.

Кәрим абзый, башны кырынрак салып, Солтанга күзенең агын әйләндереп карый.

— Әйе, әйе, төшүебез дөрес, — ди Солтан. — Мин үчкөм рәнсе булярак, сигнал алдым, кухарка төнлә рабфакчылар белән шаяра, имеш. Тикшерергә кирәкме безгә, юкмы?

— Алдаша, андый эшнең гомердә дә булганы юк, ипидер әгәр, — дип ярсынып китә кухарка, аның төнлә күргәндәге кебек, чәчләре тузгып төшә.

Мөдир кухарканы кул селтәп туктата:

— Дәвам итегез, Айдаров.

— Нәрсәсен дәвам итәсең, безнең килеп керүебез булды, ат чаклы бер егет, чиләкләрне аударып, дөбер-шатыр чыгып чапты!

— Кем икәнен танымадыгызмы?

— Танып булмады шул. Кухаркадан сорап карадык, әйтми. — Солтан, үз ялганына үзе ышанып, кинәт ярсынып китте: — Ул һәрвакыт шулай, яла ягарга оста...

Хәйләне аңлап алган Шакир да батырая төште, гөбедән чыккан төсле куе калын тавышы белән утка керосин өстәп җибәрде. Коридорга рабфакчылар җыела башлады. Уңайсыз хәлдә калган мөдир, ияк очына ябыштырган сакал кисәген сөякчел кулы белән учлап, башын иеп торды, аннары кинәт, кулын бик кискен селтәп, китеп барды.

Алар китүгә рабфакчылар бүлмәгә кереп тулдылар. Шакир — шадра шакмак — мендәр астыннан бер бөтен ипине алды да, телем-телем турап, егетләрне сыйлый башлады. Вәт шулер!

— Туктале, ничек тапмадылар моны? Тентемәделәрмени?

— Тентемәгән кая! Бүлмәнең астын өскә китерделәр. Мин аны ике мендәр арасына салган идем. Икесен бергә күтәреп читкә алып куйдым, аның өстенә матрацны әйләндереп салдым, тагын әйләндердем, караватның икенче башын ачтым, егетләргә бик ачы тавыш белән:

— Караватларыгызны әйләндерегез, матрацларны бушатыгыз! — дип команда бирдем, аннары чемоданнарны ачтырдым, яптырдым. Бүлмә тузан белән тулды.

Ипи — исән. Малайлар әвен суга. Тентү вакыйгасын исләренә төшерә-төшерә, көлешә-көлешә ашыйлар. Солтан, никадәр генә кыстасалар да, ашый алмый, ипинең валчыгы да тамагыннан үтми, әле генә үзе уйлап чыгарган ялганнан аның күңеленә төер утырган, шул аны уңайсыз бимазалап тора, ни өчендер аның мендәргә капланып елыйсы килә иде. Ә бу вакытта икенче бер кеше, кухарка хатын, рабфак мөдире бүлмәсендә ачы күз яшьләре белән елый һәм үзенең бераү белән дә буталмавын ышандырырга теләп чукына-чукына ант итә иде.

## VIII

Яшьлек үзе белән күпме генә энергия алып килмәсен, тормышның ямьсез, җан өшеткеч якларын күпме генә онытырырга, аларга күз йомдырырга тырышмасын, аяусызлык белән дорфалыкның өскә чыккан чаклары да булгалады.

Акчасызлыктан интеккән чакларда, инде ниишлибез, ачка үләбезмени дип аптырагач, кызларның берсе — зәңгәр күзле, ак чырайлы Таһирә аркан төсле юан сары чәч толымнарын кисеп, базарда сатып кайтты. Ул гына да бәладән коткара алмагач, интернатта яшәгән кечерәк балаларга дәресләр бирә башлады. География белән рус теле дәреслә-

ре иде ул. Таһирәнең иптәш кызларына караганда белеме күбрәк, ул — Алабугада гимназия бетергән кыз. Балаларны тәрбияләү эше дә аңа тапшырылган иде булса кирәк. Ул балаларның йокы бүлмәләренә дә кереп йөрергә мәҗбүр иде. Бүлмәдәшләрнең иң кыен чагында, Нуриянең әтиләреннән дә посылка-мазар килми торган вакытта, ул эшләп тапкан акча бераз гына булса да хәлне җиңеләйтергә ярап куя иде. Әмма ул кечкенә бүлмәгә зур гына мәшәкать тә тудырды. Чөнки Таһирәнең плюш пальтосына нярең бет тә кайта иде. Таһирә бичара балалар бүлмәсеннән кайтып керүгә:

— Кызлар, тикшерегез мине тизрәк, аркамда әллә ничәсе берьюлы йөри бугай, — дип сабырсызлана башлый иде.

Нурия музыка техникумында бер генә ел укып калды. Гомуми торакта үтә салкын, үз акчаңа утын алып төткәзерлек түгел, ягылмаган залдагы рояль хәтта тишек бармаклы перчатка киеп уйнаган чакта да кулны күшектереп, бармакларны берни тоймас дәрәҗәгә җиткерә иде.

Нурия бик тә авырыксынып, зар елап музыка техникумыннан китте. Рабфакта гына калды. Аның музыка техникумыннан китүенә Нух Галләм дә сәбәпче булды. Теге чакта Нурия белән килеп чыккан оят-хурлыгын ул онытмаган, үч алу өчен уңай вакыт көтеп йөри иде. Менә аңа җай чыкты. Рабфакта үткәрелгән зур бер җыелышта ул Нурия Уразаевага ташланды.

— Беләсезме, иптәшләр, безнең арабызда пролетариат идеологиясенә каршы кешеләр бар. Мәсәлән, Нурия Уразаева, сыйнфый аңын күтәрәсе урында, тулысынча буржуаз идеологиягә бирелеп, музыка мәктәбендә укып йөри.

Җыелыштагылар дәшмәделәр. Нурия әрсез егетнең авызын капларлык сүзне шул минутта гына тапмады. Өйгә кайткач, ул бик күңелсез йөрде, җырчы Гөлсемнең аны бигрәк тә үз итеп, гел ягымлы сүзләр генә әйтеп торуы аның кәефсезлеген арттыра төште — кызганганнарын белү аның өчен үлем белән бер иде. Кызларның берсе белән дә сөйләшмичә, юрганын башыннан ук бөркәнеп йокларга ятты. Күзенә йокы кермәде — пычрак эчле Галләмовның кем икәнен әйтеп бирми калуы үкендерә иде. Әйтергә иде шунда: «Син, явыз кеше, син миңа моны үч итеп әйтәсең, синең әле яңак төбең һаман ут янып торадыр,— дияргә иде.— Музыкага өйрәнү буржуаз идеология булгач, ник соң безнең завуч иптәш Виннер музыка мәктәбенә кларнет күтәреп йөри? Ник соң алайса минем коммунист абыйларым Баяновлар минем анда укуымны хупладылар?»

Җыелышта Нурия Уразаеваны рабфактан чыгару турында карар кабул ителмәде, әмма рабфак мөдире Михаил Савельевич Корбут аны икенче көнне үк үз бүлмәсенә чакырып алып бик озак сөйләште. Төпченеп-төпченеп сөйләште. Әти-әнисенең, туган-тумачаларының кем булуларына хәтле әйттереп бетерде. Нурияне курку алды: әллә югыйсәм, мулла кызы дип укудан чыгарып ташламакчы булалармы?

Мөдир, сорашып бетергәч, ак дип тә, күк дип тә әйтмәде. Ә ике көннән приказлар тактасы янына җыелган халыкны күреп, Нурия эченнән ут йотып, шунда барды. Аның рабфактан куылуы турында приказ чыккан, приказда Н. Г. Уразаеваның мулла кызы булуы, эшче-крестьян балалары укыган җирдә укырга тиеш түгеллеге, рабфакчы кызның нәсел-нәсебен яшереп йөрүе бик усал сүзләр белән әйтелгән иде.

Нурия приказ астындагы «М. С. Корбут» дигән имзаны укып бетерүгә, шунда, коридорга җыелган егетләр-кызлар алдында ук, күз яше белән елап җибәрде. Ике-өч кенә сүзле приказ аны укудан мәхрүм итә? Нинди хурлык! Егерме ике яшенә җиткән кыз баланың кайгысы шундый да зур, шундый да котылгысыз иде ки, аның күз аллары караңгыланды, аяк астындагы җир кинәт убылып, җимерелеп бара кебек тоелды.

Үз бүлмәләренә кайткач, мендәргә капланып, туйганчы, күңеле бушаганчы кайнар күз яше түкте. Әзрәк хәл алгач, кайгысын сөйләргә дип Кабан күле аръягына, Солтаннар, Каһармановлар, Кәшифәләр торагына китте. Иң авыр минутларында аңа Солтан кирәк, ярдәм итсә, бары тик ул гына итә алачак иде.

Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, Солтан өйдә юк иде. Кәшифә дә эш белән каядыр китеп барган, тик Имам Каһарманов кына, күперенке галифе чалбардан, җилкәсенә шинель салып, ишекле-түрле йөренеп тора иде. Каһарманов — кырык яшьләрендәге кеше, кеше кайгысын күтәрешә алырлык тәҗрибә дә, сабырлык та бар иде аңарда. Лышыклышык борын тартып, хәсрәтен сөйләгән Нурияне бүлми-нитми тыңлады, тыңлап бетергәч, йомшак тавыш белән юатып әйтте:

— Син, үскәнем, елап йөреп берни дә майтара алмассың. Хәзер үк наркомземга, Ибраһим Баянов янына бар. Ярдәм итсә, сиңа бары тик ул гына ярдәм итә ала. Кара аны, тартынып-нитеп торма, туп-туры Баяновның үзе янына кер, юкса, син ай буе каңгырып йөрерсең дә, сине аннары беркая да алмаслар.— Озаткан чакта тагын да юатыбрак:— Озакламый Солтан кайтыр, ул тимер юл стансасына вагон бушатырга киткәние, кайтып җитүгә синең яныңа йөгертермен, яме,— диде.

Нурия, тынычлангандай булып, наркомземга китте. Ләкин аны анда да бәхетсезлек көтә, Баянов янына керү түгел, аның ишек төбенә дә килеп җитәрлек түгел, кабул итү бүлмәсен халык басып алган иде.

Нурия, нишләргә дә белмәгәч, Нурҗиһан җиңгиләренең өенә барып карарга булды. Габидулла абзыйдан киңәш сорармын, әгәр Ибраһим абзый әле аңардан башка фатирга чыкмаган булса, аны да көтеп алырмын дип өметләнде. Ләкин синең кайгыңны җиңеләйтәм дип беркайда да атлыгып тормыйлар. Габидулла абзый эштән кайтмаган, Ибраһим абзый болардан күчеп киткән. Нурҗиһан җиңгигә үгез үлсә ит, арба ватылса утын иде. Ул авылдашын гамьсезрәк бер чырай белән тыңлап торды да:

— Бер дә генә борчылма, гөлкием, азапланып-нитеп тә йөрмә, Зартугайга әтиләрең янына кайт та балалар укыта башла, шуннан да тынычрак бер генә эш тә булмас сиңа, — диде. Кызга якын ук килеп, зур имиле күкрәге белән терәлеп, бик тә изге бер эш эшләгәндәй, Нуриянең башыннан сыйпап куйды.

— Мин Габидулла абзыйны көтәм әле, ул ни дип әйтсә шул булыр,— диде Нурия, үҗәтләнеп.

Габидулла абзый караңгы төшкәч кенә арып-талып кайтып керде. Нуриянең ник килгәнен ике сүз белән сорашты. Пөзен болыт басты.

— Да, сеңелем, эшең хөрти. Бик хөрти! Сразы Ибраһим абзыйга барырга кирәк иде. Ул наркомпроска язу язып бирер иде. Шул язу белән рабфакта кабат сөйләшерләр иде.

Нурия, елап җибәрер чиккә җитеп:

— Нишлим соң, Габидулла абзый? Наркомземга кереп булырлык түгел, ишек төбендә ике сәгать басып тордым, якын да җибәрмиләр, — диде.

— Ярый, үскәнем, син кайгырмый гына кайтып йокла. Торактан китәргә ашыкма. Мин иртәгә иртүк наркомзем белән үзем сөйләшермен, үзебезнең наркомпроста да кирәкле кешеләрне күреп куярга тырышырмын.

Бер көн узды — Нурия Уразаеваны рабфак җитәкчеләре чакырмый. Тагын бер көн узды — чакыручы юк. Солтан да күзгә-башка күренми. Яратам дип йөрүләре ялган булды микәнни? Әгәр шулай булып чыкса, аның кай җире Нух Галләмнән артык була инде? Хәзер аңа бердәнбер юл Нурҗиһан җиңги әйткән киңәшне тоту булып чыга түгелме? Авылга кайтырга да балалар укыта башларга! Ә бит аның югары белемле

кеше буласы килгән иде. Кайгырып та, авылга ни оятың белән кайтып керерсең дип гарьләнеп тә арыгач, ул ныклы бер карарга килде: кайтмаска! Ни генә булса да кайтмаска авылга, кеше көлдермәскә! Ул бит яшь, сау-сәламәт, эшлим дисә, кулыннан эш килә! Тегүчеләр фабрикына керер, өч ел буе тырышып эшләр, стажлы эшче булыр. Башына кызыл кепка-берет киеп, рабфак житәкчеләре алдына күкрәк киереп килеп басар! Менә шул чагында аны кертми карасыннар. Тик шунысы аяныч, ул инде Гөлсемнәрдән, Кәшифәләрдән өч елга соңгарак калып бетерәчәк. Өч ел! Өч җәй, өч кыш, өч яз, өч көз дигән сүз бит ул. Нурия шул хәтле озын гомерне көтеп бетерә алыр микән? Кияүгә чыкмаган, сазаган бер кыз булып кына калмас микән? Болай булгач булмады инде. Солтан аңардан йөз чөерә. Шул хакта уйлый башлагач, аның уйфикерләре бик тирәнгә кереп китте. Мулла йортына кайтып, андагы тәртипләрне барлап чыкты. Социаль тигезсезлек яшәгән чакта, өстенбашың бөтен булу, тамагың тук булу белән генә бәхетле булып булмый икән шул. Солтан аңардан мулла кызы булганы өчен баш тарта, аның көн саен килеп чыгачак мәшәкатьләрен, борчуларын уртаклашырга теләми. Социаль тигезсезлектә бәхет юк. Үз башы белән килеп житкән шушы хакыйкать кинәт аның күңел күген киңәйтеп җибәрде. Димәк, аның совет мәктәбендә укып йөргәннәре бушка китмәгән. Ул ак белән караны аерырлык хәлгә килгән. Ләкин икенче бер мизгелдә ул янә дә өметсезлеккә бирелә. Мулла йортында алган диндарлык, озак еллар буена тукылып килгән йолалар өстенлек итә башлыйлар. «И ходаем, рабфак житәкчеләренең күңеленә миһырбанлык бир. Алар мине киредән үзләренә алсыннар!» — дип теләк тели башлый. Әмма ул теләгенең бигүк кабул булачагына ышанып җитми. Уй йомгагын сүтә-сүтә, җепнең очына, аны рабфактан чыгаруга төп сәбәп булган төп фактка, үзенең мулла кызы булуына килеп җитеп, туктый. Ә кем әйтте башлап аның мулла кызы булуын? Нух Галләм. Бүтән беркем дә түгел. Бу — аның эше. Ә бит җыелышта мулла кызы булудан башламады, музыка мәктәбен сылтау иткән булды, кара елан, бәдбәхет! Кабахәт җан! Нурия кинәт башына килгән уйдан сискәнеп китә: аның мәхдүмә икәнен Нух язып биргән, үч итеп! Нурия аның үзләренә килгән көнен, төчеләнеп сөйләшүен хәтерендә яңарта, кинәт күз алларын караңгыландырып умырылып төшкән күлмәге, шәрә иңбашлары белән шул кара елан Нух алдында басып торулары исенә төшә дә бөтен тәне чымырдап китә...

Урамнан атлы олаулар дөбердәп уза, дагалы тояк тавышлары ишетеп, Нурия шул тавышларны тыңлап, озак кына уйланып ята, төн урталары узгач кына саташулы авыр йокыга тала...

Иртәгесен иртүк, Нурияләр чәй эчеп утырганда, алар бүлмәсенә атылып-бәрелеп Солтан килеп керде һәм Нурияне җилтерәтеп алып чыгып китте.

— Кая алып барасың син мине? — диде Нурия юлда барышлый.

— Барып җиткәч белерсең, сорама, — диде Солтан, ашыктырып.

Воскресенский урамыннан бара торгач, пожар депосы янындагы кечерәк бер йортның коридорына барып керделәр. Караңгыда кармаланып ишекне таптылар, шакыдылар, җавапны көтеп бетерә алмыйча, эчкә уздылар.

— Рабфак завучы иптәш Виннер биредә торамы? — диде Солтан, эчке бүлмәдәгеләр дә ишетерлек итеп.

Армиядән кайткannан бирле обмоткалы солдат ботинкасын салмый йөри торган, мыеклы, күзлекле, илле яшьләрендәге бер кеше, пиджак төймәләрен төймәли-төймәли, алар каршысына килеп чыкты.

— Иптәш Виннер сез буласызмы?

— Мин булсам ни диярсез?

Солтан тулы кызылармеец формасыннан иде, үкчәне-үкчәгә китереп бәрде дә кулны чигә турысына күтәреп честь бирде:

— Мин ТатЦИКтан килдем. Председатель заданиесе белән. Менә сезгә язу, менә сезгә тере кеше, нәтиҗәсен белергә нуль-нуль унсигез сәгатьтә керермен.

Каушый төшеп, күзлеген рәтли башлаган Виннерның кулына пакет тоттырды, пакетны алганга кул куйдырды, честь бирде һәм, бер минутын да әрәм итмәстән, чыгып та китте.

Ул киткәч, Виннер пакетны әйләндереп-әйләндереп карады, ертып укырга кирәклеген аңлап, түр якка чыгып китте. Анда ул кайчымы, пычакмы эзләде бугай, өстәл тартмаларын шакы-шокы китереп ачып-япканы ишетелеп торды. Ниһаять, ул Нурияне түр якка чакырды. Нурия пальтосын салып чөйгә элде, киез итеген почмакка куйды, йон оекбаштан түргә узды.

Нурия кергәч, Виннер кыздан рөхсәт сорап галәмәт дәү иске диванга барып ятты, аякларын диванның терәгенә күтәреп куйды:

— Гафу итегез, фронт шартларында аягым өшегән иде, озак басып торсам, сызлый башлыйлар, — диде.

— Сезнең эшне бик җентекләп, игътибар белән өйрәнүне таләп итә ТатЦИК, рабфакчы Уразаева. Я, сөйләгез, әтиегез кем, хәзер кайда яши?

Нурия, урындыгын тартып, аңар якынрак килеп утырды, әтисенең крестьян гаиләсендә туып-үскән ундүртенче бала булуын, бик авырлык белән генә укып, мәдрәсә бетерүен, казакъ даласында балалар укытуын, крестьян эшендә эшли-эшли бармаклары бирчәеп бетүен сөйләде. Авылда ике мулла булып, шуның берсе Өфедән, мөфтидән рөхсәт алып кайткан указлы Сөләйман мулла, икенчесе — Нуриянең әтисе Габбас мулла. Ул алып барган мәхәлләдә бер генә йөз хуҗалык бар, аның әтисе алардан килгән керем өчен түгел, даны өчен, өстәвенә, тол остабикәгә өйләнгәне өчен мулла булып тора...

— Ә синең үзеңнең рабфакны бетергәч нинди ниятләрең бар, Уразаева? — диде Виннер.

— Институтта укыр идем.

— Ярый, бар кайт та дәресләреңә тотын. Калган дәресләреңне укып җиткер, мөдир белән үзем сөйләшермен.

Нурия кая басканын белми чыгып йөгерде.

Ул кичнең-кич буе Солтан белән урамда йөрде, кино карады, саубуллашыр алдыннан Солтанның үткенлеген мактады:

— Ай-яй, булдыклы егет булып чыктың син, малай. Күрдең нишләде завуч: син үкчәне үкчәгә бәреп, кулны чигә турысына күтәргәч, дер калтырап төште.

Мактау Солтанны бөтенләй үсендереп җибәрде:

— Ә ул бәлки рабфак завучы булып оялаган буржуйдыр әле. Каршы килеп карасын: мин бит аны сагайский биетә алам.

— И мактанчык. ТатЦИК председателеннән алып килгән язуың булмаса, исе китәдер иде бик Виннерның — синең ише агач солдатны күрмәгән иде ул. Беләсең килсә, ул үзе дә гражданнар сугышы солдаты. Обмоткалы ботинка киеп йөри, шинелен дә салмаган әле.

— Ә син каян беләсең?

— Фронтта аягын өшеткән, сөйләшкән арада да, басып тора алмыйча, аягын күтәреп ятты.

— Аягын күтәреп?.. — Солтан ачуы чыгудан тешләрен шыкырдатты: — Яткырырмын мин аны, контра, буржуй калдыгы, адәм тәганәсе! Яшь кыз алдында ботын күтәреп ятарга ни хакы бар аның?!

— Ярар, ярар, бик чәпчемә, яме! Әйбәт сөйләште ул минем белән, якларымын, диде, мине бүтән чыгармаслар инде рабфактан.

— Чыгарсалар да аптырама: үземә кияүгә чыгарсың, гражданнар

сугышы солдатына, ярлы кеше хатынына рабфакта укырга шундук рөхсәт итәрләр.

Солтан бу минутларда моны уйнап әйтсә дә, Нуриягә өйләнү, аның белән матур гаилә кору аның соңгы көннәрдә күңеленә кереп утырган зур бер хыялы иде. Нуриянең рабфактан чыгарылуын белгәч тә ул башта наркомземдагы Баяновка, аңардан соң Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты Председателенә йөгерде. Тимерне кызуында сугып калу өчен үзенең барлык документларын күрсәтте һәм рабфактан куылган Нурия Уразаевaны булачак хатыны итеп тәкъдим итте. Әгәр Нурия үзен Солтан нинди шантаж белән рабфакта саклап калуын белсә, нәфрәтләнеп карамасмы? Гомерлеккә аңардан йөз чөермәсме?

Яшьлекнең үз законы: юк кына нәрсәне дә купертеп күрә. Тәҗрибә туплаган, дөньяның ачысын-төчесен татыган бер кеше булса: «Ничек итсәм иттем, сөйгәнемә ярдәм иттем әле», — дип сөенер иде, Солтан исә әле мәхәббәттә дә аңлашмаган кызны булачак хатыным дип әйткәне өчен үзе алдында үзе оялып бара. Колаклары ут яна. Ярый әле, көндез түгел, урам фонарьлары караңгы, Солтанның колаклары кып-кызыл икәнне Нурия күрсә нишләр иде икән?

Йөри торгач, алар Кабанның биегрәк ярына, ботак-тармакларын җәеп үскән карт бер өянке төбенә килеп чыктылар. Күктә ай да юк, анысын да болыт каплаган — гашыйклар төне түгел, димәк.

Аларга барыбер рәхәт. Тоныч кына булып шәүләләнгән Кабан күле өстеннән, аркылыга кисеп, сукмак узган, кешеләр яр буйларыннан әйләнеп йөрмичә, үзләренә сукмакны боз өстеннән салганнар. Һәркемнең үз сукмагы булырга тиеш. Тармы ул, киңме, кәкреме ул, турымы — үз сукмагы.

Солтан да үз сукмагын салыр, ә менә шул сукмактан аның белән кулга-кул тотынып кем барыр? Кем аның юлдашы булыр, кем аның шатлык-кайгысын уртаклашыр?

— Кемне уйлыйсың, Солтан?

— Сине.

— Китче, чынмы?

— Мин сине көннәр буе уйлап йөрим.

— Менәтрәк! Нишләп?

Солтан бер генә мизгелгә каушады, аннары, ни булса ул булыр дип, бер тын алуда әйтеп бирде:

— Яратам мин сине. Синсез яши алмыйм.

— Кит аннан? — дигән булды Нурия, бик озак көткән сүзнең шулай кинәт өскә авуыннан каушап, уен-көлке белән котылмакчы булды: — Мин дә сине яратам бит.

Солтан, аны күкрәгенә кысып, кайнар пышылдады:

— Безгә өйләнергә кирәк. Безнең бозылып китүебез бар. Син мине тилмертмә, Нөркәй, чык миңа кияүгә! Ник дәшмисең? Тиң күрмисең мәллә? Бәлки сиңа мулла абзый рөхсәт итмидер? Мин сине яратам, яратам, ышанасыңмы? Мин сине көн саен төштә күрәм. Сине миннән кемнәрдер алып китәләр. Мин йокымнан йөрәгем ярылыр чиккә җитеп уянам.

— Безгә бит әле укырга кирәк. Өйләнешкән кешеләрне укыталар микән соң?

— И җүләр дә инде син, Нурия! Кемнең кемдә эше бар?

— Ә фатир?

— Табарбыз, тапмасак, торакта торырбыз. Син миңа кияүгә генә чык, минеке генә бул.

Алар айсыз төндә, Кабан күле ярының йөз яшәр өянкесе төбендә, гомер буе бер-берсен яратырга, гомер буе бер-берсенә турылыклы булырга кайнар вәгъдәләр биреп, беренче кат үбештеләр.

Торакка кайткач, бер-берсенең нинди хәлдә икәннәрен күрсәләр, алар куркып калган булырлар иде.

Нурия, үзләренең бүлмәсенә кайтып кергәч, Гөлсемне кочаклап алды да. битләреннән, күзләреннән үбәргә тотынды. Сабыр табигатьле, юаш холыклы Гөлсем бу хәлгә бик аптырый калды:

— Ни булды сиңа, балакай? Әллә кияүгә чыгасыңмы? — диде.

— Ә син каян беләсең? Каян беләсең?!

— Гомердә булмаганча кыланасың бит. Күзләрең үк урыныннан купкан. Нәрсә, әллә Солтан белән вәгъдә бирештегезме?

— Ул мине яратуын әйтте. Ул миңа өйләнешик диде. Шуннан соң минем бөтен тәнем ут булып яна башлады.

Гөлсем, сабакташын үтә дә якын күргәнгә, киңәш бирүне кирәк тапты.

— Син, Нурия җаным... егетләргә бигүк ышанып җитмә. Тасма телле булып куймагае.

— Юк, юк, юк! Без инде Солтан белән бер-беребезне Алабугадан башлап яратабыз. Әйтергә генә кыймый йөрдек. Аның миңа нинди хатлар язганын белсәң...

— Туктале, кызый, син бит әле укып бетерергә тиеш.

— Ә ул миңа, беләсеңме, нәрсә ди? Я без бозылып китәрбез, чибәрлегебез бар чагында өйләнешеп калыйк, ди. Ул, исәрбаш, картаербыз, битләребезгә җыерчык басар дип курка инде, әйеме? Бозылырбыз дигәне — картаербыз дигән сүз...

Гөлсем аңа карап баш селкеп торды.

— Бигрәкләр дә бала шул әле син. Буең үскән, акылың аланнарда торып калган. Егетеңнең ни әйтергә теләгәнен аңламыйсың. Җүләркәем, ул бит сиңа башка егетләр белән танышып йөреп бозылуың турында әйткән. Белдеңме инде?

Нуриянең үз аңлавы үзенә ямьлерәк иде. Гөлсем бүтәнчә аңлаткач, ул бик күңелсезләнде, урынына барып ятты да озак кына дәшмәде.

Көтмәгәндә аларга Кәшифә килеп керде. Нурия аңар ташланды, Гөлсем әйткәннәрнең хак түгеллеген, Солтанның аны өзелеп яратуын кабат-кабат, ярсынып-ярсынып аңлатырга тотынды.

Кәшифә аны, тынычландырырга тырышып, караватка алып килеп утыртты, үзе дә аның янына утырып, яратып, үз итеп, чәчләреннән сыйпады, толымнарын яңабаштан сүтеп үрде.

— Менә син иргә чыгам дип ашкынасың. Ә балагыз булса? Әле бит сезгә бик күп укырга кирәк. Кем соң мине Казанга укырга китәбез дип кыстады? Кем мине ялгыз әнием яныннан үгетләп алып килде? Кем соң әтисе йортында алмагачы, чия агачы үстерергә хыялланып йөри? Кем соң рабфактан соң авыл хуҗалыгы институтына керәм дип сөрән сала? Син түгелме, балакаем? Шулай инде ул, вәгъдәне бирүе генә ансат аны, үтәве ансат түгел.

Нурия урыныннан сикереп торды, толымнарын атындырып, бүлмәдән ялан аяк йөгереп килде дә, Кәшифәне кочаклап:

— Ә балалар бакчасы? Ә ясле? Аларны соң ни өчен төзиләр? —дип ябырылды. — Юк, юк, авызыңны да ачма, ниятеннән кире кайтарырмын дип азапланма да! — Сүз әйтә башлаган Кәшифәнең авызын учы белән каплады. — Мин аны яратам! Мин аңа кияүгә чыгам. Мине бер генә кеше дә туктата алмый! Сез минем бәхетемнән көнләшәсез: син дә, Гөлсем дә! Сез минем бәхетле булуымны теләмисез!

... Нурияне торакларына кадәр озаткач, Солтан үзләренә кайтты. Аның күңелендә үзәк өзгеч моңсу, шул ук вакытта җанын кемдер йомшак каз канаты белән сыйпап торган төсле рәхәт иде. Ул, беркемгә бер сүз дәшмәстән, койкасына килеп утырды. Ләкин эчтән генә тынып уты-

ру мөмкин түгел, кемгәдер нәрсәдер сөйлисе килә. Ләкин нәрсә әйтергә, ничек итеп сөйләргә — сүзе юк. Кайгымы бу, шатлыкмы? Йөрәк яна, тән тетрәнә, бугазны нидер кыса, кычкырып елыйсы килә.

Яше белән дә, акылы белән дә Солтаннан өлкәнрәк булган Имам Каһарманов, җилкәсенә шинелен салган көйгә, аның янына килде.

— Ни булды сиңа, Солтан? Әллә Нурия белән ачуланыштыгызмы?

— Ачуланышмадык, Имам абый! Бергә Кабан күле буенда йөрдек...— Солтан тотлыгып кала, әйтер сүз эзли, таба алмагач, дөресен әйтеп бирми булдыра алмый.— Мин аны үпкәнием, йөрәгем әллә нишләде, елыйсым килә.

— Ела, энем, ела, Солтан. Син бәхетле кеше: син гашыйк булгансың!

— Ул да мине яратыр микән соң? Нишләрмен мин, әгәр ул мине яратмаса, башкалар белән алыштырса?

— Яратыр, ул бик яратыр сине.

— Каян беләсең?

— Авыр чакта сине эзләп килде бит. Синнән ярдәм көтте. Ә син аңа ярдәм итәргә әзер торган калай әтәчләр беткән дисең мәллә? Шул ук Галләмов! Козгын кебек әйләнә аның тирәсендә. Нурия баш бирми. Менә шуңа үчегә Галләмов. Беләсеңме, энем, ярдәмне теләсә кемнән көтмиләр, ятратканың белән чын дусларыңнан гына көтәләр. Ул сине яратачак. Мин... аңа әйтермен, Солтан Айдаров — миравай егет, аның яратылырга хакы бар, ул үз кул көче белән көн иткән кеше, ул революцияне мылтык тотып яклашкан кеше, диярмен...

Имам Каһарманов бу сүзләрне ихлас күңелдән сөйли, ләкин муеныннан гашыйк егеткә аларның барып җитәме-юкмы икәнен берничек тә белә алмый — Солтан, артка кайшала биреп, ике кулы белән койкага таянган, күзләре кайдадыр үзе генә белгән бер дөньяда яшн иде.

Их, Солтан! Син әле берни белмисең, Каһарманов инде сөюнең мәңге онытылмас рәхәтен дә, сөйгәнеңнән аерылуның йөрәк яргыч фаҗигасен дә кичерде. Хыянәт газабы аның җанын парә-парә телде. Ләкин ул хакта ярату хисләреннән башын җуйган егеткә ничек әйтәсең. Мәхәббәттә һәркемнең үз юлы, үз табышы, үз югалтулары. Ела, Солтан, син бәхетле кеше, син гашыйк булгансың!..

## IX

Рабфакчыларның эшкә билгеләнер вакытлары җитте. Аларны зур бер аудиториягә җыйдылар да төрле комиссариатлардан килгән вәкилләр алдына тезеп утырттылар.

Нурия сабырсызлык белән үз фамилиясен көтте. Ләкин аңар хәтле әле исемлек зур, завуч Виннер алфавит буенча бер дә ашыкмыйча, гаҗәеп бер төгәллек белән фамилияләрне укып килә иде.

Баштагы бер ун кеше укытучы булып китәргә теләк белдерделәр.

— Уразаева Нурия Габбасовна, — диде Виннер.

Нурия урыныннан торып басты, җиңел бер хәрәкәт белән чәч толымын артка чөйде. Йөзе кинәт бурлаттай янып, чигә тамырлары сулкылдап тибә башлады.

Рабфакчылар аңа төбәлделәр.

— Көтәбез, иптәш Уразаева.

— Мин... укуымны дәвам итәргә телəр идем.

— Кайсы институтта? — дип сорады пеләш башлы кеше. Нурия аның исем-фамилиясен белми, вузлардан вәкил булып килгәнен генә белә иде.

— Бакчачы булырга... — агроном.

Виннер исемлектәге Уразаева фамилиясе турысына «Сельхоз институт» дип язып куйды һәм башын күтәреп:

— Каршылар юкмы? — дип сорады.

Учком рәисе Охливанкин, сакал-мыек урынына сары бала йон гына төртеп чыккан озынча битле чуваш егете:

— Бездә Уразаева өстеннән ике гариза бар. Иптәш Галләмов белән иптәш Хамматов аны югары уку йортына җибәрү зарарлы булыр дип исәплиләр, — диде.

— Гариза бирүчеләр мондамы? — Виннер залга төбәлде.

Рабфакчылар арасыннан фәкыйрь генә киенгән, сөякчел зур гәүдәле Хамматов күтәрелде.

— Гаризаның берсен мин яздым,— диде, тотлыгып-нитеп тормастан.— Хәзер дә шул ук сүзләрне кабатлый алам. Бүрене бүреккә салсаң да урманга карый, диләр. Мулла кызы Уразаеваны институтка уздыруга мин категорически каршы. Әйе, әйе, каршы мин. Тешем-тырнагым белән каршы.

— Пластинка бер тирәдә әйләнә. Сәбәбен аңлатыгыз, — диде Виннер.

— Сәбәбе билгеле: Уразаева барыбер Совет иле кешесе булмас. Югары мәктәпкә керергә ярдәм итәсе урынга рабфакта алган стипендиясен түләтергә, институтка юлны бикләргә кирәк. Ул Алабугада укыды, укытучылар семинариясендә, ләкин эшче-крестьян балаларын укытырга авылга китмәде. Ни өчен? Аның белән бергә укыганнарның күбесе комсомолга язылды. Ә ул бүгенгә тикле комсомол түгел. Ни өчен? Җәй саен авылга, Габбас мулла йортына кайта, ни өчен ул шушы көнгә тикле әтисеннән ваз кичмәгән?

Залдагылар тоңык кына гөжләп алдылар. Комиссия бер-берсенә карашты.

— Гариза бирүченең икенчесе кем?

Нух Галләм урыннан торды.

— Ялгышмасам, сез, иптәш Галләмов, бер мәртәбә бу эшне эшләдегез шикелле?

— Эшләдем, эшлим, эшләячәкмен, завуч иптәш. Теге чакта Уразаеваны сез яклап калдыгыз. Сез аны бәлки хәзер дә совет вузына сөйрәп кертмәкче буласыздыр, ләкин ул эшегез барып чыкмас. Белеп торыгыз, мин Мәскәүгә чаклы барып җитәчәкмен.

Виннерның гасабилланудан фронтта өшеткән аяклары сулкылдап сызлый башлады, ул тешләрен кысып кына түзгән хәлдә, сабырлыгын җуймыйча:

— Иптәш Уразаева, сезне тыңлап карыйк,— диде.

Нурия теге заманнарда, Нух Галләм аны рабфактан чыгарырга әйткән чакта, авыз йомып калуы сәбәпле нинди авырлыклар кичерүен хәтерләп, үзе һөҗүмгә ташланды.

— Ачыклык кертәм мәсьәләгә.— Башта Хамматов ягына борылды:— Сез, Сәфәр абый, минем хәзерге көнгә тикле комсомолда булмавыма иң әүвәл үзегез гаепле бит. Чыннан да, бик кызык килеп чыга бит әле бу. Сез рабфакның алдынгы укучысы, күз өстендәге кашы, яшькә дә миңа караганда өлкәнрәк, партия члены булып та өлгергәнсез. Ник соң сез минем яныма килеп, ичмасам, бер генә мәртәбә булса да: «Сеңелем Нурия, сиңа комсомолга керер вакыт җитмәдеме икән?» — дип әйтмәдегез? Ник сез мине иптәшләрем алдында, эшкә билгеләнер вакыт җиткәч кенә, хурлаган булып кыланасыз? Ярый, соң булса да, киңәшегез өчен рәхмәт. Мин комсомолга керермен, мулла исемен йөрткән әтием белән дә араны өзәрмен. Быел ук өзәрмен. Тик мин әле өч ел буе бергә укыган башка иптәшләремнең дә сүзен тыңлап карарга телим, алар ни дисәләр, шулай эшләрмен.

Әйтүен әйтте Нурия, шундук куркып та калды. Иптәшләре аны якламасалар? Безгә мулла кызы кирәк түгел, без социализмны аңардан башка да төзи алырбыз дисәләр?

Беренче булып учком рәисе Охливанкин сүз алды:

— Мин Хамматов белән Галләмов гаризаларын дөрес дип тапмыйм. Уразаева бүре түгел. Ул өч ел буе эшче-крестьян балалары арасында кайнады, безнең белән бергә суык бүлмәләрдә яшәде, ачтан интекте, безнең белән бергә социалистик идеология белән сугарылды, бик яхшы сугарылды, без аны югары мәктәптә белем алырга лаеклы дип саныйбыз. Мин моны үз исемемнән генә түгел, барлык рабфакчылар исеменнән әйтәм.

— Тагын сөйләүчеләр бармы?

Нурия ни күзе белән күрсен, Кәшифә күтәрелде. Алабугадан башлап биш ел буе бергә укыган, ахирәт дусы булып бер телем икмәкне бергә бүлешкән Кәшифә. Әгәр ул, ярлы кызы булуыннан файдаланып, гариза язучыларны якласа, Нуриянең кешеләргә булган ышанычы җимерелеп төшәчәк. Ул чагында югары мәктәпкә керәм, Совет иле өчен файдалы кеше булам, әтиләр белән араны өзәм дип йөрүнең дә кирәге булмаячак.

Кәшифә торып басуын басты, ләкин әле һаман сүз әйтергә ашыкмый. Һай, шул сүлпәнлекләре, һай, шул җебегән әлләзи булулары! Ник әйтми инде, ник суыра җелекне?

Менә Кәшифә күлмәкләрен тарткалады, чәчен сыпыргалады, кибеп киткән иренен теле белән ялаштырып алды, ниһаять, алга иелә төшеп учына бер йөткереп алгач, әйтте:

— Мин Хамматов хакында бер сүз дә әйтә алмыйм. Галләмовның гадел түгеллеген әйтә алам... Ул әшәке, бозык кеше. Карьерист.

Зал тынды. Көттеләр. Виннер сабыры бетеп:

— Ни өчен? — диде.

— Ни өченме?

— Әйе, көтәбез.

— Галләмов Уразаева артыннан ухаживать итте. Уразаева аның ухаживаниесен кире какты.

Зал бик кинәт шауларга, көләргә, бәхәсләшергә тотынды. Шушы гөжләү эченнән кемнеңдер калын тупас тавышы «оятсыз!» дип кычкырды.

Көч-хәл белән тавышны туктаттылар.

Халисә Ишкәева сүз сорамый гына урыныннан торды:

— Мин Уразаева белән рабфак казанында өч ел кайнадым. Укуны ярата. Кешелекле. Бәла-каза килгәндә булышырга биш куллап әзер. Ә менә бүген бик тә тәти егетләр булып кыланган Галләмов белән Хамматов, мин лекция язган дәфтәрләрен сорап баргач, алар миңа: «Үзең язарлар!» — дип кенә җавап бирделәр. Мин андый кешеләргә ышанмыйм.

Зал тагын дуларга, тагын ярсынырга тотынды.

Нурия үзен кая билгеләүләрен дә ачыкламады, комиссиядә эшен бетереп чыгып киткән чакта да беркемнән берни сорашмады — аның күңеле ташып тулган иде. Бергә укыган иптәшләре аны яклап чыкты! Гаделсезлеккә юл куймады. Бердәмлек җиңде, аны яратып, яклап сөйләделәр. Шуннан да зуррак бәхет аның өчен юк һәм ул үзендә югары мәктәптә укырлык кына түгел, тау-ташлар актарырлык көч уянуын сизә иде.

Тагын ике көннән Кәшифә рабфак бетерүчеләргә командировкалар әзерли башлауларын ишетеп кайтты.

— Беләсеңме, Нуриякәем, мин икеләнә башладым әле, — диде ул кайтып керешкә. — Без ялгышмадык микән? Кешеләр әйтә, агроном бу-

лу хатын-кыз эше түгел, диләр, көне-төне тузанга батып йөрергә туры киләчәк, диләр. Сез лутчы врач булыгыз, врач булсаң, халыкка күбрәк файда китереп була, диләр.

Икәүләп баш ваттылар. Агроном булыргамы, әллә врачмы?

Вәсвәсәне үзе башлаган Кәшифә үзе үк икеләнә дә башлады.

— Ак халат киеп йөрү бик әйбәт. Ләкин бит анда мәет тә ярасы була икән.

— Мәет ярасы, бр-р-р! Ә без мәет яра торганына кермәбез, балалар врачы булырбыз.

Тагын бераз баш ватып, икеләнеп утыргач, врачлыкка укырга булдылар. Нурия командировканы авыл хуҗалыгы институтыннан алып, университетның медицина факультетына бирергә кирәклекне өзеп әйтте.

Әкрен кыймылдый торган Кәшифә бу юлы өстен киенергә кереште.

— Соңга калмыйк тагын! Безгә дигән командировкаларны алып бетерә күрмәсеннәр.

Икәүләп рабфакка чаптылар. Анда командировкаларны җибәреп өлгермәгәннәр иде әле. Секретарь карт Ильинский, тешсез авызын мүкелдәтеп, аңлаешсыз бер-ике сүз әйтте, иреннәрен кысып, күзлек өстеннән кызларга беркавым карап торды, шулай да командировканы алар теләгән вузга язып бирде. Күзлек өстеннән тагын бер мәртәбә карап алып, мөлаем гына елмаеп куйды.

Кызлар тынычланып кайтып киттеләр.

Кәшифәләрдә Солтан да, Имам Каһарманов та юк, алар да командировка артыннан йөриләр, ахрысы. Кызлар аяк киемнәрен салып, Кәшифә яшәгән ширма артына кереп утырдылар.

— Нуриякәем, өч ел артта калды. Университетта имтихан алмыйлар. Без хәзер — иректә кошлар. Әйдә, Зартугайга кайтып, рәхәтләнеп бер урманнарда йөрик инде, — диде Кәшифә.

Бу аның ахирәт дусы булып киткән Нуриягә укырга алып килгәне өчен рәхмәт әйтүе иде. Нурия дәшмәде, күзеннән ике бөртек яшь агып чыгып, бите буйлап тәгәрәде. Эшкә билгеләнү комиссиясендә, әтиләремнән ваз кичәм, дигәннән соң ул Зартугайга кайта алмый иде инде...

*Ахыры бар.*

## Гәрәй Рәхим

# СОКЛАНЫЙК БЕЗ ЯЗГЫ ТАВЫШЛАРГА

### Агым

Иделләргә кушылып Кама ага,
Аңа кушылып нәни Зәйләр ага...
...Җәйләр ага.

Мул күзләргә кушылып кышлар ага,
Кышка кушылып яшел язлар ага...
... Назлар ага.

Ага сулар, суда саллар ага,
Салга кунып карт бер карга ага...
... Бар да ага.

Җилләр ага, ак болытлар ага,
Нефть, руда, тимер, күмер ага...
... Гомер ага.

### Казанга керү

**1**

Мин Казанга керәм поезд белән.
Алда калка ап-ак биналар.
Чиркәүләрдәй ялгыз түгел алар,
Ялгыз түгел, бик тә күп алар.

Яшел таулар тулы ак биналар.
Беренче тау гүя ак болыт.
Казан тора бистәләре белән,
Әмәтләре белән ак булып.

Сөембикә әнә — кызыл орчык,
Цирк йорты — гүя тәлинкә.
Тәлинкә дә түгел, бер карасаң,
Охшый икән әле бәлешкә.

Үз халкының саклый бит гадәтен,
Казанның син кара рәвешен.
Поезд белән килгән һәр кунакка
Сузып тора цирк-бәлешен.

Мин поездым-нием белән бергә
(Язмышыма шулай язганга),
Кереп китәм мәңге кайнап торган
Казан дигән бик зур казанга.

2

Мин Казанга очып төшеп киләм,
Самолетым җайлы, заманча.
Аяк астым тулып ята минем
Күпме мәйдан, урам, каланча.

Торсам әгәр, басып китәрмен күк
Егермешәр катлы өйләргә.
Казан радиосы мачталары
Җырлап калды милли көйләргә.

Казан шундый ерак җәелгән ки —
Чал Кремль — нәни бер чатыр.
Бишбалталар, Кәҗә бистәләре
Үзәк урам хәзер, тап-такыр.

Ә еракта завод биналары —
Мәһабәтләр, зурлар, төрлеләр.
Эшче күңеле сыман гап-гадиләр,
Эшче күңеле сыман серлеләр.

Самолетым белән, күбәләк күк,
(Язмышыма шулай язганга),
Очып төшәм мәңге кайнап торган
Казан дигән чиксез казанга.

3

Мин Казанга йөзеп кереп киләм.
Чал Иделдә япь-яшь дулкыннар.
Муеннарын сузып зур краннар
Сәлам бирә Казан портыннан.

Казан белән Идел язмышына
Тәңгәл минем илем язмышы.
Ишетелә Идел төпләреннән
Бурлакларның моңлы тавышы.

Шушы елга мәңге бәйли кебек
Татарстан белән Болгарны.
Битләремдә җылы җилләр тоям,
Алар килгән кичеп чорларны.

Мәрмәр ярлар... Ярда неон уты...
Иделемдә Казан шәүләсе.
Тау башында очар бөркет сыман
Басып тора Җәлил гәүдәсе.

Параходым-нием белән бергә
(Язмышыма шулай язганга),
Йөзеп керәм зур бер диңгез кадәр
Казан дигән олы казанга.

4

Мин Казанга җәяү кереп киләм.
Акрын гына атлыйм, җай гына.
Күрми калмыйм тагын дигән сыман
Ниләр барын тирә-ягымда.

Һәр яфрагын күреп юкәләрнең,
Укып һәрбер урам исемен,
Назлап үтәм яңа Казанымның
Һәр кирпечен, һәр өй нигезен.

Нәкышларын иске биналарның,
Бизәкләнгән тәрәз башларын.
Музеена кереп сыйпап чыгам
Иң борынгы Болгар ташларын.

Аннан китәм Ирек мәйданына,
Газоннарга, гөлләр янына.
Университетның күккә ашкан
Яңа биналары ягына.

Мин үземне сиңа бирәм, Казан!
(Язмышыма шулай язганга.)
Әйт, күңелем, кайна, сине сәлам
Казан дигән алтын казанга.

## Мәскәүдә

... Күргәч Мәскәү урамында
Һинд дус, негр, башканы —
Искә төште гомер буе
Авылымда яшәп яткан
Шук керәшен картлары.

Кинәт кенә сызып-сызып
Сагындыра башлады
Әнкәемнең чуен белән
Мичкә куйган бәрәңгесе,
Парлы өйрә ашлары.

Яңгыр койды. Бөтен Мәскәү
Зонтикларын каплады.

Арыш кыры белән шаулап
Хәтеремә килеп керде
Туган Шөгер яклары.

Бастым мәрмәр баскычларга,
Күрдем яшел яшманы.
Шунда кинәт искә төште
Юл читендә тып-тын торган
Татарстан ташлары.

Таптым Җәлил урамын мин —
Мәскәүдә бер капканы.
Урамдагы һәр кешегә
Казанымны, КамАЗымны,
Әлмәтемне мактадым.

Әй, Мәскәвем, гүзәл шәһәр,
Ил үзәге, башкала!
Минем туган якка булган
Иң-иң назлы сөюләрем
Бүген синдә башлана.

## Моңлы уй

Син бүген дә миннән еракта,
Иртәгә дә миннән еракта,
Гомер буе миннән еракта —
Ләкин үзең һаман йөрәктә.

Мин бүген дә сине уйладым,
Иртәгә дә сине уйлармын,
Гомер буе сине уйлармын —
Юк, кимемәс минем уйларым.

Мин бүген дә авыр суладым,
Иртәгә дә авыр сулармын,
Гомер буе авыр сулармын —
Тик бәхетсез генә булмамын.

Мин бәхетсез була алмамын,
Син булганда минем уемда.
Җанда мондый сөю булганда,
Ямьсез була алмас бу дөнья.

## Сагышланма

Яшьлек үтте ярсу давыл сыман,
Булды анда байтак ялгышлар да.
Тик аларга карап сүнмә, күңел,
Сагышланма.

Көзләр җиткәч яшеллеген җуя,
Сары төскә керә камышлар да.
Тик аларга карап моңайма син,
Сагышланма.

Җирдә шундый дәртле гөрелтеләр...
Сокланып кал язгы тавышларга.
Гомер үтә диеп өзгәләнмә,
Сагышланма.

## Бәйрәм көткәндә

Шундый бәйрәм килер бүген безгә —
Без шатлыктан җырлар җырларбыз.
Тәрәзәне ачып куярбыз да
Төнге серле өнне тыңларбыз.

Өстәлләрдә булыр тәмле ризык.
Күңелләрдә татлы хыяллар.
Безнең утка килгән күбәләкләр
Бездә бәйрәм назы тоярлар.

Шәраб исен иснисе дә килмәс,
Татлы сүзләр безне исертер.
Язгы дөнья ачык тәрәзәдән
Безгә җылы җилләр китертер.

Тыелгысыз булыр яшерен дәртләр,
Тотанаксыз булмас тик алар.
Тәннәр буйлап тыйнак дулкын узар —
Кавышырлар күктә дөньялар.

Күпме көтеп алган бу кичәне
Бездән беркем тартып алалмас.
Иң хәйләкәр гайбәт иясе дә
Безне моннан эзләп табалмас.

Тапса да ул, күреп бу хозурны,
Җөрьәт итмәс монда керергә.
Әгәр керсә... Керсә — бөек наздан
Үз үлемен табар биредә.

Шундый бәйрәм килер бүген безгә —
Котылырбыз гайбәт, үчләрдән.
Сөйкемле һәм җайлы булыр дөнья
Безнең татлы, рәхәт хисләрдән.

1976

## Марсель Галиев

# КАЙТАВАЗЛАР

*Шигъри парчалар*

### Әби

Әби, син Тукай белән бер яшьтә икән бит!

Әбисе дәшми. Хәтерен барлагандай, кулындагы дисбе төймәләрен чыгара да:

— Син Әмәт чишмәсен беләсеңме? — ди.

Малай агач улактан инешкә чылтырап агып торган чишмәне күз алдына китерә. Хыялында әбисенең йөзе алсулана, чәчләре карала төшә. Менә әбисе, ундүрт яшьлек кыз, ак киндер күлмәген җилфердәтеп, үткән гасыр ызанынннан бүгенгегә таба йөгерә. Менә ул...

— Әби, Тукайны күргәнең булдымы синең?

Әбисе сагышлы елмая һәм «юк» дигәнне аңлатып баш селки. Малайга бу бик сәер тоела. Ничек инде, бер чорда яшәп тә...

Әбисе тәрәзә төбендәге гөлнең сулып куырылган чәчәген өзеп ала.

— Гөлгә яктылык җитми, су да сибәм, югыйсә, — ди.

### Тәэсир

Төн. Шалаш. Улы әтисенең шыгырдап торган протез каешын чишәргә булыша.

Тынлык. Кинәт йолдыз атыла. Хәнҗәр кебек ялтырый да төн кынына чума. Шул мәлдә кипкән яфраклар өстеннән җиңелчә шыбырдау уза: гүя аларга йолдыз тузаны коела.

Менә ерактан, төн тирәнлегеннән, җыр яңгырый башлый. Моңлы аһәң, төнге тугайларга сыеша алмыйча, киңлек даулап тарала. Якыная, якыная, якыная!

Ярсынган күңеленә сыеша алмыйча, әтисе тәэсирләнеп сикереп тора һәм... чайкалып артка чүмәлеп киткән чагында улына таянып өлгерә. Әтисе, аягын ял иттерим дип, сыңар протезын салып куйганын онытып күтәрелгән икән.

## Җан бирерлек булсаң гына...

Нәни малай буе җиткәнче үрелә, ак морҗага беренче сызыкларын төшерә. Сызыклар моннан меңнәрчә еллар элек гранит ташларга ясалган рәсемнәрне төсмерләтә. Ул гүя кешелекнең бала чагын кабатлый.

Үсә төшкәч рәсемнәрен ул кәгазьләргә күчерә. Рәсемнәр көннән-көн арта, камилләшә бара.

Әбисе аңа:

— Сурәт ясама, улым. Үлгәч үзеңнән җан сорарлар, — ди. Әбисенең сүзләре аңа көлке тоела.

Зур галереяларда ул әбисенең сүзләрен кабат исенә төшерер. Чынлап та шулай булса... Заманга йөзтүбән ауган картиналардан төшкән каһарманнар, Вакыт итәгенә тотынып, теге дөньяга юл алырлар иде — кайсы таякка таянып, кайсы ялангач, кайсы бөтенләй хәлсез... Алар — үзләрен тудырган рәссамнарны эзләп баручылар. Җан сорарга...

Ислам дине әнә шундый шомлы киная белән күпме туачак рәссамнарның рухын богаулаган. Ә чынлыкта исә бу: — Әсәрләреңә җан бирерлек булсаң гына сәнгатькә алын! — дигән шартлы ишарә генә түгелме?..

## Зәвык

Сәгать тавышы. Әйтерсең чиксез Вакыт океаныннан тамчылар саркый. Там, там, там... Сәгать башында рәсем — «Иртәнге нарат урманы». Вакыт тавышы, мәңгелек хәрәкәт һәм тыныч урман... Бу манзараны ул кайдадыр күргән кебек. Үтә дә таныш, табигый картинага ул сокланып карый. Күпмедер вакыттан соң бу рәсемгә битараф булачагы уена да килми.

Әгәр «табигатьне көзгедәгечә чагылдыручы» сәнгатьне инде төсле фотография узып китмәгән булса, «мин дөньяны шулай күрәм» дип бәян итүче Ван Гог, Чюрлёнис картиналарына ул мөкиббән китәр идеме? Бу бөек рәссамнарның замандашлары кебек үк аларга көлеп кенә карамас идеме?

Кем белә, бәлки ул картлык көнендә Шишкинның «Иртәнге нарат урманы»на яңадан кайтыр. Сагынып...

## Сурәт

Шәһәр урамында уйдык-уйдык шәфәкъ алсулыгы. Урам иңләтеп атлылар чиүе кирә. Тояк тавышы ишетелми... Гаскәриләр йөзендә тантана, җиңү горурлыгы.

Тояк тавышы ишетелми.

Шәһәрдә ник бер өн, ник бер хәрәкәт булсын. Мәһабәт диварда канлы кул эзе. Бу кул эзе — аркасына ядрә тигәч, йөзтүбән аумас

өчен, стенаны умырырга теләп тотынган ирнең соңгы теләге, нәфрәте.

Фанфаралар уйнатып атлылар керә. Тояк тавышлары ишетелми. Сафлар алдында — алмачуар атта һәйкәл булып тарихка сикерәсе горур меңбашы.

Урам уртасында җимерелгән дивар ташына утырган бөкре карчык — бу илнең исән калган бердәнбер җаны, шаһиты. Дулкын булып килгән сафлар карчык алдында туктала. Карга авазлары, шом салып, тынлыкны кылыч кебек кисә.

Меңбашы карчыкка торырга кушып ымлый. Бөкре карчык — телсез, хәрәкәтсез... Тапталган иленең тарихын, хәтерен күтәреп ул аягына баса алмый инде.

Кылычын күтәргән җәлладны меңбашы кычкырып туктата:

— Тимә, яшәсен!..

Ә кемдер: «Примитив сугыш театры», — ди дә бүтән сурәтләр янына юнәлә.



## Юл. Күпер. Офык

Стенадан Джоконда карый. Күзләрендә — яшерен, тыенкы елмаю. Бүлмәнең кайсы гына тарафына сугылма, үтемле караш, эзәрлекләп, синең арттан юнәлә.

Арада — гасырлар. Кайтавазы гына калган яшәеш. Бу гадәттән тыш елмаю — тормыш, яшәешнең үзе түгелме?!

Леонардо гомер буе гаҗизләнеп тә ача алмаган фәлсәфи соравын Джокондага бүләк иткән. Бөек рәссам рухы сихри күзләр аша кешелеккә төбәлгән.

Илаһи сынга карап:

— Синең бернинди дә сереҗ юк! — дип кычкырасы килә.

Күзләр мыскыллы көлә.

Арада — тын упкын.

Джоконда артында — юл, күпер, офык... Леонардо киткән юл. Матурлык, изгелек, серлелек сагына Джоконданы калдырган да үзе китеп барган. Мәңгелеккә таба. Серен ачкан кешегә генә Джоконда тайпылып юл бирәчәк.

Мона Лиза кинаяле елмаеп кешелеккә карый:

— Я, тагын кемнәр?!

## Җиңелү

Ул пианино каршына утырды. Клавишлар өстеннән бармаклар йөгереп үтүгә авазлар, сибелеп, төрле төсләргә таркалды. Билгесезлек биләвендә йокымсырап яткан өр-яңа симфония сискәнеп уяна, канатларын җәя башлады.

Стеналар артка чигенде.

Бүлмәгә диңгез тулды. Дулкыннар шавы һәм кояш тирәли биюче су кызлары...

Пианиноның кара көзгесендә тантаналы күңел чагылышы — бәхетле күзләр.

Кинәт! Су кызлары оялып туктап калды.

Ул сискәнеп артына борылды. Анда... мәһабәт тау булып Бетховен басып тора иде.

## Хәтер

Кышкы суыктан стеналар зыңлап куя. Мич артындагы сәндерәдә сагаеп малай чак ята. Асылмалы лампа астында гәпләшеп утыручы картлар. Куыгы бик пөхтә чистартылган лампалы өй якты тәрәзәләре белән әллә каян үзенә чакырып тора. Кич утыру. Хатирәләр. Бәетләр. Риваятьләр...

Кәбисә ел бураннары ак чәчле картларны үзләре белән алып киткән. Эзләрен буран күмгән.

Хәтердә бары лампа куыгыннан түшәмгә төшкән якты турысында көйгән эз генә калган. Сүнгән учак урыны кебек...

## Янау

Кулыннан тотып ул шәкертен шигъри матурлык иленә алып керде. Яңа дөньяларның пәрдәләрен күтәрде. «Төнлә атылган йолдызны һәркем күрә ала, ә менә син көндезге күктән өзелгән йолдыз тавышын ишет», — дияргә ярата иде ул. Ә бер көнне...

— Хәзер инде минем сиңа кирәгем калмады. Синең үз кыйблаң, — дип, шәкертенә фатиха бирде.

Учак янында алар төне буе утырдылар. Остаз саргаеп беткән китапларын, кулъязмаларын берәм-берәм утка ташлый торды.

— Яшьлек гөнаһлары. Мин алардан ваз кичәм. Ә син гаҗәпләнмә. Заманы шундый иде...

Учак яктысыннан сирпелгән кызыллык остазының ак чәчләренә, җыерчыклы йөзенә үрмәләде.

Остазының һич икеләнү-сызланусыз үткән иҗатын утка бирүенә карап, ул шундый уйга килде: «Тәңре аңа тагын утыз ел гомер өстәсә, йөз яшендә ул бүгенге иҗатын ничек хөкем итәр иде икән?»

Учакта бөгәрләнеп янган кәгазьләр, кара бармакларга охшап, кемгәдер янаган кебек булдылар.

## Матур алдану

Әгәр шигърияткә битарафлык туса, Венера оялып таш киемен иңенә салыр иде.

Шөкер. Хатын-кыз һаман да үзен шигъриятнең таҗы дип саный. Горур гына бәян итә ала: «Барысы да миңа табынудан...»

Шигърият эчтән генә пышылдый. «Миндәге матурлыкның син бит бары көндәше генә...»

## Клара Булатова

•

Чатнап торган аяз кичнең бере.
Башың чөеп баксаң, түбәндә
Көмеш тояк яшь ай-колын йөри,
Йолдыз чүплэп зәңгәр үзәндә.

Ай да әле синең кебегрәк,
Сабыйларга кызык табыла:
Тугыз катлы өйгә баскыч терәп
Меник микән, улым, янына?

Нәрсә тора безгә? Ай-колынның
Тоягыннан ал да бер тотып,
Чатнап торган аяз көз күгеннән
Утыр шуннан йолдыз ыргытып.

### Яшел чирәм, сары тузганак

Улым утыра шундый җитди төстә,
Нидер буяп, нидер сызгалап.
Үрелеп карыйм. Рәсем ясый икән:
Яшел чирәм, сары тузганак.

Чирәмлектән аста су йөгерә,
Зәңгәр төскә анысын буяган,
Өстә кояш, сабый күзләренә
Шулар күчкән олы дөньядан.

Дәфтәренә бала якты язны,
Тыныч майны куйган күчереп.
... Вата күрмә берүк шул дөньяны,
Бөтен сакла аны, Кешелек!

Мәңге шулай: чәчәкләр —
Сабый кызның учында,
Үсмер кызның түшендә,
Җитү кызның чәчендә,
Хатыннарның кулында,
Бәхетлешең юлында,
Ялгызакның уенда,
Парлыларның туенда,
Очрашканның куенында,
Кемнең бакча түрендә,
Кемнең тәрәз төбендә,
Аерылганның исендә,
Онытылганның төшендә,
Ирнең кабере өстендә —
Мәңге шулай: чәчәкләр...

## Салисә Гәрәева

### Тимер елый

Тимер елый. Минем үзәк өзгеч
Шул тавыштан йөрәк сызлана.
Телем-телем тиресе салдырылган
Тимерне мин өзелеп кызганам.

Колагымны яра инәлүе,
Баш миенә үтә яшендәй:
Тимер әрнүеннән керфегемә
Эленеп кала кайчак яшем дә...

Авыртуны тимер кисәге дә
Белә кебек... Бәлки беләдер?
Корал булып кеше үтергәнче
Тимер әллә ничә үләдер?

### Цехта

Станокта токарь — татар кызы
Деталь ясый, чарлый, сыр сыза.
Станогы кызның кулларына
Буйсына да гүләп җыр суза...

Корыч йомычкалар — сары бөдрә,
Агалар да алар агалар,
Станокның тигез гөрләвеннән
Туып тора тагын яңалар.

Йомычкалар авыр пресс белән
Кысыла да китә мартенга.
Ә бераздан, алтын сары булып,
Кояш чыга мартен артында...

●

Җир әйләнә Кояш тирәсендә —
Шуңа охшаш хәлгә юлыктым:
Карусельле олы станокның
Баскычында дөньям оныттым.

Җир шарының әллә яртысы бу —
Әйләнә дә бер шар әйләнә.
Күк һәм зәңгәр кайнар йомычкалар
Бер-берсенә килеп бәйләнә.

Ә расточник егет нык кулында
Әйләндерә кебек Җир шарын.
Җир шарының имин әйләнүе
Нык кулларга бәйле, дусларым.

## Көз

Көз яңадан сары чәчле җилен
Илче иткән Илмән тавына:
Җир орыну белән яшел усак
Кызыл учак булып кабына.

Миләшләрнең хәзер горур чагы —
Төймәләре кызыл якуттан.
Яшь кияүләр хәзер авыз итә
Чөгендерле кызыл катыктан.

«Жигули»лар белән туйлар уза,
Мичкәләрдә уйный әче бал...
Яшен тизлегендә яшьлек уза —
Җаның сөйгән ярга дәшеп кал!

Көз яңадан сары чәчле җилен
Илче иткән Илмән ягына:
Сары яулык булып чорнала ул
Кызыл завод торбаларына...

●

Мин әйләнеп чыктым Тургаякны,
Бастым дулкын юган ташына.
Кыяларга басып колак салдым
Ярга суккан дулкын тавышына...

Бөрлегәннәр өздем урманыннан,
Чәчәкләрдән үрдем такыя.
Серен ачты миңа яшермичә
Таганайда һәрбер тау, кыя...

Акчарлаклар очты баш очыннан
Дулкыннарда күкрәк чылатып.
Шул дулкыннар бөтен хәсрәтемне
Агызып китте, мине елатып.

Яңа туган бер нарасый кебек,
Чистарынып калды күңелем.
Чәчләремә көмеш итеп алдым
Дулкыннарның ап-ак күбеген...

●

Никадәр дәрт кайный әле күкрәгемдә
Йолдыз булып балкыр өчен күкләреңдә
Тормыш язым.
Гомер юлы аккан судай бара үтеп,
Таңнарымны каршылыйм мин бәхет көтеп,
Уйный сазым...

Яңа көннәр туа — алар дәшә алга,
Борчуларым, үткән юлдай, артта калган —
Яшәү кызык.
Үз сукмагын үтәр өчен, басып ташка,
Кызым тора юл башында, ал кояшка
Кулын сузып.

## Казан төне

Казан төне. Йолдызлары тере —
Күктә дә бар алар, җирдә дә,
Җем-җем итә алар — таң җилләре
Йолдызларны гүя җилгәрә...

Аксыл-сары, зәңгәр, кызыл утлар
Ялмап тора цирк гөмбәзен.
Балкып янган Казан утларыннан
Йолдызлы күк үзе көнләсен!

Еракларлан, Идел аръягыннан
Аваз килә. Әйтә Җир-ана:
— Элеккечә мәгърур безнең Казан,
Игелекле бул, кызым, син аңа!

...Сиңа минем йөрәк омтылышым,
Ак Казаным, ишет, өн салам:
Еракларда — Урал туфрагында
Йөз аклыгың саклый кыз балаң!

## Резеда Вәлиева

# МӘХӘББӘТ ДӘФТӘРЕННӘН

•

Мин авырдым озак. Көттем сине,
Белсәм дә син ерак икәнне.
Ялвардым мин: — Кайт син! Юллар, тизрәк
Кайтарыгыз минем иркәмне!

Мин ялвардым...
Шулай көткәнгәдер,
Бер көн төшләремә кердең син:
Кояш кебек балкып елмайдың да
Яннарыма атылып килдең син.

Толымнардан сызлый башың диеп,
Чәчләремне сүтеп тараттың.
Кулларымны куеп йөзләреңә,
Күзләремнән үбеп яраттың.

Назга сусап сулган бала төсле,
Елый-елый көлдем, куандым.
... Шундый иде синең назлауларың —
Мин йокымнан савыгып уяндым.

•

Без китәбез, дуслар озаталар.
Кайсы үбә, кайсы кочаклый.
Ә бер караш күзли читтән генә —
Ник ләззәтле соң ул бу чаклы?

Аерылыштык. Сау бул, димәдем мин,
Озатырга кил дә димәдем.
Ә шулай да үзем ул яраткан
Зәңгәр күлмәгемне кигәнмен.

Карашларын кудым күз алдымнан,
Күңелемнән — назлы сүзләрен.
Ә күзләрем, берни сизмәгәндәй,
Аны көтте, аны эзләде.

Ул очратты минем карашымны,
Күзләренә ялкын кабынды.
... Их, син, йөрәк!
Вәгъдә биргән булдың онытырга,
Поезд киткәнче үк — сагындың...

## Шәрига Таһирова

### Тукайга

Тукайны күрергә очам
Апрель канатларында.
Сабыйлыгын бер назлармын
Боеккан чакларында.

Ул әллә китеп барамы?
Киләме әллә кайтып?
Чаба Тукай пар атында
Тарих кырын чыңлатып.

### Ярты көлчә

Кырыс көзнең салкын көне иде
Без ачканда мәктәп ишеген.
Ничек хәтерләмим, укытучым,
Ничек искә алмыйм исемең.

Портфелеңнән алып сындырдың да
Ярты көлчә бирдең, кадерлем.
Бүген менә ярты байлыгымны
Сиңа тапшырырга әзермен.

«Ризык! Ризык!» иде күңелемдә,
Каян сиздең минем уемны?
Ярты көлчә сабый йөрәгемә
Ярты дөнья булып тоелды.

Кыр казының саубуллашу җырын,
Зәй буеның дымсу җилләрен,
Алсу-кызыл яфракларга төреп,
Бәйрәмеңә синең җибәрим!

### Яусана, кар!

Ак ләләләр сипкән кебек
Тәлгәш-тәлгәш яусана,
Тирә-якка сафлыгыңны,
Пакьлегеңне салсана!

Сагышларны куа-куа,
Керфекләргә кунсана,
Шәрә калган агачларга
Ак мамык шәл булсана!

Яусана, кар, каплый-каплый
Күзге җир караларын,
Капла син салкын булсаң да
Күңелем яраларын.

## Саубуллашкан чакта...

Җәем белән саубуллашкан чакта,
Үтмә тәрәзәмә күз салып,
Бу таңымның чакыру җыры булып,
Торма юлларымда тукталып.

Уйчан гына карап юкәләргә,
Көтә-көтә болай атлама.
Сукмагыңа сары яфрак төште,
Минем сагыш бит ул, таптама.

Син түгелме үрелеп яфрак өздең,
Башкалардан яшел булганга,
Саргайдым мин, җиде җилгә каршы
Хәбәр көтеп басып торганга.

# Эльмира Шәрифуллина

## Диңгезче малае

... Кыштыр-кыштыр
Дәфтәр бите буйлап
Бөтерелә буяу каләме...
Ул сулары! —
Ай-һай! Кара-кучкыл,
Дулкыннары —
Алып кадәрле.

Шаулы диңгез.
Малай басып тора
Моңсуланып биек ярында.
Ә корабы инде китеп барган —
Бик озакка микән — тагын да.

Апельсиндай түм-түгәрәк кояш,
Суга ап-ал тасма сузылган...
Малай белми нәкъ шул мәхәббәтнең
Дәшәчәген ата юлыннан.

## Бозлар китә

Бозлар китә, бозлар китә,
Су өсләре — ак күбек.
Ярсып тибә сыман йөрәк,
Һәм сызлана да кебек.

Бозлар китә шик-шөбһәләр,
Борчулар белән бергә.
Ярый әле, язлар килә,
Җан керә, бозлар, сезгә.

Ярый әле, кузгаласыз,
Күңелне кузгатасыз.
Ваемсыз, тыныч көннәрне
Дәрьяга озатасыз.

## Апаларга, әниләргә

Йомышыгыз төшсә әгәр,
Сер бүлеп сөйләшегез.
Авыр чакта, кирәк чакта,
Кызым, дип эндәшегез.

Кайгылы көннәрегездә
Күреп бер киңәшегез.
Шатлык китерербез сезгә,
Кызым, дип эндәшегез.

Ерактагы балагызны
Килсә бик күрәсегез. —
Хатлар аша, әй, аналар,
Кызым, дип эндәшегез.

## Синең сүзләр

Авырганда йомшак сүзләр әйтеп,
Әче дару бирде чит кеше:
Көчем кайтты аяк-кулларыма,
Әйбәтләнде йөрәк тибеше.

Синең сүзләр ләкин яшьләндерде
Өмет белән тулган күземне:
Иреннәрем кипте,
Хәлем китте,
Кабат авыру тойдым үземне.

Йөрәгемне
Чит кешеләр дәвалады,
Синең сүзләр кабат яралады.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАЧЫСЫ

Харисның Мәскәүдән кайтуы КамАЗда меңенче машина чыккан көнгә туры килде. Әле эш башланырга иртә булса да, өенә кереп тормады, портфелен күтәргән килеш, ул киностудиягә ашыкты.

Студиядә үзен әле берничә көн элек кенә хәерле юл теләп озатып калган вахтер түти белән: «Әллә кайтып та төштеңме?» «Нигә кайтмаска? Беренчесе дә түгел, әле соңгысы да булмас безнең кайтуларның»,— дип иркенләп бер күрешкәч, юл әйберләрен шунда ук, проходнойда, калдырып, Харис ишегалдына бакчага чыкты. Анда аларның өмәләр ясап, бергәләп карап үстерә торган алмагачлары җимеш өлгертеп утыра. Төп бер хуҗасы булмагач, быел бакча урман аланына охшый башлаган иде. Мәскәүгә китәр алдыннан гына, каравылчы карт белән икәүләп, алар шунда үлән чапканнар иде. Ул юкта карт аны чүмәләгә өеп тә куйган. Алмагачлар ышыгындагы бер эскәмияне сайлап, Харис бераз ләззәтләнеп утырып алырга ниятләде.

Хор белән булмаса да, кошлар сайрый. Үзләре кайда соң болар, дип эзләнә башлаган иде, шулчак аның күз карашы каршындагы өйнең морҗасына төште. Һәм анда кагына-кагына сайраган кошны күреп, ул кычкырып диярлек көлеп җибәрде. Әгәр шунда кеше булса, аның мондый сәер кыланышына гаҗәпләнми һәм сорамый калмас иде:

— Син нигә әле болай үзалдыңа шыркылдап утырасың?— дияр иде, мөгаен, бәлки әле маңгае тирәсендә бармакларын боргалап, мәгънәле төстә ишарә дә ясар иде, ягъни:

— Син нәрсә, егет, әллә бераз ычкындыңмы?

Ә Харис аңа үпкәләмәс иде һәм дә, тартынып тормыйча, әле генә күз алдына китергән күренешне тасвирлап бирер иде. «Безнең авылда шундый ырым бар,— дияр иде ул.— Әгәр сандугач кунып сайраган куакның чыбыгы белән күңелең төшкән кызга кагылсаң, синең мәхәббәтең сөйгәнеңә дә күчә, имеш. Шундый матур ырым менә. Ә монда, шәһәрнең урта бер җирендә, әнә, күрәсезме, кошлар морҗага кунып сайрый. Әлеге ырымны ярдәмгә чакырган егет әнә шул морҗаны кубарып төшәргә һәм шуның белән мәхәббәтенең иясенә кагылырга... тиеш була түгелме? Болай иткәндә матур ырымнан фаҗига ясавы да ерак йөрми». Менә шундый күренешне күзаллап, бөтен бакчаны яңгыратып, тагын бер көлде дә Харис студиягә юнәлде.

...Мәскәүгә ул «Беренче КамАЗ» дигән соңгы фильмын тапшырырга барган иде. Юлы уңганлыгын белеп, хезмәттәшләре аны бик көткәннәр, күренүенә сырып алып, сорауларга күмделәр.

— Я, ошаттыларммы КамАЗны?

— Эше беткәнме фильмның?

— КамАЗ ошый инде ул, ә менә фильмның эше бетмәгән,— диде ул һәм, үзенә кирәкле кешеләрнең янәшәсендә булуын күреп алып:— Зәки, Тамара, әйдәгез үз урыннарыгызга,— диде һәм тавыш язу бүлмәсенә юнәлде.— Ә син, Володя, дикторны алыштырырсың...

Владимир Игнатюк — үзе режиссер кеше. Мәскәүдә фильмга карата нинди тәнкыйть булганлыгын Харисның бер сүзеннән аңлады. Ул аны тыңларга әзер иде, һәм чыннан да Харисның иң күп киңәшләре дикторга булып чыкты...

Татарстанда авыр йөк автомобильләре заводы һәм яңа шәһәр салу турында хөкүмәтебезнең карарыннан соң нибары алты ел узды. Шундый зур гигант өчен

ул — нибары алты ел! Синең белән минем өчен, КамАЗны төзүче гади кешеләр өчен исә алты ел — үзе бер гомер ул!

Күтәп тору белән куып тотудан да кыенрак нәрсә юклыгын үзең беләсең. Көтеп утыру түгел, бәлки шул көнне якынайту хакына алты ел буе тырышкан кешеләр өчен беренче КамАЗ конвейердан төшкән көн — истәлекле көн, аңлыйсыңмы шуны? Истәлекле дию генә аз, бәйрәм көне, төшенәсеңме шуңа? Күрәшеп алган бәхеттән дә шатлыклырак нәрсә булырга мөмкинме соң? Шуны тоясыңмы син, Володя дустым? Шуны төшенсәң, белсәң генә, сизсәң-тойсаң гына утыр син микрофон алдына.

Диктор бүлмәсеннән Харис кайнарланып чыкты. Тәмәкесен кабызды. Тиешле кешеләрнең үз эшләре белән мәшгуль булуларыннан һәм залда дөм-караңгылыктан файдаланып, соңгы ярты елда башкарган төп эшен яңабаштан зиһене һәм күңеле аша үткәреп утырды.

Аның төп эше! Шәһәр һәм автозавод салучыларның, автомобиль төзүчеләрнең менә инде алты ел дәвамында төп эше — беренче машиналарны чыгару булды. Ә аның төп эше нидән гыйбарәт? Шуннан гыйбарәт: аның да төп эше — менә шушы беренче машиналар чыгаруга бәйле эш. Беренче машиналар партия съезды делегатларын сәламләргә Кама буеннан Мәскәүгә, Кызыл мәйданга бардылар. КамАЗның олысы-кечесе аларны озатып калды. Машинаны төзүче, монтажчы һәм шофер алып барды. Харис та алар белән иде. Аның да биленә «Кинохроника» дип язылган җыйнак кына машинасы «КамАЗ» исемле баһадирлар рәтендә чапты, алар сафында, әле алга чыгып, әле артка калып, я булмаса янга төшеп, Мәскәү урамнарын әйләнде. Бу — җиңүчеләрнең, мәскәүлеләрнең алкышлавына күмелеп, «круг почета» ясавы иде. Һәм чыннан да «КамАЗ»ны таныдылар, аларны урамны ике яклап тутырып һәм кул чабып каршыладылар. Харис машинасындагы кешеләр — аның хезмәттәшләре: операторлары, ярдәмчеләре бу чакта тиргә батып эшләделәр.

Бу — бәйрәм иде, алты ел буе йөз меңнәрнең маңгай тире белән сугарып үстерелгән хезмәт агачының беренче чәчәкләре иде. КамАЗ машиналары сафында Мәскәүне әйләнгән минутлары җаваплы эш белән тулы булса да, режиссер Харисның бик тә шатлыклы минутлары иде бу...

Иң мөһиме: аның мондый хисләрне тоярга хакы бар. Әле 1969 елның декабрь суыкларында беренче чүмеч туң балчыкны чумырып алган экскаваторчы белән янәшә фотографлар, журналистлар, киночылар төзүчеләрнең үзләреннән дә күбрәк булды. Алар инде ул вакытта ук илебез юлларында эшчән баһадирлар — КамАЗлар чабасы көннәрне күз алдына китереп яшиләр иде.

Кызыл мәйданда урнашкан аэрофлот кассасына чиратка тезелешкән яшьләрнең ул чактагы сөйләшүләрен Харис әле дә хәтерли.

— Яр Чаллы? КамАЗ кай тирәдә соң ул?

— Казан шәһәрен беләсезме? Әйе, Казан — Татарстан башкаласы була, ә КамАЗ шул Татарстанда инде. Димәк, Казан ягына карап очарга кирәк сиңа. Эх, башың яшь шул әле синең. Ярый, ярый, чәпчемә, бервакыт үзең кешеләрне өйрәтә башларсың әле...

Хәзер исә халыкара аэропортларда ул башка сөйләшүләрне ишетә:

— Казанмы? Ишеткәнем бар, тик кайда соң әле ул!

— Ишеткәнең булгач, син инде мәгърифәтле кеше дигән сүз. Хәзер мине тыңла: КамАЗның кайдалыгын беләсеңме? Әйе, Татарстанда, ә Татарстанның баш шәһәре — шул үзе, Казан була инде...

Әйе, ул һәм аның коллегалары КамАЗ тавышын еракларга җиткерделәр. Ул төшергән тасмаларда Чаллы эпопеясенең иң киеренке чорлары тасвирлана. Инде менә әлеге «Беренче КамАЗ» фильмын эшләп бетерде. Ул да Харис күңеленнән, аның хезмәттәшләре кулыннан экраннарга юл ала...

Фильмның режиссеры буларак әллә Харис кызыбрак киттеме, дикторга үзенең дә күңел күтәренкелеген күчерергә теләп, бераз купшыландымы? Йөрәк кайнарлыгын биреп бару — моңардан да җанлырак, заманчарак эш булырмы? Әйе, киләчәк үзенә кирәген сайлый белер, ә КамАЗда исә, өмәгә җыелып, бөтен илебез завод һәм шәһәр сала. Бүген сала.

Харис шул өмәдә. Кинорежиссерлар, тәзүче дуслары әйтмешли, «киношник», ягъни киночы Харис Фәхретдиновның шул өмәдә үзе генә эшли ала торган эше бар. Һәм менә алты ел инде КамАЗдан чыкмыйча диярлек шул эшен башкара. Казан кешесе булса да, Чаллыны ул яхшырак белә, аның үзенең дә анда таныш-белешләре күбрәк.

Менә карыйк: ишләрме алар?

Әгәр Харис Фәхретдинов «КамАЗ — минем мәхәббәтем» ди икән, сөйләсен әле: нәрсә өчен ул камазчыларны аеруча үз итә? Нәрсә тарта аны алар янына. Энтузиазмы артык ташып тормаска тиешле кырык яшьлек кеше бит инде ул, югыйсә. Ә андагы халыкның уртача яше — егерме өч, диләр.

— Ә мин һаман егермедә бит,— ди ул.— Онытырга мөмкинмени ул чакларны?..

...Чирәм җирләрне яшәрткән чакларны. Илле алтынчы елның җәендә Казан университеты студентлары Казагыстан далаларына эшкә барырга чыкканнар иде. Вагонда үзләре белән чит-ят егетне күреп гаҗәпләнделәр.

— Син безнең арага каян килеп эләктең?— дип сорау ала башладылар моңардан.— Кая барасың болай?

— Сезнең белән барам,— ди егет.— Мин педагогия институтыннан.

— Үзегезнекеләрдән ник аерылдың?

— Аларны җибәрмиләр бит, шуны да белмисезмени?

— Моны белү кемгә хаҗәт, ятсыннар шунда пионерлар белән ял итеп.

— Менә үзегез дә әйтеп бирдегез,— ди егет.— Миңа чирәм җирләрдә эшләү ошый төшә.

Үзләрен Казагыстанга җибәрмәячәкләрен белеп, ул университет студентлары отрядына язылган икән.

— Син безгә ошыйсың,— диләр алар егеткә.— Синең белән бергә эшләргә без риза.

Ул исә ике куллап риза. Тик менә әнисен рәнҗетмәдеме икән? «Лагерьга барам» дип чыгып китте ләбаса өйннән. Һәм аның «качуы» тиз ачылды. Моңа аның, әлеге дә баягы, тиктормас холкы сәбәпче булды. Эш шунда ки, барып төшүгә ул «Казанский» совхозында якташларын табып алды. Мондый очрашу — зур шатлык бит. Ә шатлыкны уртаклашмый түзеп булмый. Чирәм җирче якташлар Татарстанга, Дөбьяз районына хат яздылар, ә хатларында шундый сүзләр дә бар иде:

«Казаннан килгән студентлар арасында гармунчы егетне бик яраттык. Чүриле авылыныкы, Харис исемле үзе...» Сүз тиз йөрде, әнисенә дә килеп иреште. Дөрес булса, әнисе рәнҗемәгән ди, хәтта гаҗәпләнмәгән дә ди, нибары: «Минем малай бит бу, тәки нидер хәйләләвен сизенгән идем», дию белән чикләнгән ди.

КамАЗдагы хәзерге танышлары аның биографиясендәге чирәм җирләр сәхифәсен белмиләрдер, шулай да аның үзләре кебек үк энтузиаст җан булуын сизмиләрме соң?

...Абайладыгызмы бер нәрсәне: кинорежиссер Харис Фәхретдинов турында сөйләгәндә, аның яшьлегенә күчеп, бер генә сәхифәне искә алган идек, ул безнең күз алдына студент Харис, тик менә кино институты студенты түгел, бәлки педагогия институты студенты булып килеп басты. Әйе, ул — югары белемле укытучы. Горький өлкәсенә барып, анда да башка кеше урынына китеп, өч ел укыткач, Казанга бер ялга кайтканда күптәнге теләген тормышка ашырырга омтылыш ясый, киностудия директоры кабинетына барып керә.

— Югары белемле кешене йомышчы итеп алырга хакым юк,— ди директор.— Ә бездә сез башка эшкә ярамыйсыз.

— Киләсе елга кино институтына җибәрү өчен әзерләнүче сыйфатында алыгыз,— ди Харис, ялварып кына калмый, алдан ук әзерләп куелган карт һәм дәрәҗәле оператор ярдәменә таяна.

Бер ел ул кино төшерүчеләрнең әйберләрен күтәреп, йомышларын үтәп йөри. Тик бушка йөрми: карт оператор «университетын» уза. Я, әйтегез инде шуннан: җылы урыннарыннан кубып, меңәр чакрым җир үтеп, КамАЗ төзүдә катнашу өчен ашыккан кешеләр токымыннан түгелмени ул?

...Бөтенсоюз дәүләт кинематография институтын тәмамлаганда диплом эше итеп яшь режиссер Харис Фәхретдинов «Тукай» фильмын әзерли. Шушы беренче мөстәкыйль хезмәте өчен ул Бөтенсоюз конкурсында приз белән бүләкләнә. Призның да шагыйрь Тукай тормышын күрсәтүне үзенчәлекле чишә алган өчен бирелә торганына лаеклы итеп табалар аны.

1969 нчы ел була бу. Шушы ел ахырында Татарстан җиренә КамАЗ килде. Иҗат кешеләренә дә сынау, ныгу һәм эш күрсәтер өчен мәйдан — олы сабан туй житкәнлеген Хариска аңлатып торасы юк иде. Ул үзе кайберәүләрне төшендерергә керешге: КамАЗда студиянең даими пунктын ачарга кирәклеге, үзенең шунда күчеп китәргә әзер торуы турында сөйләүдән туктамады. Казан студиясенең биш автономияле республикага хезмәт күрсәтүен аның исенә төшерделәр, төзелеш купкан һәр шәһәрдә махсус пункт ачарга кешесе дә, акчасы да җитенкерәмәвен аңлаттылар.

Төшенде, аңлады, әмма күңеленнән барыбер килешмәде. Җае чыккан саен КамАЗга юл ала торган булды. Анда барган хезмәтнең эчендә кайнамыйча, геройларыңны шунда табып, алар белән әвәрә килеп яшәмичә, төзелешнең дә, төзүчеләрнең дә зурлыгын ачып булмый. Төп проблемаларны аңламый гына эшкә файдалы фильм төшерү мөмкин түгел. Ә проблеманы китереп бирмиләр, аны шул проблемалар, мәсьәләләр, бурычлар... һәм тагын әллә никадәр мәшәкатьләр туып, бәрелешеп, чишелеп, тормышка ашырылып торган җирдә генә тотып алырга, аларның чишелүенә ярдәм итәргә була.

КамАЗ тарихында һәр хезмәт елының йөзен билгеләгән үз проблемасы ачык ярылып ята. Әйтик, җир эшләре елы, фундаментлар салу елы, аннары стеналар торгызу һәм түбә ябу, ягъни монтаж эшләре... Шулар арасында бер этап — җылылык бирү белән бәйләнешле эшләр. Аның бер фильмы шушы проблеманы хәл итүчеләргә багышланган булып, «Җылылык трассасы» дип атала да. Беренче фильмнарыннан ул аның, шуңа күңеленә бик озакка уелып калган.

Елы үтә яңгырлы булды. Төзүчеләрнең иң зур дошманы ул — яңгыр. Ә режиссер Харис, эшчеләр арасында бөтен җәфаны күрсә дә, яңгыр коюына шатланып йөргән иде. КамАЗ салу ул Камада балык тотып кәефләнү генә түгеллеген күрсәтерлек шартлар тудырды Хариска ул чакта яңгыр. Хәзер шул вакытларны искә алып, киночы иптәшнең «яңгыр яу-яу, иләкләп тә чиләкләп» дигән теләктә йөрүен белсәләр, төзүчеләр аны нишләткән булырлар иде икән дип уйлап куйса, ирексездән «прых» итеп көлеп җибәрә. Аннан үзен-үзе төзәтә: «КамАЗда хезмәтнең тәмен беләләр, эш белән йөрисең икән, синең хезмәткә дә аларның хөрмәте зур». Чөнки белә ич: аңа кирәк булганда алар бер эшне кабат-кабат башкарырга да иренмиләр иде.

КамАЗга аны әре характерлы, чын ир-ат холыклы кешеләр тарта. Аның андагы танышлары шундыйлар. Бригадир Рәис Ганиев турында махсус фильм да эшләде. Рәис бөркет йөрәкле егет булып үскән, теләге дә — очучы булу булган. Ә ул — бетончы, юллар салучы. Хезмәттәге аеруча уңышлары өчен аңа Ленин комсомолы премиясе бирелде. Аңа багышланган фильмда шундый кадр бар: Рәис Мәскәүдә, зиннәтле бер залда лауреат дипломын ала. Аңа космонавт Леонов кул чаба. Әйе, Рәис Ганиев очучы була алмады, ә аны космонавтлар котлый! Кешеләрне шундый биеклеккә күтәргән төзелешкә килергә кем ашкынып тормас икән!

Фильм экраннарда режиссер җиткерергә теләгән фикерләрне, хисләрне миллионнарча йөрәкләргә күчереп йөри.

...КамАЗ конвейерыннан яңадан-яңа машиналар чыга. Почык борынлы бу баһадирларны илебез трассаларында очратып, аларга хөрмәт белән карап калсак та, без хәзер хисләргә артык бирелмибез дә инде. КамАЗ өмәсенең дә әкренләп илебездәге зур төзелешләр елъязмасына кереп калуымы бу? Харис һәм аның кебек меңләгән иҗат кешеләренең хезмәтләре дә газета битләре, китаплар, телевидение һәм кино тасмалары, радио тапшырулары сыйфатында үткәннәр турында елъязмага әверелүме?

Әлбәттә, шулай.

— Киләсе буыннар өчен без барыбыз да — елъязмачылар! — Харис Фәхрет-

динов шулай уйлый. Шул ук вакытта беренче елъязмачыларның архив кешеләре түгеллеген дә ул яхшы белә, үз иҗаты белән шуны раслап яши.

Озак та үтмәс, алар салган завод бүгенге кебек ярты елга мең машина түгел, бәлки көненә ике йөз илле, аена алты-җиде мең, ә елына йөз илле мең машина чыгарырлык егәрлек җыяр.

Ә өч йөз илле мең кеше яшәрлек шәһәр! Аны әле чыннан да шәһәр итәсе бар. Бу хакта уйланганда Харисның хәтерендә бала чакта әбисеннән ишеткән әкият яңара. Ул әкияттә җен-парилар таң әтәчләре кычкырганчы бер төндә гүзәл сарай өлгертәләр. Матур әкият. Ә бит җен-парилар гашыйк егет фәрманын, димәк, мәхәббәт фәрманын үтиләр. Мәхәббәт бер төндә гүзәл сарай салдыра! — менә ничек.

«Әби минем философ булган!» — шулай уйланып, елмаеп куя Харис.— Сүзләре дә дөрескә чыга, хыяллары да тормышка ашты. КамАЗда йөзгә якын милләт кешесе — «әйттек — бетте» дип, көнне төнгә ялгап эшлиләр: заводлар салалар, шәһәр торгызалар. Монда да гуманизм, мәхәббәт фәрманы өстенлек итә. Ә бу фәрман партия Үзәк Комитетының КамАЗ һәм яңа шәһәрне төзүгә кагылышлы карарларында законлашкан. Коммунист кинорежиссер Харис Фәхретдинов шул фәрманны баһадир машиналарга, гүзәл шәһәргә әвереддерүчеләрнең берсе булуын белеп эш итә.

КамАЗ коммунистларының бүгенге мәшәкатьләрен чагылдырган бер фильмында аның герое — партия работнигы шәһәр төзүне, торак йортлар, культура сарайлары, шифаханә һәм ашханә-кибетләр, мәктәпләр һәм балалар бакчалары төзүне тизләтә бару турында сөйләп килә дә, сүзен йомгаклап, әйтеп куя:

— Кешеләрнең шәхси мәнфәгатьләре никадәр тулырак канәгатьләндерелсә, хезмәт җитештерүчәнлеге дә шул кадәр югары була. Туп-туры бәйләнеш шундый,— ди.

Харисның «Туп-туры бәйләнеш» исемле фильмын илебездә генә түгел, чит илләрдә дә карыйлар. Германия Демократик Республикасы телевидениесе һәм башкалар аны күптән инде үзләрендә күрсәтәләр.

Харис үзенең фильмнарында заманның техника куәтен, хезмәт киренкелеген, индустрия пейзажлары романтикасын, зур төзелешнең хезмәт симфониясе аһәңен бирергә омтыла. Ләкин төп геройлары аның кешеләр — шул куәтне эшкә җигүчеләр. Төзелешнең генә түгел, һәр эшнең төп резервы — кешеләр... Иҗат кешеләре: язучымы, композитормы ул, журналист яки кино сәнгате вәкиләме — алар барысы да кеше рухы инженерлары, димәк, әнә шул төп резервны хәрәкәткә китерүчеләр.

— Менә шундый туп-туры бәйләнеш!— үз героеның сүзләре белән үз хезмәтенә дә биргән бәясе Харисның әнә шундый.

...Бүген ул «Беренче КамАЗ» фильмын эшләп бетерде. Моңа ул өч-дүрт ел элек әзерләнә башлаган иде. Инде конвейердан дистәләрчә мең КамАЗлар төшеп, илебез юлларында хезмәткә кушылдылар. Миллионынчы машина да булачак бит. Нигә әле «Миллионынчы КамАЗ» фильмын да ул эшләмәскә тиеш? Димәк, хәзердән үк әзерләнә башларга вакыт.

Тукайның да йөз еллыгы җитәр. Ә нигә соң әле КамАЗдан Тукайга, Тукайдан КамАЗга күчеп йөгерә аның уйлары, хыяллары? Нигә дип, шулай булырга тиеш икән лә бит. КамАЗ бит Тукай районында! Хыяллар түгел, ә тормыш үзе туп-туры бәйләгән язмыш икән лә бит.

Ә иртәдән бирле күңелдә яңарган күренешне дә онытмыйсы иде. Сандугач куныш сайраган куакны табып, шуның чыбыгын алып сөйгәненңнең күлмәгенә булса да кагылу турындагы борынгылар ырымын да берәр фильмда образ итеп файдаланасы иде. Димәк, ул фильм гашыйклар турында, мәхәббәт турында, яшьлек һәм мәңгелек турында булырга тиеш. Хыялында йөрткән КамАЗ һәм Тукай турындагы фильм өчен шигъри образ түгелме соң әлеге бу ырым — сандугач һәм ул кунып сайраган куак чыбыгы — күлмәгенә кагылу белән мәхәббәтеңне сөйгән кешеңнең йөрәгенә кабыза алырлык сихри чыбык... Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе кинорежиссер Харис Фәхретдинов яңа фильм белән әнә шулай илһамланып йөри.

ХӘМЗӘ ЗАРИПОВ.

Эдуард Касыймов

# ЫК ТАМАГЫНДА

*«Кама офыклары» циклыннан*



Күзләрнең явын алырлык, җаннарны иләсләндерерлек гүзәл дөнья...

Язның кинәнгән чагы... Карашыңны кай тарафларга гына төбәмә, күз нурың ни нәрсәгә эләгергә белми: еракларга китеп югалган зәңгәрсу үзәннәр... Хәтта вертолетта очкан чагында да су баскан тугайлар кайда бетеп, кайда күк чите башлануын аерырлык түгел.

Язның ягымлы һәм йомшак кояшы үзенең алтын нурларын җәлләми, дөньяны иркәләвен белә. Озакламас, ташу сулары чигенеп, данлы Кама да, яшь кызлардай чибәр Ык та үзләренең ярларына кайтыр, ә менә бүген су эченә күмелеп, кинәнеп утырган купшы тал куаклары, әрәмәлекләр һәм уйсу тугайлар ямь-яшел төскә керер.

Гаҗәп бер тынлык. Яңа Чаллының шау-шуыннан соң үтә дә сәер бу тынлык. Хәтта колаклар чыңлап тора. Ләкин озакламас — монда да сихри тын һава дәртле һәм шашкын авазлар белән тулыр. Ә хәзергә тургайлар кайда сайраша икән? Нишләп соң әле баш өстебездә аларның тансык авазы яңгырамый.

— Тургайлармы? Һе, кырлар өстендә сайраша торганнардыр, бер дә аптырыйсы юк. Кырларда чәчүгә тотындылар бит инде, — ди Мирзанур елмаеп.

Мирзанур — кыска буйлы, ачык күңелле, чандыр гына гәүдәле егет. Аягында резин итекләр, өстендә җиңел сырма. Ул — гап-гади оператор, шушында, Кама белән Ык арасындагы үзәнлектә урнашкан һәм «Күлләр» дип аталган нефть чыганагында җир куеныннан май кысып чыгаручы.

Без аның белән язгы ташу килеп җитә алмаган киң генә бер сыртта басып торабыз. Күз карашларыбыз әйләнә-тирәне иңли.

Каманың аргы як ярлары урыны-урыны белән бик тә текә. Тирән уемнар белән сырланган ул кызгылт ярларны чикләвек куаклары каплаган. Куаклыклар артында ерак-еракларга үр һәм кал-

кулыклар сузылып китә. Каманың кинәт кенә текә борылыш ясаган төшендә, үрләр сөзәкләнеп, киң генә иңкүлек ясалган. Анда үзенең «Шифалы су»ы һәм санаторие белән дан казанган Ижевка авылы урнашкан. Тап безнең каршыда әлеге кызыл ярлар өзелеп, янә бер киң иңкүлек хасил булган. Аның түренә, сөзәк калкулыклар куенына Турай авылы сыенган.

— Минем авыл Турайдан әллә ни ерак түгел, — ди Мирзанур Сабиров. — Әнә теге сырт артында гына... Әтәс дигән авыл.

Аннары ул биредәге табигатьнең матурлыгы, хозурлыгы турында сөйли башлый.

— Минем монда булганым бар, — дим мин, аның сүзен бүлеп. — Күптән инде... тугыз-ун еллар булыр. Ул чагында бик еракта, томан эчендә кебек кенә булып, бер буровой шәүләсе күзгә чалынганы хәтеремдә.

— Шулайдыр, чалынгандыр... — дип баш какты Сабиров. — Нефтьне Минзәлә конторасыннан килеп эзләделәр. Тапкач, мондагы чыганакны үзләре үк бораулап та бетерде.

Безнең янибызга таза, калын гәүдәле ир уртасы бер кеше килеп туктады. Ык Тамагы авылыннан Петр Пономарев булып чыкты ул. Сабировның хезмәттәше — нефтьче-оператор икән. Ул бик әшлекле кыяфәттә Мирзанурдан хәл-әхвәл сорашты, анысын-монысын эшләгәндә ярдәм кирәк түгелме дип төпченде. Ахырда, инде кузгалып китим дигәндә, әйтә куйды:

— Суыткычта калдырдым мин сезгә... Син, Мирзанур, зинһар кичен дә, төнлә дә күз-колак була күр инде! Таллыклар арасында берәрсе шаяртмагае дип әйтүем...

Мин, билгеле, берни дә аңламадым, ә Мирзанур исә авызыннан очкыннар чәчрәтте:

— Башлары ике булса, тыгылып карасыннар! Бер генә дә кайгырма, Петя, тынычлап йокла!

Пономарев, былтыргы соры үләнне озын куньгчлы зур итекләре белән кыштырдатып, әпен-төпен китеп барды. Озак та үтмәде, куаклар артындагы култыкта мотор гөрелтесе ишетелде. Тын һавада мотор тавышының әле ерагая, әле якыная төшеп яңгыравыннан ук бу тирәләрдә Ыкның ни тикле бормалануын чамаларга була иде.

— Тирән сулы култыкларга җәтмәләр салган иде. Шуңа пошына...

— Браконьермы әллә?.

— Ниткән браконьер ди! — Мирзанур хәтта борынын тартып куйды. — Балыкчылар бригадасыннан... Кантурлары Минзәләдә... Браконьерларны ул үзе эләп ала, селкеп сала дигәндәй...

— Тукта, ул бит нефтьче-оператор булып та исәпләнә ләбаса. Монысын тагын ничек аңларга?

— Шушы гап-гади нәрсәне дә аңламаска соң..: Петя ул үзенең напарнигы Митя дәдәй Калабанов белән бер атна буе оператор булып эшли, бер атна ял итә. Ә ял иткәндә тик ятсынмы? Митя дәдәй дә, Петя да әнә шулай бер атна буе балык тоталар.

— Ә син нишләп япа-ялгызың? Напарнигың юкмыни?

— Бар. Ирек Әюпов. Тик сырхаулап китте әле. Без аның белән авылдашлар. Бу вахтага чыга алмады. — Мирзанурның тавышы кинәт күтәрелә төште. — Ял әләккәндә без дә алай җил куып йөрмибез үзе. Ни дисәң дә, авыл җирендә яшибез, колхозда...

Бу юлы инде аның сүзләрендә җир хуҗасы булган игенченең ата-бабалардан күчә килгән горурлыгы да, тормышка аек акыл белән каравы да бик ачык сизелде...

Мирзанур белән бер скважинадан икенчесенә йөрибез. Аралары

ярыйсы ук. Озын сырт буйлата атлаганда Сабиров әледән-әле сыкрану аша әйтә куя:

— Быелтыр бу төшләрдә су иде... Быелгы ташу ташумыни ул! Тагын корыга китәрме инде, болыннар тагын такыр калырмы? Эх, яңгыр яуса икән, ичмаса, яңгыр!

Скважина янында Мирзанур бөтенләй үзгәрә. Авыз эченнән генә нидер көйли-көйли, тегесен караштыра, монысын боргалаштыра, тикшерә-нитә, ахырда, брезент бияләйләрен шапылдатып ала. Анның ябык йөзен балкытып, авыз тутырып елмая. Димәк, скважинаның эш режимыннан канәгать!

Нефть промыселларында минем беренче тапкыр гына булуым түгел, элекке елларда да байтак йөргәләгән идем. Ләкин бу юлы мин биредә үземне аптырашка калдырган нәрсәгә тап булдым. Һәр скважина янында диярлек җыйнак кына будка тора, әмма үзе буп-буш. Эчендә ни нефть кудыру насосы, ни АДУ күренми. АДУ дигәнем, русчалатып әйтсәк, «автоматическая депарафинизационная установка» була.

— Ә хәзер аларның кирәге калмады. Котылдык! — диде Мирзанур һәм җиңел сулап куйды. — Безнең бөтен скважиналарда да хәзер эчено пыяла йөгертелгән торбалар. Ә аларга парафин утырмый. Шулай булгач, АДУ ни пычагыма? Кирәкле басымнымы? Анысын скважинага төшерелгән электр насослары бирә... Нефтьне чыгара, аны торба буйлап групповойга да кудыра.

— Алай икән, — дип ияк кактым мин. — Моннан ун-унбиш еллар элегрәк, ай-һай, чиләнерләр иде шул парафин белән.

— Әйтерең бармы... АДУ булышты инде булышуын, эшне шактый җиңеләйтте. Ләкин бит автоматның да чыгымлап куйган чаклары була. Ул чакта инде үзеңә тир түгәргә кала. Скважинадагы кыргычны күтәрткәндә лебедканы әйләндерә-әйләндерә кулбашларың калмас иде. Тагы да элегрәкме, АДУларга тикелеме? Кыенның да кыены иде инде. Җиңел булмаганга күрә ул заманда бер коллектив, ягъни ике кеше, сменага нибары ике-өч скважинага хезмәт күрсәтте дә шул. Үзем иза чиктем — бик беләм, туган!

— Ә хәзер сездә ничәләп скважина?

— Ике дистә ярым... Болай исәпләгәндә, бер сменада без дә икәү генә ич...

— Бүген син әле хәтта япа-ялгызың...

— Ничево, өлгерербез, авыз-борынны канатмабыз... Заманалар үзгәрә бит, хәзер инде, туган, кул көче белән түгел, күбрәге баш белән эшләү кирәк...

Шулай да Мирзанур бер скважина янында тоткарланмыйча булдыра алмады. Монысы хикмәтлерәк скважина икән. Дебиты болай ярыйсы гына — тәүлегенә кырык тонна чамасы, ди. Әмма нефть белән бергә су да күп килә — кырык процентка тикле. Шул сәбәпле, бу скважинада нефтькә махсус дисолван куша торган насос куелган. Һәм менә хәзер шул насос эшләүдән туктаган.

Сабиров, кашын-күзен җимереп, бер мәл колак артын кашып торды.

— Ифрат та көйсез нәмәрсә. Тап хан кызы инде. Тагы пружинасы ычкынды микәнни чәнчелгеренең? Эх, әттәгенәсе, дип әйтте ди берәү.

Мирзанур өстендәге сырмасын салып ташлады, күлмәк җиңнәрен сызганды, аннан бәләкәй генә насоста актарынырга кереште.

— Менә бит, баш белән эшләү кирәк дигән идең, кулларның осталыгы да кирәк икән ич әле, — дип көлемсерәдем мин, егетемнең баягы сүзен исенә төшереп.

— Анысы шулай инде... Остармыйча ярамый хәзер! Ә болай шәп нәрсә үзе — РИТС башлыгы Шәүкәт Хәсәнов үзе керттерде. Аның уй-исәбе ярады.

— Ә нәрсәсе белән ярады алай?

— Соң, дисолван кушылдыргач, нефть судан бик тиз арына. Торба буйлап групповойга җиткәнче ук диярлек. Ә бу безнең өчен бик тә файдалы... Әһә, шул икән, пружинада икән хикмәт...

Юк, Мирзанур әлеге «хан кызыдай» кире беткән насоста алай озак азапланмады. Бер мәлне бу шәп нәрсәкәй тигез ритм белән келт-келт итеп эшли дә башлады.

— Булды бу... Эшең бетте, кодагый, дигәндәй...

Бу «хикмәтле» скважина артта калды, без ары атладык. Ерак та түгел, биек күтәртелгән металл эстакадада зур гына махина-качалка хәрәкәтсез катып тора иде. Хәер, монда һәр нәрсә: вагон да, скважина җиһазлары да, трансформатор будкасы да — әнә шулай югарыга, эстакада өстенә урнаштырылган иде. Шулай итмичә ярамый да. Зур ташу була калса, нишләргә дә белмәссең. Син һич уйламаганда, куәтле Каманың әллә ниләр эшләп ташлау ихтималы бар...

— Бусының дебиты нибары ике тонна. Шунлыктан аңа качалка куйдылар. Күбрәк вакыт тик тора. Автоматик режимда. Скважинада кирәк хәтле нефть җыелганын көттерәбез. Тәүлегенә нибары ике-өч кенә сәгать эшләп ала.

Эстакада мәйданчыгына күтәреләбез. Мирзанур әллә нәрсәләр тикшерә, боргалап карый, аның соңында бер почмакта эленеп торган саклавыч тактадагы кнопкага баса. Кинәт бу авыр махина, бик каты дыңгырдап-ухылдап, хәрәкәткә килде һәм яньчелгән олы башын, тавык ашлык бөртеге чүпләгән сыман, әле күтәреп, әле төшереп, скважина тамагын «чукырга» керешә.

— Дәүләт файдасына беравык эшләп алсын әле! Вакыты җиткәч, автомат туктатыр үзен.

Группалы установка культбудка артындарак. Анда өч булит тора. Булит — сигарага охшашлы озын һәм юан чан ул. Аны, янтайтып, җирдән беркадәр күтәртеп салганнар. Ике булит янәшә бер уңайга куелган, ә өченчесе, кечкенәрәге, шуларның очында аркылы ята. Үзара кушылып һәм үрелеп беткән торбалар. Якында гына берөзлексез гүләп-калтыранып торган куәтле насослар. Чыганактагы бар булган нефть шушында агып килә һәм моннан инде Чаллыдагы Баш корылмаларга кудырыла. Бер читтәрәк, сүнәр-сүнмәс кенә булып, бәләкәй генә газ факелы дөрли. Күрәсең, биредә газ әллә ни күп килми.

— Тозлы су, олы булитта нефтьтән аерылгач, шушы бәләкәенә җыела, — дип аңлатырга тотынды Мирзанур. — Ярап куйды ул безгә... Нәрсәгәме? Соң, скважинага ремонт үткәргәндә аны нефтьтән арындырырга кирәкме? Кирәк. Ә нефтьне ни нәрсә белән бастырасың? Иң шәбе — тозлы су. Элегрәк ремонтчылар махсус эремә ясап иза чигәләр иде. Хәзер ул үзебездә, кул астында. Акча да янга кала... Аннан килеп, артык балластны ни пычагыма дип Баш корылмаларга кудырырга, ди?

— Ә моннан Чаллыга кадәр еракмы соң? Төгәл исәп белән исәпләгәндә дип соравым.

— Нефть үткәргеч буйлап барганда төп-төгәл кырык ике километр диләр. Сезнең Баш корылмаларда булганыгыз бармы? Чамалыйсызмы кайдарак икәнен?

— Мин аның белән җирдән дә, күктән дә таныштым. Әле күптән түгел генә вертолетта нефтемагистральләрне тикшереп йөргән идек. Патруль очыш дигәндәй. Сезнең нефть үткәргеч тә, магистральный да Чаллыда Яңа шәһәр кырыеннан ук уза бит. Гомумән, зур төзе-

леш мәйданын кистереп үтә... Моның ни икәнлеген үзең дә бик яхшы аңлыйсыңдыр.

Группалы установкада Мирзанур озаграк тоткарланды. Винтильләрне тыгызлады яисә бушата төште, нәрсәләрнедер сөртештерде, тазартты, аннары куен дәфтәренә нидер язып куйды... Ниһаять, брезент бияләйләрен янә шапылдатып, миңа таба борылды.

— Булды. Бүгенгә җиткәндер.

— Ә ерактагы скважиналарга бармыйбызмыны?

— Аларына иртәгә иртәнге якта инде. Резина көймәне бик әйбәтләп кабартырмын да, турыдан, әнә теге култык аша гына сыптырырбыз. Юл яртылаш диярлек кыскарыр... Үзебезнең карын турында да онытмыйк. Ни әйтсәң дә, сез — минем кунагым бит... Балык бар — димәк, уха булыр...

— Уха?!.

Вагонның сул канаты кухня рәвешенә китерелгән: матур гына өстәл һәм урындыклар, «Полюс-2» суыткычы һәм азык-төлек шкафы, газ плитәсе һәм электр җылыткычына көйләнгән җыйнак кына калай чапчак. Шушы ук вагонның икенче почмагына рация аппаратлары да урнаштырылган иде.

Мирзанур, суыткычны ачып, аннан зур гына корбан, ярыйсы ук шәп судак һәм галәмәт дәү алабуга балыгы алды. Алабуганың кучкыл сырты кабарынып, бөкрәеп тора. Руслар андыйны «горбач» диләр. Минем гаҗәпләнүемә каршы, Мирзанур (кая монда сөенү!) бөтенләй риза түгел сыман: бәбәкләрен алартып, башын селеккәләде дә күптән инде өенә кайтып киткән иптәшенә төбәп, сукранырга тотынды:

— Эх, Петя, аңгыра баш! Балыкны нигә инде суыткычның югары өлешенә тыгып катырырга иде, ә? Калдырган балыгың бөтенләй таш булган бит. Хәзер бу килеш ничек тазартасың инде аны?

— Ярар, чәпчемә юкка. Бераз җебегәнен көтәрбез, — дидем мин аңа.

— Ә бәлкем, тизрәк җебесен өчен, бераз суга салып тотаргадыр?

— Анысын үзең кара инде, агайне. Тик нигә кирәк бу хәтле балык?

Мин корбан балыгын Мирзанурның кулыннан алып кире суыткычка тыгып куйдым. Мирзанур балыкның калган хәтлесен буш чиләккә салды да чыгып китте. Судак белән алабуганы ул беравык култыктагы суда тотмакчы.

Ялгызым калгач, вагонның икенче өлеше белән танышырга керештем. Пөхтә итеп җыештырылган ике койка, өстәлдә бер өем газета-журналлар, шунда ук әйбәт кенә экранлы телевизор, ә түрдәге почмакта күркәм генә радиоалгыч шүрлеккә менеп кунаклаган. Бүлмә эче җыйнак, чиста.

— Шәп кайгырткannар сезнең хакта! Байларча яшисез икән! — дидем мин, Мирзанур әйләнеп кергәч.

— Ходага шөкер кылып, башлыкларга рәхмәтләр укып, шыпырт кына яшәп ятабыз инде шулай!

— Җитмәсә тагы, эшкә дә өегездән туп-туры вертолетта гына алып китәләр. Көнләшеп үләрсең!

— Дөп-дөрес. Утырасың шулай үз өеңдә җылыда, өстәлеңдә самавар гөжли. Үзең инде вахтага китәргә күптән әзер: төенчегең төйнәлгән, дигәндәй. Баш өстеңдә дөбер-шатыр килеп, бакча артыңа вертолет кунаклаганчы рәхәттә тыныч кына оеп утыра бирәсең. Тик алай-болай һава хәлләре генә бозылып куя күрмәсен...

Мирзанур, кирәк кадәр савыт-сабасын әзерләп куйгач, урындыкка җәйрәп утырды да бәрәңге чистартырга кереште. Минем дә аңа

булышырга теләп кулым кычытып тора торуын, әмма ул һаман үзенекен тукый бирә:

— Ярамый, килешми. Сез минем кунакмы... бетте — вәссәләм! — Аннары ул, сүз сөрешен икенче җайга бору нияте белән, ахры, әйләнә кайтып әйтә: — Начальствога рәхмәт инде, профсоюзга да. Онытмыйлар үзе. Безнең ише авылда торучы эшчегә кышлык утын да бирәләр, бүтәненә булышкалыйлар.

— Мирзанур дус, әйт әле син миңа: оператор булу өчен өйрәнүе озакмы?

— Нишләп озак булсын, ди. Тәҗрибәлерәк оператор тирәсендә карангалап-искәргәләп, тегесен-монысын өйрәнеп йөрисең дә разрядка имтихан тотасың. И бетте-китте — вәссәләм!

— Сезнең монда Ык Тамагында галәмәт бит: тынычтыр, иркендер. Вәт килеп урнашырга иде шушында! Көндезләрен эштә, ә кичләрен, дөнья мәшәкатеннән бушагач, рәхәтләнеп утыр да языпмыяза бир. Беркем комачауламый-нитми. Тынлык! Минем ишләрдән кем генә хыялланмый икән әнә шул хакта... Романтика!

Менә шунда гына Мирзанур минем соравымның астыртын ягын сизеп алды һәм, урындыгында утырган шәйгә, башын артка каерып җибәрде:

— Ә-әнә сез ничекләй... хыяя, имеш... дөнья рәхәте... Романтика... Һе-һе!

Аннары ул тышта, култык суында җебеп яткан балыкны алырга чыгып китте. Әйләнеп кергәндә — гаҗәп хәл — ул бөтенләй башка кеше иде инде: уйчан, хафалы йөзендә көлү-елмаюның эзе дә калмаган иде. Балык тазартырга керешкәч, ниһаять, телгә килде.

— Анысы шулайдыр инде, кызык күренәдер. Бигрәк тә читтән караганда. Ә бит бездә дә төрле хәлләр булгалый. Кайчагында монда, сез әйткән «рәхәт тынлыкта», улардай булып йөрисең. Бүре айга улаган шикелле. Ярый әле, яныңда иптәшең бар. Икәүләшеп уларга ябышмассың бит инде, аннары килешми дә: ни дисәң дә, ир-ат лабаса без... Менә һавалар бозылып китте, ди. Аның өстенә электрның рәте-чираты юк. Иң кирәк чагында аяктан ега да куя. Ә нефть суырту уен эш дисеңме... Ачы буран диме, зәһәр суык диме чабып йөрисең ялан кырда ач җанвар шикелле. Аннан кайтасың да койкаңа авасың. Кая анда радио тыңлау, кая анда телевизор кайгысы. Тизрәк җылыну ягын карыйсың.

— Аның караве, зиһен үткенләнә, уйның берәгәйлесе уйлана торгандыр, — дим мин, чигенергә теләмичә.

— Бәлкем, кирєсенчә, тупас уйлар уйланадыр? Кыш көнендә без гадәттә рәттән икешәр атна вахтада ятабыз. Әгәренки, һавалар бозылып, сменаң алмашка килә алмаса? Вертолетка ышаныч — ташка үлчим! Кайчагында киеренкелектән башың бөтенләй тупыйлана, тубал була... Ә бит диңгез тамчылардан җыела. Нефть елгасы да шулай... Аннан инде өйгә кайткач, ике-өч көн буена тәннән дә, җаннан да әлеге суык белән миңгерәүләнүләрне кызу мунчада шәпләп кудырасың. Тагын бүтәнрәк им белән дә... Тик шуннан соң гына син яңадан үз хәлеңдә, җаның яңадан уйнаклый башлый... тегени... сез әйткән романтика бәлки шул үзедер... Менә шулай, туган!

Бик әйбәтләп тазартылган балык белән эре итеп туралган бәрәңгене, суган, тоз ишесен дә бергә салып, зур кәстрүлне газ плитәсенә куйгач, Мирзанур зур канәгатьләнү белән тамак кыргалап алды:

— Ашыгыр җиребез юк. Әкренләп пешсә, шулпасы тәмлерәк булыр. Ә хәзер чәй эчеп алыйк. Чәйне үзебезчә парлап кына... Ризамы?

Электр чапчак инде ыңгыр-шыңгыр ухылдарга керешкән иде.

— Риза булмыйлармы соң!

Хуш исле тәмле чәй белән кортны беркадәр баскач, уха пешкән арада без телевизор карыйбыз. Хикмәтнең дә хикмәте инде: үзебез әллә кайда җәһәннәм артында, ә үзебез шул ук вакытта башкала тапшырган күңелле концертны карап, ләззәткә чумып утырабыз. Чыннан да әкияттәге сыманрак...

Мин телевизор белән артыграк мавыгып киткәнмен, ахры: бер заман, ни күрим, янымда Мирзанур юк. Ишекнең икенче ягында рациядән сөйләшә. Мин аны берәр әһәмиятле хәбәр җиткерәдер дип уйлаган идем. Түгел икән: егетемнең авызыннан, канатларын матур җилпегән асылкош шикелле булып, хатын-кыз исеме очып чыккалый иде...

Мирзанурның да, аның кулалмашы Ирек Әюповның да әле өйләнергә өлгермәүләрен мин ишеткән идем инде. Бәлкем Мирзанурның җан сөйгәне телефонисткалар арасындадыр?

Бик озаклап һәм тәмләп сөйләште...

*

* *

Мирзанурның ухасы хәйран булып пешкән иде. Бер тәмләүдән телеңне йотарсың? Ул да түгел, пешекче дустым шәп судакның дәү башын миңа да тоттырды.

Инде хәзер тышта саф һавада, сөзәк сырт буйлата, ах-ух килеп йөренә бирәм. Һава суларга дип, Мирзанур да чыкты. Төньяк-көнчыгыш тарафта тонык кына яктылык шәүләсе сызылган. Озакламый таң беленер.

Ык ярына якынлашабыз. Таң алды эңгерендә тал ботаклары шыбырдаша. Куак араларында язгы ташкын су чыпыр-чапыр бәргәләнә. Бүтән бер төрле дә аваз ишетелми.

Шунда Мирзанур миңа үзенең башыннан кичкән бер хәлне сөйләргә кереште. Күңелле нәрсә түгел, ямьсез бер вакыйга иде ул.

Бервакыт шулай Петя Пономарев белән моторлы көймәдә Ык буйлап менеп киләләр икән. Борылыш арты борылыш. Бер заман, ни күрсеннәр, елга өсләтеп бихисап балык агып килә. Тересе бар, ярым үлгәне. Күбесе вак балык. Бу ни гаҗәп тагы? Янә бер борылышны үтүгә, болар яр читендә ыгы-зыгы килгән кешеләрне күреп алалар. Югарыда, яр өстендә исә грузовик...

— Безнең көймә выж гына килеп чыгуга, яр читендәгеләр чабыша-чабыша машиналарына төялделәр дә ялт кына сыздылар. Без алар артыннан. Әмма алар, каһәрләр, машина номерын брезент итәге белән каплаганнар булып чыкты. Таный алмадык... Белмим инде, балыкны ни белән шулай харап иткәннәрдер. Шартлаткан дияр идең, бернинди тавыш ишетмәдек. Ә бәлкем электр тогы беләндер? Нихәтле балык бит!... Бер дә әллә кемнәр түгел, камазчылар булырга тиеш...

Мин сискәнеп куйдым һәм, КамАЗның чын патриоты буларак, аның сүзен кырт кистем:

— Ә бәлкем чеп-чи яла ягасыңдыр, дускай, ә? Сез бит төгәл аныклый алмагансыз. Монда ыбыр-чыбыр халык аз киләмени? Әйтик, Минзәләдән, я булмаса Әлмәт хәтле Әлмәттән?

— Анысы хак: төрлесе килә, — диде Мирзанур, моңсу гына ризалашып. — Соңгы елларда җәйләрен Ык буйларын машина басып ала. Арада нинди генә юк! Кайчагында Ык буйлап көймәдә менгәндә, спиннинглары белән якаңнан эләктермәгәйләре дип шүрләп барасың, билләһи менә! — Тирән итеп тын алгач, минем бавырны ул икенчеләйрәк рәвештә чәнчергә тотынды.— Баягынак сез мондагы тугайларда җир җиләгенең хәйран булуына шаккатуыгыз-

ны сөйләдегез. Дөрестән дә, хәйран инде анысы. Ә сез быелтырларда биредәге тамашаны күрсәгез иде. Бусында инде ап-ачык, төп-төгәл камазчылар... Һәр шимбә белән һәр якшәмбедә катер артыннан катер килеп туктый. Бер төрле десант диярсең! Йөзәрләгән кеше! Болын-тугайларны әйтерсең бөтен бер яу басып ала... Чабылмаган печәнне таптыйлар, изәләр. Колхоз председателе дә, парторг та болынга чыгып, тәмләп тә, тәмсезләнеп тә аңлатырга, үгетләргә тырышып карадылар. Файдасы нуль... Йөдәп беткәч, ахырда кул селтәделәр. Шуннан соң үзебезнең авыл халкына да җиләк җыярга рөхсәт ителде.

— Замана каршылыгы, — дидем мин һәм тавышымның үтә коры чыкканлыгын тойдым. — Берәүләрнең зур төзелештәге кайнар хезмәттән соң табигать кочагында иркенләп, рәхәтләнеп ял итәсе килә, икенчеләре болын-тугайларны саф, имин хәлендә сакларга тели... Көннән-көн көчәя барган каршылык...

Вагон тирәсенә кире әйләнеп кайтабыз һәм шундагы бүрәнә өстенә утырабыз.

— Әйтче, Мирзанур, — дип сүз башлыйм мин, мөмкин кадәр йомшаграк, җылырак итеп. — Сезнең мондагы чыганакны нишләтмәкче булалар? Ком юдырып, дамба күтәртерләрме, әллә аерым-аерым утраучыклар гына ясарлармы? Скважиналар өчен, дим...

— Тәгаен генә әйтә алмыйм. Дамба күтәртмәкчеләр шикелле. Тик бернәрсә ап-ачык: Бәзәкә үзәнлегендәге яки Кызыл Тау тирәсендәге кебек үк, болыннарны тунап, каезлап бетерәчәкләр. Су басканчы, ичмаса, шушындагы бар нефтьне суыртып бетерә алсаң иде менә.

— Тагын бер каршылык. Арада иң авыры, иң яманы, дөресме?

— Дөрес: чияли төен... Әмма килер бер көн, ГЭС корылып бетәр, анда инде ул каршылыклар, яман бәрелешләр, бөтенләй булмаган да шикелле, мәңгегә су астында калыр...

—Җәлме болыннарыгыз?

Мирзанур эндәшми, бик озак эндәшми. Җайсызрак сорау бирдем, ахрысы.

Сыек караңгылыкта баш өстебездән бер пар үрдәк очып үтте. Читтә, шактый еракта, карасу тал куаклары артында, тулып ташыган Кама күкрәген ярып, төрле төсләрдәге утлары белән сихри балкып, һичбер нинди тавышсыз-нисез диярлек, югарыга таба дәү теплоход менеп бара иде.

Ниһаять, Мирзанурның теле чишелде, сулганрак моңсу бер тавыш белән әйтә куйды:

— Мин бит шушы болыннарда тәгәрәп үскән малай...

*

* *

Галәмәт эссе һәм коры көннәре белән җәй дә үтеп китте. Һавалар беркадәр сүрелә төште.

Вертолетта без өчәү: РИТС[1] башлыгы Шәүкәт Хәсәнов, инженер-технолог Лаврухин һәм шушы язмаларның авторы.

Баш корылмалар янындагы бәләкәй генә мәйданчыктан күтәрелдек тә машиналар ташкыны берөзлексез агылып торган шоссе юл өстеннән оча башладык. КамАЗ юлы...

Безнең аста ак ташпулатлары, күп санлы күтәрү краннары белән югары калкынып, киң урамнары, бульвар-скверлары белән җәйрәп Яңа кала ята. Уң тарафта исә киң басу күкрәкләрен биләгән

[1] РИТС — районная инженерно-технологическая служба.

КамАЗ корпуслары сузыла. Ерактарак РИЗ һәм кою заводы биналары шәйләнә...

Олы төзелеш мәйданнары акрынлап артка таба шуыша, чигенә бара. Менә инде каршыбызда калын Боровецк урманы...

Лаврухин, минем шикеле үк, күз карашын иллюминатордан аерып ала алмый. Шәүкәт Хәсәнов, югарыдан түбәнгә бер-ике генә тапкыр күз ташлады да, кулларын тез капкачына куеп, уйчанланып калды. Аның түгәрәгрәк саргылт-аксыл йөзендә сүрән күләгә аермачык сизелә иде.

Бик аңлыйм мин аның хәлен: әле күптән түгел генә ул, һич көтмәгәндә-уйламаганда, операция өстәленә эләгә: аппендицит. Җитмәсә тагы, Алабуга больницасында яшь һәм тәҗрибәсез хирургка тап була. Шул сәбәпле, савыгуы да шактый озакка сузыла. Соңгы көннәрдә ул үзен инде тәмам сәламәтләндем дип исәпләп йөри иде. Ләкин вертолет дигәннәре тап-таза, нык хәлле кешеләрне дә бик тиз хәлсезләндерә шул.

Ә Шәүкәт үзе болай мөлаем чырайлы, җор телле, һәр чак ярдәмчел, бик тә ипле кеше, мин инде аны шактый вакыттан бирле беләм. Тормыш һәм хезмәт юлы белән дә беркадәр таныш. Нефть үзәге — Әлмәт районының Тайсуган авылында туып-үскән, димәк ки, нефть исе аның канына бик яшьләй сеңгән. Хезмәткә ярарлык булып җитлеккәч, ул якындагы промыселга оператор булып эшкә урнаша, соңрак электрик булып эшли. 1960 елда, Хәрби-диңгез флотында хезмәт итеп кайткач, яңадан үз эшенә тотына һәм кичке институтта укып, инженер дипломы ала. Тора-бара ул «Лениногорскнефть» идарәсендә бай эрудицияле, төпле һәм тырыш белгечләрнең берсенә әверелә.

Кама елгасының сул ягында нефть чыганаклары байтак. Эреләре бар, вaклары бар. Һәркайсының үз холкы, үз мәшәкатьләре. Аларның һәркайсын авызлыклый белергә кирәк...

Моннан ике-өч ел элек биредә дә РИТС оештыру идеясе туа. Алай гына да түгел, берләшмәдә дә, министрлыкта да беренче тапкыр буларак комплекслы РИТС. Ә мондый РИТС нефтьне чыгарып кына калмыйча, аны тиешенчә эшкәртү белән дә, җир астына — нефть катламына су кудыру кебек четерекле эшләр белән дә шөгыльләнергә тиеш. Эреле-ваклы чыганакларны берләштергән РИТС төрле машиналарны һәм механизмнарны куллануда бик тә эффектлы булыр дип уйланыла. Соңыннан бу уй чынлап та аклана... Бу идеяне «Кама буе» нефть һәм газ чыгару идарәсе башлыгы, бай тәҗрибәле инженер Аклим Мөхәммәтҗанов күтәреп чыга һәм, югарыдан да яклау тапкач, аны тормышка ашырырга керешә. Ләкин яңа РИТСка начальник итеп кемне куярга? Уйлый-эзләнә торгач, Аклим Мөхәммәтҗанов кайчандыр Лениногорскида үзенең кул астында эшләгән тыйнак холыклы, әмма һәр эшне җиренә җиткереп башкарырга сәләтле яшь инженерны исенә төшерә...

Яңа шартлар, йөкнең авыры, саллысы... Шулай да Шәүкәт югалып калмый. Кирәк булгач, дәртләнеп җиңнәрен сызгана. Уңышлар озак көттерми. Сүзне озынга сузмас өчен мин монда шуны гына әйтеп китим. Кама буенда оештырылган өр-яңа РИТС-3 соңгы ике елда нефть чыгару һәм эшкәртүне бер ярым тапкырга арттыра. Әлбәттә, елга аръягындагы төп көчләрнең өзлексез, ышанычлы ярдәменә таянып...

Ләкин, минем белүемчә, кичектермичә хәл итәсе проблемалар да җитәрлек әле монда. Җитди проблемалар...

Хәсәнов, кулларын тезенә куеп, мыштым гына шул проблемалар хакында уйланып бара торгандыр...

Менә Суык-су чыганагын гына ал. Аны күптән түгел генә үз-

ләштерергә керештеләр. Әллә ни зур түгел үзе — нибары ике дистә ярым скважина. Ләкин нефте күкертле-водородлы, тозы да җитәрлек. Ул чыганак өчен үзенә аерым «Тайфун», ягъни термо-химик установка кормыйча һич ярамый.

Кызыл Тау тирәсендәге дистәләрчә скважиналарга ныклы профилактика кирәк. Алабуга мәйданында да шул ук хәл. Шулай да иң четерекле хәл Ык Тамагындагы «Күлләр» чыганагындадыр, мөгаен. Анда катламдагы басымны күтәртмәсәң, нефть суыртуның күзгә күренеп кимүен көт тә тор. Димәк, катламга су кудырырга кирәк. Инде махсус скважиналары да бораулаган. Әмма кудыру өчен Кама белән Ык суы бөтенләй яраксыз — пычрак. Иң кулае, әлбәттә, нефтькә ияреп чыккан тозлы су. Катламның үз суы... Кулаен кулай да, ләкин аны ныклап аерырга һәм тупларга кирәк. Чыганакның үзендә үк зур күләмле махсус резервуар кормыйча котыла алмыйсың... Шәүкәт Хәсәнов моны НГДУ җитәкчеләре алдына күптән куйган, күптән таләп итә. Ниһаять, төзүчеләр куба... Ләкин аларның эшләре ничек бара: акрынмы, шәпме? Менә ни өчен Хәсәнов иң әүвәл Ык Тамагыннан әйләнеп кайтырга ниятләде шикелле...

Ул арада түбәндә КамАЗ төзүчеләренең һәм завод коллективларының урман кырыйларына, аулак тугай куеннарына сыенып утырган ял базалары, пионер лагерьлары күз алдыбыздан йөгереп үтте. Озакламый карашларыбыз Камага килеп кушылган Ык елгасының өзек-өзек көмеш тасмасына текәлде.

Менә шунда гына Шәүкәт Хәсәнов, башын миңа таба борып, нәрсәдер әйтте, аның тавышын вертолет гөрелтесе йотты. Мин иңнәремне сикерткәч, ул тавышын көчәйтә төште:

— Чаллыда, дим, горисполком председателе Гыйләҗев алай-болай ялга китмәдеме икән?

— Белмим... Ә нигә?

— Нигә дип, квартирлар хакында инде...

Нефтьчеләрдән дистә ярымлап кеше, шул исәптән Шәүкәт үзе дә, Яңа калада һәйбәт квартиралар алып, төпләнеп өлгергәннәр инде. Иртәләрен эшкә дә вахта автобусына төялешеп китәләр. Ләкин читтә ятта яшәп, торакка чират көтүчеләр дә байтак икән әле.

— Гыйләҗевнең, дим, җаен китереп булса ярый ла!..

Коточкыч гөрелдәп, дер-дер калтыранып очкан вертолетта әнә нәрсә турында уйланып барган икән бу иплә-инсафлы җитәкче. Хәер, монысы да бәләкәй проблемалардан түгел шул...

*

* *

Вертолетның һәр сәгате, һәр минуты кадерле. Хәсәнов белән Лаврухинның әле бүтән мәйданнарда да буласылары бар. Мондагы эреле-ваклы чыганаклар Кама буйлап йөз илле чакрымнаргача сибелгән. Өлгерсәләр, Алабугадагы төп базага да сугылмакчылар. Шул сәбәпле РИТС башлыгы белән инженер-технолог Ык Тамагындагы «Күлләр»дә әллә ни озак тоткарланмадылар.

Төзүчеләр олы резервуар кору эшенә керешкән инде. Кирәкле төзү материаллары китертелгән, механизмнар бар, тик эшче куллар саны гына такыррак. Эшкә тотынуларына Хәсәнов канәгать. Ул кинәт җанлана төште. Төзүчеләр белән сөйләшкәндә, аның тел төбендә бер нәрсә ятканлыгын чамаларга була: эшләрне тизләтеп булмасмы, резервуарны кышка тикле ничек тә өлгертәсе иде — катламга су кудырырга кирәк ләбаса! Ә төзүчеләрнең җавабы ап-ачык:

— Материалга тоткарлык булмаса, эш бездән тормас!

Аннары Хәсәнов беравык оператор Ирек Әюпов белән гәпләшеп алды. Килгән шәпкә үк Лаврухин операторга бер кочак газета-журнал тоттырган иде, Ирек шуларны култык астына кыстырган килеш, сыңар кулы белән сумаладай чәчен сыпыргалап ала:

— Энергия булмагач, нишлисең инде... туктaлдык шулай...

— Кайчан өзделәр?

— Ике сәгатьтән артык инде.

— Соң электриклар базадан иртүк киткәннәр ләбаса! Бу тикле дә «акрын өлгермәс» булырлар икән!

— Җиренә җиткереп эшләгез дип, мин аларга үзем дә кат-кат әйттем... Профилактика әйбәт үткәрелсә, соңыннан үзебезгә үк җиңелгә туры киләчәк,— диде Хәсәнов.

Вертолетка утырып китәр алдыннан ук Ирек Әюповны янә кисәтергә кирәк тапты:

— Энергия килеп, групповойны җибәргәндә замерны төп-төгәл ал. Хата китә күрмәсен тагын...

— Абынмабыз...

Вертолет, өем-өем болытларга таба күтәрелеп, бераздан бөтенләй чебенгә әверелде һәм аның гөрелтесе дә ишетелмәс булды. Мин әрле-бирле сугылып йөрүнең бернинди дә кызыгын тапмыйча, культбудкага кердем.

Ирек Әюпов койкага утырган да газета-журналларга чумган. Мин аның белән гәп корып җибәрмәкче идем, әмма ул сүзгә үтә саран булып чыкты. Биргән сорауларыма да: «Шулай инде», «Болай ярыйсы гына» кебек өзек-төлек җавап бирүдән узмый. Ахырда, минем үземә дә газета-журналларга үрелүдән бүтән чара калмады.

Без шулай, гыйлем өстәп, энергия килүен көтеп утырганда, бер заман ни ишетим, җил купты, ул да түгел, чиләкләп яңгыр коярга тотынды.

Ирек Әюпов койкага утырган да газета-журналларга чумган, кучкыл йөзендә чиксез куаныч балкытып, ишекле-түрле йөренеп алды. Аннары ишекне ачып, ялангач башын яңгыр астына куйды:

— Вәт кирәк иде! Җәй буе көттерде бит. Үзе шундый җылы! Бәрәңгеләр өчен әкәмәт инде бу!

— Чәчкән уҗымнарга да!

— Әйтерең юк!

Без шулай сөенешеп ишекле-түрле йөргән чагында, түбәндә, эстакадада утырган вагоныбыз астында дөбер-шатыр мотоцикл тавышы ишетелде. Гөрелте тынып, бераз вакыт үтүгә, ишектән Мирзанур Сабиров атылып килеп керде. Өсте-башы манма су, үзенең авызы колагына җиткән.

— Менә, ичмасам, булдырды! — Кинәт ул мине шәйләп алды. — О, кунак бар икән! Төкле аягың белән!.. Чәй эчтегезме әле?

Мин аны шул хәлендә бөтереп алмакчы булдым:

— Чәй калмас... Ә менә син өйләндеңме әле?

— Кая ул!.. Вакыт тими, кәләш килми, дигәндәй...

Сүзгә Ирек тә кушылды:

— Мирзанур инде менә дигән өй дә өлгертте. Тик кыз дигәне генә, каһәре...

— Ә үзең соң?! Мин менә син юньсезнең, син булдыксызның муенына кайчан элмәк салырлар икән дип көтәм! Өйләнгәч ничек була икән дип карап карарга...

Культбудканы яңгыратып көлешеп алдык.

Мирзанур тиз генә өстен-башын алыштырды да яшь киленчә җитезлек белән кухняда эштер-өштер килә башлады.

— Иң әүвәл чәйләп алыйк! Кичкә таба бәлкем балык та чама-

ларбыз. Петя куна киләм дигән иде. Иртәгә аларга сменага чыгасы. Тагын төнгә каршы уха ашап кына...

Мин шундук кулымны селтәдем:

— Юк, юк, рәхмәт! Монысында мин бөтенләй куну нияте белән килмәдем. Өйдә эшләр муеннан... Вертолет электрикларны алмага килү белән...

— Ниткән вертолет ди бүген?! Күрмисезмени, бөтен дөньяны каплап алды ич. Иртәгә очса да рәхмәт әйтерсең әле.

Шул чак түшәмдәге лампочка гөлт итеп кабынды. Мирзанур белән Ирек ашык-пошык кына җыендылар да тышкы якка атылдылар. Ике-өч минут үттеме-юкмы, Мирзанур үзенең мотоциклына атланып, пычрак чәчрәтә-чәчрәтә, ерак скважиналарга элдертте, ә Ирек якындагы группалы установкага чапты.

Бу юлы миңа чәйне япа-ялгызыма эчәргә туры килде.

*

* *

Җәйнең соңгы көннәре... Яңгыр хәзер сибәли генә. Болын-тугайларны җиңелчә томан баскан. Бер кырыйда, әрәмәләр артында җыйнак кына вышка күренә. Анда — скважиналарга җир асты ремонты үткәрүчеләр. Илдар Сәләхетдинов бригадасы. Алар оста хирурглар сыман: авыр сырхаулаган скважинага тиешле «операция» ясап, аны терелтәләр, сафка бастыралар.

Якындагы группалы установкада куәтле насослар гөрелди. Еракларга сузылган торбалар буйлап «кара алтын» ага. Чаллыдагы Баш корылмаларда тәмам тазартылгач, ул Әлмәт тарафларына кудырыла һәм анда «нуленче» километрда «Дуслык» магистраленә килеп кушыла. Аның соңында дөнья читләренә сәфәр тота...

Җыйнак кына, бәләкәй генә «Күлләр» чыганагы. Гүзәл Ык Тамагы... Куәте алай зур да түгел үзенең. Ләкин Мирзанур бик тә хаклы: тамчылардан җыела лабаса ташкыннар...

...Кичке эңгер таралырга торганда, электриклар килеп төште. Озын чәчләләр, шуклар. Шау-гөр килеп иң әүвәл трансформатор будкасына сугылдылар. Анда сүз булсын өчен генә операторларны әрләгәндәй иттеләр. Шуннан соң үзара бәхәскә керештеләр. Вертолет булмаячак, нишләргә? Туп-турыдан Турай перевозы аша Алабугадагы төп базага элдертергәме, әллә әйләнеч һәм озын юллардан Минзәлә, Чаллы аша китәргәме?

— Бу пычракта паромга керүләре, ай-һай... Безнең машинаны күтәрә аламы-юкмы бит әле ул...

— Иртәгә Кызыл Тауга дигәннәр иде. Әллә шунда гына сыптырабызмы?

— Ай-һай ла, әйләнүләре!

Ниһаять, кабинада утырып килгәне, калынрак гәүдәлесе, кулы белән һаваны ярып, кырт кисте:

— Әйләнечтән юл туры!.. Минзәлә аша.. Чаллыда кунарбыз...

Минем бәхет басты. Махсус машинаның ябык кузовына менеп кунакладым да аның бәләкәй генә тәрәзәсенә борынымны төрттем. Кузгалдык.

Миңа инде кичке эңгердә карасуланган тал куаклары, тонык җемелдәгән сирәк-сирәк утлар артка таба йөгерешә башлады. Ык Тамагы торган саен ераклаша бара...

Анда озын көз һәм кыш алдының мең төрле мәшәкатьләренә чумып, үз кичерешләрен заман каршылыкларына бәйли белүче минем дусларым калды. Борынгы игенче һәм балыкчы токымының уллары һәм оныклары — җир хуҗалары, илгә көн-төн байлык өстәүчеләр калды.

**Мансур Хәсәнов,**
филология фәннәре докторы

# ӘДИПНЕҢ БӨЕКЛЕГЕ

Дөнья әдәбияты тарихы бик күп мәшһүр исемнәрне, гаҗәп көчле талантларны белә. Аларның беришеләре даннарын аерым әсәрләре белән мәңгеләштергән, классик язучы булып танылган, икенчеләре сүз сәнгате үсешенең нинди дә булса бер этабында тирән эз калдырган, әдәби юнәлешне билгеләгән. Бар өченче төрләләре: болары — бөек талант көчләре һәм күпкырлы иҗатлары белән үз халкының рухи үсешендә зур сикереш ясаган, аның сәнгатьчә фикерләү дөньясын ачкан, милли әдәбиятның эстетик принципларын нигезләгән шәхесләр. Бөек рус әдәбиятында Пушкин һәм Горький, украин әдәбиятында Тарас Шевченко, полякларда Адам Мицкевич, венгрларда Шандор Петефи, латыш әдәбиятында Ян Райнис — әнә шундыйлар.

Татар әдәбиятында мондый тарихи рольне Г. Тукай белән Г. Ибраһимов башкарды.

Галимҗан Ибраһимов — XX гасыр башындагы бөек иҗтимагый хәрәкәтләр, пролетар революциясе һәм социализм төзелеше тудырган, татар халкының милли-рухи яңарыш дәвере үстергән, коммунистлар партиясе чыныктырган олы шәхесләрнең берсе.

Күренекле рус совет язучысы Л. Соболев аны татар әдәбиятының титаны дип атаган иде. Чыннан да, аның иҗат эшчәнлегенең төп юнәлешләрен санап кына чыгу да күз алдына әдипнең титаник образын китереп бастыра: халкыбызның иҗтимагый фикер үсеше һәм революцион хәрәкәт тарихында тирән эз калдырган олы акыл иясе, революционер һәм дәүләт эшлеклесе; татар әдәбиятының классигы, милли әдәбиятта социалистик реализмга нигез салган, күп милләтле совет сәнгатенең үсешенә зур өлеш керткән мәшһүр язучы, сүз остасы; күренекле тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече, әдәби-мәдәни хәрәкәтне оештыручы һәм әйдәп баручы, яшь талантларга остаз; Октябрьга кадәрге демократик татар матбугатында һәм совет журналистикасында онытылмаслык урын алган ялкынлы публицист һәм журналист; тирән эрудицияле, киң колачлы галим-филолог, тарихчы, ориенталист; ниһаять, мәгариф өлкәсендәге гыйльми хезмәтләре һәм нәтиҗәле эшчәнлеге белән күпләрне сокландырган педагог — боларның һәркайсы махсус талант һәм хәзерлек, иҗат көчеңне тулысынча шуңарга гына сарыф итүне сорый торган өлкәләрдер. Ә менә Галимҗан Ибраһимовның бөек таланты шуларның барысын да колачлый, аның иҗаты шул тармакларның бөтенесен бергә җыйный алган. Ул әлеге өлкәләрнең һәркайсында яңа сүз әйтеп кенә калмый, аларның күбесендә юл яручы, башлап йөрүче, нигез салучы була. Талантының һәм фәнни-иҗат эшчәнлегенең характеры белән ул чын мәгънәсендә энциклопедист кеше иде.

Г. Ибраһимов үз халкының гомум Россия күләмендә җәелгән революцион-азатлык хәрәкәте аша яңа тормышка, социализмга тарихи күчешен, бу күчешнең зарури

булуын революцион һәм иҗтимагый эшчәнлегендә, әдәби һәм фәнни иҗатында, гүзәл әсәрләрендә гаять тулы һәм тирән итеп, бөтен катлаулылыгы белән чагылдырды.

Еллар саны белән санасаң, Г. Ибраһимов озак яшәмәде. Ләкин тарихи шәхесләрнең роле гомер озынлыгы белән түгел, ә бәлки эшләгән эшләренең олылыгы, тарихта, халык күңелендә калдырган эзенең тирәнлеге белән үлчәнә.

Шәхеснең зур, тарихи булуы өчен бер талант көче генә җитми, В. Г. Белинский әйтмешли, ул яшәгән чорының бөеклеге, халкының рухи көченең зурлыгы да кирәк. Бу яктан караганда, Ибраһимов бәхетле шәхес була. Аның тормышы бай иҗтимагый-политик вакыйгалар, кешелек тарихындагы бөек алмашынулар чорына туры килә. Ул үз гомерендә өч революция кичерә, шуларның идеяләре белән рухлана, ә соңгысының — социалистик революциянең ышанычлы солдаты, актив көрәшчесе була. Әдип социализм төзелешендә актив катнаша, илдә барган бөек үзгәрешләрнең эчендә кайный. Татар совет культурасының кайсы гына тармагын алып карасаң да, анда Г. Ибраһимов талантының җуелмас эзләрен, коммунист әдипнең көчле йогынтысын күрәсең.

Г. Ибраһимов үткән юл — татар халкының XX гасыр башларыннан алып, утызынчы еллар ахырына кадәр, ягъни илдә революция булып, социализм җиңүенә тикле булган рухи үсеш юлы. Әдипнең тормышы һәм иҗаты халыкның революцион көрәш тарихы, яңа тормыш төзү, социалистик культура формалашуы белән аерылгысыз бәйләнгән.



1

Г. Ибраһимовның культура тарихындагы роле турында сүз барганда, барыннан да элек, аның матур әдәбият өлкәсендә тоткан урыны аеруча зур һәм үзенчәлекле булуын әйтергә кирәк. Әдипнең иҗат эволюциясе һәм татар әдәбиятында тоткан урыны турында фәнни хезмәтләр язылган, аның иҗаты шактый җентекле тикшерелгән дияргә була. Һәм һаман да тикшерелеп тора, киләчәктә дә шулай булыр. Чөнки зур талантлар, классик язучылар, бай иҗатлар турында һәр чор, һәр буын үз сүзен әйтә, аңарга карата үзенең мөнәсәбәтен билгели. Мондый тарихи шәхесләр рәтенә керү үзе генә дә язучының олылыгын, үлемсезлеген күрсәтә. Г. Ибраһимов — әнә шундый затлардан.

Әмма һәр яңа буын нәрсә генә әйтмәсен, безнең карашыбызча, классик язучыларга мөнәсәбәттә үзгәрми торган, тарих тәҗрибәсе белән расланган тотрыклы бәяләр бар. Мондый тарихи бәягә Г. Ибраһимов та лаек. Ул нидән гыйбарәт соң? Иң элек шул кадәресен басым ясап әйтергә кирәк, Г. Тукай белән бергә, ул бездә яңа, Европа тибындагы әдәбиятның нигезен салучы була. Хәзерге заман укучыларына — татар прозасының камиллеген, фикер куәтен һәм эстетик матурлыгын К. Нәҗми, А. Шамов, Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, И. Гази, Ә. Еники, А. Расих һәм Г. Ахунов әсәрләре аркылы ачкан буынга — әдипнең новаторлыгын, татар әдәбиятына керткән яңалыгын билгеләү җиңел түгел, әлбәттә. Чөнки, бик табигый ки, Ибраһимов иҗатының күп кенә үзенчәлекләре, әдәби традиция буларак, әлеге язучылар иҗатына күчкән, бүгенге әдәбиятның аерылмас сыйфатына әверелгән. Ерактан башланган олы елгага юлда яңадан-яңа кечерәк елгалар кушылгач, төп елганың суын аерып алу мөмкин булмый башлый. Шуның шикелле, хәзерге татар әдәбиятында, хосусан, прозада Г. Ибраһимовтан килә торган хасиятләрне аерып күрсәтү дә җиңел түгел. Аның иҗаты — хәзерге татар әдәбияты дәрьясының өстәге дулкыны түгел, бәлки төп агышы, нигез юлы.

Г. Ибраһимов милли сүз сәнгатенә зур сыйфат үзгәрешләре кертте. Татар прозасы, сүз сәнгате буларак, үзенең куәтен, эстетик матурлыгын һәм эмоциональ мөмкинлекләрен Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал әсәрләрендә ачты. Ибраһимов безнең прозабызның идея эчтәлеген һәм тематикасын, социаль колачын киңәйтте, аңа гражданлык сулышы өрде, революцион рух һәм дәрт кертте, музыкальлек өстәде, аны романтик пафос белән сугарды, яңа сурәтләү чаралары белән баетты. Ибраһимов керткән бу үзгәрешләр соңыннан милли әдәбиятның аерылмас сыйфаты булып китте.

Әдип үзенең әсәрләрендә тормышның тирән катламнарын күтәрде, татар халкының иҗтимагый үсешендәге әһәмиятле этапларны чагылдырды.

Мәгълүм булганча, татар әдәбияты, бөек рус әдәбиятының прогрессив казанышларыннан иҗади файдаланып, революциягә кадәр критик реализм этабын үтеп өлгерә, XX йөз башында Россиянең алга киткән башка милли әдәбиятлары (украин, белорус, әрмән, әзербәйҗан) рәтенә баса. Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов һәм Ш. Камаллар белән бергә, Г. Ибраһимов XX йөз башы татар әдәбиятының демократик магистраль юнәлешен билгели, үзенең иҗаты белән революциягә кадәрге демократик әдәбиятны яңа, совет әдәбияты белән бәйләүче, аңа нигез салучы да була. Аның иҗатында Октябрьга кадәрге милли әдәбиятның югары казанышлары, прогрессив традицияләре белән яңа, социалистик сәнгатьнең новаторлыгы бергә кушыла. Капитализмнан социализмга күчеш процессында татар милләтенең прогрессив көчләре үзләренең калку чагылышын Ибраһимов әсәрләрендә таба. Аның әсәрләре үз халкының политик, социаль һәм рухи үсеше юлындагы әдәби маяклары булалар. Безнең әдәбиятта социалистик реализмның формалашуы һәм үсүе барыннан да бигрәк Ибраһимов иҗаты белән бәйле. Аның әсәрләрендә һәм фәнни хезмәтләрендә татар культурасы марксистик-ленинчыл нигездә үзенең милли үзенчәлеген раслый, шулар йөзендә ул элекке тарлыктан, милли чикләнгәнлектән киң дөньяга чыга, бөтенсоюз тәҗрибәсе югарылыгына күтәрелә.

Мөгаен, Тукайдан башка бер генә язучы, бер генә фикер иясе дә милли әдәбиятыбыз һәм культурабыз үсешенә Ибраһимов кебек көчле йогынты ясый алмагандыр. Ул — татар дөньясында пролетар революциясе тудырган, социализм үстергән һәм чыныктырган беренче һәм иң зур талант.

Алай гына да түгел. Күренекле төркмән язучысы Б. Кербабаев бик дөрес билгеләп үткәнчә, совет властеның беренче елларында татар әдәбияты, илебезнең башка төрки әдәбиятлары белән чагыштырганда, нык үскән, алга киткән әдәбиятлардан санала иде. Шул әдәбиятның алгы сафында Г. Ибраһимов барды. Революционер язучының иҗат тәҗрибәсе башка күп кенә тугандаш әдәбиятлар өчен принципиаль әһәмияткә ия була. Шуңа күрә Ибраһимовның роле милли әдәбият рамкаларында гына калмый, илебезнең башка тугандаш әдәбиятларына да күчә. Октябрьга кадәрге чорда ул, Г. Тукай белән бергә, татар әдәбиятын гомум Россия киңлекләренә алып чыкса, совет чорында күп милләтле совет әдәбиятының нигез ташын салышучыларның берсе булып танила.

Г. Ибраһимов әдәбият мәйданына XX йөз башында — татар халкы гомум Россия күләмендәге революцион-азатлык хәрәкәтенә ныклап тартылган, хезмәт ияләре социаль һәм милли азатлык өчен актив көрәшкә күтәрелгән бер чорда — килеп керә. Бу вакытта татар телендә вакытлы матбугат, милли театр һәм сәнгатьнең башка төрләрен үстерү өчен кирәкле мөмкинлекләр яулап алынган була. Нәкъ шушы чорда татар милли әдәби теле формалашып җитә. Шулай ук милли әдәбиятның интенсив үсү процессы башлана, анда капма-каршы идея-эстетик принципларның аерымлануы һәм үзара көрәше, төрле жанрларның барлыкка килүе һәм чарлануы, критик реализмның формалашу процессы бара. Г. Ибраһимов әнә шул катлаулы һәм каршылыклы әдәби-эстетик хәрәкәтнең үзәгендә кайный, аның күренекле вәкиле, әйдәп баручысы була.

Әдәбият, культура үсешендә олы шәхесләр тиктомалга барлыкка килми, зур күренешләр буш урында туа алмый. Г. Тукай белән Г. Ибраһимов артында татар әдәбиятының берничә йөз еллык зур тарихы тора. Ибраһимов милли әдәбиятның — Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Курсави, Кандалый, Мәрҗани, Насыйри кебек олы вәкилләре булган әдәбиятның — бай, прогрессив казанышларына таянды. Язучының әдәби иҗат чыганаклары шулай ук, милли әдәбиятның күп гасырлык алдынгы традицияләре белән беррәттән, бөек рус һәм көнбатыш Европа әдәбиятына, көнчыгышның гуманистик поэзиясенә һәм философиясенә барып тоташа.

Г. Ибраһимовның татар әдәбияты, милли культура үсеше каршындагы тагын бер зур, тарихи хезмәте шунда, ул Бөек Октябрь революциясеннән соң партия җитәкчелегендә әдәби хәрәкәтне оештыручы, өлкән буын татар язучыларының күбесенә совет платформасына, марксизм-ленинизм идеологиясенә күчүдә ярдәм итүче, милли

әдәбиятка принципиаль идея-эстетик үзгәрешләр кертүче була. Ул үзгәрешләрнең асылына тукталуның хаҗәте юк: бу мәсьәлә әдәбият галимнәре тарафыннан, бигрәк тә Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Халит, Х. Госман хезмәтләрендә нык тикшерелгән.

Г. Ибраһимов иҗаты — чорның төп, әһәмиятле проблемаларын чагылдыруы белән зур һәм үзенчәлекле. Ул үзенең әсәрләрендә татар тормышының төрле якларын сурәтләде, төрле социаль катлауларның типик образлар галереясен тудырды. Әдип иҗат иткән бик күп образлар, атап әйткәндә, Салих («Яз башы») һәм Шаһи карт («Карт ялчы»), Зыя белән Җәләш мулла («Яшь йөрәкләр»), Батырхан («Яңа кешеләр») һәм Солтан («Кызыл чәчәкләр хикәясе»), атка гашыйк авыл малае Закир һәм башкорт Әлемгол («Алмачуар»), Карлыгач-Сылу белән Биремҗан аксакал («Казакъ кызы»), Гайшә белән Җиһанша бабай («Тирән тамырлар»), Гөлбану һәм әрем телле Сабира («Татар хатыны ниләр күрми»), Давыт Урманов белән Габдулла («Безнең көннәр») татар әдәбиятындагы классик образлар рәтеннән урын алдылар. Ул иҗат иткән образларда татар халкының, аның милли характерының күп кенә әһәмиятле сыйфатлары гәүдәләнеш тапты.

Әдипнең художниклык таланты киң колачлы һәм күпкырлы булуы, тормыш күренешләренең асылына һәм кеше күңеленә тирән үтеп керү көче, социаль яктан үткенлеге белән аерылып тора. Г. Ибраһимов бай иҗат хыялын тормыш агышы белән яраклаштыра, органик төстә куша белә. Хыял канатлары ничаклы гына көчле булмасын, язучы реаль тормыштан аерылмый, тормышчан һәм реалист художник булып кала.

Ибраһимовның художниклык талантына шулай ук әзлекле төстә тарихилык принцибын саклау, җәмгыятьнең иҗтимагый үсеш законнарын тирән аңлау, заман тормышы күренешләрен үткәннең законлы дәвамы итеп карау һәм тарихи перспективада күрә белү кебек әһәмиятле сыйфатлар хас.

Ниһаять, Ибраһимов таланты гади фактларга тирән, фәлсәфи мәгънә сала белү, психологик драматизмны нечкә лиризм белән бергә кушу, катлаулы һәм күптөрле хисләр гаммасын бирү осталыгы белән аерылып тора.

Тагын шуны күрсәтеп үтәргә кирәк, Г. Ибраһимовның художник буларак үзенчәлеге, новаторлыгы әдәбиятка мул итеп авыл тормышын кертүдә, җиргә, крестьян хезмәтенә дан җырлауда да чагылды. Авыл тормышы әдип өчен илһам чыганагы булды, бөтен иҗат гомере буена аның иҗат хыялын сугарып торды. Әдип ул тормышны аеруча яратып, ихлас күңелдән, бөтен нечкәлекләре һәм колориты белән сурәтләде, татар, башкорт һәм казакъ авылының бай этнографик картиналарын тудырды. Авыл халкының хезмәте һәм көнкүреше, ашау-эчүе, кием-салымы, гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре (печән өмәләре һәм сабан туйлары, кыз алышу-килен төшерү йолалары һ. б.) аның әсәрләрендә классик гәүдәләнеш тапты. Ибраһимов әсәрләреннән татар халкының, шулай ук башкорт һәм казакъларның тормыш-көнкүрешен өйрәнергә мөмкин. Бу — шулай ук олы, классик язучыларның гына иҗатына хас бер сыйфат.

Г. Ибраһимов татар прозасының сәнгатьчә сурәтләү мөмкинлекләрен бик нык баетты. Үз әсәрләрендә ул автор хикәяләвен дә, геройларның сөйләм характеристикасын да, күңел монологын да бик оста итеп эшкә җигә алды. Аның әсәрләренә вакыйгаларның киеренкелеге, психологик драматиклык һәм характерлар контрастлыгы хас.

Г. Ибраһимовның шулай ук пейзаж остасы булуын әйтеп үтәргә кирәк. Аның әсәрләрендә табигать күренешләренең бик күп төрләрен — бер караганда, драматик моментларын (күк күкрәүле яшенле яңгырларны, кышкы бураннарны, җилле-давыллы чакларны), ә икенче караганда, элегик, тыныч вакытларны — очратырга мөмкин.

Г. Ибраһимов геройның рухи халәтен, аеруча аның хисләр киеренкелеген пейзаж фонында күрсәтергә ярата. Аның әсәрләрендә шулай ук пейзажның символик мәгънәдә кулланылуын да билгеләп үтәргә кирәк.

Г. Ибраһимов стиле — тирән эмоциональ, тыгыз һәм пластик стиль. Моңа ул автор һәм персонажлар сөйләменең югары экспрессив тонусы белән, эндәш сүзләргә, кабатлауларга, антитезаларга, метафора һәм чагыштыруларга еш мөрәҗәгать итү юлы белән ирешә.

Г. Ибраһимов, сүз остасы буларак, әдәби тел белән бик сак эш итә. Үзенең бер мәкаләсендә ул: «Телдә халыкның рухы, аның кайгы һәм шатлыгы, фикер вә хисләре тупланган. Ул бөек хәзинә», — дип язган иде. Иҗат практикасында әдип әнә шул «бөек

хәзинәдән» оста файдаланып кына калмады, әдәби телне үзе дә осталарча эшкәртте һәм баетты, аңа яңа матурлык, үткенлек һәм нәфислек өстәде. Ибраһимов сүзләрнең мәгънә төсмерләрен арттырды, аларның эмоциональ-экспрессив мөмкинлекләрен көчәйтте, диалогларның төрле формаларын кертте. Ул татар теленең моңарчы файдаланылмаган мөмкинлекләрен хәрәкәткә китерде, аның сәнгатьчә фикерләү куәтен, кешe кичерешләрен тасвирлау байлыгын арттырды. Әдәби телгә мул рәвештә сөйләм теле элементларын кертеп, Г. Ибраһимов аны тагын да баетты, халыкка якынайтты. Аның әсәрләрендә татар теленең барлык җирле сөйләшләре бергә кушылды, гомуми максатка хезмәткә җигелде. Кыскасы, Г. Ибраһимов милли проза формалашуга гаять зур өлеш кертте, татар әдәби теленең үсешенә тирән эз салды. Әгәр ул күп кенә татар совет язучыларының, сәнгать кешеләренең остазы булу дәрәҗәсенә ирешкән икән, бу Ибраһимовның милли прозадагы зур тарихи урыны белән бәйләнгән.

Ибраһимовның тагын бер зур, тарихи роле шунда ки, ул безнең әдәбиятның интернациональ офыкларын киңәйтте. Әле революциягә кадәрге чорда ук ул төрле милләтләрнең күренекле язучылары, алдынгы фикер ияләре сафында булды. Ул татар әдәбиятын бөек рус әдәбиятының туганы, дөнья күләмендәге әдәби процессның бер өлеше итеп санады, бездәге әдәби хәрәкәтне А. С. Пушкин, Н. В. Гоголь, И. С. Тургенев, Л. Н. Толстой һәм А. М. Горькийларның, шулай ук Гомер, Данте, Шекспир, Шиллер, Гете, Байрон кебек көнбатыш әдәбияты классикларының әдәби-эстетик казанышлары белән сугарырга, баетырга чакырды. «Безгә... фәкать үз кабыгыбызга бикләнеп калырга мөмкин түгел, — дип язды ул. — Безгә гакыл вә фикеребезне гомум бәни адәм офыгына таба юнәлдерергә ...татар әдәбиятыннан үтеп, бөтен дөнья әдәбиятының тарихи адымнары белән дә танышырга лязим булачак»[1].

Г. Ибраһимов татар әдәбиятының интернациональ бәйләнешләрен көнбатыш әдәбияты белән генә чикләми, бу орбитага ул көнчыгыш классик поэзиясен һәм философиясен дә кертә: «Киләчәк-көнебезнең яктыруы өчен Гареп әдәбияты белән файдалануыбыз никадәрле лязим булса, шул нисбәттә үк, безгә Шәрыкның үткәне белән дә танышырга, Шәрык даһиларының хикмәт вә шигырьләре белән дә азыкланырга тиештер. ...Гомер, Данте, Шекспир кебек Гареп классиклары илә янәшә утырып, алларына бердәй тезләнергә фарыз булган Шәрык даһиларын хәтергә ала башларга вакыттыр дип уйлыйм. Мәдрәсә көрсиләренә, аннан бөтен татар йөрәгенә «Илиада»лар, «Илаһи комедия»ләр белән бергә үк гарәпнең Мәгарри, Фирдәүсинең «Шаһнамәләре», Сәгъди белән Фозулиның «Гөлстан» вә «Ләйлә-Мәҗнүн»нәре кереп утырырга тиешледер»[2].

Г. Ибраһимов иҗатының интернациональ характеры аның әдәби әсәрләрендә дә чагылды. Ул, мәсәлән, «Безнең көннәр» романына башкорт тормышыннан «Башкорт кызы Гөлбикә» дигән гүзәл парча кертте, «Казакъ кызы» исемле мәшһүр романын казакъ халкының тормышын, киләчәк язмышын күрсәтүгә багышлады. Әдип иҗатының интернациональ характерын билгеле торган иң әһәмиятле сыйфат, әлбәттә, үз халкының хәзерге тормышын, үткәнен һәм киләчәген тар милли рамкаларда түгел, бәлки интернациональ принципларда торып сурәтләвендә чагыла. Нәкъ менә шуның өчен Г. Ибраһимов әсәрләре бер татарлар арасында гына түгел, бөтенсоюз укучысының да мәхәббәтен казанды, русча тәрҗемәләре аша дөнья аренасына чыкты.

## 2

Г. Тукай һәм Ф. Әмирханнар белән бергә, Г. Ибраһимов татар әдәби тәнкыйтенә нигез салучы булды.

Бездә әдәби тәнкыйть XIX йөз башларында ук туса да, иҗат эшенең мөстәкыйль тармагы, әдәби хәрәкәтнең аерылгысыз бер компоненты буларак, ул 1905 ел революциясеннән соң, вакытлы татар матбугаты барлыкка килгәч кенә формалашып җитте. Дөрес, башка милли әдәбиятлардагы тәнкыйть белән чагыштырганда, Октябрь революциясенә кадәр үк инде ул шактый күп әдәби-эстетик казанышлар яулап һәм тәҗрибә туплап өлгергән иде. Аның Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Кәрам, Г. Рәхим кебек танылган тәнкыйтьчеләре бар иде. Тәнкыйть өлкәсендә шулай ук Г. Тукай, Ф. Әмирхан,

---

[1] «Тормыш» газетасы, 1915 ел, 27 ноябрь.
[2] Шунда ук.

Г. Камал, С. Рәмиев, Ш. Камал, Г. Коләхметов, Н. Думави кебек язучылар үзләре дә актив эшләделәр. Г. Ибраһимов исә бездәге демократик тәнкыйтьнең башында торды, аңа тон бирүче, әйдәп баручы булды. Һәм бу җаваплы вазифаны үтәгәндә ул, барыннан да бигрәк, рус революцион-демократик тәнкыйтенең идея-эстетик казанышларына таянды. Аның тәүге мәкаләләренең берсе В. Г. Белинский иҗатына багышланган булуы һич тә очраклы хәл түгел. Ибраһимов бу мәкаләдә бөек рус тәнкыйтьчесенең эстетик принципларын татар әдәбиятына һәм татар тәнкыйтенә нигез итеп алу кирәклеген әйтеп чыкты. Үзенең әдәби-тәнкыйть практикасында әле революциягә кадәр үк Белинский принципларын тормышка ашырырга тырышты, әдәбият һәм сәнгать үсешенә кагылышлы күп кенә идея-эстетик проблемаларны Белинский аңлатканча хәл итте. Аның хезмәтләрендә кузгатылган мәсьәләләрнең кайберләрен искә төшереп үтик: әдәбият һәм сәнгатьнең спецификасы, аларның тормышка мөнәсәбәте; сәнгатьнең барлыкка килүе һәм үсеш этаплары; талант һәм аның җәмгыять үсеше белән бәйләнеше, язучының дөньяга карашы; реализм һәм халыкчанлык; типиклык; милли әдәбиятның бөек рус һәм көнбатыш Европа әдәбиятларына эстетик мөнәсәбәте һ. б. Ибраһимовның тәнкыйть мәкаләләрендә шулай ук татар әдәбиятының гомуми хәле, төрле әдәби жанрларның формалашуы һәм үсеше, теге яки бу язучының әдәби процесста тоткан урыны, татар матбугатының барышы, милли театр мәсьәләләре зур урын алып тора. Башкача әйткәндә, ул әдәбият теориясе һәм эстетиканың нигез проблемаларын күтәреп чыга. Ибраһимов татар әдәбиятының үсеше турында еллык күзәтүләр язуны практикага кертә һәм ул бу җаваплы эшне революциягә кадәр дә, совет чорында да даими рәвештә алып бара.

Шуның белән бергә, Г. Ибраһимовның Октябрьга кадәрге тәнкыйть эшчәнлегенең шактый катлаулы, хәтта каршылыклы булуын да онытмаска кирәк. 1913 елда Оренбургта чыккан «Татар шагыйрьләре» исемле китабында, мәсәлән, Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәттә хата фикерләр уздыра. Әмма шунысы бар, Ибраһимов, тәнкыйтьче буларак, бер урында тукталып калмый, аның эстетик карашлары зур үсеш, үзгәреш кичерә. Революциягә якынайган саен, аның тәнкыйть эшчәнлегендә, әдәби иҗатындагы кебек үк, революцион-демократик принциплар өстенлек ала, мәкаләләрендә әдәбият һәм сәнгатьнең үсеш перспективаларын турыдан-туры иҗтимагый көрәш мәсьәләләре белән бәйләп карый, әдәби әсәрләрне анализлаганда политик мәсьәләләр күтәрә, революцион нәтиҗәләр ясый. Ибраһимов демократик әдәбият вәкилләренең игътибарын өлгереп җиткән социаль мәсьәләләргә юнәлтә: «Мөхәррир... үзенең тугры тасвиры белән тормышның авыр җәрәхәтләреннән берен укучы алдында ачып салып, халыкны шул хакта уйларга, **авыр язмышны җиңеләйтү турында чаралар күрә башларга**, һич булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга салырга мәҗбүр итсен! Әдәбияттагы реализмның бердәнбер әһәмияте фәкать шул ноктадандыр. (Курсив безнеке. — М. Х.)»[1].

Яңа революцион күтәрелеш чорында язылган бу мәкаләнең цензура иләге аша үтүен һәм авторның эзоп теле кулланырга мәҗбүр булуын искә алсак, тәнкыйтьченең монда **нинди чаралар күрергә** чакыруы җиңел аңлашылыр.

Октябрьга кадәрге демократик татар тәнкыйте һәм эстетик фикер үсеше үзенең югары ноктасына Ибраһимовның тәнкыйть эшчәнлегендә ирешә. Һәм аның аркылы ул марксистик тәнкыйтькә килеп тоташа. Чөнки ул революциядән соң татар тәнкыйтен чын фәнни нигезгә куючы, тәнкыйть өлкәсенә марксистик-ленинчыл методологияне кертүче була. Без татар әдәбиятында марксистик тәнкыйтьнең формалашуын бик хаклы рәвештә Ибраһимовның тәнкыйть эшчәнлеге белән бәйләп карыйбыз.

Аның совет чоры тәнкыйть мәкаләләрендә һәм хезмәтләрендә марксистик эстетиканың күп кенә әһәмиятле проблемалары кузгатыла (яңа тормыш төзүдә әдәбият һәм сәнгатьнең иҗтимагый роле; әдәби мираска мөнәсәбәт; әдәбиятның сыйнфыйлыгы; әдәби-иҗат практикасында язучының дөньяга карашының, иҗтимагый позициянең әһәмияте; әдәби осталык мәсьәләләре һ. б.). Әдип үзенең хезмәтләрендә яңа әдәбиятның идея юнәлеше белән бергә, форма, тел-стиль, иҗат методы мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Ләкин бу өлкәдә һичбер төрле схемалар тәкъдим итми. «Марксизм

[1] «Тормыш» газетасы, 1915 ел, 27 февраль.

алдан хәзерләнгән формалар бирми», — дип язды ул. Совет әдәбиятының иҗат методы, буржуаз советологлар язганча, кемнәрдер тарафыннан уйлап чыгарылган һәм иҗат практикасында декрет белән кертелгән догма түгел, ә бәлки егерменче еллардагы җанлы әдәби процессның бөтен барышы белән барлыкка китерелгән әдәби-эстетик казаныш була. Моның шулай икәнлеге татар совет әдәбиятының һәм тәнкыйтенең иң күренекле вәкиле Г. Ибраһимовның әдәби-иҗат һәм тәнкыйть практикасы, бу өлкәдәге эстетик эзләнүләре белән тулысынча раслана.

Октябрьгә кадәр татар телендә әдәбият теориясе һәм методикасы буенча кайбер хезмәтләр басылып чыкса да (Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди һ. б. китаплары), бездә әдәбият белеме, фән буларак, совет чорында гына формалашып җитте. Ул тулысынча Октябрь җимеше итеп каралырга тиеш. Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Гали аның нигез ташларын салучылар һәм бинасын коручылар булдылар. Бу өлкәдә Ибраһимовның «Пролетар әдәбияты турында» (1924), «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1924) исемле хезмәтләренең, аерым мәкаләләренең әһәмияте аеруча зур булуын әйтергә кирәк.

Әдәбиятның узганын өйрәнми торып, аның хәзерге хәлен билгеләү, киләчәге турында фикер йөртү, әлбәттә, мөмкин түгел. Татар әдәбиятының күп гасырлык бай тарихын системалы рәвештә фәнни нигездә тикшерү шулай ук Октябрьдан соң гына киң колач алды. Һәм бу совет әдәбиятының уңышлы үсеше, аның халык рухи культурасындагы бай традицияләр белән азыкландуы өчен бик кирәкле факторларның берсе иде. Марксистик методология нигезендә бу эшкә башлап тотынучы шулай ук Г. Ибраһимов булды. Ул үзенең «Иҗтимагый-әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» (1922), «Татар әдәбияты тарихының мөндәриҗәсен билгеләү мәсьәләсе» (1922), «Татарның соңгы тарихында өч дәвер (эпоха)» (1922), «Революция һәм әдәбият тарихларын эшләү юллары» (1922), «Татар әдәбиятын өйрәнү юлында» (1923) исемле һәм башка мәкаләләрендә әдәбият тарихына идеалистик карашларны тәнкыйтьли, алар урынына фәнни, материалистик принциплар урнаштыра. Әдәбият тарихын, аның дәверләрен, буржуаз галимнәр шикелле, аерым шәхесләр, әдәби талантлар тирәсенә кормыйча, ул әдәби күренешләргә ныклы нигез итеп революцион-азатлык хәрәкәте тарихын, халык тормышындагы социаль-экономик үзгәрешләрне ала. «Әдәбиятлар, — дип яза Ибраһимов, — фәлсәфәләр, гыйльми ысуллар, диннәр, әхлаклар, кыскасы, бөтен идеология хәрәкәтенең һичбере күктән яумаган кебек, нинди дә булса бер даһиның тик үз башыннан уйлап чыгаруы белән дөньяга килмиләр. Боларның фикерләре, рухлары, мөндәриҗәләре — һәммәсе тарихның мәгълүм дәверендәге мәгълүм бер матди, иҗтимагый катлаулар туфрагында үсеп чыга торган чәчәкләр генәдер»[1].

Әдәбият тарихының тикшерү объекты итеп ул татар халкының үз туфрагында, үзе тарафыннан тудырылган әдәби җимешләрне алу тиешлеген куйды. Һәм шушы принциптан чыгып, татар әдәбияты тарихының эчтәлеген барлады, аның феодализм чорыннан алып Октябрьгә кадәр үткән юлын күрсәтте, төп этапларын билгеләде. Һәм, әйтергә кирәк, егерменче елларда әдәбият тарихын тикшерү өлкәсендә ул зур эш башкарды. Ибраһимов сызган юлдан барып, әдәби күренешләр, әдәби ядкарьләр социаль-тарихи җирлектә, халык тормышына, үз чорының иҗтимагый вакыйгаларына бәйләнешле рәвештә өйрәнелә башлады, бик күп материал тупланды. Бу өлкәдә әдәбият тарихчыларыннан Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Г. Газиз, Җ. Вәлидиләр зур эш башкардылар.

Әмма әдәбият тарихы фәне җиңел генә формалашмады. Бу өлкәдә марксистик методологиянең урнашуына, бердән, татар филологиясендә әле революциягә кадәрге чордан ук ияреп килгән пантюркизм, буржуаз-милләтчелек карашлары комачауласа, икенчедән, егерменче елларда әдәбият һәм гомумән культурада киң таралган вульгар-социологизм шаукымы үзенең тискәре йогынтысын ясамый калмады. Боларның беренчесенә Г. Ибраһимов кискен отпор бирсә, үзенең хезмәтләрендә пантюркизм калдыкларын, буржуаз-милләтчелек карашларын эзлекле рәвештә кире какса, аларның икенчесе — ул елларда гомумән совет әдәбият белемендә шактый киң таралган бу чир — Г. Ибраһимовка да йокмый калмады. Табигый, язучының әдәбият тарихына багышланган хезмәтләре турында сүз барганда, без аның йомшак

[1] «Безнең юл» журналы, 1922 ел, 1 сан, 31 бит.

якларын читләтеп үтә алмыйбыз. Чөнки татар әдәбият белеме формалашуына Ибраһимовның, әдәбият галиме буларак, күчле яклары гына түгел, кимчелекләре дә тәэсир итте, үзенең эзен калдырды.

Әдәби мираска мөнәсәбәттә Ибраһимовның йомшак ягы шунда, ул революциягә кадәрге әдәби әсәрләрнең эстетик кыйммәтенә бәя биреп җиткерми, аларның кирәклеген үткәнне танып-белү ягыннан булган әһәмиятләренә генә кайтарып калдыра. Бу вакытта В. И. Ленинның һәрбер милли культурада ике культура барлыгы турындагы өйрәтмәләре әдәбият фәнендә тулысынча урнашып җитмәгән иде әле. Шуның нәтиҗәсе буларак, үткән дәверләрдә иҗат ителгән барлык әсәрләрнең тарихи кыйммәтләре бертигез дип танылды. Ибраһимов хезмәтләрендә һәм гомумән татар әдәбият белемендә, шулай ук әдәбият үсешендә буыннан-буынга күчә бару, кайсы дәвердә иҗат ителгән булуларына карамастан, классик әсәрләрдә чагылган гомумкешелек идеяләренең әһәмияте кебек кайбер мәсьәләләргә игътибар җитмәде. Бу, әлбәттә, яңа совет әдәбиятын төзүдә әдәби мирасның ролен, әһәмиятен тарайтуга китерә иде.

Әдәбият тарихының конкрет эчтәлеген һәм хронологик чикләрен билгеләү мәсьәләсенә килгәндә исә, Г. Ибраһимов аны Казан ханлыгы чорыннан башлады, аңа кадәрге этаплар турында сөйләү өчен әдәби ядкарьләр юк дип санады. Дөрес, алар табылган очракта галим әдәбият тарихының чикләрен киңәйтү мөмкинлеген инкарь итмәде. Ибраһимовтан соңгы тикшеренүләр татар әдәбияты тарихының Болгар дәүләте чорында язылган «Йосыф-Зөләйха» поэмасыннан башлануын расладылар.

Г. Ибраһимовның тел белеме, педагогика һәм методика өлкәсендәге хезмәтләре дә зур. Ул татар әдәби теленең үсешенә, аның саф һәм халыкчан булуына әдәби әсәрләре белән генә түгел, бу өлкәдәге гыйльми хезмәтләре, педагогик эшчәнлеге белән дә зур өлеш кертте. Ул телнең эчке закончалыкларын тикшерде, терминология принципларын нигезләде, татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасына нигез салды. Профессор М. Корбангалиев аны бик хаклы рәвештә «бөек методист» дип атады [1].

Г. Ибраһимовның социалистик культура төзелешенә караган кайбер теоретик мәсьәләләрне эшләвен дә билгеләп үтәргә кирәк. Ул, В. И. Ленин хезмәтләре, партия документлары нигезендә, егерменче еллардагы культура төзелешенең фактик тәҗрибәсенә таянып, социализм һәм милли культура, социалистик культурада милли һәм интернациональ сыйфатларның үзара мөнәсәбәте, милли культураның характеры һәм үсеш перспективасы кебек теоретик мәсьәләләрне күтәрде, культура төзелешендә партия политикасын бозуларга, милли нигилизмга кискен каршы чыкты, бу мәсьәләләрдә марксистик карашларның урнашуына ярдәм итте.

Ниһаять, Ибраһимовның татар совет әдәбияты каршындагы зур хезмәте тагын яшь талантларны тәрбияләп үстерүдә, аларга марксистик-ленинчыл эстетиканы үзләштерергә ярдәм итүдә күренә.

«Безнең әдәбиятыбызда, матбугатыбызда, сәхнәбездә яңа көчләр бер-бер артлы туа торалар... Мин ун еллар буенча мәдәни-әдәби дөньябызга чыккан яшь көчләрне, яңа исемнәрне артык дикъкать белән күзәтә киләм» [2],— дип язды ул 1920 елда. Октябрьдан соң әдәбият мәйданына килгән татар язучыларының күбесе аны үзенең әдәби остазы, зур сәнгатькә юл күрсәтүче итеп санады. Аның иҗади ярдәме белән әдәбият мәйданына Х. Туфан һәм Г. Нигъмәти, С. Кудаш һәм Ш. Бабич, казакъ совет әдәбиятына нигез салучылар Б. Майлин һәм Н. Манаев, үзбәк әдибе М. Ширмөхәммәтов, чиркас Ә. Хатков, адыгей Т. Керашев кебек шагыйрьләр, әдипләр һәм журналистлар күтәрелеп чыкты. Һ. Такташның зур шагыйрь, социализм чорының ялкынлы трибуны булып формалашуына аның йогынтысы зур булды. Әдипнең Ф. Бурнаш поэмалары турында әйткән фикерләре, К. Нәҗмигә һәм Г. Кутуйга биргән киңәшләре әлеге язучыларның идея-эстетик формалашуында гына түгел, гомумән, татар әдәбиятының реализм һәм халыкчанлык юлыннан үсешендә, әдәби хәрәкәттә формализмга каршы көрәштә гаять зур роль уйнадылар.

Г. Ибраһимовның яшь талантлар белән эшләү өлкәсендәге тәҗрибәсе әдәбият мәйданына һәм сәнгатькә бертуктаусыз яшь көчләр килеп торган хәзерге көндә

[1] «Галимҗан Ибраһимов» исемле мәкаләләр җыентыгы, Казан, 1928 ел, 166 бит.
[2] «Эшче» газетасы, 1920 ел, 20 октябрь.

аеруча зур игътибарга лаек. КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында» күптән түгел кабул ителгән карары яшь иҗат көчләре белән эзлекле һәм нәтиҗәле эшләүнең нихәтле актуаль һәм перспективалы булуын тагын бер кат раслый. Яшь талантлар турында даими кайгыртуы, игътибарлы, принципиаль һәм түземле булуы, яшьләр иҗатындагы уңай яралгыларны вакытында күреп алып үстергән кебек, кимчелекләрне принципиаль һәм иптәшләрчә тәнкыйтьләве, аларга юнәлеш бирә белүе белән Г. Ибраһимов бүгенге язучыларның күбесенә үрнәк була ала.

Шулай итеп, әдипнең зурлыгы әдәби әсәрләрендә һәм фәнни хезмәтләрендә генә түгел, бәлки әдәби варислары иҗатында, ул нигезләгән әдәби мәктәпнең, бүгенге әдәби хәрәкәтнең олылыгында да чагыла.

## 3

Г. Ибраһимов күренекле тарих галиме, ориенталист, марксизм-ленинизмны ялкынлы пропагандалаучы иде. Ул бу өлкәдәге эшчәнлеген революциягә кадәр үк башлап, татар тарихына караган күп кенә мәкаләләрен бастырса да, тарихчы галим буларак Октябрьдан соң формалашты.

Г. Ибраһимов, союз күләмендә беренчеләрдән булып, Бөек Октябрь революциясе тарихын язуны башлап җибәрде. Аның 1920—1922 елларда басылып чыккан «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы», «Сарайларга сугыш, фәкыйрь өйләргә туганлык» кебек хезмәтләрендә кешелек җәмгыяте үсешендә сыйныфлар һәм сыйнфый көрәшнең тоткан урыны, 1789 һәм 1848 елгы буржуаз революцияләр, Париж коммунасы, пролетариат диктатурасы, Октябрь революциясен хәзерләү һәм гамәлгә ашыру, аның дөньякүләм әһәмияте, халыкара революцион процесска йогынтысы һ. б. әһәмиятле мәсьәләләр тикшерелә. Бу хезмәтләрдә шулай ук Советларның роленә зур урын бирелә. Алар әдипнең гомуми тарих, Россиядә революцион-азатлык хәрәкәте, большевизм тарихы буенча тирән белемле һәм киң эрудицияле булуын күрсәтәләр.

Шунысы аеруча әһәмиятле, Ибраһимов аларда Октябрь революциясе, Коммунистлар партиясе тарихын меньшевистик, троцкистик бозуларга каршы чыга, революциядә В. И. Ленинның даһи юлбашчылык ролен күрсәтә. Бөек Октябрьның халыкара әһәмияте турында сөйләгәндә, автор аның бигрәк тә көнчыгышка йогынтысына киң туктала, Кытайда, Һиндстанда, Төркиядә һәм Иранда, Африка илләрендә революцион-азатлык көрәшенә бөек Октябрьның хәлиткеч тәэсир итүен күрсәтә. Шул ук вакытта автор ул илләрдә киң җәелгән милли-азатлык хәрәкәтенең революцион көрәш юлында әле беренче этап кына булуын да искәртә, хезмәт ияләренә чын азатлыкның сыйнфый көрәш нәтиҗәсендә генә киләчәген әйтә. Ул көнчыгыш халыкларының милли азатлык хәрәкәтен Европадагы сыйнфый көрәш, халыкара эшчеләр хәрәкәтеннән аерып карау омтылышларына кискен каршы чыга.

Революцион хәрәкәт тарихын марксистик-ленинчыл методология нигезендә өйрәнү эшен башлап җибәрүдә Г. Ибраһимовның «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» (1925) исемле зур фәнни хезмәте аеруча әһәмиятле роль уйный. Бу хезмәттә Татарстандагы революцион-азатлык көрәшенең ерак тамырлары, тарихи һәм экономик сәбәпләре, политик шартлары тирән яктыртыла, революция алдыннан булган социаль-экономик хәл, революциягә хәзерлекнең идеологик аспектлары бай тарихи чыганаклар, матбугат һәм архив материаллары нигезендә тикшерелә. Г. Ибраһимов, тарихчылардан беренче булып, татар пролетариатының формалашуын, аның ил күләмендәге революцион хәрәкәтенә кушылуын, беренче татар большевиклары Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов һ. б. эшчәнлеген тикшерә, вак буржуаз партияләргә, татар буржуазиясенең политик оешмаларына марксистик бәя бирә. Китапның шактый өлешен 1905 ел революциясе чорында барлыкка килгән вакытлы татар матбугатын тикшерү, газета-журналларның идея-политик йөзен билгеләү, татар телендәге беренче большевистик газета «Урал»ны һәм татар большевикларының листовка һәм прокламацияләрен анализлау кебек мәсьәләләр алып тора. Кыскасы, бу хезмәттә Беренче рус революциясенә бәйләнешле күп кенә социаль-экономик, политик һәм идеологик проблемалар тикшерелә, марксистик күзлектән карап, фәнни хәл ителә. Әйтергә ки-

рәк, аның республикада тарих фәне үсеше өчен әһәмияте зур була, ул шулай ук «Правда», «Известия» газеталарында, үзәк журналларда югары бәя ала.

Г. Ибраһимов шулай ук республикада дәүләт төзелеше проблемаларын тикшерүне башлап җибәрде, Татарстан АССР төзелү тарихының марксистик концепциясен бирде, буржуаз милләтчелек, эсер-меньшевистлык уйдырмаларын фаш итте, бу мәсьәләдә дә В. И. Ленин хезмәтләренең методологик әһәмиятен күрсәтте.

Г. Ибраһимовның 90 еллык юбилее уңае белән язылган бу мәкаләдә аның тарих фәне өлкәсендәге барлык хезмәтләренә тукталып булмый. Тарихчы буларак, аны махсус тикшерергә кирәк. Йомгак ясап, бары шуны әйтергә кирәк: галимнең Татарстан тарихы буенча, аеруча революцион хәрәкәт тарихына караган хезмәтләре тарих фәнендә бүген дә зур казаныш булып кала, алар фактик материалга байлыклары ягыннан да, фәнни нәтиҗәләренең объективлыгы һәм дәреслегe җәһәтеннән дә, автор позициясенең партиялелеге белән дә бүген дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмыйлар, Татарстан тарихын тикшерүчеләр аларны читләтеп үтә алмый.

Г. Ибраһимовның тарихи әһәмияткә ия тагын бер зур хезмәте — марксизм-ленинизм теориясен, фәнни социализмны пропагандалавы. Ул Казанда Татар коммунистлар университетында, өлкә партия-совет мәктәбендә, төрле хәрби курсларда марксизм-ленинизм, РКП(б) тарихы, революцион хәрәкәт тарихы буенча лекцияләр укый, алар гына да түгел, бу хакта матбугатта күп санлы мәкаләләр бастыра, китаплар чыгару чарасын күрә, редакцион коллегияләргә җитәкчелек итә һ. б. Әле «Чулпан» газетасында эшләгән чагында ук ул совет хөкүмәтенең беренче декретларын татарчага тәрҗемә итеп чыгара, Октябрь революциясе һәм фәнни социализм, совет властеның милли политикасы турында брошюралар бастырып фронтка җибәрә. Ул — төрки телләрдә марксизм-ленинизм, партия тарихы, революцион хәрәкәт буенча китаплар бастыру эшенә нигез салучыларның берсе.

Г. Ибраһимов Октябрьның беренче көннәреннән үк В. И. Ленин әсәрләрен, аның революцион эшчәнлеген татар халкы арасында пропагандалауга керешә. Бөек юлбашчы идеяләрен туган халкына җиткерүне, хезмәт ияләрен марксизм-ленинизм рухында тәрбияләүне ул үзенең изге бурычы итеп саный, һәм бу өлкәдә зур дәрт белән, аеруча илһамланып эшләде.

В. И. Ленин эшчәнлегенең төрле аспектларына, юлбашчының теоретик хезмәтләренә, шулай ук аның бөек шәхси сыйфатларын ачуга Г. Ибраһимовның алты зур мәкаләсе багышланган. Алар 1920—1924 елларда татар вакытлы матбугатында, төрле җыентыкларда басылганнар. Бу оригиналь мәкаләләр, В. И. Ленинның тәгълиматын һәм революцион эшчәнлеген яктырту белән бергә, әдәбиятта һәм сәнгатьтә бөек юлбашчы образын тудыруга лаеклы өлеш тә булып торалар. Аларны бик хаклы рәвештә татар әдәбиятында ленинианаының башлангычы дип санарга мөмкин.

Г. Ибраһимов — шулай ук бөек юлбашчының теоретик мирасын татар теленә тәрҗемә итү һәм бастырып чыгару эшен башлап җибәргән кеше. Ул Татарстан партия өлкә комитеты тарафыннан В. И. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итү өчен төзелгән махсус комиссиянең председателе була. Әгәр дә без, илебез халыклары арасында беренчеләрдән булып, В. И. Ленин әсәрләренең җыелмасын (IV басма, 45 том) татарчага тәрҗемә итү һәм бастырып чыгару эшен тәгәлләгәнбез икән, монда Г. Ибраһимовның хезмәте гаять зур. Чөнки ул бу зур эшкә нигез сала, әле егерменче еллар башында ук аның перспектив планын төзи, квалификацияле тәрҗемәчеләр хәзерләү чараларын күрә.

4

Г. Ибраһимов — зур талант иясе, иҗат кешесе генә түгел, үзендә галимлек һәм художниклык сыйфатларын революционер йөрәге белән бергә кушкан язучы-көрәшче дә. Ул һәр вакыт дөрләп һәм балкып янды. Үзенең табигате белән үк ул көрәш өчен, янар өчен туган иде. Кирәк чагында, революция таләп иткәндә, ул язучылык каләмен революцион көрәш коралына яки дошман тылында разведчик вазифасына алмаштырды.

Зур язучы һәм галим булуын исәпләмәгәндә дә, ул — үзенең революцион эш-

чәнлеге белән генә дә тарихыбызда күренекле урынны алырлык шәхес. Ул — киң халык массаларының революцион аңын үстерүдәге зур роле, Октябрь революциясен тормышка ашыруда, совет властеның беренче елларында милли дәүләт төзелешендә һ. б. тарихи эшләрдә актив катнашуы белән татар халкының күренекле революционерлары Х. Ямашев, М. Вахитов, К. Якупов һ. б. белән янәшә торырлык шәхес. Аның революцион хәрәкәт, совет властен урнаштыру, буржуаз-милләтчеләргә каршы көрәш, татар халкының автономияле республикасын төзү һ. б. өлкәдәге хезмәтләре гаять зур.

Г. Ибраһимов әле шәкерт чагында ук иске татар мәдрәсәләрендәге тәртипләргә каршы чыга, аларның заман таләпләреннән артта калуын күрсәтә. Ул Киевтә мөселман студентларының яшерен оешмасында катнаша, патша властьлары тарафыннан төрмәгә ябыла, берничә ел охранка күзәтүе астында яши. Кыскасы, Октябрьга кадәрге чорда Ибраһимовның революционерлык таланты катлаулы үсеш юлы үтә. Моның социаль-тарихи сәбәпләре бар. Хәзер аларга тукталуның кирәге юктыр. Алар әдипнең тормыш юлына, революцион эшчәнлегенә багышланган махсус хезмәтләрдә тикшерелә. Әмма революционер буларак Г. Ибраһимовның зурлыгы да шунда, ул, вак буржуаз революционерлык этабын үтеп һәм милли чикләнгәнлекне җиңеп, катлаулы һәм каршылыклы революцион көрәш сукмаклары аша, эсерлар сазлыгын ерып чыгып, марксизм-ленинизмга, большевиклар партиясенә килде. Аның революционерлык таланты тулысынча Бөек Октябрьдан соң ачылды, шул чордан әдипнең политик биографиясендә яңа этап башланды.

Ибраһимовның революционер буларак җитлеккәнлеге һәм политик сизгерлеге барыннан да элек 1918 елның гыйнварында Учредительное собраниега мөнәсәбәтендә күренде. Ул аның политик асылын тиз аңлады. Мөселман делегатлары, аерым бер фракция төзеп, учредилкага өметләр баглаган бер чакта, Ибраһимов большевик делегатлар белән бергә аны ташлап чыкты, революционер дусты М. Вахитов белән бергә В. И. Ленин җитәкчелегендә үзәк дәүләт аппаратында эшләде, советларның III һәм IV Бөтенроссия съездларында катнашты, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетына әгъза булып сайланды. Нинди җаваплы чор һәм нинди зур вазифалар! Боларның һәммәсе бер кеше башыннан кичкән бит!

Бу катлаулы чорда Ибраһимовның революцион көрәш юлын В. И. Ленин идеяләре яктыртып тора. Аңа ВЦИК утырышларында катнашу, бөек юлбашчының чыгышларын тыңлау насыйп була. Г. Ибраһимов, татар язучыларыннан беренче булып, В. И. Ленин белән очрашып сөйләшү, киңәшләшү бәхетенә ирешкән кеше.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты утырышында Брест тынычлык договоры каралган вакытта ул икеләнүсез В. И. Ленин тәкъдимен яклап чыга. Болар — Г. Ибраһимов революцион эшчәнлегенең әһәмиятле этаплары, иң калку моментлары гына. Аның бу өлкәдәге хезмәтләре партия тарафыннан шул вакытта ук тиешле бәя ала. Мәгълүм булганча, большевиклар партиясенә ул официаль рәвештә 1920 елның декабрендә кабул ителде. Әмма актив революцион эшчәнлеген һәм марксизм-ленинизмны пропагандалаудагы хезмәтләрен искә алып, аның партия стажы 1917 елның 15 апреленнән саналды. Социалистик революциягә, большевиклар партиясенә вак буржуаз революционлыгы аша килгән революционер өчен бу зур бәя иде.

Г. Ибраһимовның совет чорындагы иҗтимагый-политик эшчәнлеге гаять бай, күпкырлы һәм нәтиҗәле.

Беренчедән, ул татар буржуаз матбугатын җимерүдә, совет милли матбугатын нигезләүдә зур роль уйный. Мәгълүм булганча, татар буржуаз матбугаты революциягә кадәр нык үскән, материаль базасы шактый көчле булган милли матбугатларның берсе иде. Октябрь революциясе булгач, ул совет властена, большевиклар партиясенең милли политикасына һәм татар милләтенең революцион көчләренә каршы ачыктан-ачык көрәш җәелдерде. Шуңа күрә аны җимерү, тамырларын өзү кирәк иде. Бу бурычны үтәү башлыча М. Вахитов белән Г. Ибраһимов, алар җитәкләгән Үзәк Мөселман Комиссариаты өстенә төште. Менә шуңа күрә дә татар буржуаз милләтчеләре М. Вахитовны һәм Г. Ибраһимовны аеруча дошман күрделәр.

Икенчедән, бу шул ук вакытта яңа совет матбугаты өчен җирлек хәзерләү дә иде. Ә аны төзүдә Ибраһимовның роле шулай ук кечкенә түгел.

Г. Ибраһимов — татар телендәге беренче совет газетасы «Чулпан»ның оештыручысы һәм фактик редакторы. Бу газета татар матбугаты тарихында тиешенчә тикше-

релмәгән әле. Хәлбуки, аның революция каршында һәм милли телләрдә совет матбугаты формалашуда роле гаять зур. Совет хөкүмәтенең беренче декретлары әнә шунда турыдан-туры Ибраһимов тәрҗемәсендә басылалар һәм Россиянең төрки халыклары арасында таралалар.

Башка кайбер татар газеталарының да башлангыч адымнары Ибраһимов исеме белән бәйләнгән. Ул — Октябрьдан соң барлыкка килгән татар педагогика журналын нигезләүче һәм аның редакторы, әдәби-политик журнал «Безнең юл»ның оештыручысы һәм редакторы. Г. Ибраһимов тагын «Коммунистический путь» журналы һәм «Татарстан» газетасының эшендә актив катнаша. Татар телендә партия-совет матбугаты әле яңа гына оешып килгән бервакытта аның шикелле зур язучының һәм авторитетлы журналистның актив эшләве башка өлкән буын татар язучыларына һәм журналистларына бәрәкәтле йогынты ясый, демократик иҗат көчләрен партия матбугаты тирәсенә туплауга, аларның талантын һәм бай иҗат тәҗрибәсен социалистик культура төзү эшендә файдалануга хезмәт итә.

Өченчедән, Г. Ибраһимов — татар совет мәгарифенә нигез салучыларның берсе. Әле Үзәк Мөселман Комиссариатында эшләгәндә үк ул бу әһәмиятле идеологик коралны буржуазия кулыннан тартып алып, совет власте органнарына бирүгә күп көч куйды. Ул мөселман укытучыларын совет власте платформасына күчерүдә гаять зур эш башкарды. Аның Бөтенроссия мөселман укытучыларының 1918 елның маенда Казанда үткәрелгән III съездының политик платформасын билгеләүдәге тарихи роле, 1924 елның февралендә Мәскәүдә үткәрелгән татар-башкорт мәгариф эшчеләренең съездындагы актив эшчәнлеге һ. б. татар мәгарифе һәм педагогика фәне үсеше тарихына алтын хәрефләр белән язылырга лаек.

Ә Г. Ибраһимовның Гыйльми үзәктәге эшчәнлеге тагын да зуррак хөрмәткә лаек. Бу әһәмиятле дәүләт органы эшендәге иң бай, иң нәтиҗәле чор нәкъ менә ул эшләгән елларга туры килә. Ибраһимовның зур галим, гыйльми-тикшеренү һәм культура эшләрен оста оештыручы булуы да тулысынча нәкъ әнә шунда күренде.

Гыйльми үзәк партия органнары җитәкчелегендә республикада гыйльми-педагогик, әдәбият-сәнгать фронтында киң эшчәнлек җәелдереп җибәрә, Татарстан мәктәпләре өчен стабиль программалар төзүне оештыра, марксистик дәреслекләр һәм кулланмалар бастырып чыгаруны юлга сала, татар телен гыйльми эшкәртү чараларын күрә. Шулай ук туган якны һәм культура тарихын өйрәнү, табигать һәм сәнгать ядкарьләрен саклау буенча эш башкара.

Г. Ибраһимов җитәкчелек иткән чорда Гыйльми үзәк чын-чынлап фән учагына әверелә, фәнни җәмәгатьчелек каршында авторитет һәм популярлык казана. Республикада тарих, тел һәм әдәбият буенча гыйльми-тикшеренү эшләрен җайга салуда, фән, әдәбият, культура һәм сәнгать көчләрен берләштерүдә бу оешманың роле зур була. Татарстанда гуманитар фәннәр үсеше үзенең башлангычын шушы оешмадан ала. Гыйльми үзәк татарлар арасында иҗтимагый фикер үсеше һәм революция хәрәкәтләре тарихын өйрәнү буенча нәтиҗәле эш башкара. Ибраһимовның тагын бер зур хезмәте бу оешма эшенә күренекле рус галимнәрен тартуда. Мәскәүнең һәм Ленинградның күп кенә фәнни учреждениеләре белән бәйләнеш урнаштыруда. М. Павлович, А. Самойлович, В. Добрянский, Н. Фирсов, И. Бороздин, П. Коган шикелле тарихчылар, әдәбият белгечләре аның белән нык элемтәдә тордылар, совет властеның беренче елларында Татарстанда фән эшләрен оештыруга, татарлардан гыйльми кадрлар хәзерләүгә зур өлеш керттеләр.

Әдипнең совет чорында культура өлкәсендәге эшчәнлегенең һәр тармагы махсус тикшерүгә лаек. Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: Ибраһимов үзенең иҗтимагый-политик һәм оештыру эшчәнлеге белән дә татар совет культурасы үсешенә зур өлеш кертте, аны һәрьяклап баетты һәм югары күтәрде. Һәм, әйтергә кирәк, аның белән бергә ул үзе дә югары күтәрелде, фән, культура һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, бер Татарстанда гына түгел, бөтен ил күләмендә танылды. Ул культура өлкәсендәге эшчәнлеге белән дә революционер иде.

Г. Ибраһимовның әдәби иҗатын, фәнни һәм иҗтимагый-политик эшчәнлеген, ул калдырган бай әдәби мирасны туплау, фәнни тикшерү, халыкка җиткерү буенча зур

эш башкарылды. Хәзер бу өлкәдә алда торган әһәмиятле бурычларның берсе — аның 8 томлык әсәрләр җыентыгын әзерләп бетерү һәм бастырып чыгаруны тәгәлләү.

Бу басма беренче тапкыр әдипнең югарыда сөйләнгән этрафлы эшчәнлеген бөтен тулылыгы, тирәнлеге һәм масштаблылыгы белән күз алдына китереп бастырачак, бөек әдипкә лаеклы һәйкәл булачак. Ә бит әдипнең эшләгән эшләренә бәя биргәндә партия һәм совет дәүләте аның нәкъ әнә шул сыйфатына басым ясаган иде. Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының аңа Хезмәт Герое исеме бирү турындагы карарында (1932 ел) болай диелә:

«Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы, Сезнең татар хезмәт иялэренең социаль-культура өлкәсендәге бик күренекле һәм аеруча файдалы хезмәтләрегезне — татар матур әдәбияты классик әсәрләрен тудыру, татарлар арасында сыйнфый көрәш һәм революцион хәрәкәтне өйрәнү буенча хезмәтләрегезне, шулай ук актив җәмәгать эшчәнлегегезне искә алып, Сезгә Хезмәт Герое исеме бирә»[1].

Г. Ибраһимов иҗатына күп милләтле совет әдәбиятының күренекле вәкилләре югары бәя бирделәр. Совет әдәбиятына нигез салучы, милли әдәбиятлар үсешен зур кызыксыну белән күзәтеп барган бөек А. М. Горький Ибраһимовны күп милләтле совет әдәбияты үсешенә аеруча зур өлеш керткән олы художниклар рәтенә куйды[2]. Әдипнең бай һәм тиңдәшсез иҗат хәзинәсе хаксызга читкә этәрелгән бервакытта А. А. Фадеев аны һич икеләнмичә яклады, бөтен союз трибунасыннан торып, Ибраһимовның тиңдәшсез стилист һәм сүз художнигы булуын, әдәби осталыкка аннан өйрәнергә кирәклеген әйтеп чыкты[3]. Күренекле француз язучысы, коммунист Л. Арагон татар әдәбиятында роман жанрының формалашуында Ибраһимов әсәрләренең роле гаять зур булуын билгеләп үтте[4].

Г. Ибраһимов иҗаты бигрәк тә илебезнең төрки халыкларына яхшы таныш. Чөнки бу әдәбиятларга аның әдәби йогынтысы аеруча бәрәкәтле, тирән һәм нәтиҗәле булды. Башкорт халык шагыйре С. Кудаш, мәсәлән, аны үзенең турыдан-туры остазы дип атады. Аның фикеренчә, башкорт совет әдәбиятының өлкән буын вәкилләреннән байтагы әдәбиятка турыдан-туры Ибраһимовтан сабак укып яки аның классик әсәрләреннән өйрәнеп килделәр[5].

«Галимҗан Ибраһимовны казакълар үз язучылары — казакъ язучысы итеп исәплиләр,— дип язды академик С. Муканов.— Безнең халык тормышын шулай яратып язганы өчен казакълар Ибраһимовка һәр вакыт хөрмәт белән карарлар... Галимҗан Ибраһимов исеме безнең күп милләтле социалистик культурабыз тарихына мәңгелеккә керде»[6].

Ибраһимов әдәби традицияләренең үзбәк язучысы А. Кадыйри, таҗик әдәбияты классигы С. Айни иҗатында, кыргыз әдибе А. Токомбаев әсәрләрендә дәвам итүен билгеләп үтәргә кирәк. «Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар» романнары минем әдәби университетым булдылар. Әдәбият дөньясына аяк басуым белән мин өлкән буын татар әдипләренә бурычлымын»[7],— дип язды күренекле төрекмән язучысы Б. Кербабаев.

Ибраһимов иҗатына шулай ук Ч. Айтматов югары бәя бирде, аның йөзендә татар прозасының күп милләтле совет әдәбиятына зур өлеш кертүен әйтте[8].

«Зур татар прозаигы, романист Г. Ибраһимовның әсәрләре республикабыздагы киң катлау укучылар арасында зур уңыш казанды. Күпләр хәтта аны әзербәйҗан язучысы итеп саныйлар иде»[9],— дип язды атаклы әзербәйҗан әдибе Мәһди Хөсәен.

Ибраһимовның олылыгын күрсәткән, тарихи ролен раслаган фикерләрне дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Алар татар язучысының иҗаты күп милләтле совет әдәбиятында үзенә лаек урын алуы турында сөйли. Әле Г. Ибраһимов үзе исән чакта ук Дәүләт сәнгать фәннәре академиясе президенты профессор П. С. Коган:

«Ул әһәмияте үз иле чикләреннән еракка китә торган художникларның берсе. Ул

---

[1] КПССның Татарстан өлкә комитеты архивы. 1378 фонд. 1987 тасвирлама, 378 эш, 33 бит.
[2] Г. Ибраһимов турында истәлекләр. Казан, 1966 ел, 306 бит.
[3] «Социалистик Татарстан», 1971 ел, 23 декабрь.
[4] «Совет әдәбияты», 1956 ел, 10 сан, 79 бит.
[5] «Социалистик Татарстан», 1967 ел, 12 март.
[6] «Литературная газета», 1962 ел, 13 март.
[7] «Социалистик Татарстан», 1972 ел, 26 апрель.
[8] Шунда ук, 1967 ел, 18 март.
[9] Шунда ук, 1964 ел, 28 май.

кешелек дөньясының иң яхшы, шагыйрьләре рәтенә горур атлап керә ала» [1],— дигән иде. Әйе, П. С. Коган сүзләрен тарих раслады. Ул, чыннан да, бөек шагыйрьләр семьясына — Гёте һәм Пушкин, Толстой һәм Шевченко, Горький һәм Райнислар семьясына керде һәм үзенең исемен мәңгеләштерде.

Ибраһимовның классик әсәрләре, сүз сәнгатенең югары үрнәге буларак, коммунизм төзүче совет халкының гомуми рухи байлыгына әверелде. Алар хәзерге әдәби-эстетик хәрәкәттә актив катнаша, җаваплы идеологик эш башкара. Язучының бай әдәби мирасы әдәбият һәм сәнгать алдына КПССның XXV съезды куйган җаваплы бурычны үтәүгә уңышлы хезмәт итә.

**Гали Халит,**
филология фәннәре докторы

# ЧЫНЛЫК ҺӘМ ГҮЗӘЛЛЕК ГАРМОНИЯСЕ

*Г. Ибраһимовның эстетик карашлары үсешен күзәтү тәҗрибәсеннән*

**1**

Галимҗан Ибраһимов, тормышта да, сәнгатьтә дә чынлык һәм гүзәллек гармониясен эзләп, гаять дәрәҗәдә катлаулы, каршылыклы юл узган художниклардан. Ләкин ул тик социалистик революциядән соң гына үз юлының якты офыкларын күреп иҗат итү югарылыгына күтәрелә. Аңа кадәр үтелгән юлның сикәлтәләре һәм борылышлары күп була. Язучы теләгән чынлык һәм гүзәллек гармониясе тиз генә, җиңел генә табылмый, аның серләре кинәт кенә ачылмый.

Кешене изгән тәртипләр белән килешергә теләмәгәне һәм ирек даулаганы өчен, Зәки шәкертне мәдрәсәдән куалар. Гөлбану, каенана йортындагы изү-мәсхәрәләргә чыдый алмыйча, ирләр киеменә киенеп, читкә чыгып китә һәм шул юл белән ирек табарга тели. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) һәм «Татар хатыны ниләр күрми» (1910) кебек беренче хикәяләрендәге әнә шундый гыйсъянчы геройларда ук инде Ибраһимов иҗаты аша үтәчәк төп тенденциянең характерлы яралгыларын күрергә мөмкин. Яралгылар дигәндә, без әдәби геройның үзен әйләндереп алган чынбарлыкка кискен протест белдерүен, үз шәхесенә ирек даулавын, шуның белән гадәти кешеләрдән аерылып торуын һәм күп очракта гадәттән тыш хәлләр, гамәлләр кылуын күздә тотабыз. Язучы иҗатының үзенчәлекле сыйфаты булып әвереләчәк романтик башлангыч нәкъ шушы моментларда күренә дә инде. Шулай итеп, Г. Ибраһимов иҗат методының, аның чынбарлыкка сәнгатьчә мөнәсәбәтенең һәм эстетик идеалының романтик юнәлешен, барыннан да элек, аның әдәби герое билгели. Торабара бу герой чынбарлыкның киңрәк мәйданына чыгып, үзенең киеренке эчке дөньясын һәм каршылыклы идеалларын тулырак ачу югарылыгына күтәрелә.

«Диңгездә» (1911) хикәясенең герое («Мин»), җир өстендәге мәгънәсез, ямьсез, күңелсез тормыштан туеп, диңгез эченә кереп китә һәм табигатьнең мәһабәт, дәһшәтле стихиясендә үз рухына якын матурлык эзли. Ләкин җир тормышын ләгънәтләп, әллә кайда башка бер ләззәт, рәхәтлек һәм гүзәллек эзләгән герой яңадан үзе ташлап киткән чынбарлыкка әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. «Ярга якынлашып, андагы поездның вәхши акыруын ишетү, корымнар, төтеннәр белән буялып беткән завод

[1] Вестник научного общества татароведения. 1928 ел, 8 сан, 5 бит.

морҗаларын күрү белән җаным кысыла, йөрәгемдә бер әрнүле пошыну уяна. Эчемдә нидер җимерелә, нидер югала. Күңелемнән нәрсәнедер тартып алалар... Ләкин башка чара юк»,— ди ул.

Димәк, ул герой кеше шәхесен җәберләгән, аның рухын кыскан чынбарлыктан югары торган матурлык идеалын әзли һәм корым-төтеннәр белән агуланган көндәлек тормыштан табигать дөньясының өстен булуын расларга тели. Бу инде — табигатьне идеаллаштыру, табигать культы дигән сүз. Әмма Ибраһимов герое моның белән генә чикләнми әле. «Сөю — сәгадәт» (1911) хикәясенең герое картлык көннәрендә яшьлек мәхәббәтен сагына. Ибраһимов иҗатында тагын бер культ — кешеләр рухын сафландырырга, аларның рухи ирегеН, гүзәллеген сынландырырга тиешле мәхәббәт культы чәчәк ата. Мәгълүм ки, табигатьне һәм мәхәббәтне идеаллаштыру — традицион романтизм әдәбиятының үзәген биләгән тенденцияләрдән. Гадәттә ул идеал чынбарлыктагы вак теләкләргә һәм түң күңелләргә каршы куела, ирек даулаган шәхеснең рухи бәйсезлеген күрсәтә. Ибраһимов иҗатында да бу нәкъ шулай.

1910 елларда ук инде Ибраһимов үзенең мәкаләләрендә кайбер эстетик концепцияләрен шактый ачык билгеләде. «Әдәбият мәсьәләләре» дигән мәкаләсендәге кайбер фикерләре, мәсәлән, бу яктан аеруча характерлы. Шагыйрь,— диде ул,— «безгә назик вә мөәссир[1] хисләр, гали[2] моң, матур ләүхәләр[3] түксен! Безгә гади күренгән нәрсәләрне бөтенләй башка итеп күз алдыбызга салсын. Шуның өчен дә истигъдатлары икърар кыйлынган[4] олуг шагыйрьләрнең хакыйкый шигырьләрендә табигатьнең моң, мөәссир вә матур манзаралары[5], үзенең хиссияте шәхсиясе[6], әүлахы руханиясе[7] мөһим урын тоталар... Табигать белән сугышыр хәл юк. Кеше үзе шагыйрь була алмый, аны табигать ясыйдыр».

Бу фикерләр башлыча натурализмга һәм дидактизмга, ягъни тормыш койрыгында сөйрәлеп барган һәм коры сүз белән үгет саткан шагыйрьләргә төбәлеп әйтелсәләр дә, шул ук чакта аларда инде романтизм эстетикасының яралгылары да шактый ачык сизелә. Чынлыкка каршы куелган яки аннан югары торган гүзәллек идеалына һәм әдәби талантның табигый-тума сыйфатларына басым ясау нәкъ шул хакта сөйли.

«Яшь йөрәкләр» романы (1912) — язучының романтик ашкыну һәм әзләнүләренең иң югары ноктасын күрсәткән әсәр. Үзләре яшәгән тормыш шартлары, гореф-гадәтләр белән тирән конфликтка кергән Зыя һәм Мәрьям мәхәббәт ләззәтенең һәм газабының корбаннары булып гәүдәләнәләр. Алар, барыннан да элек, мәхәббәт ирекe аша шәхси бәхеткә ирешү турында хыялланалар. Ләкин, бу теләкләргә каршы килгән көчләрне һәм шартларны җиңәрлек сәләтләре булмаганлыктан, Зыялар, Мәрьямнәр котылгысыз һәлакәткә баралар. Бу да — романтик геройның бик характерлы сыйфаты, үзенең һәлакәте, фаҗигасе белән дә ул үзе кире каккан чынбарлыктан югары торуын, килешә алмавын әйтергә тели.

«Яшь йөрәкләр» романында табигать һәм мәхәббәт культларына тагын сәнгать культы өстәлә. Бигрәк тә Зыя образында мәхәббәт, сәнгать һәм табигать культлары җырлегендә туган романтик психологизм да шактый тулы гәүдәләнә. Бу психологизм геройларның кызганыч хәлен көчәйткән сентиментализм һәм мелодраматизм белән сугарылган. Язучы фикеренчә, шәхеснең ирекe һәм рухи гармониясе — кешене изүче чынбарлыкка капма-каршы булган табигый тормышта мәхәббәт һәм сәнгать культының чәчәк атуы белән бәйле. Бу, әлбәттә, традицион романтизмга хас идеалистик караш, иллюзия иде.

«Яшь йөрәкләр»нең үзәгенә, чорның иҗтимагый мәсьәләләреннән бигрәк, кеше характерларының бик индивидуаль-психологик төсмерләре, аларның мораль-этик контрастлары куелган. Шуңа күрә дә аның татар прозасында беренче психологик роман дип аталуы хаклы иде. Әмма шул ук вакытта бу психологизм Көнчыгышның традицион романтизмына хас хирыс экстазы белән дә тирәннән сугарылган. Мәгълүм ки, Урта гасыр Көнчыгыш классик әдәбиятында чәчәк аткан хирыс психологизмының нигезендә мәхәббәт культы ята. «Яшь йөрәкләр» романы шул традицияне яңарта. Ләкин монда хирыс психологизмы мәхәббәт белән генә чикләнми. Җәләш мулла,

---

[1] Назик вә мөәссир — гүзәл һәм тәэсирле. [2] Гали — бөек. [3] Ләүхә — күренеш, картина. [4] Истигъдатлары икърар кыйлынган — талантлары танылган. [5] Манзара — күренеш, картина. [6] Хиссияте шәхсия — шәхес кичерешләре, хисләре. [7] Әүлахы рухания — рухи күренешләр, хәлләр.

Сабир һ. б. шундый геройлар психологиясен белгән хирыс һәм теләк-дәртләр бөтенләй икенче. Ибраһимов хирыс психологизмының төсмерләрен баета һәм аларны индивидуаль характерларның капма-каршы рухи билгеләре итеп тасвирлый.

Язучы иҗатының башыннан ук романтик характер аңа чит чынбарлыкка кискен каршы куеп сурәтләнә. Бу алым «Яшь йөрәкләр»дә дә мул кулланыла. Зыя белән Мәрьям нинди генә югары хыяллар дөньясында йөзмәсеннәр, алар көндәлек тормышның гадәти хәлләреннән һич тә читтә тормыйлар. Киресенчә, алар шул хәлләр эчендә, аларның авырлыгын һәм каршылыгын җиңеп, үзләренең югары, изге теләкләренә ирешергә омтылалар. Ләкин бу төр романтик геройларның хыяллары, идеаллары чынбарлык белән көрәштә җимерелә, җиңеләләр. Кайбер белгечләр моны «Яшь йөрәкләр» романында романтизм белән реализмның каршылыгы, бәрелеше дип аңлаталар. Ләкин асылда без монда һич тә романтизм белән реализмның каршылыгын түгел, ә романтик геройларның чынбарлык белән якын мөнәсәбәттә булуларын гына күрәбез. «Шагыйрь халкы,— әгәр дә ул чын мәгънәсе илә шагыйрь булса,— бу җирдәге вак, гади тормыш илә канәгатьләнә алмый,— дип язды Ибраһимов шул ук 1912 елда.— Аның хыялы әллә кая, ерак, югары һәм хыялый галәмгә алып китә, ләкин хакыйкатьтә китә алмый. Һаман шул үзе сөймәгән, нәфрәтләнгән вак, түбән тормыш эчендә яшәргә мәҗбүр була. Шуннан туа — аның изтирабы, бу тормыштан зарланулары, ачы әрнүләре»[1]. Димәк, романтизм да, романтик геройлар да гел күктә яшәмиләр, ә хакыйкатьне җирдән эзлиләр. Ибраһимов чынбарлык белән тыгыз бәйләнештә иҗат иткән романтикларның берсе иде.

## 2

Иҗади үсү процессында Ибраһимовның эстетик карашлары теоретик яктан да формалаша барды. Шул хакта сөйли торган әсәрләрнең иң характерлысы — «Татар шагыйрьләре» (1912—1913). С. Рәмиев, Дәрдмәнд һәм Г. Тукай иҗатларын күзәтүгә багышланган ул очеркларда Ибраһимовның романтик концепцияләре ярылып ята. Аларда автор, нәкъ романтикларга хас булганча, әдипнең, шагыйрьнең табигый талантын, үтә индивидуальлеген һәм интуиция, хис-тойгы колы булырга тиешлеген яклый. Әдип, шул позициядән торып, художникның үтә сизгер, сәнгатькә хас нечкә сыйфатларга ия булырга тиешлегенә басым ясаган икән, бу бит гомумән әдәбият алдына куела торган таләпләрне дә яклау дигән сүз. «Татар шагыйрьләре»ндә генә түгел, аңа кадәр үк инде Ибраһимов татар әдәбиятында сәнгатьлелек ягыннан түбән, тормышның төп-төгәл, әмма зәгыйфь копиясе, шәүләсе булган әсәрләрне тәнкыйть итеп чыккан иде. Димәк, ул татар әдәбиятының художество дәрәҗәсен күтәрү өчен Г. Тукай, Ф. Әмирхан һ. б. алып барган көрәшкә кушыла. Әмма шуның белән бергә, «Татар шагыйрьләре»ндә сүзне Рәмиевтән һәм Дәрдмәндтән башлап, аннан соң гына Тукайны тәнкыйтьләргә керешүеннән үк Ибраһимовның үтә романтик һәм субъектив карашлардан чыгып эш итүе күренеп тора.

Ибраһимовның, Рәмиев белән Дәрдмәндне беренче планга куеп та, әле 1910 елда гына үзе «хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле һәм галәбәле[2] рольне уйнаучы» дип бәяләгән Тукайны алардан артка куюы очраклы хәл булмады. Дәрдмәнд белән Рәмиев поэзиясендә, аларның лирик геройларында ул гаять көчле, кискен гәүдәләнгән субъективизмны, үзләренә генә хас, башкаларда табылмас шәхси башлангычларны күрде. Һәм, әйтергә кирәк, татар әдәбият белемендә беренче мәртәбә дияргә мөмкин, Рәмиев һәм Дәрдмәнд иҗатларындагы романтизмның кайбер үзенчәлекләрен Ибраһимов шактый төгәл итеп билгели алды. Мәсәлән, Рәмиевне ул: «Чын мәгънәсе белән — дөньяның бөтен гадәт, әдәп вә низам дип йөртә торган нәрсәләренең һәммәсеннән аша сикергән, дөньяда хөррияте шәхсияне ниһаясез югары вә мөкаддәс урынга куеп, үз хисе вә үз уена башка булган һичбер нәрсә илә хисаплашмый торган адәмнәрдән берседер»[3],— дип санады.

---

[1] Г. Ибраһимов. Татар шагыйрьләре. Оренбург, 1913 ел, 22—23 битләр.
[2] Шәүкәтле һәм галәбәле — куәтле һәм өстен.
[3] Г. Ибраһимов. Татар шагыйрьләре, 26 бит.

Ләкин Тукайга мөнәсәбәтендә инде Ибраһимов үзенең романтик тенденциозлыгыннан югары күтәрелә, бу шагыйрьгә карата объектив бәясен, анализын бирә алмады; алай гына да түгел, аның заман чынлыгы һәм халык тормышы белән аерылмаслык бәйләнгән реализмына кимсетүле бәя бирде. Халык кичергәнне, халык уйлаганны үз иҗатында чагылдыруын шагыйрьнең индивидуаль йөзе, үз шәхси дөньясы булмауга дәлил итәргә тырышып, Ибраһимов бу очракта әдәбияттагы халыкчанлык һәм тормышчанлык мәсьәләсенә бик субъектив ноктадан якын килде, «шагыйрь һәм халык» проблемасын дөрес хәл итмәде. Ә «Татар шагыйрьләре» басылып чыккан вакытларда, бигрәк тә Тукай үлгәннән соң, аның мирасын бәяләү тирәсендә көрәш кызып киткәч, «шагыйрь һәм халык» проблемасы татар әдәбиятының һәм тәнкыйтенең үзәгенә куелды. Россиядә көчәя башлаган яңа революцион хәрәкәтләр тәэсирендә бу проблема тагын да кискенләшеп китте. Тукай реализмы һәм халыкчанлыгы тирәсендә куерып киткән бәхәсләр әнә шул яңа революцион көрәш таләбе һәм аның әдәбият алдына куйган яңа бурычлары белән һичшиксез бәйләнгән иде.

1912—1913 еллар тирәсендә Ибраһимовның сәнгатькә карашларында шактый гыйбрәтле үзгәрешләр барлыкка килә. Чөнки ул яңа революцион шартларны бик якыннан аңларга омтылган һәм шул сәбәпле үз иҗатында, эстетик карашларында сизелерлек үзгәрешләр кичергән язучы гына түгел, ә актив көрәш юлына баса башлаган революцион идеолог сыйфатында да эшчәнлек күрсәтә башлаган иде инде. Ирек даулаган шәхес һәм явыз чынбарлык, сәнгать һәм халык мәсьәләләрен аңлауда да аның беренче романтик карашларыннан аермалы төсмерләр, тенденцияләр күренде. Дөрес, моңа кадәр үк инде Ибраһимов язучының тормыш һәм халык белән бәйләнеше турында фикер йөрткән иде. Моны Тукай поэзиясенә, халык иҗатына һәм Белинский истәлегенә багышланган һ. б. мәкаләләрендә очратырга мөмкин. Ул, мәсәлән, Л. Толстойның сынлы сәнгатьтә дә «фәкыйрь вә ач булган авыл крестьяннарының аяныч хәлен», «авыл крестьяннарының ярым-ялангач балаларының елашып торулары кеби аяныч маназараларны рәсем белән күрсәтергә» [1] чакыруына игътибар итә; халык иҗатын югары бәяли; [2] Белинскийның «яңа милли һәм реальный булган әдәбиятны» яклавын [3], «әдәбияттан тормышның һәр ягын мөкәммәл тугры вә тулы тасвир кыйлуын таләп итүен» хуплап чыга. Мондый фикерләрне бер ноктага җыеп карасак, алар Ибраһимовның әдәбиятта тормышчанлык һәм халыкчанлык өстенлек итәргә тиешлегенә ышанган әдип булуын раслыйлар. Әмма әдәбиятта тормышчанлыкны һәм халыкчанлыкны яклау — ул әле реализм да, романтизм да түгел, ә язучының идея позициясе генә. Реалист та, романтик та әнә шул позициядән торып, тормышка, халыкка төрле-төрле эстетик мөнәсәбәт күрсәтергә, сәнгатьчә матурлык идеалын аңларга мөмкиннәр. Демократик әдәбият принципларын үстергән язучы буларак, Ибраһимов, әлбәттә, сәнгатьтә тормышчанлыкны һәм халыкчанлыкны яклап чыга.

«Яшь йөрәкләр»дә һәм «Татар шагыйрьләре»ндә алга сөрелгән берьяклы романтик концепцияләреннән Ибраһимов тиз арада югары күтәрелә барды. Әдәбиятның тормышчанлыгын һәм халыкчанлыгын аңлауда да төгәлрәк фикерләр белән чыкты. Аның 1913 елгы бер мәкаләсендә мондый сүзләр бар: «... Халыкка якынлыгы, тик халык өчен яшәве, халык йөрәгеннән туып, аның авыр хәятына бер нур, бер җиңеллек бирүне үзенә вазифа итеп алган булучылыгы белән рус әдәбиятының бөтен дөньяда мөмтаз вә мөстәсәм [4] урын тотканлыгы мәйдандадыр. Рус — әдәбиятыннан үз кайгысына бер җиңеллек көтә... Аның һәр әдибе иң элек үзен халыкның угылы итеп хис кыла, язу дигән сүздән рус хәятының авыр яраларына шифа эзләү дигән мәгънәне аңлый» [5].

Шул рәвешчә, әдәбиятның тормышчанлыгына һәм халыкчанлыгына бөек үрнәкне рус классикасында күреп, Ибраһимов сәнгатьнең, художникның беренче нәүбәттә халыкка хезмәт итәргә, аңа якын торырга тиешлеген яклый. Һәм шундый ышанычын ул үзенең иҗат практикасында да тормышка ашыра башлый. «Карт ялчы» (1912) һәм «Көтүчеләр» (1913) кебек хикәяләрендә, аның иҗатында беренче мәртә-

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 1960 ел, 29 бит.
[2] Шунда ук, 42 бит.
[3] Шунда ук, 55 бит.
[4] Мөмтаз вә мөстәсәм — аеруча күренекле, югары.
[5] «Йолдыз» газетасы, 1913 ел, 17 март.

бә диярга мөмкин, гади кеше, хезмәт халкы образлары алгы планга куеп сурәтләнә, әдип явыз чынбарлык һәм җәберләнгән кеше арасындагы мөнәсәбәт һәм каршылыкның иҗтимагый мотивларына игътибарын көчәйтә төшә. Әлбәттә, язучы бу әсәрләрендә дә чынбарлыкка романтик мөнәсәбәтеннән баш тартмый. Бер очракта аның әдәби герое кызганыч, мескен ялчы, көтүче карт булып, ә икенче очракта кешене шундый хәлгә төшергән чынбарлыкка нәфрәт белдергән, әмма үзенең ялгыз протестыннан һәм бунтыннан югары күтәрелмәгән яшь герой рәвешендә сурәтләнә. Соңгысына мөнәсәбәттә авторның романтизмга хас риторик схема беләнрәк эш итүе дә күзгә бәрелә. Әмма ничек кенә булмасын, Ибраһимов үзенең теоретик карашларын сәнгатьчә реальләштерү, конкрет сурәтләргә әверелдерү юлында тагын бер кыю адым ясый.

Чынлык һәм гүзәллек гармониясен эзләү, аның сәнгатьчә кыяфәтен, образын күз алдына бастыру, әлбәттә, җиңел булмады. Шулай да халык белән турыдан-туры бәйләнгән идеалдан башка ул гармониянең тулы сынын һәм матурлыгын тудыру мөмкин түгеллеген төшенү котылгысыз иде. «Табигать балалары» (1914) хикәясе — Ибраһимов иҗатында чынлык һәм гүзәллек гармониясен гади халык арасында табуның Октябрьга кадәр күренгән иң югары бер үрнәге. Бу әсәрдә романтик эстетика халык темасын, халык образын чагылдыру, шул юнәлештә чынлык һәм гүзәллек эзләү ноктасыннан гаять үзенчәлекле булып гәүдәләнә.

Нидән гыйбарәт иде соң ул? Әсәр юкка гына «Табигать балалары» дип аталмаган. Бу исемдә хикәянең сәнгатьчә төп мәгънәсе чагыла. Чыннан да, әсәрдән гади кешеләрнең табигать кочагында хезмәт һәм мәхәббәт белән рухланып яшәү шигърияте бөркелеп тора. Аларның физик һәм рухи тормышында язучы чынлык һәм гүзәллек идеалын таба. Әлбәттә, монда крестьян психологиясеннән бик нечкә итеп тотып алынган реаль детальләр белән бергә, бу тормышның идиллиясен, андагы хезмәт һәм мәхәббәтне идеаллаштыру, аны һәртөрле авырлыклардан, җәфа-газаплардан, каршылык-фаҗигаләрдән арындырып тасвирлау да күзгә нык ташлана. «Карт ялчы» белән чагыштырганда, «Табигать балалары»на идиллик романтика пафосы характерлырак. Шуңа да карамастан, бу хикәя гади кешене, аның хезмәт поэзиясен алгы планга куеп сурәтләве белән һәм шул гади кешенең сөйләмен гаять җанлы итеп бирүе белән аерылып торган оригиналь әсәрләрдән булды. Анда татар прозасындагы романтик стильнең крестьян теле белән хикәяләнгән яңа бер төсмере тәмам ачылып китте. Ибраһимовның шул рухтагы хикәяләү манерасы — стилизациясе егерменче еллар татар прозасында шактый киң кулланыш тапты.

### 3

Әйткәнебезчә, Ибраһимовның эстетик карашларында «художник, сәнгать һәм халык» проблемасы үзәк мәсьәләләрнең берсенә әйләнә бара. Аның иҗатын үтәдән-үтә сугарган чынлык һәм гүзәллек идеалы да шул проблема яктылыгында карала башлый. Әдипнең эстетик карашларындагы үзгәрешләрнең бик әһәмиятле билгеләрен, мәсәлән, «Каһарман шагыйрь» (февраль, 1914) һәм «Талант трагедиясе» (апрель, 1914) мәкаләләрендә табарга мөмкин. Беренчесе бөек украин шагыйре Т. Шевченко истәлегенә багышланган һәм анда «шагыйрь һәм халык» темасы гаять конкрет ачылган.

«Ул — хөррият каһарманы. Болардан бигрәк ул — мәхкүм [1] бер халыкның киң, якты бер дөньяга чыгу юлындагы тарихи идеалының тәмсале мөҗәссәме [2]; ул — малорус халкының бөтен иҗтимагый әмәлләренең [3] символы,— ди Ибраһимов...— Ул, безнең кебек мәхкүм бер халык эченнән чыгып, үзен һәм сүзен шул халык кайгысын ачык вә ачы рәвештә ифадә итү [4], шулай итеп, яңа җиңеллеккә юл ачу хакында корбан итте» [5].

Моның белән Ибраһимов украин шагыйре Т. Шевченко үрнәгендә «көрәшче шагыйрь нидән гыйбарәт?» дигән сорауга җавап бирергә теләде.

[1] Мәхкүм — хөкем ителгән. [2] Тәмсале мөҗәссәме — гәүдәләнү мисалы.
[3] Әмәлләренең — теләк-өметләренең. [4] Ифадә итү — аңлату.
[5] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре, 68—69 битләр.

«Талант трагедиясе» Тукай истәлегенә багышланган иде. Тулаем Тукайга мөнәсәбәтендә Ибраһимов «Татар шагыйрьләре»ннән килә торган субъектив тенденциозлыгыннан югары күтәрелмәсә дә, художник талантының һәм язмышының зур чынбарлык, иҗтимагый тормыш белән бәйләнгән булуына басым ясап сөйләве авторның моңа кадәр табигый-тума талантны, интуицияне, хис-тойгы колы булуны яклау кебек романтик караштан күпмедер читләшә барганлыгын да күрсәтә иде. Талант «күктән ямый», ул — «җир җимеше, тормыш җимеше», ди әдип. Шагыйрьләрнең, талантларның «тишеп чыгуы, үсүе, зураюы, асыл гөл шәкеленә кереп, матур чәчәкләр бирә алуы өчен дә монасиб[1] хәят, монасиб мохит лязем», «реальный әсәрләр генә түгел, иң мөхали[2] хыяллар да башка фәкать тышкы дөнья тәэсире белән генә киләләр» кебек фикерләрдә талантның, сәнгатьнең иҗтимагый тормыш, тарихи чынбарлык таләбе, ихтыяҗы белән бәйләнеше раслана. Җыеп кына әйткәндә, Ибраһимовның искә алынган бу ике мәкаләсендәге төп акцент художникның, язучының заманга һәм халыкка якын торырга, азатлык өчен көрәшче булырга тиешлегенә ясала.

Беренче империалистик сугыш еллары Ибраһимовның шундый рухта борынлый башлаган яңа карашларын һич тә тоткарлый, какшата алмады, ә киресенчә, аның шул юнәлештәге ышаныч һәм эзләнүләрен тагын да тизләтеп, кискенләштереп һәм тирәнәйтеп җибәрде. Бөтендөнья сугышы дәһшәтләрен, шул сәбәпле кешелек цивилизациясе, культурасы һәм сәнгать өстенә килгән куркынычны күз алдында тотып язылган «Сәнаигы нәфисә альбомы»на кереш сүзендә Ибраһимов «сәнгать һәм халык» мәсьәләсенә «сәнгать һәм кешелек язмышы» ноктасыннан караш ташлады. Моңа кадәр әйтелгән фикерләрен тагын да ачыклый төшеп, ул болай ди: «Сәнгатькярнең — теләсә шагыйрь вә әдип булсын, теләсә рәссам ва композитор булсын — халыкка мөнәсәбәтенең, халыкның аны үз итүенең, йөрәгенә якын алуының сере — иштә шул ике йөрәк арасындагы уртак тәэсирнең шул әсәрдә, шул рәсемдә, шул көйдә табигый вә ачык рәвештә тәҗәссем итүендә, сүз беләнме, рәсем беләнме шуның гәүдәләнә алуында, тагы ачыграк әйткәндә, сәнгатькярнең йөрәгеннән халык йөрәгенә тугрыдан-тугры юл салынуындадыр»[3].

Күренеп тора, язучының бу карашларында «сәнгать, художник һәм халык» проблемасын демократик рухта аңлау шактый ачык һәм төз итеп формалаштырылган иде. «... Мәрхүмнең дәфтәреннән» дигән әсәрендә шундый карашларның җанлы әдәби гәүдәләнеше бирелде. Аның герое сугыш чынбарлыгы, гади кеше язмышы һәм шул шартларда художник, язучы позициясе кебек катлаулы мәсьәләләргә бәйле настроениеләрне кичерә, хәтта шул мәсьәләләрне хәл итү газабына дучар була. «... Мәрхүмнең дәфтәреннән» героен язучының үз образыннан, аның уй-кичерешләреннән читтә калдырып бәяләү кыен. Бу әсәрне автор монологы дип атарга да мөмкин булыр иде. Үтелгән иҗат юлына караш, бүгенге чынбарлыкка мөнәсәбәт һәм шунда язучының, әдәбиятның ролен билгеләү — болар һәммәсе Ибраһимовның шул вакытларда күтәргән фикерләренең дәвамы иде.

«Мин хәят эзләдем, хәятта мин мәгънә эзләдем, хәятның барлык рәхәтләрен фида кыйлдырырлык мәртәбәдә изге була алырлык бер идеал эзләдем.

Моны кем эзләмәгәндер, ләкин табучы булганмы?» — кебек сораудан соң герой чынбарлык контрастларын күз алдыннан кичерә һәм куелган сорауга шунда ук җавап та таба: хикәя героена сукбай әйткән сүзләр сәнгать иң гади кешеләргә якын булырга, аларга хезмәт итәргә тиеш дигән хакыйкатьне раслыйлар. Шулай да Октябрьгә кадәр Ибраһимов, бу хакыйкатьне раслаганда, сәнгатькә, аның җәмгыятьтәге роленә романтикларча идеаллаштырып каравыннан тәмам арына алмады әле. Аның «Сәнаигы нәфисә альбомы»на язган мәкаләсендә сәнгать белән тормыш арасындагы бәйләнешкә караган күпме генә тарихи-реалистик фикерләр булмасын, мәкаләнең үзәгеннән үткән пафос идеалистик концепцияләрдән дә азат булмады. Болар арасында сәнгатьне тышкы максатлардан башка, тик эчке теләкләр буенча туа торган, ягъни интуитив бер күренеш дип санау, милләт язмышын сәнгатьнең нииндидер серле көче белән хәл итү мөмкинлегенә ышану һәм, ниһаять, сәнгатьне яңа заманның дине дип идеаллаштыру рәвешендәге фикерләргә басым ясалды, һәм болар, әлбәттә, романтик идеализм ягыннан килә торган фикерләр иде.

---

[1] Монасиб — лаек, кирәкле. [2] Мөхали — булмый торган.
[3] Сәнаигы нәфисә альбомы. Казан, 1915 ел, 13—14 битләр.

Сөйләгәннәрне бер ноктагарак җыеп караганда, Ибраһимовның әдәби иҗаты һәм эстетик карашлары үсеше кайдан кая табан барды? — дигән сорау куяу табигый булачак. Һичшиксез, ул татар әдәбиятының демократик, халыкчан принципларын яклап, аның реализмга тирән теләктәшлек белән сугарылган прогрессив-романтик юнәлешен үстерде. Әдәбиятның, сәнгатьнең тормышчан һәм халыкчан булырга тиешлеген аңлавы көчәйгән саен, язучы үзенең иҗаты белән дә реализмга якыная барды. Ләкин бу якынаюны ул романтизм традицияләреннән баш тарту дип түгел, ә романтизм белән реализм эстетикасының нык керешүе, синтезлаша баруы дип аңлады. Бу юнәлешне без татар әдәбиятында романтик реализмның барлыкка килүе дип бәяләгән идек.

Романтик реализм безнең әдәбиятта нигездә унынчы еллардан башлап үзен ачыграк сиздерде. Без Тукай, Гафури һәм Ибраһимов иҗатларында яңа революцион күтәрелеш тәэсирендә барлыкка килгән тенденцияләрне күздә тотабыз [1]. Ибраһимов иҗатында гына түгел, гомумән татар прозасында беренче тарихи-социаль роман саналган «Безнең көннәр» шундый реализмның күренекле бер үрнәге булды. Мәгълүм ки, бу әсәрнең беренче варианты 1914 елда ук язылса да, цензура тоткарлау сәбәпле, басылып чыкмый кала. Ул тик 1920 елда гына дөнья күрә. 1914 елда Х. Кәримгә хатында Ибраһимов бу романын «Хәят дулкыннары» атлы трилогиясенең беренче кисәге дип атый. «Яшь йөрәкләр»дән соң байтак гыйбрәтләр булды, хәзерге романым «Безнең көннәр»дә байтак яңа кешеләр чыгар кебек» [2],— ди ул. Чыннан да, язучы шушы ике романы арасындагы бик кыска бервакыт эчендә киеренке идея-эстетик эзләнүләр аша үтте. Әдәбияттагы чынлык һәм гүзәллек идеалының тарихи барыш һәм халык белән бәйләнешен аңлау юлында бик гыйбрәтле сынаулар кичерде. Социалистик революция процессында инде аның революцион-гражданлык активлыгы һәм эшчәнлеге киң колач алуы идея-эстетик эзләнү һәм сынауларын һич булмаганча тизләтте, ачыклады. Шуңа күрә дә, «Безнең көннәр» романын бастырганда, авторның 1914 еллардагы позициясен яңадан карамыйча калуы мөмкин түгел иде. Без бу романны язучының 1914 — 1920 еллар арасындагы иҗат үсешенең, идея-эстетик эволюциясенең нәтиҗәсе, көзгесе дип саныйбыз. Ул әсәр Ибраһимов иҗатының ике чорын бер-берсе белән бәйләп тора. Һәм анда шул бәйләнешнең традицион ягы да, новаторлык сыйфатлары да шактый тулы чагыла.

«Безнең көннәр»нең яңалыгы — 1905 — 1907 елларда Россияне тетрәткән халык хәрәкәтләренең татар җәмгыятенә, бигрәк тә милли интеллигенциянең төрле катлауларына ясаган тәэсирен күрсәтүдән гыйбарәт. Татар прозасында беренче мәртәбә киң колач белән милли интеллигенция типларының галереясе тудырыла. Революция барышында алар арасыннан гаять чуар, каршылыклы һәм хәтта бер-берсенә капма-каршы идеяләрне яклаучылар чыга. Революцион чынбарлыкка һәм иҗтимагый-сыйнфый җирлекләренә нисбәтән, алар төрле юнәлештә китеп, төрле үзгәрешләр кичерәләр. Халыкның самодержавиегә каршы көрәше кызган көннәрдә революционер булып күренгән яки шул көрәшкә теләктәшлек иткән кайберәүләр, реакция һөҗүм башлагач, үзләренең элекке тыныч почмакларына кайтып посалар, ә икенчеләре исә, авыр шартлардан өрекмичә, яңа көрәшләргә хәзерләнергә, киләчәккә ышанып яшәргә һәм шуның өчен эшләргә ант итәләр. Соңгылары арасында большевик Зариф Булатов та бар. Димәк, романның төп сюжет линиясе тарихи чынбарлык белән нык бәйле реалистик юнәлештә алынган һәм шушы моментта Ибраһимов иҗатында беренче тапкыр социаль детерминизмның алгы планга чыгуы күренә дә. (Аның асыл мәгънәсе — әдәби әсәрдәге вакыйгаларны һәм геройларның үзара мөнәсәбәтен, кыланышларын иҗтимагый чынбарлык закончалыклары яктылыгында тасвирлау дигән сүз.) Шул момент реалистик әдәбиятның нигезендә ята, һәм ул безнең егерменче йөз башындагы романтизмга да йогынты ясый. Романтизм белән реализмның бер-берсенә якынаюында, синтезында социаль детерминизм, бәлки, иң әһәмиятле эстетик күренешләрнең берсе итеп каралырга тиештер.

Әмма «Безнең көннәр»нең 1920 елгы вариантында романтизм да үзенең позициясен нык саклый. Геройларның интим хиссларына, мәхәббәт мөнәсәбәтләренә, характерларның һәм кичерешләрнең субъектив-эмоциональ кискенлегенә күбрәк игътибар

---

[1] Бу хакта карагыз: Г. Халит. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Казан, 1975 ел, 190—192, 202—203, 250—252 битләр.
[2] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре, 80 бит.

биру — бусы Ибраһимов иҗатындагы романтик традицияләрнең дәвам итүе. Халык хәрәкәтләреннән бигрәк, шәкертләр һәм интеллигенция дөньясындагы вакыйга-хәлләрнең алгы планга куелуы да романтик пафосның бер чыганагы булып тора дияргә мөмкин. Эшчеләр хәрәкәтеннән ерак торган Давыт Урманов кебек революцион демократия вәкилләренең идеалларына авторның теләктәшлеге аның элекке романтик настроениеләреннән шулай ук аерылгысыз. Тулаем алганда, «Безнең көннәр» романы Ибраһимов иҗатында реализм һәм романтизм синтезының үсә баруын раслады.

## 4

Социалистик революция булу белән, Ибраһимовның идея-эстетик карашларында, әйткәнебезчә, тирән үзгәреш, кискен борылыш барлыкка килә. Яңа чынбарлыкның гүзәллеген, яңа идеалларның бөеклеген гәүдәләндергән беренче әсәр — «Яңа кешеләр» (1920) драмасы языла. Тарихны үзгәртүче революцион-сыйнфый көрәш пафосы һәм ул көрәшне әйдәүче халык вәкилләре сәхнәгә чыга. Үзләренең шартлы-романтик атрибутларын әле ташламаган гади кешеләрнең тарихи-революцион ташкын эчендә заман геройларына әверелүләре әсәрнең үзәген били. Туры, саф мәгънәсендә драма булудан бигрәк, «Яңа кешеләр» чорның революцион-драматик хәлләрен эпиклык белән җанландырган әсәр иде. Анда революция дошманнары белән көрәштә халык кичергән зур тарихи вакыйгалар төп драматик ситуацияне тәшкил итә. Шулар эчендә геройларның сыйнфый-иҗтимагый, шәхси һәм семья мөнәсәбәтләре ачыла. Элек тормыш төбенә ташланган гади кеше тарих сәхнәсенә чыга: Батырхан кебекләр халыкны җитәкләүче булып күтәреләләр. «Яңа кешеләр»дә кырыс тормыш чынлыгы һәм шунда чыныга, җиңә барган матур теләкләр гармониясен әдип, барыннан да элек, әнә шул Батырхан аша күз алдына бастыра. Бу герой революция романтикасының кайнар пафосы һәм югары идеаллары белән сугарылган. Дөрес, ул традицион-романтик геройларга хас уникальлеге, сирәк очрый торган үткәне һәм тирәягындагы геройлардан күп калку итеп сурәтләнүе белән аерылып тора. Әмма ул инде чынбарлыкка каршы герой түгел, ә тарихның үзеннән тамырланып, үсеп чыккан революцион-романтик герой иде. Бу геройны зур тормыш җирлегеннән аерып алу һич мөмкин түгел. Аңарда чынлык белән гүзәллек гармониясе үзенең беренче реаль гәүдәләнешен тапты.

1921 елда «Кызыл чәчәкләр хикәясе» языла. Мондагы Солтан образы — шулай ук Батырханнар токымыннан. Ул да, тормыш төбеннән күтәрелеп, тарихның киң революцион юлына чыга һәм үзен халык бәхете өчен көрәшкә багышлый. Солтан да үз тирәсендәге башка геройлардан калку итеп һәм гармоник характерга ия итеп күрсәтелә. Ул «Табигать балалары»ндагы Хафиз язмышын дәвам иттергән шикелле. Хафиз әле крестьян көнкүрешендә һәм үзенең интим-шәхси дөньясында гына гәүдәләнсә, Солтан инде зур иҗтимагый вакыйгаларда чыныгып, үзен халык бәхете өчен җаваплы санаган көрәшче, оптимист герой югарылыгына күтәрелә. Аның алдында революциянең тыныч шартларындагы чынлык һәм гүзәллек гармониясе балкып тора.

«Кызыл чәчәкләр»дә дә элекке геройлар яңадан туалар, әмма үзләренең шартлы-романтик билгеләрен бөтенләй ташлап та бетермиләр әле. Шулай да яңа романтик билгеләр искеләреннән күп көчле һәм бай инде: алар революцион героизм, батырлык ореолына куелганнар, аларны шул идеал яктырта һәм рухландыра. «Яңа кешеләр»дәге шикелле үк, бу әсәрендә дә язучы чынлык һәм гүзәллек гармониясенең асыл сыйфаты итеп әнә шул революцион героизм романтикасын саный. «Кызыл чәчәкләр хикәясе»ндәге социаль детерминизм шулай ук революцион-сыйнфый көрәш законнарына нигезләнгән. Андагы геройлар революциягә мөнәсәбәттә үзләренең иҗтимагый һәм шәхси кыйблаларын табалар. Әмма шуның белән бергә, геройлар язмышын билгеләүдә Ибраһимов вульгар социологизм йогынтысыннан да бөтенләй үк әле азат түгел иде. Геройлар арасындагы мөнәсәбәт һәм аларның язмышлары күбесенчә сыйнфый чыгышларына карап билгеләнә. Мондый нәрсә, әлбәттә, тормыш законнарын һәм кешеләр язмышын тар итеп бер яссылыкта аңлауга китерә һәм совет әдәбиятындагы реализмга хас социаль детерминизмны ялангачландыра иде. Ләкин бу мәсьәләнең икенче ягын да истән чыгармаска кирәк. Әдипнең геройлар

язмышын капма-каршы юнәлешләрдә хәл итүендә романтизм поэтикасының да роле бар иде, әлбәттә. Романтик поэтикада аеруча яратып кулланылган үтә кискен һәм гадәттән тыш антитеза һәм трагизм күренешләре белән мавыгу Ибраһимовны, мәсәлән, «Адәмнәр» (1923) хикәясендә ачлык елларының фаҗигале һәм вәхши хәлләрен чамадан тыш куертып тасвирлаган натурализмга да китерде.

Һичшиксез, Ибраһимовның бигрәк тә егерменче еллар башындагы әдәби эшчәнлегендә интенсив, киеренке, вакыты-вакыты белән хәтта каршылыклы эстетик эзләнүләр дә урын ала. Аның эзләнүләрендәге төп момент башлыча иске һәм яңа геройлар арасындагы бәйләнешне, көчәмлелекне, традиция һәм новаторлыкны ничек аңлауга һәм нинди стильдә күрсәтүгә кайтып кала. Иске һәм яңа темаларга, иске һәм яңа геройларга сәнгатьчә мөнәсәбәтне, эстетик идеал юнәлешен билгеләү гел туры сызыктан гына бармады, әлбәттә. Аның борылмалары, сикереш һәм чигенешләре, отыш һәм оттырышлары теге яки бу рәвештә аралашып килде. «Безнең көннәр»нең беренче редакциясе белән, әйтик, «Казакъ кызы» арасындагы 3—4 ел эчендә генә дә Ибраһимов кызыклы һәм гыйбрәтле эзләнүләр, тәҗрибәләр белән тулы юл үтте. Мәсәлән, «Кызыл чәчәкләр хикәясе»ннән соң ул «Алмачуар»да үзенең темасы, геройлары һәм стиле белән «Табигать балалары»ндагы шикелле эмоциональ һәм үтә күренүчән романтикага бай шигъри стилен кабатлады.

Ниһаять, 1923 елда «Казакъ кызы» басылды. Шул ук елда дөньяга чыккан «Адәмнәр» белән чагыштырганда, бу ике әсәр арасында искиткеч аерма барлыгы турында сөйләп торасы да юк. «Казакъ кызы» — элекке татар прозасында тиңе булмаган сәнгатьчә матурлык югарылыгында иҗат ителгән шедевр иде. Анда үткән заман темасын һәм геройларын сурәтләүче традицион-классик стиль яңа иҗтимагый пафос алды. Бу әсәр Ибраһимовның алдынгы совет язучысына хас тарихи-иҗтимагый сизгерлеге гаять тирән идея-эстетик катламнарга үтеп керә алырлык сәләткә, новаторлыкка ия булуы турында сөйли. Әсәрдә иске казакъ далаларындагы кабиләчелек мөнәсәбәтләре белән пәрдәләнгән иҗтимагый-сыйнфый каршылыклар панорамасы тудырыла, шуның фонында иске һәм яңа кешеләрнең эчке дөньясы, казакъ халкының гореф-гадәтләре һәм мәхәббәт романтикасының драмасы киң колач белән, әмма искиткеч җыйнак, лаконик итеп сурәтләнә. Арсланбай, Карлыгач-Сылу һәм Җолкынбайлар — патриархаль далага яңа рух кертәчәк һәм кешегә ирек яулап алачак яшь буынның беренче карлыгачлары. Үткәнгә яңача караш җирлегендә тагын да көчәйгән реализм һәм традицион мәхәббәт романтикасы «Казакъ кызы»нда дала фольклоры, аерата дастан кебек халык эпосы колориты белән сугарылды һәм нәтиҗәдә оригиналь стиль синтезы барлыкка килде. Әйтергә мөмкин ки, бу роман Ибраһимовның эпик-лирик стиле үсешен һәм аның традицион сыйфатлары тулысынча өлгереп җитүен күрсәткән югары үрнәкләреннән берсе иде.

## 5

Революция башында ук Ибраһимов үзен электә бик борчыган күп кенә әһәмиятле сорауларга ачык җавап тапты. Болар арасында, әлбәттә, культура, сәнгать, әдәбият мәсьәләләре зур урын тота. Шулардан иң беренчесе — кешелек җәмгыятендәге әнә шундый рухи-идеологик күренешләрнең барлыкка килү сәбәбе, аларны тудырган көч, ихтыяҗ нидән гыйбарәт икәнлеген яңача аңлау иде. Һәм язучы нык материалистик позициягә басып фикер йөртә башлады.

Дөрес, егерменче еллар дәвамында вульгар социологизм алга сөргән догматик схемалардан Ибраһимов читтә кала алмады. Идеологик өскормаларны экономик базисның турыдан-туры һәм берьяклы чагылышы итеп күз алдына китерү аның тарихи-публицистик әсәрләрендә дә урын алды. Әмма сәнгатькә һәм әдәбиятка мөнәсәбәттә ул, художник буларак, вульгар социологизм рецептларыннан югары торды, аның ясалма доктриналарын кабул итмәде. Ибраһимовның, мәсәлән, совет әдәбиятына хас яңа иҗат методын һәм стильләрне аңлау юнәлешендәге беренче фикерләре ук гаять кызыклы һәм гыйбрәтле иде. Аларда А. М. Горький һәм А. В. Луначарский кебек бөек әдип һәм күренекле теоретик-марксист яклаган эстетик концепцияләргә аваздашлык шактый көчле сизелә.

Социалистик реализмның нигезен салган художник буларак, Горький яшь совет

әдәбиятының иҗат методында һәм стильләрендә реализм белән бергә яңа революцион романтизм да урын алырга тиешлеген яклады. Яңа сәнгатьтә гегемонлык ролена дәгъва белдергән пролеткультчыларның җирдән аерылган космик романтикасын кире какты. Луначарский да шул ук рухтагы карашлар белән чыкты. Мәсәлән, аның 1921 ел азагында Пролеткультның 2 нче Бөтенроссия съездында сөйләгән сүзләре аеруча игътибарга лаек. Безгә романтика[1] белән реализмның ниндидер эретмәсе, кушылмасы кирәк. Безгә гаять тирән дөреслек һәм тойгының гаять бөек куәте кирәк, ди ул. Яңа сәнгать, массаларга исәп тотканлыктан, монументальлеккә омтылачак. Шул ук вакытта мондый сәнгать нигезендә һәркемгә аңлаешлы гадилек һәм ачыклык ятарга тиеш. Ә моңа тик реализм аша гына ирешеп була. Пролетариат кулындагы реализм монументаль дә, эмоциональ дә булачак, чөнки пролетариат — тормышны яңабаштан кору дәрте, идеалы белән яшәүче сыйныф. Ниһаять, пролетариат сәнгатендә реализмның монументаль һәм эмоциональ идеалы өстенлек итәргә тиеш[2].

Күрәсез, егерменче еллар башында ук инде совет әдәбиятына лаек иҗат методын иске реализмнан яки романтизмнан принципиаль аермасы булган, ягъни революцион чынбарлык һәм революцион идеаллар белән органик бәйләнгән яңа метод итеп аңларга кирәклек хакында сүз барган. Шуңа күрә реализм белән романтизм мөнәсәбәтен һәм синтезын ничек аңлау мәсьәләсе дә көн тәртибенә куелырга тиеш иде. Аның тирәсендә төрле фикерләр кузгала һәм бәхәсләр кыза башлый. Бу очракларда да Ибраһимов, беренчеләрдән дип әйтергә мөмкин, үзенең фикерләрен әйтеп чыга. Яшь татар совет әдәбиятының революцион чынбарлык белән бәйләнешендә ул, барыннан да элек, реализмны күрә һәм шуның белән бергә үк анда романтизм барлыгына да игътибар итә. Аның **«Реаль туфрак, романтизм хыялы»**[3] дигән формуласының да мәгънәсен яңа чынбарлыкны, революция көрәшчеләрен калку итеп, югары пафос белән гәүдәләндерү дип аңларга кирәк.

Егерменче еллар башындагы җанлы әдәби хәрәкәттә әле төрле әдәби юнәлеш һәм агымнар үзләренә урын даулый һәм аларның беришесе, реализмга чит позициядә торып, шактый зур активлык күрсәтә иде. Менә шундый шартларда Ибраһимов реализм — совет әдәбиятының төп юнәлеше, әйдәүче методы, ә романтизм — аның аерылмас юлдашы дип чыга. Аның бу карашы, беренчедән, яңа иҗтимагый шартларда сәнгатьнең халык һәм чынбарлык белән бәйләнешен тагын да тирәнрәк итеп аңлавыннан, ә икенчедән, революциягә кадәрге әдәби традицияләрнең нигездә реализм җирлегендә үсүен төшенүеннән килә иде.

Яңа әдәбиятның төп идея-эстетик юнәлешен билгеләү белән бергә, Ибраһимов әдәби мираска мөнәсәбәт һәм традиция мәсьәләләренә карата да, беренче буларак, күп кенә әһәмиятле фикерләр әйтергә өлгерде. Аның реализм һәм романтизм турындагы карашларын мираска, традициягә мөнәсәбәт ноктасыннан тагын да тулыландыру өчен, без бу очракта Ш. Бабич иҗатына һәм М. Фәйзинең «Галиябану» драмасына багышланган мәкаләләрен генә искә алуны кирәк саныйбыз (1922 елда язылганнар). Бу язучыларның икесе дә татар әдәбиятында романтизм вәкилләре буларак урын алдылар. Бабич турында сөйләгәндә, аның иҗат методын конкрет атамаса да, Ибраһимов бу шагыйрьнең иҗаты нинди юнәлештә булуын искәртерлек тәгъбирләр куллана: «Ул йөрәк дулкыннарын тасвирда Новалис, Фозули, Байроннарны хәтергә китерерлек дәрәҗәләргә менеп, сөю, сөелү, табигать, шәхси хәсрәт тасвирларында әдәбиятыбызда тиңе булмаган җәүһәрләр биргән шикелле, иҗтимагый фаҗигаләрне, хезмәт кайгыларын тасвирда да Некрасов, Верхарн, Демьян Бедныйлар белән янәшә куярлык ачы каһәрләр, агулы көлкеләр чәчеп ташлыйдыр».

Бабичны, бер яктан, атаклы романтиклар, ә икенче яктан, реалистлар белән тиңләштергән бу кыска гына өзектән шул аңлашыла: Бабич нигездә романтик булган, ләкин реализмнан да читтә тормаган икән.

Инде «Галиябану»га килгәндә, Ибраһимов аны туры һәм тулы мәгънәсендә «саф реализм» үрнәге дип бәяли. «Беренче мәртәбә диярлек, — ди ул, — саф булганча,

---

[1] А. В. Луначарский чыгышында романтика һәм идеализм атамалары романтизм мәгънәсендә дә кулланыла.— Г. Х.
[2] Карагыз: «Вопросы литературы» журналы. 1976 ел, 10 сан, 209 бит.
[3] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 146 бит.

үзләренең уен-көлкеләре, җырлары, музыкалары, гыйшыклары, интригалары, бәетләре, көрәшләре белән крестьян егетләре, крестьян кызлары бу әсәр аркылы безнең театр сәхнәсенә килеп керәләр»[1]. Әнә шундый моментларны истә тотып, Ибраһимов «Галиябану»да «саф реализм нигезендә сыйнфый каршылыкларны табигый әдәби рәвештә ачып бирүе кебек хасиятләрне»[2] күрә. Хәзерге әдәбият фәне ирешкән теоретик югарылыктан караганда, мондый характеристикада берьяклы караш ярылып ята дияргә мөмкин булыр иде. Чыннан да, Ибраһимов «Галиябану»ның традицион романтизм моделе белән эшләнгән мелодрама булуына бөтенләй игътибар итмәгән. Ләкин китерелгән өзекләр әдипнең реализм концепциясен ничек аңлавына тагын бер характерлы мисал була ала. Монда ул, барыннан да элек, «Галиябану»ның тормышчан һәм халыкчан эчтәлегенә игътибар итеп, аңа социаль детерминизмның чагылышы булган сыйнфый интригалар килеп керүен һәм гадәттә традицион романтизмга хас риторикадан, купшылыктан шактый азат булуын әһәмиятле саный. Әнә шул моментларны истә тотып, бу драмада «саф реализм» өстенлек итүен раслый. Һичшиксез, «Галиябану» драмасының реалистик яңгырашы ни өчен көчле булуын Ибраһимов дөрес билгеләгән.

## 6

Мәгълүм ки, әдәбият тарихында күренгән иҗат методлары кинәттән генә мәйданга чыгып, бер-берсен алмаштырып яки инкяр итеп кенә үзләренә урын яуламаганнар. Чынлыкта исә алар бер-берсенең тәҗрибәсен уртаклашып, кабул итеп һәм кире кагып, билгеле тарихи шартлар туу нәтиҗәсендә генә өстенлек алганнар. Димәк, нинди генә даһи художник та, тарихи-иҗтимагый сәбәпләр таләбеннән һәм ул азыкланган сәнгатьнең билгеле күләмдә җитлегүеннән башка, яңа эстетик ихтыяҗларга җавап бирә торган новаторлыкка ирешә алмый. Шул рәвешчә, художникның сәнгатьтәге яңалыкны тудыруы өчен, бер яктан, тарихи шартларның өлгерүе һәм, икенчедән, аның үткәндәге һәм үз чорындагы югары сәнгать казанышларын, ягъни традицияләрнең алдынгы өлешен үзләштерүе кирәк. Бу әйтелгәннәр хәзерге әдәбият белемендә бик гади хакыйкатьләрдән санала. Ләкин үткәнгә әйләнеп карасак, мондый хакыйкатьне кабул итү-итмәү тирәсендә шактый кискен көрәш барганын күрербез. Мәсәлән, социалистик революция алдыннан һәм беркадәр вакыт аннан соң да әле футуристлар, имажинистлар, пролеткультчылар һ. б. нәкъ шул хакыйкатьне аңларга теләмәделәр. Бу шаукым татар әдәбиятына да кагылып үтте. Егерменче елларда бик активлык күрсәткән вульгар социологизм тарафдарлары да ул авырудан котыла алмадылар, хәтта котылу максатын куймадылар да. Әнә шундый шартларда Ибраһимов «Пролетариат әдәбияты турында» (1924) дигән хезмәтен чыгарды, һәм ул анда әдәби мираска мөнәсәбәт һәм яңа әдәбиятның үзенчәлеге кебек гаять актуаль мәсьәләләрне яктыртты.

Үткәндәге милли культура һәм әдәбият мирасын бәяләүдә билгеле социологик схема белән эш итеп, аны өстен сыйныфларга хезмәт иткән идеологик корал дип кенә караса да, Ибраһимов яңа сәнгать төзүдә мирасның роле зур булуын бик ачык аңлый һәм аны ныклап өйрәнү кирәклеген күтәрә. Аны аерата кызыксындырган актуаль мәсьәлә, әлбәттә, яңа культураның, совет әдәбиятының төп сыйфатларын ачып бирү иде. «Әгәр барын җыеп әйтсәк, — диде ул, — пролетариат әдәбиятына төп нигез булган, аны башка әдәбиятлардан аерган моментларның башлычалары: динамика, көрәш, сыйныфчылык, коллективизм, хезмәт һәм интернационализм кебек берничә мәгълүм нәрсәгә кайтып калыдыр ки, боларның һәрбере әдәбият өчен генә ясалган хасиятләр түгел, бәлки пролетариатның сәясәтендә, хәрәкәтендә, фәлсәфәсендә, бөтен идеологиясендә уртак булган нигез ташларыдыр»[3].

Шулай итеп, Ибраһимов совет әдәбиятының нигезендә ятарга тиешле идея принципларын бик дөрес билгели һәм ул принципларны сәнгать дөньясында гәүдәләндерү һичбер вакыт нормага салынмаячагын, ягъни «алдан калыплар ясап биреп, шулар буенча гына эшләтү бездә булмаячагын», ә формалар заманына, максатына карап, алмашынып торачакларын[4] басым ясап әйтә.

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 141—142 битләр.
[2] Шунда ук, 142 бит.
[3] Шунда ук, 177 бит.
[4] Шунда ук, 179 бит.

Сәнгатьчә һәм эстетик кыюлыгы исә аның әдәби иҗат практикасында гаять җанлы һәм тулы булып гәүдәләнеп калды. «Казакъ кызы»ннан соң бу нәрсә аның «Тирән тамырлар» (1926—1928) повестенда[1] тагын бер тапкыр ачылып китте. Бу әсәре белән язучы совет әдәбиятының идея-эстетик принциплары ничек булырга, ничек реальләштерелергә тиешлегенә җавап бирде. Зур тарихи чынлык һәм көрәш каршылыклары эчендә чыныга торган герой проблемасын, тагын да конкретрак алсак, көрәшче коммунист образларын Ибраһимов тулысынча реалистик җирлектә хәл итте. Фәхри белән Садыйк — шуның үрнәкләре. Алар — шул ук Батырхан һәм Солтаннар токымыннан килә торган һәм тарих тудырган идеаль геройлар. Язучы аларның характерында иҗтимагый һәм шәхси гармонияләрен күрсәтүгә ирешә, нәкъ шушы моментта аның яңа реализмга керәкле романтик калкыту, гомумиләштерү поэтикасы ярдәмгә килә. Әмма үзләренең гармонияләрен ул геройлар тормыш көндәлеге аша, аның ыгы-зыгысы эчендә һәм интим-семья мөнәсәбәтләрендә гәүдәләндерәләр. Гаять кискен һәм хәтта маҗаралы итеп корылган сюжет калейдоскобына күп төрле геройлар эләгә. Аларның үзара мөнәсәбәт һәм кыланышлары чынбарлыкның каршылыкка, конфликтка бай платформаларына чыгарыла. Ибраһимов осталыгының беренче сере шунда: ул тормышчан чынлыкны һәм сәнгатьчә гүзәллекне бер бөтен итүнең, гармониягә кертүнең төп чыганакларын, төп нокталарын таба белә. «Тирән тамырлар»ның сюжет, композиция һәм гомумән архитектоникасында алдан көтелмәгән һәм гадәттәгедән бик аермалы элементлар күпме генә булмасын, әмма алар я алай, я болай тарихи чынлык логикасына килеп керәләр һәм шунда, бер фокуста, әсәрдә күрсәтелгән чорның тере геройлар галереясен тудыралар. Әнә шундый зур чынлык иллюзиясенә ирешүдә Ибраһимовның художниклык осталыгы күренә дә иде. Тормыш закончалыкларының логикасын бозмаган сәнгатьчә иллюзия «Тирән тамырлар»ның реалистик эчтәлеген көчәйтә һәм үткенләштерә. Ниһаять, әдип катлаулы яңа чынбарлыкны тасвирлауның оригиналь әдәби формасын таба. Нәкъ үзе әйткән теоретик положениене, ягъни совет әдәбиятында һәр әсәр тормыш материалының, эчтәлекнең үзенчәлегенә туры килә торган формаларны иркен кулланып язылырга тиеш, дигән фикерне исбат итә. Кыскача гына әйткәндә, «Тирән тамырлар» — яңа чынбарлыкны һәм аның кешеләрен зур тарихилык принцибы белән яктырткан әсәр булды. Бу принцип исә — социалистик реализм әдәбиятының нигез ташларыннан берсе.

Иҗатында социалистик реализм принциплары ныгый һәм үсә барган саен, Ибраһимов үткәндәге мирасының традицияләрен яңача аңлап һәм бәяләп, аларны дәвам иттерүгә дә өзлексез игътибар бирә килде. Шуның бер матур үрнәге булып, 1929 елда «Татар хатыны ниләр күрми» повесте басылды. Бу әсәрнең беренче варианты сәнгатьлелек ягыннан бик зәгыйфь эшләнгән иде. Әлбәттә, 20 елдан соң кабат иҗат ителгән яңа вариантта элекке тема һәм геройлар искесе белән чагыштырмаслык дәрәҗәдә үзгәрделәр, дөресрәге, өр-яңа повесть барлыкка килде. Хәтта күпмедер күләмдә язучы бирелә үзенең беренче романтик традицияләре белән тегеләй я бу төстә бәхәскә дә кергән шикелле. Шуның нәтиҗәсендә Гөлбану образында, элекке бунтарь героиняга капма-каршы буларак, патриархаль крестьян деспотизмы, башбаштаклыгы, томаналыгы һәм кыргыйлыгының ихтыярсыз корбаны булган татар хатыны сурәтләнә. Бу очракта Ибраһимов, барыннан да бигрәк, критик реализм традицияләренә таяна һәм кеше язмышының трагик сәбәпләрен, чыганакларын иҗтимагый яктан сәнгатьле мотивировкалаштыру нечкәлеге белән ачуга ирешә. Гөлбану ни өчен һәлак була? Чөнки ул иске крестьян тормышындагы кыргый гореф-гадәтләрнең газабын һәм кешелексез мөнәсәбәтләрнең авырлыгын күтәрә алмый, шулардан котылу өчен, шуларга нәфрәт белдереп, үзен-үзе һәлак итә. Алай гына да түгел, ул килен булып төшкәч, электә бай һәм данлы булган Шибай картның хуҗалыгы да, токымы да таркалуга бара. Димәк, Гөлбану драмасы — ул яшәгән шартларның котылгысыз фаҗигагә дучарлыгыннан килә торган хәл дә икән. Нәкъ шушы моментта герой язмышының иң әһәмиятле реалистик чыганагы һәм мотивировкасы ята да инде. «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендә язучы хәлле татар крестьяннарының гадәти көнкүрешен һәм шундагы гади кешеләрнең драмасын күрсәтү аша авылдагы

[1] Г. Ибраһимов үзе бу әсәрен «хикәя» дип атый. Ул вакытларда бу атама «повесть» мәгънәсендә дә кулланылды. — Г. Х.

патриархаль-феодаль мөнәсәбәтләрнең җимерелүе, таркалуы шикелле стихиянең зур иҗтимагый мәгънәсен ачуга ирешә. Бу — Ибраһимов реализмының гаять көчле ягы. Гөлбану образы, аерым алганда, үзе күпме генә кызганыч һәм мелодраматик булмасын, әмма аны әйләндереп алган шартларны һәм кешеләр мөнәсәбәтен сурәтләүдәге кырыслык повесть стиленең төп реалистик пафосын билгели. Шулай ук традицион мәхәббәт темасының, ягъни гадәттә романтик линияне тәшкил иткән теманың, аерым алынмавы да шул кырыслыкны көчәйтә. Сайланган реалистик стиль белән бу очракта инде ул тема, бәлки, сыешa да алмас иде. Мәхәббәт линиясе романтик әдәбиятта, һәм Ибраһимовның шул рухтагы әсәрләрендә дә, гадәттә явыз чынбарлык белән конфликтка, каршылыкка кергән геройларның рухи хәлен, психологизмын күрсәтү өчен җайлы һәм кирәкле иде. «Татар хатыны нилләр күрми»дә Ибраһимов бу юл белән бармый, чөнки реалистик куелыш моңа мохтаҗ түгел. Әмма, шуның белән бергә, явызлыкка каршы торган гүзәллек идеалы алып та ташланмый. Ул идеал башлыча Гөлбану рухи дөньясында гәүдәләнә. Аның матур, тигез мәхәббәт аша бәхетле тормыш төзү теләге — әнә шул гүзәллек идеалы инде.

Ибраһимов — язучының чынбарлыкка сәнгатьчә мөнәсәбәте, эстетик идеалы ничек булырга тиешлегенә бөтен иҗаты буенча конкрет җавап табуны максат итеп килгән әдәби сүз осталарының берсе. «Мин натурализмга каршы, — диде ул. — Тормыш кисәкләрен шул көенчә, фотографияләп, дөньяга ташлау юлы белән төзелгән әсәрләрнең кыйммәте юк. Минемчә, әдәби әсәрләр тормышның каты көрәшле, күп катлаулы, бай каршылыклы тирән процессларын иҗат механизмы аркылы, җанлы сурәтләрдә гәүдәләндерү, чагылдыру юлы белән язылганда гына социалистик реализмга ирешеп булачак...»[1]

Чыннан да, Ибраһимовның бигрәк тә социалистик революциядән соңгы иҗат юлы — әнә шундый максатка ирешү өчен кирәкле тырышлыкның һәм сәнгатьчә осталык югарылыгына күтәрелә баруның күркәм үрнәге. Тормышның иҗтимагый тирәнлегенә һәм каршылыкларына эченә керү бурычын совет язучысы сыйнфый-партияле караш позициясеннән торып кына башкара алачагын ул бик тиз аңлады һәм революциядән соңгы беренче әсәрләрендә үк әнә шундый позициядән чыгып иҗат итә башлады. Ибраһимов совет әдәбиятының партиялелек принцибын догма итеп түгел, ә тормышның, тарихи барышның үз эченнән һәм шул тормышны төзүчеләр эшчәнлегеннән үсеп чыккан җанлы, реаль нәрсә итеп, чынлыкка әверелгән идеал итеп күрде. һәм шуны үз иҗат практикасында тулылыгы белән күрсәтергә теләде, әдәби көчләрне дә шуңа өндәде. Кабаттан «Безнең көннәр» трилогиясенә әйләнеп кайтып, әсәрне яңабаштан эшләргә тотынуы да, иң әүвәл, социалистик реализмның партиялелек принцибы яктылыгында халыкның һәм аның юлбашчыларының үткәндәге зур көрәш тарихын җанландыру теләгенә бәйле иде. Бу әсәрдә егерменче йөз башындагы революцион хәрәкәтләрнең киң картиналары һәм актив көрәш мәйданына баскан большевик образлары ачылды. «Безнең көннәр»нең беренче басмасы белән чагыштырганда, икенче басманың иң зур аермасы әнә шул моментларда күзгә бәрелә. Большевик Зариф Булатов һәм аның фикердәшләре тарихи вакыйгаларның үзәгендә баралар. Башка геройларның да рольләре үзгәрә, аларның язмышлары да тарихи-революцион вакыйгалар яктылыгында яңа төсмер, икенче юнәлеш һәм бәя ала. Тарихилык һәм партиялелек принципларының ачыклыгы роман геройлары арасындагы мөнәсәбәтләр, шәхси-интим кыланышлар атмосферасын да нык үзгәртә. Элекке романтик мавыгулар, хирыслар да чамага керәләр һәм икенчерәк планда калалар. Чынлык һәм гүзәллек гармониясенең дә төп пафосы инде төрле геройларның революцион көрәш һәм реакция шартларында күрсәткән сыйнфый-политик һәм идея-мораль кыяфәтләрен реалистик гәүдәләндерүдә чагыла.

Чынбарлыкны һәм кешеләр, сыйныфлар арасындагы һәртөрле мөнәсәбәтләрне кискен каршылык, рәхимсез бәрелеш һәм фаҗигаләрдән арындырып, шомартып сурәтләүне Ибраһимов социалистик реализмга чит тенденция һәм әдәби иҗат эшен арзанлы, җиңел һөнәргә әйләндерү дип санады. 1932 елда ул бер төркем яшь әдипләргә киңәш рәвешендә язылган хат-мәкаләсендә болай ди: «Беләсез: партия бик зур корбаннар бирде, безнең һәммә фронтларыбыз, һәммә җиңүләребез күп кыйм-

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 219 бит.

мәтле корбаннар аркылы алынды... Әдәбият боларны яшереп калдырсынмыни?.. Киресенчә, бу корбаннар, бу газаплар, бу үлемнәр яшь буынны ялкынландыра торган рәвештә кискен тасвирларда күрсәтелергә тиеш»[1].

Галимҗан Ибраһимов чынлык һәм гүзәллек гармониясенең бөек гәүдәләнешен социалистик җәмгыятьтә һәм аны төзүчеләр эшчәнлегендә күрде. Әнә шул гармонияне совет язучысы үз эстетик идеалының үзәгенә куеп, чынлыкны, хакыйкатьне халык белән партия карашыннан чыгып сурәтләргә чакырды.

**Резеда Ганиева,**
филология фәннәре кандидаты

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ КӨНЧЫГЫШ ӘДӘБИЯТЛАРЫ

Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең киң яңгыраш алуына китергән сәбәпләр хакында сүз барганда, барыннан да элек, аның дөнья әдәбияты хәзинәләренә йөз тоткан олы художник булуын истән чыгармаска кирәк. Ул рус классик язучыларын һәм рус совет әдәбиятын ныклап өйрәнә, шул ук вакытта, рус һәм төрек телендәге тәрҗемәләр аша, Европа әдәбиятларыннан да яхшы хәбәрдар була. Мәдрәсәдә укыганда аның Әбугалисина, Фараби, Ибне Рөшд, Мәгарри, Фирдәүси, Низами, Җәләлетдин Руми, Хәйям, Хафиз, Сәгъди, Нәваи, Фозули кебек Шәрык даһиларын зур тырышлык куеп өйрәнүе һәм төрек әдәбияты белән мавыгуы мәгълүм.

Кыскасы, Галимҗан Ибраһимов әдәби бәйләнешләрны тарихи-әдәби процессның аерылгысыз бер өлеше дип саный, татар әдәбияты үз кабыгына гына бикләнеп ятмаска тиеш, ди. Октябрь революциясенә кадәр үк әле мәдрәсә шәкертләрен дөнья әдәбияты җәүһәрләре белән таныштыру, Гомер, Данте, Шекспир, Гете, Байрон, Мәгарри, Фирдәүси, Сәгъди, Фозули кебек әдипләрнең әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү турында хыялллана.

Шунысы да игътибарга лаек: буржуаз галимнәр, Көнчыгыш культурасын түбәнсетеп, аны Көнбатышка каршы куйган бер чорда, я булмаса, пантюркист язучылар һәм тәнкыйтьчеләр бары тик Көнчыгыштан гына өйрәнергә чакырган елларда Галимҗан Ибраһимов һәр ике культураның тигез хокуклы булуын яклап чыга. «...Гомер, Данте, Шекспир кебек Гареп классиклары илә янәшә утыртып, алларына бердәй тезләнергә фарыз булган Шәрык даһиларын хәтергә ала башларга вакыттыр дип уйлыйм, — ди ул. — Мәдрәсә көрсиләренә (кафедраларына), аннан бөтен татар йөрәгенә «Илиада»лар, «Илаһи комедия»ләр белән бергә үк гарәпнең Мәгарри, Фирдәүсинең «Шаһнамәләре», Сәгъди белән Фозулиның «Гөлстан» вә «Ләйлә-Мәҗнүн»нәре кереп утырырга, шуңа күрә боларны тәрҗемә вә нәшер кыйлырга, шәкерткә, боларны укып, тикшереп, алар илә нык танышып өчен, юл ачуны уйлый башларга бик тиешледер»[2].

Шул рәвешчә, Г. Ибраһимов XX йөз башы татар әдәбиятын Көнбатыш һәм Көнчыгыш әдәбиятларының уңай казанышлары белән баетуны, «гакыл вә фикеребезне алар кояшы илә» яктыртуны мөһим бер эш итеп карый, татар галимнәреннән беренче буларак, әдәби бәйләнешләрне өйрәнүгә зур өлеш кертә.

Г. Ибраһимов мәкаләләрендә татар әдәбиятының Шәрык әдәбияты белән бәйләнешы хакында сөйли торган күп кенә мисаллар китерелә. Мәсәлән, ул Шәехзадә Бабич иҗатының гарәп әдәбияты белән мөнәсәбәте зур булуга игътибар итә, ә «йөрәк дулкыннарын тасвирда» аның Әзербәйҗанның күренекле романтигы Фозулины хәтергә китерерлек дәрәҗәләргә менүен искәртә. Ул Тукай иҗатында да Фозули лирикасының тәэсирен күрә. Үзбәк әдәбиятының алтын дәверендә җитешкән Нәваи

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 222 бит.
[2] Шунда ук, 102 бит.

кебек шагыйрьнең барлык төрки әдәбиятлар өчен дә кадерле булуын билгеләп үтә, Хуҗа Насретдин мәзәкләренең, «Таһир-Зөһрә», «Буз егет» кебек романтик эчтәлекле мәхәббәт дастаннарының татарлар арасында кулдан-кулга йөреп укылган әдәби җәүһәрләр икәнлегенә басым ясый. Аның фикеренчә, әдәбиятлар арасындагы үзара мөнәсәбәтләр беркайчан да очраклы рәвештә тумыйлар, «кай заманда, кайсы дөньяның тәҗрибәсен сайлау... икътисади (экономик) нигезләр кушуы буенча була»[1]. Урта гасыр татар әдәбиятының тулысы белән Шәрык мәдәнияте тәэсирендә булуын да Галимҗан Ибраһимов җитештерү көчләренең шул замандагы халәте, иҗтимагый ихтыяҗлар белән аңлата.

Үзбәк, әзербәйҗан әдәбиятлары белән беррәттән, Галимҗан Ибраһимов татарларга госманлы әдәбиятының, бигрәк тә «Мөхәммәдия» китабының тәэсире зур булганын күрсәтә. «Кәлибули шагыйренең талантлы язган «Мөхәммәдия»се,— ди ул,— бездә, һәм шигырь, һәм җыр, һәм музыка буларак, йөз еллар буенча җан азыгы булды. Истамбулның башка күп әсәрләре дә бездә үз итеп укылды» [2].

Чыннан да, һәм формасы, һәм эчтәлеге ягыннан демократик рухта булган, киң катлау укучылар массасына адресланган «Мөхәммәдия» китабы бездә киң таралган булган. Татар егетләре һәм кызлары аның байтак өлешләрен яттан белгәннәр. Шигъри формасы үтемле булганга күрә, татар шагыйрьләре «Мөхәммәдия» китабы алымнарына еш мөрәҗәгать иткәннәр. Галимҗан Ибраһимов та бу моментны игътибарсыз калдырмый. Мәсәлән, «Татар шагыйрьләре» исемле хезмәтендә Тукай иҗатының башлангыч чорын ул «Мөхәммәдия» дәвере» дип атый. Ул шагыйрьнең милли прогресс, мәгърифәт турындагы шигырьләрендә, мәхәббәт газәлләрендә, тәнкыйть һәм зарларында «Кәлибули хәзрәтләренең күләгәсен» күрә. «Аның (ягъни Тукайның — Р. Г.) вәзеннәренең байтагы, — ди ул, — «Мөхәммәдия»дәгечә улдыгы кебек, ифадә (аңлату) вә тәркибләр дә (сүз тезмәләре), өслүб тә тәгъбиратның бик күбендә, хәтта гыйшык вә шикаять хакында булган шигырьләренең мәгънә вә мәфһүмнәрендә (эчтәлек) дә җанәбе Кәлибули хәзрәтләренең күләгәсе бик ачык төшеп тормактадыр. Шуның өчен Тукаевның бу язуларын тудырган заманны «Мөхәммәдия» дәвере» дип атау да бер хаксыз булмас иде» [3].

Галимҗан Ибраһимовның әлеге фикерләрен дәвам итеп, шуны гына өстәргә мөмкин: «Мөхәммәдия» тәэсире Тукайның беренче әдәби алымнары белән генә чикләнмәгән. Иҗатының җитлеккән чорында да ул, «Мөхәммәдия» шигырьләреннән файдаланып, феодализм калдыкларын, кадимчелекне тәнкыйтьләгән «Ысулы кадимче» кебек сатирик әсәрләр яза. Гомумән, иске дини-дидактик әдәбиятка, суфичылык поэзиясенә пародияләр һәм назирәләр язуда Тукай тиңдәшсез художник булып кала.

Көнчыгыш әдәбиятларының татар әдәбиятына булган йогынтысы турында сөйләгәндә, Галимҗан Ибраһимов аларның үсеш диалектикасы, киләчәктәге язмышы белән дә кызыксына. Татар әдәбиятының икенче дәверендә, ягъни XIX йөздә, ул иске Шәрык традицияләренең Курсави, Мәрҗани, Акъегет, Акмулла кебек мәгърифәтче галим һәм язучылар тарафыннан «җимерелеп», Гарәп тибындагы әдәби хәрәкәтнең мәйданга чыгуын күрсәтә. Әмма Галимҗан Ибраһимов кулланган «җимерү» сүзен Көнчыгыштан бөтенләй баш тарту дип аңларга ярамый. Бу очракта сүз торгынлык процессы кичергән феодаль Шәрык, аның идеологик нигезләре, клерикаль һәм суфичылык әдәбиятындагы консерватив традицияләр турында бара.

Көнчыгыш Ренессансының бөек галимнәре, философлары, шагыйрьләре иҗатына, гуманистик эчтәлекле халык әдәбиятына Галимҗан Ибраһимов һәр вакытта да зур ихтирам белән карый, аның кайбер алымнарын үзенең әсәрләрендә файдалана.

Әйтик, «Диңгездә» хикәясендә (VII бүлек) сюжетны һинд фольклорында һәм урта гасыр көнчыгыш прозасында киң таралган маҗаралы, гыйбрәтле хикәяләр белән үреп бару алымы очрый (зур балык чәнечкеләренә чуп-чар җыелудан ясалган утрау; ут яккач, балык сыртындагы утрауда купкан зилзилә; җиде тәүлектән соң гына корабка юл биргән гигант балык, Юныс пәйгамбәр язмышын кабатлап, балык карынына ташланган Гаптулла хаҗи турындагы хикәяләр). «Яшь йөрәкләр» романының прологында Мәрьямнең Зыя белән бәхетле тормыш турындагы хыяллары Көнчыгыш ро-

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 162 бит.
[2] Шунда ук, 137 бит.
[3] Г. Ибраһимов. Татар шагыйрьләре. Оренбург, 1913 ел, 59 бит.

мантикларындагыча маҗаралы хикәя алымнарына нигезләнеп сурәтләнә. Мәсәлән, елга буендагы гаҗәп матур чәчәкле бакча; бакча эчендәге кечкенә чатыр; чатыр эчендәге ниһаясез зур диңгез, пароходлар, матур агачлар, чибәр хатыннар, алар уртасында тәхеткә утырган, «Әлфе ләйлә вә ләйлә»дәге кызлардан мең вә йөз мәртәбә матуррак кыяфәткә кергән» Мәрьям. «Диңгездә» хикәясеннән беркадәр үзгә буларак, биредә маҗаралы хикәя алымы хикәя эчендә хикәя рәвешендә бирелгән һәм өстәвенә Көнчыгыш әдәбиятларында жанр буларак яшәгән төш күрү алымы белән үрелгән.

«Диңгездә», «Яшь йөрәкләр» кебек әсәрләрдә романтизм эстетикасы таләпләренә буйсындырылган һәм эпизодик рәвештә генә кулланылган теземле һәм уралы хикәяләү алымы «Тирән тамырлар» романында үзәк бер композицион чарага әйләнә. «Мең дә бер кичә»дәге әкиятләр, Низаминың «Җиде чибәр» поэмасы, К. Насыйриның «Әбугалисина», «Кырык вәзир» кыйссалары кебек үк, роман хикәя эчендә хикәяләр формасында язылган [1]. Коммунист Фәхринең язмышы, аның яңа тормыш төзү өчен көрәше төп, зур хикәяне тәшкил итә; кечкенә хикәяләр — Фәхринең үтерелүенә мөнәсәбәттә сюжет җебенә тезелгән һәм шул чорның катлаулы сыйнфый көрәш диалектикасын гәүдәләндергән башка геройлар (Гайшә, Нәгыймә, Садыйк, Камали, Гыймади, Вәли бай һ. б.). Шул рәвешчә, Көнчыгыш әдәбиятларында озак гасырлар дәвамында кулланылып килгән бу традицион формага яңа эчтәлек салып, Галимҗан Ибраһимов социалистик реализмның зур казанышы булырлык әсәр тудыра. Татар язучысының бу романдагы новаторлыгы төрки әдәбиятларда бүген дә дәвам иттерелә. Үзбәк прозаигы Әсгать Мохтарның «Чинар» романы бүгенге совет әдәбиятында традицияләрнең әледән-әле яңарып торуына уңышлы мисал була ала.

Алда әйтелгәнчә, Г. Ибраһимов татар әдәбиятына урта гасыр госманлы әдәбиятының дөньяви канаты нык тәэсир иткәнлеген күрсәтә. Төрек әдәбиятының күренекле вәкилләре Хәмдуллах Хәмдине, Йосыф Синан Гирмияни, Гыйшыкизадәләрне ул уңай яктан телгә ала, солтан режимын, аның якыннарын тәнкыйтьләгән өчен үтереп диңгезгә ташланган талантлы сатирик Гомәр Нәфгый иҗатына югары бәя бирә. Яңа заман төрек матбугатын, сәнгатен, әдәбиятын Г. Ибраһимов шулай ук яхшы белгән, XIX һәм XX йөз башында иҗат иткән күпчелек төрек шагыйрьләре, прозаик һәм драматурглары белән оригиналда танышкан. Яңа төрек әдәбиятына нигез салган талантлы шагыйрь, драматург, тәрҗемәче, ялкынлы публицист Шенаси иҗаты, революцион мәгърифәтчелек идеяләре, гражданлык пафосы белән сугарылган Тәүфыйк Фикрәт романтизмы Г. Ибраһимов күңеленә хуш килгән. Төрек әдәбиятында новелла жанрын башлап җибәргән, француз язучысы А. Дюма-атасы әсәрләренә охшатып хикәя, повесть, романнар иҗат иткән Әхмәт Мидхәтне ул игътибарга лаек автор дип исәпли, аның «Хөсәен фәллах», «Хәсән мәллах» исемле романнары белән таныш булуын әйтеп үтә.

Киевтә Галимҗан Ибраһимовтан конфискацияләнгән әдәбият исемлегендә Төркия тарихына, аның сәнгатенә һәм әдәбиятына караган материаллар да байтак очрый. Алар арасында талантлы төрек шагыйре, романтик Габделхак Хәмид әсәрләре аеруча зур урын алып тора. Галимҗан Ибраһимов Киевтә Габделхак Хәмиднең «Индус кызы», «Андалузия батыры», «Үләләр яки хуҗалар», «Астыртын кыз», «Әшбәр», «Каберлек», «Зәйнәп», «Нарцисс», «Кызганычның васыяте» кебек феодаль һәм колониаль изүгә протест белдергән, изелгәннәр мәнфәгатен, шәхес азатлыгын яклаган, хатын-кызларга ирләр белән тигез хокук таләп иткән шигъри драмаларын укыган. 1913 елның 14 мартында Киевтән Фатих Кәримигә язган хатында Галимҗан Ибраһимов бу елларда Габделхак Хәмиднең әдәби куәте алдында хәйран калуын әйтә [2]. Атаклы «Ирек» драмасы, «Кабер» поэмасы авторы, алдынгы иҗтимагый идеаллар белән сугарылган һәм Европа әдәбиятларының художество казанышларын үзләштергән Габделхак Хәмид иҗаты татар язучысының иҗади һәм рухи эзләнүләренә аваздаш булган. Габделхак Хәмид кебек, Галимҗан Ибраһимов та яңа заман татар романтизмының нигез ташларын салучы зур әдипләрнең берсе. Габделхак Хәмид әсәрләре белән мавыгуы аның иҗатында төрек романтизмының да билгеле бер дәрәҗәдә өлеше барлыгы турында сөйли.

---

[1] Моңа тәнкыйтьче Р. Бикмөхәмматов та игътибар итә. Карагыз: «Вместе с народом». Рус телендә, Мәскәүдә, 1959 ел, 125 бит.

[2] «Совет әдәбияты» журналы, 1963 ел, 1 сан, 108 бит.

Танылган төрек романнарының исемнәре, геройлары белән без Галимҗан Ибраһимовның әдәби әсәрләрендә дә очрашабыз. Мәсәлән, «Яшь йөрәкләр» романындагы Мәрьям бик «тәмләп вә баллап язылган» исәпсез-хисапсыз төрек романнары белән мавыга. Нәмыйк Кәмал, Әхмәд Рәсим кебек зур мәгърифәтче язучыларның һәм французчадан тәрҗемәләр кызның «бертуктаусыз теләп тора торган рухи ризыгы»на әйләнә. Мәрьям, бөтен дөньясын онытып, реалистик төрек әдәбиятын башлап җибәрүчеләрдән Халид Зыя Ушаклыгөлнең «Нәмидә», «Фәрди вә шөрәкя» кебек романнарын укый, үзенең эчке дөньясын аларда мәхәббәт чире белән авырган Нәмидәләр, һаҗәрләр, Наилләр, Тайфурлар хәяты белән үлчи, бу геройларның фаҗига, канлы күз яшьләре белән үрелгән мәхәббәтенә үзенең якты өметләрен каршы куя. «Европалашу», дөресрәге, «французлашу» процессы кичергән бу чор төрек әдәбияты үзенең идеологик асылы, эстетик табигате белән бик тә чуар һәм катлаулы була. Андагы иҗат методлары да саф килеш кенә яшәми, реализм да, романтизм да XVIII һәм XIX гасыр француз әдәбияты өчен хас булган классицизм, сентиментализм, натурализм, импрессионизм күренешләре белән бергә аралашып, үрелеп бирелә. Азмы-күпме бу әдәби ысулларның (бигрәк тә сентиментализм һәм натурализм элементларының) тәэсире Галимҗан Ибраһимовның Октябрьгача романтизмында да күзгә ташлана. Шул рәвешчә, татар язучысының иҗаты төрек әдәбияты аша француз романтизмы традицияләренә барып ялгана[1].

Октябрь революциясенә кадәр үк Галимҗан Ибраһимов халыклар дуслыгын яклаган язучы, журналист һәм революционер буларак таныла. Әле 1913 елда — Киев вакыйгалары чорында ук — бу юнәлештә зур эш башкара. Аның актив катнашлыгында башкорт, казакъ, үзбәк, әзербәйҗан студентлары төрки халыкларның иҗтимагый тормышы, культуралары, әдәбиятлары турында рефератлар тыңлыйлар, фикер алышалар; җирле һәм үзәк матбугат битләрендә милли һәм тәрҗемә әдәбиятның иң яхшы үрнәкләрен пропагандалыйлар, гади халык арасында төрле темаларга язылган фәнни-популяр брошюралар тараталар. Якташлык оешмасы члennарының мондый эшләренә Галимҗан Ибраһимов һәр вакыт диярлек политик төсмер бирергә тырыша, аларның чыгышларын тар «мөселманлык», мәгърифәтчелек кысаларыннан киң интернациональ юлга, самодержавиегә каршы көрәш мәйданына алып чыгарга омтыла. Патша цензурасы материалларында да бу момент теркәлеп калган. «Киев мөселман студентларының яшерен съезд үткәрү идеясенә сезнең мөнәсәбәтегез ничек?» — дип сорагач, Галимҗан Ибраһимов: «Мин, әдәбиятчы буларак, мөселман яшьләренең тормышы, рухи халәтләре белән кызыксынуны, хәбәрдар булуны үземнең бурычым итеп исәплим», — дип җавап бирә. Съездда сәяси мәсьәләләр генә каралырга тиеш, дигән тәкъдимнең дә үзе тарафыннан кертелүен раслап үтә[2].

Бу чорда Галимҗан Ибраһимов Шәрыкны өйрәнүче галимнәр, прогрессив карашлы журналистлар, демократик матбугат органнары белән дә якын мөнәсәбәтләрдә була. Әле Киевтә чагында ук ул профессор В. В. Бартольд белән бәйләнешкә керә. Башка мөселман студентлары белән берлектә, ул редакцияләгән «Мир ислама» журналының патша цензурасы тарафыннан эзәрлекләнүенә ризасызлык белдерә, аның иҗтимагый-политик мәсләген яклап чыга. «Мир ислама» журналында басылган объектив эчтәлекле фәнни мәкаләләр Эчке эшләр министры Макаровка ошамый. Ул журналны царизмның колониаль политикасын үткәрүче рупорга әйләндерергә тели. Ләкин В. В. Бартольд министрның бу таләбен катгый рәвештә кире кага һәм нәтиҗәдә редакторлык эшеннән алына. Министрлыктан журналның элеккеге юнәлештә чыгару кирәклеген яклауны үтенеп, В. В. Бартольд Галимҗан Ибраһимов җитәкчелек иткән Киев мөселман студентларының якташлык оешмасына мөрәҗәгать итә. Бер үк вакытта ул «Мир ислама» журналының татар бүлегендә нинди материаллар белән катнашу мөмкин икәнлеген дә аңлата. Якташлык оешмасы протоколлары, цензура материаллары профессор В. В. Бартольд мөрәҗәгатенең Г. Ибраһимов катнашында махсус тикшерелүе турында сөйли[3]. (Совет власте елларында да Галимҗан Ибраһимов академик

---

[1] Г. Ибраһимовның французчадан тәрҗемәләрне укуы турында үзенең истәлекләрендә Зәйнәп Кәримова да әйтеп үтә. «Казан утлары», 1967 ел, 3 сан, 139 бит.

[2] Украина Үзәк дәүләт тарих архивы, 274 фонд, 1 тасвирлама, 3151 эш, 562—563 битләр.

[3] Шунда ук, 352 бит.

В. В. Бартольд белән язышып тора, төрки халыкларның, шул исәптән татарларның тарихы, мәдәнияте турында фикер алыша.)

Киев якташлык оешмасы члennары, шул исәптән Галимҗан Ибраһимов, Петербургта Дагстанның күренекле язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Сәет Габиев редакторлыгында чыга торган «Мусульманская газета»ны шатланып каршы алалар һәм аны царизм тарафыннан кимсетелгән, изелгән Көнчыгыш халыкларының мәнфәгатен яклаучы прогрессив матбугат органы дип бәяләп, махсус телеграмма белән котлыйлар[1]. Бу телеграмма текстын язуда Галимҗан Ибраһимов та катнашкан. Үз чиратында Сәет Габиев якташлык оешмасы белән бәйләнешкә керә, Көнчыгыш халыклары тормышын өйрәнү буенча студентларга киңәшләр бирә һәм аларны «Мусульманская газета»да язышырга чакыра.

Күрәсез, Галимҗан Ибраһимов үзенең беренче адымнарыннан ук Көнчыгышны өйрәнүче галим буларак формалаша. Һәм аны революцион, педагогик, фәнни-оештыру эшчәнлеге белән бергә үреп алып бара. 1915—1916 нчы елларда «Галия» мәдрәсәсендә укытканда ул әзербәйҗан, казакъ, кыргыз, үзбәк, төркмән шәкертләре арасында туганлык җепләрен ныгытуга, аларда милли культура мәсьәләләренә демократик караш тәрбияләүгә зур игътибар бирә. Бу уңай белән Гомәр Бәшировның Тукай белән Ибраһимов башка халыкларга мөнәсәбәттә «революциягә кадәр үк үзләрен дөнья әдәбиятының бөек гуманистлары биеклегендә тоттылар» дип язуы бик тә урынлы[2]. Дөрестән дә, Галимҗан Ибраһимов украиннарның бөек шагыйре Шевченко турында язамы, төрки әдәбиятлар һәм телләр мәсьәләсен кузгатамы — һәрнәрсәдә интернационалистик принципларны яклый. Мәсәлән, 1916 елның кышында ул «Галия» мәдрәсәсенең 10 еллык юбилее уңае белән үткәрелгән тантаналы җыелышта зур чыгыш ясый һәм шунда төрки халыкларның милли интеллигенциясе һәм милли культуралары мәсьәләсенә дә туктала. Аның киләчәктә һәр халыкның милли культурасы, үз милли әдәбияты, үз милли теле булырга тиеш дигән тезисына Муса Бигиев кебек буржуаз идеологлар, бер төркем муллалар каршы чыгалар, барлык төрки халыклар өчен «бердәм мәдәният, уртак әдәбият һәм лисан» кебек пантюркистик идеяләрне алга сөрәләр. Җыелышта катнашучы демократик интеллигенция вәкилләре, шул исәптән «Казакъ» газетасы редакторы Әхмәт Байтурсунов, Галимҗан Ибраһимов фикерен куәтлиләр, аны «милләткә хыянәт»тә гаепләүчеләргә отпор бирәләр.

Төрки мәдәниятләрнең үсеш закончалыкларын чын фәнни нигездә аңлату буенча да Галимҗан Ибраһимов «Галия»нең күп милләтле шәкертләре арасында зур эш башкара, шовинистик һәм милләтчелек теорияләренә каршы чыга. Шул ук елда мәдрәсәдә казакъ телендә чыгарылган «Садак» кульязма журналы тирәсендә барган бәхәсне, мәсәлән, дөрес юлга юнәлдерә, «татарчылык» сөреме кагылган яшьләрнең ялгышларын күрсәтә; төрек, әзербәйҗан, үзбәк, казакъ, татар әдәбиятларының үсеш үзенчәлекләре турында сөйли, казакъ халкының үз телендә әдәбият, фән, матбугат тудырырга омтылуын зарури бер күренеш итеп исәпли. Соңыннан бу турыда «Аң» журналында мәкалә белән чыгыш ясый. «Телләре башка булса да, күңелләре бер» исемле бу мәкаләдә Галимҗан Ибраһимов казакъ халкының «рухында көчле самобытность» күрә, аның фольклорына зур бәя бирә һәм аннан өйрәнергә чакыра. «Боларның халык әдәбияты, — дип яза ул, — башка һичбер төрле кабиләләргә охшамас дәрәҗәдә бай һәм зурдыр. Безгә казакъларны татар теле вә әдәбияты астына кертү хыялыннан бигрәк, әдәби хәзинәмезне баету өчен казакъ халкы әдәбиятын киң рәвештә өйрәнү тиешледер»[3].

Үләң вә җырларга бай Абай Кунанбаев кебек шагыйрьләре булган казакъ әдәбиятының киләчәгенә Галимҗан Ибраһимов зур өметләр баглый: «Ләкин бара торгач алар (ягъни казакълар — Р. Г.) мөмтаз рухлары белән парлак мәйданга чыгачаклар. Моны һичбер куәт туктата алмаячак»[4]. Казакъ культурасы һәм әдәбиятының Октябрь революциясеннән соңгы үсеше Галимҗан Ибраһимовның бу сүзләрен тулысы белән раслады.

Совет дәүләтенең беренче адымнарыннан ук Галимҗан Ибраһимов Көнчыгышны

---

[1] Украина Үзәк дәүләт тарих архивы, 274 фонд, I тасвирлама, 3151 эш, 352 бит.
[2] «Казан утлары» журналы 1967 ел, 3 сан, 139 бит.
[3] «Аң», 1916 ел, 5 сан, 88—89 битләр.
[4] «Аң», 1916 ел, 5 сан, 90 бит.

өйрәнүне марксистик нигезгә кору буенча киң колачлы эшкә катнаша. СССР Үзәк Башкарма Комитеты каршында Көнчыгышны өйрәнүнең Бөтенсоюз гыйльми берләшмәсе оештырылгач, ул аның член-учредителе була. Әдип Совет Көнчыгышындагы халыкларның тарихын, фәлсәфәсен, революцион хәрәкәтләрен, мәдәни үсешләрен, матбугат һәм әдәбиятларын яктыртуга бердәй игътибар бирә.

Фәннәр академиясенең 200 еллык тантанасы уңае белән Г. Ибраһимов Ленинградта һәм Мәскәүдә Көнчыгышны өйрәнү фәненең күренекле галимнәре белән очраша, тюркологларның Бакудагы I Бөтенсоюз съездын ничек үткәрү, хәзерләү турында фикер алышуларда катнаша. Татарстан делегациясе җитәкчесе итеп Бакуга ул үзе җибәрелә. Яңалиф турындагы доклады бәхәсләр тудырса да, Көнчыгыш халыкларының революцион хәрәкәтен өйрәнү мәсьәләсе съезд программасына Галимҗан Ибраһимов тарафыннан кертелә. Бу — марксистик методологияне гамәлгә ашыру юлында аның зур адымы иде. Шуны ук ул үзенең замандашларыннан — язучылардан, галимнәрдән, художниклардан таләп итә. Бу җәһәттән танылган скульптор Бакый ага Урманче истәлекләре игътибарга лаек [1]. Бервакыт Галимҗан Ибраһимов аңа Октябрь революциясенең Көнчыгыш халыкларын уятудагы ролен күрсәткән китапка рәсем ясавын үтенә. Әмма художникның зур, ажур тәрәзәле бүлмәдә бизәкле келәмнәр, йомшак мендәрләр өстендә кальян суырып, тәрәзәдән кергән кояш нурларына (ул Октябрь революциясен символлаштыра) гаҗәпләнеп утырган бае Галимҗан Ибраһимовка ошамый. Моның сәбәбе — Көнчыгыш халыклары тормышының тышкы бизәкләрен генә күрү, күренешләрнең асылына үтеп керә алмау, сәнгатьчә фикерләүдә гасырлар буенча килгән традиционлылык кысаларында калу. Иң мөһиме — яңа заман көнчыгыш тарихын изелгәннәрнең милли һәм социаль азатлык өчен көрәшләре белән бәйләмәү. Шунлыктан Галимҗан Ибраһимов бу рәсемнән баш тарта. Бу факт Галимҗан Ибраһимов өчен һәр адымда иҗтимагый, культура, әдәби хәрәкәтләрне марксизм ысулы белән өйрәнү җитәкче методологик принципларның берсе булып калуын раслый.

Галимҗан Ибраһимов «революциянең могҗиз куәте белән» татар, әзербәйҗан, үзбәк, төркмән, казакъ, уйгур телләрендә «киң бер ташкын булып мәйданга чыккан» марксистик юнәлештәге иҗтимагый-политик һәм әдәби матбугатны «югъбәгез изге» дип, сөенеп каршы ала. Мәсәлән, ул «Коммунист», «Инкыйляб» («Революция»), «Кызыл Казагыстан», «Төрекмән иле», «Яшь уйгур», «Кызыл ил», «Кызыл укучы», «Чаткы» кебек журнал, газета һәм мәҗмугаләргә күзәтү ясап, кайбер мәкаләләрдә күзгә ташланган иҗтимагый битарафлык тенденцияләрен тәнкыйть итә, революция дошманнарын «үтерерлек итеп чәнчергә» өнди, яшь мөхәррир һәм язучыларның чыгышлары сыйнфыйлык принцибы белән, заман рухы белән сугарылырга тиешлеген яклап чыга («Төрки кавемнәрнең әдәбияты һәм матбугаты тирәсендә», «Төрки халыкларның әдәбиятлары дөньясыннан») [2].

Галимҗан Ибраһимов Совет Көнчыгышындагы төрки дөньяның шактый күп җәмәгать һәм культура эшлеклеләре, галимнәре, язучылары, журналистлары белән дуслык мөнәсәбәтләрендә була. Мәсәлән, Киевта чакта ул мөселман студентлары якташлык оешмасы члены, Әзербәйҗанның танылган прозаигы Йосыф Вәзиров белән аралаша. Жандарм идарәсе тарафыннан Г. Ибраһимовтан конфискацияләнгән китаплар исемлегендә Йосыф Вәзиров әсәрләре дә бар. Галимҗан Ибраһимов белән очрашу Йосыф Вәзировта да татар әдәбияты белән якыннанрак танышу теләге уята. Ул зур кызыксыну белән Ибраһимов әсәрләрен укып бара, аннан үрнәк алырга тырыша. Г. Ибраһимов Әзербәйҗанның күренекле революционеры, дәүләт эшлеклесе, язучы Нариман Нариманов турында мәкаләләр яза («Нариман иптәшнең 30 еллык хезмәт бәйрәме», «Нариман ага вафат»), аны талантлы язучы һәм Көнчыгыш халыклары туфрагында марксизмны үстерүче бөек шәхес дип бәяли. Танылган революционер, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Сәкен Сәйфуллин аның фикердәш һәм каләмдәш дусты була. Казагыстанда һәм Татарстанда Совет властен урнаштыру, казакъ һәм татар социалистик милли культураларын тудыруга зур өлеш керткән бу күренекле шәхесләрнең Мәскәүдәге бер очрашуы турында академик Сабит Муканов үзенең истәлекләрендә язып калдыра. Сәкен Сәйфуллин һәм Сабит Мукановлар белән Галимҗан Ибраһимов саф казакъ телендә сөйләшә, җылы хисләр белән казакъ җәйләүләрендә

[1] Г. Ибраһимов турында истәлекләр. Татарстан китап нәшрияты, 1966 ел, 164—167 битләр.
[2] «Безнең юл», 1922 ел, 1—2 саннар.

укыткан вакытларын, аның кешеләрен искә төшерә. Бу әңгәмәдән алган тәэсирләре турында Сабит Муканов болай дип яза: «Казакъ халкының телен, тормышын, гореф-гадәтләрен һәм культурасын аның ни дәрәҗәдә яхшы белүенә мин тагын бер тапкыр ышандым»[1].

Казакъ җәйләүләрендә яшәгән, укыткан елларда алган тәэсирләренә нигезләнеп, ул мәшһүр «Казакъ кызы» романын яза. Шул ук вакытта бу әсәр интернационалист язучының, галимнең пролетариат революциясе һәм партиянең Көнчыгыш халыклары тормышын иҗтимагый-тарихи планда өйрәнүне мөһим бер эш дип санап, көн тәртибенә куюына һәм бу өлкәдә актив хезмәттәшлеккә чакыруына җавабы да иде. Революциягә кадәрге даладагы сыйнфый көрәшне бу кадәр оста, реалистик үткенлек белән сурәтләгән әсәр XX йөз башы казакъ әдәбиятында юк иде әле. Карлыгач-Сылу белән Арсланбай мәхәббәтен тарих сәхнәсенә яңа гына аяк басып килгән сыйныфларның иҗтимагый көрәш перспективасы ятылыгында романтик пафос белән гәүдәләндерү әсәрнең идея-эстетик кыйммәтен, Көнчыгыш халыклары аңына эмоциональ тәэсир көчен икеләтә арттырган. Казакъ укучысы Галимҗан Ибраһимовны үз язучысы кебек яратып кабул итә, күпләр аның романын оригиналда укый. «Казакъ кызы» үз вакытында Казагыстан язучыларына рус һәм Европа әдәбиятлары традицияләрен үзләштерү өчен киң мөмкинлекләр ача, М. Әуэзов кебек талантларга «Абай» эпопеясын иҗат итү һәм казакъ әдәбиятының бөтендөнья әдәбияты мәйданына чыгуы өчен уңдырышлы җирлек хәзерләшә.

Галимҗан Ибраһимовның төрки халыклар әдәбиятына булган тәэсире Октябрь революциясенә кадәр үк башланган иде. Бу халыкларның кайбер язучылары, мәсәлән, башкорт Сәйфи Кудаш, Шәехзадә Бабич, казакъ Бәембит Майлин, үзбәк Мирмухсин Ширмөхәммәтов Галимҗан Ибраһимовның лекцияләрен тыңлыйлар, аның җитәкчелегендә үзләренең әдәби зәвыкларын үстерәләр.

Әдипнең феодаль-патриархаль тәртипләргә, социаль һәм рухи изүгә ялкынлы протест белдергән хикәяләре, революцион-демократик идеяләр белән сугарылган публицистикасы башкорт, казакъ, кыргыз, уйгур, үзбәк, каракалпак, төркмән, әзербәйҗан укучылары арасында зур теләктәшлек таба, аларның иҗтимагый аңын уятуга зур өлеш кертә, рус, француз, төрек әдәбиятларыннан килә торган прогрессив романтизм һәм реализм традицияләре белән таныштыра.

Гарәп графикасы белән файдаланган вакытта төрки халыклар Галимҗан Ибраһимовның әсәрләрен турыдан-туры оригиналда укыганнар. Егерменче-утызынчы елларда, милли телләр формалашу процессын кичергән бер чорда, татар язучысының әсәрләрен Көнчыгыш телләренә (әзербәйҗан, үзбәк, казакъ, төркмән, уйгур) тәрҗемә итү эше дә җанланып китә, аның аерым әсәрләреннән өзекләр төрки халыкларның әдәбият дәреслекләренә кертелә. Кайбер хикәяләре, «Безнең көннәр» романы төрек телендә басылып чыга.

Совет власте елларында Галимҗан Ибраһимов үзенең әдәби әсәрләре белән генә түгел, тарих, философия, педагогика, тел һәм әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть буенча язылган хезмәтләре белән дә төрки халыкларның алдынгы интеллигенциясенә сыйнфый көрәш закончалыкларын аңларга ярдәм итә, аларның социалистик эчтәлекле милли культураларының нигез ташларын салуда булыша. Галимҗан Ибраһимовның феодаль-патриархаль тәртипләрне камчылаган, сыйнфый бәрелешләр, революцион хәрәкәтләр темасына язылган әсәрләре Көнчыгыш халыклары арасында аеруча популярлык казана. Хатын-кыз азатлыгына багышланган хикәя, повесть, романнары бигрәк тә яратып укыла. Бу аңлашыла да. Чөнки ислам дине, шәригать кануннары хатын-кызны «тере курчак», кол иткән Көнчыгыш халыклары дөньясында бик тә четерекле һәм әһәмиятле социаль проблемаларның берсе иде. Кайсы гына Көнчыгыш әдәбиятына мөрәҗәгать итмик, аларның яңа заман прозасы шушы актуаль теманы яктыртудан башлана. Бу — үзенә күрә бер закончалык. Галимҗан Ибраһимов прозасының тәэсире дә башта шул юнәлештәрәк бара.

Татар интеллигенциясенең политик көрәш сферасына тартылуын, революциягә килү юлларын гәүдәләндергән «Безнең көннәр» романы Көнчыгыш әдәбиятларында повесть, роман кебек яңа жанрларның мәйданга чыгуына һәм социалистик реализм

[1] Г. Ибраһимов турында истәлекләр. 335 бит.

методының формалашуына да булыша диярга кирәк. Башкорт, казакъ, үзбәк, таҗик, төркмән, әзербайҗан әдәбиятларында сыйнфый көрәш диалектикасын чагылдырган проза әсәрләренең бер-бер артлы дөнья күрүе шул турыда сөйли.

Сәкен Сәйфуллин, Сабит Муканов, Габиден Мустафин, Бәембит Майлин, А. Токымбаев, Әүләни, Суфизадә, Зауки, Хәмзә Хәким-задә, Мирмухсин Ширмөхәммәтов, Абдулла Кадыйри, Мәһди Хөсәен, Йосыф Вәзиров, Берди Кербабаев, Садертдин Гайни, Һадия Дәүләтшина һәм башка бик күп шагыйрь, драматург, прозаиклар Галимҗан Ибраһимовны үзләренең остазы, фикердәш һәм каләмдәш дусты итеп санадылар, аннан өйрәнделәр. Бу уңай белән төркмән совет әдәбиятын башлап җибәрүче һәм нигезләүче академик Берди Кербабаев сүзләре аеруча гыйбрәтле: «Әйе, Галимҗан минем беренче укытучым булды, — ди ул. — Өстәп әйтәм: ихтимал, бердәнбер укытучым булгандыр. Билгеле, мин башка язучылардан һәм, беренче чиратта, рус классик әдәбияты һәм совет әдәбияты үрнәкләреннән дә өйрәндем. Ләкин ул чагында әле рус телен бик начар белә идем. Совет власте урнаштырылган беренче елларда, Урта Азия халыклары әдәбиятлары белән чагыштырганда, татар әдәбияты аеруча алга киткән иде. Анда Галимҗан Ибраһимов күренекле урын алып торды. Аның әсәрләрендә барлык социалистик милли әдәбиятлар нигезләнгән принципиаль яңалык бар иде. Һәм бу яңалык минем өчен, башка язучылардагыга караганда, көчлерәк, аңлаешлырак һәм гүзәлрәк яңгырады. Һәм мин Ибраһимовның бер генә әсәрен дә укымый калмадым. Аның һәр сәхифәсе минем өчен бер ачыштай була иде»[1].

Берди Кербабаевның Галимҗан Ибраһимов турында әйткән сүзләрен Совет Көнчыгышы халыкларының бик күп язучылары кабатлый алыр иде. Әмма Галимҗан Ибраһимов һәм Көнчыгыш әдәбиятлары дигән тема бездә әле бик аз өйрәнелгән. Бу юнәлештә И. С. Брагинский, Л. И. Климович, М. И. Багданова, Е. Исмәгыйлов, М. Хәсәнов, Б. Исхаков, Ә. Хаҗиәхмәтов, Ш. Турдыев кебек галимнәр тарафыннан инде бер кадәр эш эшләнде. Ләкин әле бу — беренче адымнар гына.

**Азат Әхмәдуллин,**
филология фәннәре кандидаты

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕ

Әхмәт Фәйзинең «Галимҗан абзый янында» исемле истәлегендә шундый юллар бар:

«Галимҗан абзый театр һәм драматургия мәсьәләләре белән нык кызыксына. Сораша. Үзенең театрны яратканлыгын, драма әсәрләренең тамаша өчен язылуларына карамастан, аларны яратып укыганлыгын сөйли. Аның китапханәсендә классик һәм яңа драматургларның, театр эшчеләренең зур гына әсәрләре, мемуарлары почетлы урында торалар».

Чыннан да, әдип драматургия һәм театр белән даими кызыксынып торган, һәм бу — коры кызыксыну, гади ярату гына да булмый. Ул үз гомерендә бер генә сәхнә әсәре яза, шулай да без Г. Ибраһимовның татар драматургиясен үстерүдә роле зур булды дип әйтә алабыз.

Әдип драматургияне әдәбиятның мөстәкыйль һәм үзенчәлекле бер төре дип карый. Аның сәхнә әсәрләре турындагы карашлары анык бер концепция төсендә Бөек Октябрьга кадәрге чорда ук формалаша. Тарих сәхифәләре шул хакта сөйли.

1915 елның 23 январенда Шәрык клубы сәхнәсендә Фатих Сәйфи-Казанлының

[1] Г. Ибраһимов турында истәлекләр. 331—332 битләр.

«Ямьсез тормыш» исемле пьесасы куела. Г. Ибраһимов әсәр һәм спектакль турында шунда ук рецензия язып чыга [1].

Пьеса рецензент игътибарын, иң әүвәл, үзендәге яңа типлары белән җәлеп итә. Г. Ибраһимов фикеренчә, әсәрдәге ул типлар шул чордагы татар тормышын, татар җәмәгатьчелегенең аерым катлауларын билгеләп алган алдынгы фикерләрне дөрес һәм төгәл чагылдыралар. Халыкка хезмәт итү юлына баскан Мөхәммәт кебек образларның тормышчан булуын рецензент татар хәятенең үзенчәлекләре белән бәйләп аңлата, Саттар, һаҗәр образларының әдәби эшләнешләрендәге кечле якларга туктала.

Әсәрнең идеясе әһәмиятлеме, түгелме, аның төп фикере яңамы-юкмы — Г. Ибраһимов пьесага әнә шул ноктадан карап якын килә. һәм аерым образларны бәяләгәндә ул, иң әүвәл, шул критерийларны күздә тота. Татар халкының башка халыклар белән тигез хокуклы булырга тиешлеге турындагы фикерләрне, Мөхәммәт образы аша уздырыла торган башка фикерләрне ул яклый һәм үстерә.

Драматург Мөхәммәтне милләт, халык өчен җаны-тәне белән көеп йөрүче итеп сурәтләгән, ди рецензент. Бераүләр, «милләт», «халык» сүзен үзләренең шәхси мәнфәгатьләре өчен файдаланырга тырышып, аның белән сату итсәләр, Мөхәммәтнең милли аңы рухының төбенә, тирәнгә яшерелгән. «Халыкка матди азмы-күпме файда итим дигән һәрбер татар — милләтемезнең 90 процентын ясый торган ярлы татар арасына керергә кирәк, ярлылык сәбәпле үрчи алмый торган авыл халкына, эшнең иң авырын эшләп, акчаның иң азын ала торган завод-фабрика халкына, көн уздыру кайгысыннан котыла алмый торган шәһәр әһелесенә үзләренең кеше икәнен аңлатырга кирәк, аларның бүтән милләт кешеләре белән тигез яшәргә хаклары бар икәнен төшендерергә кирәк». Мөхәммәтнең төп максаты менә шул. һәм шул идеяне уздырганы өчен, Г. Ибраһимов аны татар әдәбияты өчен яңа, кирәкле һәм файдалы образ дип саный.

Пьесаның гомуми әһәмиятен билгеләгәндә Г. Ибраһимов аның сәнгатьчә эшләнешенә дә нык игътибар бирә. Монда әдипнең драматургия законнарын яхшы белеп эш йөртүе күренә. Мәсәлән, ул пьесаның композицион яктан йомшак булуын билгеләп уза. «Пьесаларда... булса да, булмаса да, ярарлык нәрсә урын алмаска тиеш,— дип яза Г. Ибраһимов. — Пьеса шундый бер калыпка куелган булсын ки, аның бер җирен төшерү яки киметү өйнең бер почмагын җимереп алу дәрәҗәсендә хис ителерлек булсын». Пьесадагы һәр нәрсә бер юнәлешкә, төп фикерне ачуга хезмәт итәргә тиеш — Г. Ибраһимов драма әсәренә әнә шундый таләпләр куя.

Пьесаның үзенә тулы һәм тирән бәя бирү белән бергә, әдип аның сәхнәгә куелышына карата да игътибарга лаек фикерләр әйтә. Ул артистларның уеннары турында, аерым рольләрнең башкарылу дәрәҗәсе хакында төпле сүз йөртә, дөрес искәрмәләр ясый.

Г. Ибраһимов гаҗәеп ныклык белән һәм эзлекле төстә әдәбиятның идея сафлыгы өчен көрәшә. Моңар мисалларны аның Октябрьгача булган тәнкыйтеннән үк күпләп китерергә мөмкин. Мәсәлән, «Тормыш» газетасының 1915 елгы 26 февраль санында аның «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләсе басыла. Исеменә караганда, сүз анда аерым бер әсәр хакында гына барырга тиеш иде кебек. Ләкин тәнкыйтьче соңыннан ак эмигрант булып киткән Г. Исхакыйның бөтен иҗатына тирән анализ ясый: бу кешенең анык бер мәсләге булмавын күрсәтә, аның әсәрләрендәге идея буталчыклыгын ачып сала. Чыннан да, буржуаз табигате һәм идея тотнаксызлыгы Г. Исхакины олы сынау көннәре — Октябрь социалистик революциясе җиткәч каршы як лагерьга алып чыга, аны хезмәт иясенең кан дошманына әверелдерә. Шул рәвешчә, тормыш Г. Ибраһимовның хаклы булуын тулысынча раслый.

Әлеге мәкаләдә сәнгать әсәрендәге персонажлар, типлар һәм типиклык турында кызыклы фикерләр бар. Аның бу мәсьәләләргә карашын тулырак аңлату өчен, бер өзек китерик:

«...Татар шәкерте, татар мулласы, татар сәүдәгәрләре бар,— ди әдип.— Татар шәкерте яки татар сәүдәгәре эчендә бик наданы, галимрәге, бик бае, бәхетлесе, бәхетсезе булырга мөмкин. Аларның һәрбер кешесе — үзенә бер хәят, аерым бер шәхес. Ләкин язмышлары тәэсире белән шул бер сыйныфта төрле «аерым шәхесләр»нең

[1] «Йолдыз» газетасы, 1915 ел, 25 январь.

һәммәсе, һич булмаса, күбе арасында уртак булган сыйфатлар бар. Мөхәррир бер шәхесне, мисле бер Габдене ала да, аның шәхес хәяте эчендә бөтен сыйнфыйны галәм[1] булып шәкертлегеннән, яки сәүдәгәрлегеннән килгән сыйнфый язмышын, сыйнфый сыйфатларын тәҗәссем иттерә[2]. Сәүдәгәр сыйныфының шәхесендә без аның бөтен сыйныфына галәм булган язмышын табабыз.

Менә шулай эшләнсә, аны әдәби галәмдә тип дип атыйлар».

Шушы карашка таянып, әдип татар тормышында соңгы вакытларда мәйданга чыккан мөгаллимәләрнең характерлы сыйфатларын күрсәтеп бирә, аларның авыр эш шартлары хакында, алар яшәгән мөхит һәм шул шартлар тәэсирендә барлыкка килгән психологик үзенчәлекләре турында сүз йөртә. Әнә шул ноктадан карап «Мөгаллимә» пьесасындагы образларны бик нык тәнкыйть итә.

«Мөхәррир я матур вә мәгънәле хыял язсын, яки үзенең тугры тасвиры белән тормышның авыр җәрәхәтләреннән берен укучы алдына ачып салып, шул хакта уйларга, авыр язмышны җиңеләйтү турында чаралар күрә башларга — һич булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга салырга мәҗбүр итсен», — ди ул.

Г. Ибраһимовның шундый характердагы принципиаль чыгышлары татар драматургиясенең һәм гомумән татар әдәбиятының реализм һәм халыкчанлык нигезләрендә үсүе өчен ныклы җирлек хәзерли. Әгәр дә бу мәкаләнең революция алды елларында, ягъни әдәбиятта реализмга, халыкчанлыкка хилафлык очраклары күбәйгән бер чорда язылган булуын да истә тотсак, аның кыйммәте тагын да арта төшүен күрербез.

Бөек Октябрьдан соң драматургиянең яңа нигезләрдә үсәргә тиешлеген әдип иң беренчеләрдән булып аңлый. Бик гыйбрәтле факт: аның революциядән соң иҗат иткән иң беренче оригиналь сәхнә әсәре — «Яңа кешеләр» исемле драма була. Бу, күрәсең, тикмәгә түгел. «Чөнки әдип, — дип яза бу турыда М. Хәсәнов, — тормыш һәм көрәш темпы гаять көчле бер чорда гади бер повесть яки хикәянең әле берничә кеше тарафыннан укылып өлгергәнче, пьесаның сәхнәдә инде йөзләрчә тамашачылар тарафыннан каралачагын яхшы белә иде»[3]. Шуның белән бергә, мәсьәләнең икенче ягы да бар: революциянең беренче елларында татар театрларының репертуарлары шактый чуар була. Аннан соң әле генә сәнгатькә һәм әдәбиятка якынайган хезмәт иясе массаның күпчелеге грамотасыз булуын да хәтердән чыгарырга ярамый. Театрның халыкны тәрбияләүдәге мөһим роленә һәр вакыт югары бәя биреп килгән язучы, әлбәттә, революцион репертуарны булдыруга кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша.

«Яңа кешеләр» 1920 елның көзендә язылып тәмамлана һәм, Бөек Октябрь бәйрәменә багышлап, шул ук елның 8 ноябрендә сәхнәгә куела. Җәмәгатьчелек спектакльне түземсезлек белән көтеп ала һәм шактый җылы каршылый. Тәнкыйтьче Галә Ходаяров аны «инкыйлап әдәбияты нигезендә зур бер таш буларга ярарлык» әсәр дип саный[4]. Драма шулай ук хәзерге әдәбият гыйлемендә дә югары бәя алды. Г. Ибраһимов иҗатын җентекләп өйрәнгән күренекле әдәбият галиме Гали Халит, мәсәлән: «Бу пьеса татар драматургиясендә социалистик революция темасына багышланган әсәрләр арасында күренекле урын алды», — дип язды[5].

Социалистик революция тормышның һәрбер өлкәсенә яңалык алып килә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне баштанаяк үзгәртеп кора, кешеләрнең үзләрен яңарта. Революция чын мәгънәсендә яңа кешеләр, яңа геройлар барлыкка китерә. Аларны яңа әдәбиятта чагылдыру, андый геройлардагы иң күркәм сыйфатларны шигырь һәм җырда олылау, сәхнәдә сурәтләү иң актуаль бурычларның берсе булып көн тәртибенә баса. Шуңа күрә дә алдынгы язучылар революцион үзгәрешләрне эстетик күзаллауларын бер урынга — заман каһарманын гәүдәләндергән образда туплап бирергә омтылалар. Азатлык сугышында катнашу һәм революцион эшкә бирелгәнлек андый уңай геройны билгеләүдәге төп сыйфат итеп алына.

---

[1] Галәм — билге.
[2] Тәҗәссем иттерә — гәүдәләндерә.
[3] М. Хәсәнов. Галимҗан Ибраһимов. Казан, 1964 ел, 142 бит.
[4] «Эшче» газетасы (Мәскәү), 1920 ел, 16 ноябрь.
[5] История татарской советской литературы. Рус телендә, Мәскәү, 1965 ел, 153 бит.

Г. Ибраһимов революция тудырган һәм революцияне ясаган көрәшчеләрне «яңа кешеләр» дип атый, яңа дәвернең үзенчәлеген һәм өстенлеген иң әүвәл шундый каһарманнарда күрә. Дөрес, чорның үзәк каршылыгын тәшкил иткән сыйныфлар көрәше әсәрдә драматургик яктан тәмамланган бер үзәк конфликт аркылы чагылмый. Драмага композицион бөтенлек тә җитенкерәми. Андагы эпизодлар — әйтерсең лә гражданнар сугышы вакыйгаларының бер җирдә бүлеп алынган аерым өлеше. Әдипнең драматургия жанрында тәҗрибәсезлеге башка яклардан да үзен сиздерә. Мәсәлән, озын монологлар күп, персонажларның эш-хәрәкәтләре еш кына сәхнәдән тышта калдырыла. Шулай да тәҗрибәле язучы революцион көрәшнең кешеләр язмышына ясаган тәэсирен, бу язмышларның күп төрле вариантларыннан берничәсен шактый ышандырырлык итеп күрсәтеп бирә. «Яңа кешеләр»дә беренче героик-революцион һәм тарихи-революцион драмаларга җитеп бетмәгән нәрсә — образларны индивидуальләштерүдә шактый алга китеш бар. Берсе өстенә икенчесе махсус өелгәндәй тәэсир калдырган дәһшәтле, ләкин таркаурак вакыйгалар үзәгендә Батырхан, Камәр, Зәйния, Тимеркәйләрнең җанлы образлары калкып тора.

Ш. Усманов үзенең сәхнә әсәрләрендә, яңа бер проблеманы күтәреп, революциягә килүнең гаять үзенчәлекле юллары булырга мөмкин икәнлеген куйган иде. Г. Ибраһимов исә, мондый мөмкинлекләрнең төрле вариантларын алып, шуны конкрет образлар ярдәмендә күрсәтә. Батырханның революциягә юлы белән Камәрнең, Тимеркәйнең яки Шәйбәк картның көрәшкә килү юллары һич тә бер-берсенә охшамый. Ләкин күпме генә төрле-төрле булмасын, аларның һәркайсының көрәш юлы тормыш логикасы белән аклана һәм сәнгатьчә ышандыра. Батырхан характерындагы ныклык һәм катылык соңыннан аңа танылган кызыл каһарман булып җитешергә ярдәм итә. Ә Камәрдә һәм Тимеркәйдә, мәсәлән, андый сыйфатларны революцион вакыйгалар тәрбияли. Камәр баштарак үтерү-үтерешүләр турында тыңларга да авырсына. Бераздан канлы көрәш ситуацияләре аны чыныктыра, ләкин моңар карап ул һич тә тупасланмый. Бу кызда кече күңеллелек, ягымлылык дошманнарга карата нәфрәт һәм катылык белән бергә яши.

Революция үз нәүбәтендә Батырхан характерын да баета, аңа яңа үзенчәлекләр өсти. Ул хәзер дошман канына сусаган таш бәгырьле кеше түгел инде. Ул — бер дә юкка кан түгүләргә, җан кыюларга каршы кеше, революцион көрәш тәртипләренә буйсынуны үзенә катгый закон итеп алган, башбаштаклыкка юл куймаучы акыллы җитәкче. Бу яктан аның үсеше күз алдында. Икенче пәрдәдә үз-үзен белешмичә сыйнфый дошманнарын атып үтергән Батырхан соңгы пәрдәдә, гәрчә Камәрне үтерүчеләргә күңелендә нәфрәт ташыса да, самосуд ясаудан тыелып кала, Тимеркәйгә дә андый эш эшләргә ирек куймый.

Алда сөйләгәннәрдән күренгәнчә, язучы бу әсәрендә революция чоры көн тәртибенә куйган тагын бер әһәмиятле мәсьәләне күтәрә. Сүз пролетар гуманизмның асылы хакында бара. Пьесадагы үзәк образлар да, сюжет үстерелеше дә шул проблеманы хәл итүгә буйсындырылган. Моны аерата Шәйбәк карт образы ачык раслый. Бу образда язучы көч куллануга каршы булган, бар нәрсәгә дә яхшылык һәм йомшаклык белән генә ирешергә омтылган диндар кеше тибын күрсәтә. Революция мондыйларның да күзен ача. «Ташка каршы аш белән ат!» дигән беркатлы ышаныч сыйнфый дошманнар белән эш иткәндә яраксыз гына түгел, хәтта зарарлы да икән. Картның «кан түгүгә киткәч, шәп түгел инде ул!» дигән сүзләренә Батырхан «канлы юл — изге юл!» дип, ачыктан-ачык каршы төшә. һәм тормыш, фаҗигале вакыйгалар ярдәмендә, Шәйбәкне көрәшнең корбаннарсыз гына була алмаганлыгына төшендерә. Шулай итеп, әсәр пролетар гуманизмның төп кануннарын дөрес чагылдыра, Шәйбәк кебекләргә революциянең тирәнлеген аңларга, катлаулы сорауларга җавап табарга, кирәксез шик-шөбһәләрне читкә атарга булыша.

«Яңа кешеләр»дә Г. Ибраһимовның әдәби стиленә хас үзенчәлек тә чагыла. Монда да реалистик һәм романтик алымнарның үзара тыгыз катнашмасы — синтезы күзгә ташлана. Гомумән, татар әдәбиятында бу чорда революцион романтизмның торган саен ныграк урын ала баруын күрергә мөмкин. Моны тарихи шартлар, азатлык пафосы, яңарыш омтылышы тудыра. Яңа театр — героик театр төзү бурычын уңышлы хәл итү өчен, драматурглар революцион романтизмның көченә таяналар.

Батырхан образында романтизация геройны башка персонажлардан һәм массадан югарырак, өстенрәк куеп сурәтләүдә ук чагыла. Аның үз сүзләрен әйтү рәвеше, сөйләү стиле үзенчәлекле. Ул хәтта үзен чолгаган кешеләр арасыннан эре гәүдәсе белән дә күтәрелеп, калкып тора. Боларны автор ремаркаларда кат-кат искәртеп бара. Камәр образы шулай ук якты, романтик планда бирелгән: бу кызда көрәш һәм җиңү, бәхетле тормыш төзүгә омтылыш бергә берләшкән. Вакыйгаларны оештыруда ачык контрастлык, дәһшәтне арттыра бару да әсәрнең романтик яңгырашын көчәйтә.

Шул рәвешле, беренче революцион пьесалар арасында «Яңа кешеләр» проблематикасының шактый катлаулы булуы белән аерылып тора. Монда сыйнфый көрәш, гәрчә аның трактовкасы әле шактый ук туры сызыклы булса да, бары тик пафос белән генә, берьяклы гына сурәтләнми инде. Автор аның күп төрле политик, иҗтимагый һәм хәтта этик мотивларын тотып алган. Язучы заманга һәм геройга хас үзенчәлекләрне, төрле катлаулардан чыккан кешеләрнең революция тәэсире астында рухи үсешен сурәтли.

Яшь татар совет театрын дөрес юлдан үстерү өчен барган көрәштә Г. Ибраһимов тәнкыйтьче буларак та якыннан торып катнаша. 1922 елның 22 январенда татар театрында Афзал Таһировның «Янгура» дигән драмасы куела. Г. Ибраһимов әсәрне һәм аның сәхнәгә куелышын кискен тәнкыйтьләп чыга [1]. Ул драма авторын халыклар арасындагы дуслыкны инкарь итүдә һәм зарарлы дини-милли фикерләрне куертып тасвирларга тырышуда гаепли. Г. Ибраһимовның рецензиясен укыгач, А. Таһиров Сәмәркандтан әдипкә хат язып җибәрә. Бу хатны Г. Ибраһимов тулы килеш газетада бастырып чыгара [2]. А. Таһиров аңар «Янгура»ның 1918 елда ук язылган булуын, әмма Оренбургта сәхнәгә куелырга хәзерләнгәндә авторы катнашыннан тыш бөтенләй үзгәртелгән булуын хәбәр итә. «Шуның күчергән нөсхәсеннән берсен үзем күреп хәйран калдым, — дип яза А. Таһиров. — Чөнки күп кешеләр алыштырылып, чеп-чи ялган монологлар өстәлгән. Шул күчерелмәдән бер нөсхәсе Фатих Әмирханда да бар иде. Сездә уйналган «Янгура» әнә шул булырга кирәк» [3].

Г. Ибраһимовка драматургиябезнең идея сафлыгы һәм сәнгатьчә югарылыгы өчен көрәшне нэп елларында бигрәк тә киң җәелдерергә туры килә. «Контрреволюция каберстаныннан күтәрелгән... черек сөрем хәзер инде мәсьәләнең кая баруын (ягъни нэп чорының үзенчәлеген — А. Ә.) аңлап җитмәгән безнең иптәшләр, кайбер язучылар, артистлар, укытучылар арасында да үзенең кара сукмагын салырга, сиздермәстән анда да агуын чәчәргә уйлый», — ди ул. Аның шикләнүләре дөрес булып чыга — төрле урыннарда идея ягыннан тотнаксыз пьесаларны сәхнәләштерү ешая. Чыңгызлар, Мамайлар хакында һәм дини сюжетларга мөрәҗәгать итеп язылган әсәрләр күбәя. «Әгәр дә бер революционер каләменнән үтсә, һәртөрле Чыңгызлар, Әюбиләр, Мөхәммәтләр бөтен мәгънәсе белән тарихтагы сыйнфый, икътисади революция хәрәкәтләрен ачып бирергә ярарлык маузуглардандыр, — дип яза Г. Ибраһимов. — Ләкин, бердән, мондый нәрсәләр хакында язу планнары революционерлар тарафыннан түгел, бәлки, иң азы, «битараф» кешеләр каләменнән чыкканга, аннан да бигрәк, берсе Оренбургта, берсе Казанда, берсе Троицкида, берсе әллә кайда яткан язучыларның берсен-берсе белмәстән, күрмәстән берьюлы шундый маузугларга тотынулары — бу тормышның кайбер җирендәдер, ниндидер бер кара дулкын күтәрелүен, болар шуның җимеше генә икәнен күрсәтә торган галәмәтләр (симптом) дер» [4].

Шуның белән бергә, әдип революцион эчтәлекле яңа әсәрләрне һәм аларның үз вакытында, кичекмәстән сәхнәгә куелуын һәр вакыт яклый һәм хуплый, аларны пропагандалый. Ш. Усманов, Ф. Бурнаш, К. Әмири һ. б. пьесаларын ул үзенең әдәби ел йомгаклары төсендәге хисап мәкаләләрендә, аерым чыгышларында уңай бәяли, бу язучыларның алга үсешенә ярдәмләшә. Мәсәлән, Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр», «Таһир-Зөһрә» әсәрләрен «пролетариат хәрәкәтенең көчле дулкыннары астында, шулар

[1] «Татарстан хәбәрләре» газетасы, 1922 ел, 31 январь.
[2] Шунда ук, 1922 ел, 3 апрель.
[3] Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивындагы Фатих Әмирхан фондында, чыннан да, пьесаның бер нөсхәсе саклана.
[4] «Кызыл шәрык яшьләре» журналы, 1922 ел, 2 сан.

тәэсире белән» дөньяга чыккан пьесалар[1] дип бәяләү белән бергә, ул аларның авторына «үзенең талантын үстерү өчен... ярлы авылларда, кызыл казармаларда, завод-фабрикаларда булу — шунда кайнау, шул рух белән сугарылу» кирәклеген әйтә, яңа тормышны конкретрак белеп язарга киңәш итә[2].

Яңа драматургияне һәм театрны үстерүдә Г. Ибраһимов классикага ышаныч баглый. Бу җәһәттән аның Г. Камал, М. Фәйзи, Г. Коләхметов әсәрләренә мөнәсәбәте характерлы. Әдип Г. Камалның татар әдәбияты тарихында зур урын биләве турында берничә мәртәбәләр язып чыга. Мәсәлән, «Татар әдәбияты хакында тагын бер әсәр» дигән мәкаләсендә ул Җамал Вәлидинең русча чыккан китабында атаклы драматургка тиешле урын бирелмәүне зур җитешсезлек саный. «Г. Камал һәм әдип, һәм журналист, — ди ул. — Аның хезмәте бездә бик зур. Рус җәмәгатьчелеге алдына Г. Фәйзи, Ш. Рәхмәтуллинны китереп утыртып, Г. Камалларны хәтердән чыгару — бу музейга кереп филне күрмәү, әмма әһәмиятсез төймәне дөя иту буладыр»[3]. Икенче бер урында әдип: «Г. Камалның хезмәтләре һәркемгә мәгълүм, аның драмалары, комедияләре татар театрына нигез булды... әдәбият тарихында урыны зур булган кебек, революция матбугатында да аның ихлас хезмәте бар», — дип яза[4].

Г. Ибраһимов беренче татар пролетар язучысы Г. Коләхметовның иҗатына һәм революцион эшчәнлегенә зур бәя бирә, аның драмалары, аларның әдәбиятыбыз тарихында уйнаган рольләре хакында ихтирам белән кат-кат язып чыга. Мисал өчен аның «Беренче марксист әдипнең мәҗмугасе»[5], «Г. Коләхметов большевиклар белән эшләде»[6] дип исемләнгән мәкаләләрен күрсәтү дә җитә.

1922 елда Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасы аерым китап булып басылып чыга. Г. Ибраһимов аңа кереш сүз яза. Әдип әсәрнең татар драматургиясендә тоткан урынын билгели, аның югары идея-эстетик дәрәҗәсен күрсәтә. Үзенең халыкчанлыгы һәм реализмы белән бу әсәр драматургиядә яңа бер юнәлеш, яңа бер мәктәп ача, ди.

Гыйльми үзәк председателе сыйфатында Г. Ибраһимов республикадагы әдәбият-сәнгать эшенә турыдан-туры җитәкчелек итә, бу өлкәдәге бер генә тармак та аның игътибарыннан читтә калмый. Гыйльми үзәк театрларның репертуарын яхшыртуда, конкурслар уздыруда, драма әсәрләрен бастырып таратуда һ. б. зур эшләр башкара. 1925 елның 11 февралендә Гыйльми үзәк «Татар әдәбияты көтепханәсе» төзү мәсьәләсен карый һәм һәрберсе бишәр табактан барлыгы 40 китап чыгару турында карар кабул итә. Бу «Көтепханә» татар әдәбиятының халык авыз иҗатыннан, борынгы әдәбият үрнәкләреннән алып соңгы көннәрдәге язучыларның иҗатларына кадәр булган әдәби мирасны билгеле бер тәртиптә укучыга җиткерергә тиеш була. Шул хакта Гыйльми үзәкнең председателе Г. Ибраһимов һәм секретаре З. Нуркин белдерү белән чыгалар[7]. Монда бу зур басманың конкрет программасы бирелгән. Татар әдәбиятының күренекле вәкилләре рәтендә Г. Камал, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин, М. Фәйзи, Ш. Усманов, Ф. Бурнаш, К. Әмири һ. б. драматургларга да аерым томнар билгеләнгән.

Г. Ибраһимов татар операсының тууына чын күңелдән ярдәм итә. Мәсәлән, «Эшче» операсына нигез итеп М. Гафури поэмасы аның киңәше буенча сайлап алына. 1926 елда татар театрының 20 еллык юбилей бәйрәмен уздыруның киң җәмәгатьчелек яңгырашы алуы өчен ул күп эшли, юбилей кичәсендә татар драматургиясенең һәм театрның үсеш юлларын тирән итеп яктырткан доклад белән чыга.

Менә бу, әле һич тә тулы саналмаган фактлар, мәкаләләр, рецензияләр һәм, ниһаять, «Яңа кешеләр» драмасы Г. Ибраһимовның татар драматургиясе һәм театрына керткән өлеше зур булуы турында сөйлиләр.

---

[1] «Татарстан хәбәрләре», 1922 ел, 31 сан.
[2] Шунда ук, 1921 ел, 96 сан.
[3] «Безнең байрак» газетасы, 1923 ел, 4 апрель.
[4] «Татарстан» газетасы, 1923 ел, 2 сентябрь.
[5] «Татарстан», 1926 ел, 12 январь.
[6] «Атака» журналы, 1931 ел, 1 сан.
[7] «Татарстан», 1925 ел, 8 март.

**Нил Юзиев,**
филология фәннәре докторы

# АКАДЕМИЯНЕҢ 250 нче ӘГЪЗАСЫ...

Галимҗан Ибраһимовның Сәнгать фәннәре академиясенең члены итеп сайлануы турында беренче тапкыр «Кызыл Татарстан» газетасы язып чыга[1]: «Бөек татар әдибе Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык хезмәт бәйрәме уңае белән, Дәүләт сәнгать фәннәре академиясе, әдипнең әдәби-иҗади, шулай ук гыйльми хезмәтләрен тәкъдир итеп, аны шушы академиянең члены иттереп бертавыштан сайлавы турында Татарстан Мәгариф халык комиссариатына Мәскәүдән рәсми кәгазь алынды. Галимҗан Ибраһимов — татарлардан академия члены дәрәҗәсен алган беренче гыйльми эшче».

Соңыннан бу хәбәрне республиканың башка матбугат органнары күчереп баса. Галимҗан Ибраһимовның Сәнгать фәннәре академиясенә сайлануы әдипнең үзе өчен дә, Татарстан республикасы һәм татар халкы өчен дә шатлыклы һәм истәлекле вакыйгага әйләнә.

Галимҗан Ибраһимовның академия члены итеп сайлануы хак икән, аның турындагы мәгълүматлар да шул ук академия архивында сакланырга тиеш бит инде. Эзләнүләрне академиянең үзен һәм аның архивын ачыклаудан башладык.

СССР Художество академиясе белән Сәнгать фәннәре дәүләт академиясе икесе ике чорда оешкан һәм бер-берләреннән нык кына аерылып торган фәнни оешмалар булып чыкты. СССР Художество академиясе 1947 елда гына төзелә. Үзеннән-үзе аңлашыла ки, әлеге академия архивында безне кызыксындырган мәгълүматлар була алмый. Кала ГАХН (Государственная академия художественных наук) архивы. Сәнгать фәннәре дәүләт академиясе фәнни-тикшеренү учреждениесе буларак 1921 елда оештырылган икән. Төп максаты — әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге фәнни-тикшеренү эшләрен оештыру. Аның әдәбият белеме, музыка белеме, сынлы сәнгать белеме, театр белеме, кино белеме буенча махсус бүлекләре булган. Академия үз тирәсенә шушы өлкәләрдә эшләүче күренекле галимнәрне берләштергән, зур оештыру эшләре алып барган. 1931 елда ул Сәнгать белеме дәүләт академиясе (Государственная академия искусствознания) булып үзгәртелгән. 30 нчы елларның ахырында аның эшчәнлек даирәсе тагы да тарайган — Ленинградка күчерелеп, Театр һәм музыка фәнни-тикшеренү дәүләт институты булып калган.

Сәнгать фәннәре дәүләт академиясенең архив фонды Ленинградта түгел, ә Мәскәүдә Үзәк дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивында сакланган булып чыкты. Шул архивтагы материаллар белән танышканда, без 250 нче делога юлыктык[2]. Аның тышына «Личное дело Ибрагимова Галимжана. Начато 13 января 1928 года» дип язылган.

Шул елларның җанлы эзләрен саклаган документларны зур дулкынлану белән укый башлыйбыз. Менә күренекле әдәбият галиме, юбилей комиссиясе члены Габдрахман Сәгъдинең Сәнгать фәннәре дәүләт академиясенең президенты профессор П. С. Коганга адресланган хаты. Ул 1927 елның 16 декабрендә язылган. Бу хат, безнеңчә, берничә яктан әһәмияткә ия. Беренчедән, ул 20 нче елларда рус һәм татар әдәбиятчылары арасында яшәп килгән иҗади дуслык турында сөйли. Г. Сәгъди хатының баштагы өлеше шуңа яңа бер дәлил була ала.

---

[1] 1928 ел, 29 январь саны.
[2] Үзәк дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивы (ЦГАЛИ). 941 фонд. 10 тасвирлама, 250 эш.

«Сезнең хатыгызны һәм аның белән бергә рус әдәбияты тарихы буенча язган гаять тә кыйммәтле хезмәтегезне алуым белән бик тә шатмын. Хезмәтегезне аеруча бер ләззәтләнү, канәгатьләнү хисе белән укып чыктым. Аны укыганнан соң бу хезмәтнең миңа Октябрьдән соңгы чор татар әдәбияты тарихын төзегәндә гомуми фәнни характердагы зур чыганак буларак бөтен кыйммәте тагы да ачыла төште».

Хатта П. С. Коган хезмәтенең исеме аталмаган. Сүз нинди хезмәт турында бара— әйтүе кыен. Бу елларда танылган әдәбият галименең рус совет әдәбиятына караган ике китабы басыла. Аларның берсе — «Пролетарская литература» (1924), икенчесе — «Литература Великого Х-летия» (1928) исемле китаплар. Г. Сәгъди хаты 1927 елның ахырында язылган, димәк, П. С. Коганның икенче китабы әле чыгып өлгермәгән була. Шулай ук авторның 1924 елны чыккан беренче китабын җибәрүенә дә ышанып бетәсе килми, чөнки бу вакытта инде андагы күп кенә фикерләр искергән, тәнкыйтьләнгән була. Күрәсең, П. С. Коган татар галименә китабын түгел, ә шул вакытларда басылган берәр хезмәтен җибәргәндер. Хатның үзендә сүз китап турында түгел, ә рус әдәбияты тарихы буенча язылган яңа хезмәт турында бара.

Г. Сәгъди хатының Г. Ибраһимов юбилеена багышланган өлешендә дә татар әдәбиятчысы белән рус галиме арасындагы якын һәм дусларча җылы мөнәсәбәтне бик ачык тоярга мөмкин:

«Сезгә билгеле булган Галимҗан Ибраһимовның иҗтимагый-әдәби эшчәнлегенә 20 ел тулу уңае белән Татарстан республикасының Мәгариф халык комиссариаты махсус дәүләт комиссиясе төзеде. Комиссия юбилейны үткәрүгә хәзерлек эшен башлады да инде. Бу юбилей шушы елның март аенда, аның беренче яртысында үткәреләчәк. Юбилейны үткәрү буенча дәүләт комиссиясе тарафыннан Галимҗан Ибраһимовны Сәнгать фәннәре академиясенә тәкъдим итү турында — аны академиянең члены итеп сайлау өчен — карар чыгарылды. Озакламыйча Сез әлеге рекомендацияне алырсыз, бу турыда мин Сезгә алданрак хәбәр итәргә кирәк дип санадым. Үземнең шәхси фикерем буенча да, бөтен татар җәмәгатьчелегенең фикере буенча да Галимҗан Ибраһимов Сәнгать фәннәре академиясенең члены итеп раслануга бик тә лаеклы. Ул, бер яктан, классик татар язучысы, икенче яктан, әдәбият галиме. Галимҗан Ибраһимов татар әдәбияты тарихын һәм әдәбият теориясен марксистик нигездә эшләүгә күп хезмәт һәм көч куйды, бу өлкәдә кыйммәтле күп хезмәтләр бирде. Татарстан республикасы дәүләт комиссиясенең әлеге тәкъдиме Сезнең тарафтан тиешле бер булышлыкка очрар дигән ныклы ышаныч белән калам.

Сезне ихлас күңелдән хөрмәтләүче — **Г. Сәгъди**».

Документлар арасында ТАССР Мәгариф халык комиссариатының Г. Ибраһимовны Сәнгать фәннәре дәүләт академиясенә член итеп тәкъдим иткән хаты да бар. 1928 елның 5 январенда язылган ул хатка юбилей комиссиясе председателе, ТАССРның Мәгариф халык комиссары Н. Мөхетдинов, Гыйльми үзәк председателе М. Таһиров, Гыйльми үзәкнең гыйльми секретаре М. Фазлуллиннар кул куйган. Анда Г. Ибраһимовның төрле өлкәдәге эшчәнлеге күрсәтелә. «Татарстан республикасының Мәгариф халык комиссариаты,— диелә ахырдан,— Галимҗан Ибраһимовның югарыда саналып үтелгән зур хезмәтләрен искә алып, аны Сәнгать фәннәре академиясенә тәкъдим итүне зарури дип таба һәм аны Сәнгать фәннәре академиясенең члены итеп раслау турында Сезнең алда үтенеч кузгата».

Сәнгать фәннәре дәүләт академиясенең җитәкчелеге, шул исәптән аның президенты П. С. Коган Татарстан партия, совет оешмаларының һәм галимнәренең Галимҗан Ибраһимовны академиягә член итеп тәкъдим итүләрен хуплап каршы алалар һәм бу мәсьәләне озакка сузмыйча хәл итеп тә куялар. «Дело»да шул турыда сөйләүче документлар теркәлгән:

«СССР халыклары сәнгатен өйрәнү бүлеге президиумының 1928 ел, 12 январьда үткән утырыш беркетмәсе.

Катнашалар: П. С. Коган, Б. М. Соколов, Ю. А. Самарин.

Тыңланды: Татар әдибе Галимҗан Ибраһимов кандидатурасын академиянең почетлы әгъзасы итеп сайлау турында.

Карар: Г. Ибраһимов кандидатурасын бик урынлы дип хупларга һәм Гыйльми советта раслатуга куярга.

Председатель: **Б. М. Соколов».**

Күрәсез, Г. Ибраһимов академиянең СССР халыклары сәнгатен өйрәнү бүлеге буенча тәкъдим ителә. Бүлек белән күренекле галимнәрдән торган президиум җитәкчелек иткән. П. С. Коган, Б. М. Соколов, Ю. А. Самарин — шул чорның күренекле, авторитетлы галимнәре.

СССР халыклары сәнгатен өйрәнү бүлегенең карары нигезендә Г. Ибраһимовны академиянең почетлы әгъзасы итеп сайлау турындагы мәсьәлә 13 январьда академиянең Гыйльми советында карала. Советны, гадәттәгечә, П. С. Коган алып бара. Мәсьәләне тикшерүнең тулы барышы, кызганычка каршы, сакланмаган. «Дело»га кыскача беркетмәнең күчермәсе генә теркәлгән:

«Дәүләт сәнгать фәннәре академиясе Гыйльми советының 1928 ел, 13 январьда үткән утырыш беркетмәсенең (№ 179) күчермәсе.

Председатель: **П. С. Коган.**

Гыйльми секретарь: **А. А. Сидоров.**

Секретарь: **Л. П. Копейкина.**

Тыңланды: СССР халыклары сәнгатен өйрәнү бүлеге буенча Г. Ибраһимовны член-корреспондент итеп сайлау турында.

Карар: Кабул итәргә һәм конференция раславына тапшырырга».

5 нче биттә кара белән кулдан язылган түбәндәге язу бар: «1928 елның 13 январенда (протокол № 179—§ 7) СССР халыклары сәнгатен өйрәнү бүлегенең член-корреспонденты булып расланды».

Г. Ибраһимовны академиягә сайлауга кагылышлы кәгазьләр арасында бер документ игътибарны үзенә аеруча нык җәлеп итә. Ул — Сәнгать фәннәре академиясенә әдипнең үз кулы белән язылган хат:

«Сәнгать фәннәре дәүләт академиясенә.

Минем Сәнгать фәннәре дәүләт академиясенә сайлануым турында Сезнең 1928 елның 25 январенда җибәргән 108 номерлы хәбәрегезне алдым. Мине шулай олылавыгыз өчен бөтен академиягә гаять тә тирән рәхмәт хисләремне белдерүемне үземнең бурычым саныйм. Хәзергесе вакытта (1927 елның апреленнән) Ялта шәһәрендә климатик дәваланып ятам — миндә каверналы үпкә туберкулезы. Минем быелгы академик елда Сәнгать фәннәре дәүләт академиясенә доклад укырга баруым тулысы белән дәвалануның барышы һәм сәламәтләнүемнең темпы белән бәйле. Беренче мөмкинлек булу белән шәхсән доклад сөйләүне үземнең бурычым саныйм.

Сезнең хатыгызга җавабымны соңга калып язам, чөнки Сезнең тарафтан миңа дип җибәргән хәбәрегезне Татарстан республикасы аша шушы көннәрдә генә алдым.

Хөрмәт белән: **Галимҗан Ибраһимов.**

*Ялта, Барятинская, 5.*

20 февраль, 1928 ел».

Әлеге хаттан күренгәнчә, Сәнгать фәннәре дәүләт академиясенә сайлануы турындагы хәбәр әдипкә 1928 елның 25 январенда җибәрелгән. Тик аңа ничек дип хәбәр иттеләр икән — академиянең почетлы члены дипме, член-корреспонденты дипме? Табылган архив материаллары бу мәсьәләгә дә өлешчә ачыклык кертергә булышалар.

Сәнгать фәннәре дәүләт академиясенең составы действительный членнардан һәм член-корреспондентлардан торган. Документлардан күренгәнчә, Г. Ибраһимов член-корреспондент итеп расланган. Академия әгъзаларының сайлану процедурасы ягын-

нан икенче төрле аерымлыклары да булган: гадәти членнар һәм почетлы членнар. Почетлы әгъзалар итеп әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә аеруча зур казанышларга ирешкән әдәбият һәм сәнгать әһелләре сайланган. Г. Ибраһимов — әнә шундыйлардан.

Академиягә сайланганнар академия әгъзалары алдында фәнни доклад сөйләргә тиеш булганнар. Хаттан аңлашылганча, әдипкә дә шул турыда хәбәр иткәннәр һәм доклад уку өчен Мәскәүгә чакырганнар. Архивта Г. Ибраһимовның академиядә доклад укуына кагылышлы документ очрамады — көчле авыруы әдипкә андый мөмкинлек бирмәве мәгълүм нәрсә.

Галимҗан Ибраһимовның шәхси эше барысы 60 биттән тора. Баштагы 8 битте — әдипне академиягә сайлауга бәйле документлар, хатлар. 9 нчы биттән Г. Ибраһимовның иҗатына кагылышлы материаллар башлана. Шулардан 5 биттә, мәсәлән, әдипнең язган әсәрләренең библиографиясе һәм алар турындагы рецензияләр исемлеге китерелгән. Болардан соң 32 биттә язучының әсәрләренә басылган һәртөрле рецензияләрдән өзекләр бирелгән. Өченче төр материаллар — Г. Ибраһимов документларының күчермәләре (алар 7 бит урынны алып тора). Боларның барысын да Гөлсем Мөхәмәдова төзегән, оештырган икәнлеге әйтелгән. Иң ахырдагы 8 биттә Г. Ибраһимовның автобиографиясе теркәлгән [1].

Шунысын да әйтеп узарга кирәктер, «Автобиография» академия өчен махсус язылмаган. Г. Ибраһимов үзе билгеләгәнчә, 7 битлек ул автобиография райком өчен 1924—25 елларда төзелгән, ә өстәмәләр 1927 елда теркәлгән. Райком өчен язылуы автобиографиянең эчтәлегеннән дә күренеп тора: әдәби һәм фәнни эшчәнлегенә караганда, әдип күбрәк үзенең революцион эшчәнлеге, социалист-революционерлар партиясе белән ничек араны өзүе, коммунистлар партиясенә ничек керүе турында җентекләп яза.

Соңгы 8 нче биттә автобиографиягә Г. Ибраһимовның үз кулы белән язган өстәмәсе бар. Аны тулысы белән китереп үтәбез:

> «Бу автобиография 1924—25 елларда төзелгән иде. Авыруым турындагы өстәмә генә 1927 елга туры килә. Шуңа күрә берничә сүз белән генә булса да түбәндәге өстәмәләрне кертү кирәк:
>
> 1) Семья хәлем турында: 1924 елның 28 июнендә Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студенткасы Өммегөлсем Давыдовна Мөхәммәтовага өйләндем. 1926 елның 5 ноябрендә улым туды, аның исеме — Рөстәм.
>
> 2) 1925 елның сентябрендә мин Казанның фәнни делегациясе председателе сыйфатында Бөтенсоюз Фәннәр академиясенең 200 еллыгы уңае белән үткәрелгән тантаналарда катнашу өчен Татарстан республикасы хөкүмәте тарафыннан Ленинградка һәм Мәскәүгә командировкага җибәрелгән идем.
>
> 3) 1926 елның февралендә Татарстан республикасы делегациясе председателе булып Бакуга, Беренче тюркология съездына бардым. Бу съездның президиум члены булдым, «Төрки телләрнең орфографиясе» дигән темага доклад ясадым.
>
> 4) 1926 елның ахырларында, бигрәк тә 1927 елның мартында аспирацион пневмониянең авыр формасы белән һәм III стадиядәге үпкә туберкулезы белән каты авырдым. Уң үпкәдә ике каверна. Шуның нәтиҗәсендә Татреспублика совнаркомы карары буенча озак вакытлы климатик дәвалану өчен Кырымга җибәрелдем, хәзерге вакытта гаиләм белән шунда яшим. Һәртөрле эш докторлар тарафыннан тыела».

Академиянең 250 нче әгъзасының эш кәгазьләренә менә нинди материаллар тупланган булып чыкты. Язучының фәнни биографиясен ачыклауда аларның да күпмедер дәрәҗәдә әһәмиятләре булса кирәк.

---

[1] Бу автобиография «Азат хатын» журналының 1967 елгы 2 санында басылды.

Ринат Мөхәммәдиев



# ҖАВАПЛЫЛЫК ХИСЕ

*Г. Ибраһимовның татар әдәби тәнкыйтен формалаштырудагы роле*

Вакытлы матбугат битләрендә Галимҗан Ибраһимовның беренче тәнкыйть мәкаләләре 1910 елда күренә башлый. «Күренә башлый» дип кенә әйтү, мөгаен, бик үк дөрес тә булмас. Чөнки әдәби тәнкыйть мәйданына ул кыяр-кыймас атлап йөргән тәҗрибәсез кеше булып түгел, иҗат көче ташып торган гайрәтле ир, зур талант буларак килеп керә һәм беренче хезмәтләре белән үк Г. Тукай, Ф. Әмирхан кебек замандашлары сафына кушыла.

Әмма шул кадәресен дә истән чыгарырга ярамый, әдәби тәнкыйтьнең төп бурычларын, аерым алганда, әдәбиятның заман тормышына һәм иҗтимагый процесска мөнәсәбәтен аңлау мәсьәләсендә Г. Ибраһимов зур һәм катлаулы үсеш юлы үтә. Әлеге әһәмиятле мәсьәләгә мөнәсәбәтен ул тәнкыйть эшчәнлегенең беренче адымнарында ук белдереп чыга. Бу яктан аның «Рус мөхәррирләреннән мәшһүр интикатчы В. Г. Белинский җәнаблары хакында» дип исемләнгән мәкаләсе аеруча характерлы. М. Хәсәнов бик дөрес билгеләп үткәнчә: «Г. Ибраһимовның әдәбият мәйданына аяк баскан елларында ук язган мәкаләләренең берсе бөек рус тәнкыйтьчесе В. Г. Белинский иҗатына багышланган булуы бер дә очраклы хәл түгел. Моның белән ул үзенең иҗат юнәлешен билгели» [1].

Билгеле булганча, «Әдәби хыяллар» дип исемләнгән тәүге мәкаләсендә В. Г. Белинский, әдәбият җәмгыять тормышының асылын чагылдырырга тиеш, дигән эстетик таләпне күтәреп чыга. Шуннан соңгы иҗат эшчәнлегендә күпме генә үзгәрешләр кичермәсен, ул шул фикеренә һәрчак турылыклы булып кала. Татар тәнкыйтендә Белинский принципларын күтәреп чыккан Г. Ибраһимовка бу факт аеруча әһәмиятле булып күренә. һәм ул үзе дә, әдәби-эстетик карашлары нинди генә каршылыкларга очраса да, әдәбиятның шул ягына игътибарын киметми. Әдәби әсәрләрне ул чынбарлыктагы тормыш вакыйгалары белән бәйләп карарга тырыша.

К. Бәкернең «Җанлы курчаклар» әсәре уңае белән 1912 елда язылган рецензиясендә тәнкыйтьче реалистик әдәбиятның капиталистик җәмгыятьтәге барлык контрастларны кискен фаш итеп чыгарга тиешлегенә басым ясый. Капиталистик чынбарлыкка хас һәм аның нигезен тәшкил иткән тигезсезлекләрнең асылы нидән гыйбарәт?. Аны әнә шундый характердагы сораулар борчый. «Татар шагыйрьләре» исемле хезмәтендә Г. Ибраһимов экономик һәм политик тигезсезлекләрнең соңгы чиккә җитүен, халык массаларының яшәү «шартлары һаман да кыенлаша» баруын «хәзерге капиталның бер кулга җыелу»ы белән аңлата. Сүз уңаеннан шуны да искә алып үтәргә кирәк, «Йолдыз», «Вакыт кебек газеталарның шул елларда чыккан саннарын актарганда, Казан һәм Оренбург губерналарында үтерү, талау, мораль таркалу һәм фахишәлек фактлары турындагы хәбәрләр өзлексез очрап тора. Боларның һәркайсы капиталистик чынбарлык тудырган күренешләр булуы бәрәүгә дә сер түгел. Ләкин «Дин вә мәгыйшәт» кебек матбугат органнары аларны диннән читләшү һәм шәригатьне ихтирам итмәү белән бәйләп аңлатырга тырышсалар, буржуаз милләтчеләр исә, шул фактларга таянып, татар һәм рус хезмәт ияләре арасында ныгып барган бердәмлек һәм туганлык хисләрен какшатырга маташалар. Менә шул чорда Г. Ибраһимов: «Дөньяга кызганыч фахишәлекне тудыруда нә татарлык, нә руслык гаепле — ул тормышның хәзергечә капитал вә милеккә корылган булуыннан килгән бер һәлакәттер»,— дип чыга.

[1] Г. Ибраһимовның «Әдәбият мәсьәләләре»нә сүз башы. Казан, 1960 ел, 10 бит.

Г. Ибраһимов үзенең тәнкыйть хезмәтләрендә әдәбиятның тормышка мөнәсәбәте, иҗтимагый тормыштагы роле һәм идеялелеге кебек мәсьәләләргә аеруча зур игътибар бирә. Аның фикеренчә, әдәбият, бигрәк тә романнар, кызык өчен, укып, көлеп тә ахырында ташлар өчен генә язылмый һәм язылмаска тиешле. Анда мөхәррирнең әйтергә теләгән бер... күренеше, халык һәр көн күреп, сөйләп тә сизми кичкән мөһим вә хас бер мәгънә була»[1]. Игътибар итегез, җөмләнең башында ук «әдәбият» диюгә тәнкыйтьче «бигрәк тә романнар» дип конкретлаштыруны кирәк саный. Бу бер дә очраклы хәл түгел. Менә шушы кечкенә генә детальдә Г. Ибраһимов эстетикасының эзләнүләр чорына хас булган һәм аның Октябрьга кадәрге тәнкыйть эшчәнлеген (бигрәк тә Г. Тукай иҗаты уңае белән әйтелгән тәнкыйть фикерләрен) дөрес бәяләүдә шактый кыенлыклар тудырган каршылыкларның иң зурысы чагылып китә дә инде. Әле генә әдәбият һәм сәнгатьнең иҗтимагый бурычларын беренче планга куйган, «әсәрләр күк әмере белән язылмый. Алар эчендә яшәгән мохитларының табигый ихтыяҗына җавап буларак, шуны кирәксенә башлау тәэсире белән туалар»[2],— дип язган тәнкыйтьченең шигырьләргә идеалистик эстетика таләпләреннән чыгып якын килүе шактый сәер һәм гаҗәп күренеш булып тоела. Ләкин, шуңарга да карамастан, тәнкыйтьчене эклектизмда яисә принципсызлыкта гаепләү хата булыр иде. Әлеге каршылыклар, беренчедән, эзләнүләр җимеше булып, тәнкыйтьченең Көнбатыш Европа һәм рус эстетикларына иярүе белән аңлатыла иде. Икенчедән, әдәбият төшенчәсенә беренче чиратта проза әсәрләрен генә кертеп, ул шигырьне бу төшенчәдән күпмедер дәрәҗәдә югарырак торган жанр итеп карый.

Г. Ибраһимовның әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә һәм хезмәтләрендә 1915 нче елларга кадәр үзен сиздереп килгән каршылыклар татар әдәби-эстетик фикеренең үсеше процессында туган каршылыкларның бер чагылышы иде. Г. Халит «Халыкчан һәм тормышчан сәнгать өчен» исемле мәкаләсендә[3] XX йөз башы татар әдәби-эстетик фикерендә туры мәгънәсендә реализмга юнәлеш, реализм белән романтизмның якынлыгын табарга теләү һәм фәкать милли романтизмны гына өстен итәргә тырышу кебек тенденцияләр яшәвен күрсәтә. Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатындагы тәнкыйть принциплары исә, барыннан да бигрәк, бу юнәлешләрнең икенчесенә якын тора. Аның күпчелек тәнкыйть мәкаләләрендә без романтик идеал белән реаль чынбарлык арасында барган тартышуның ачык мисалын күрәбез. Шулай да бу конфликт ничек хәл ителде соң? Сүз дә юк, әдәбият белгече буларак, Г. Ибраһимов өзлексез үсә бара, аның тәнкыйть мәкаләләрендә һәм рецензияләрендә революцион-демократик карашлар өстенлек итә, тәнкыйтьче турыдан-туры әдәбият һәм сәнгатьнең халык тормышына мөнәсәбәте һәм иҗтимагый роле кебек проблемаларны да күтәреп чыга башлый. Әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын социаль мәсьәләләргә юнәлдереп, ул «Мөхәррир... үзенең тугры тасвиры белән тормышның авыр җәрәхәтләреннән берен укучы алдына ачып салып, халыкны шул хакта уйларга, авыр язмышларын җиңеләйтү турында чаралар күрә башларга, һич булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга салырга мәҗбүр итсен! Әдәбияттагы реализмның бердәнбер әһәмияте фәкать шул ноктададыр»[4],— дип яза.

1914—1916 нчы елларда язылган күпчелек мәкаләләрендә инде Г. Ибраһимов әдәби әсәрләрнең иҗтимагый кыйммәтен аларда күтәрелгән мәсьәләләрнең актуальлегеннән чыгып аңлата башлый. Аның фикеренчә, әдәбият һәм сәнгать чынбарлыкны ничек бар шул хәлендә чагылдыручы гади көзге генә түгел, ә бәлки азатлык һәм прогрессив идеяләр өчен көрәш мәйданы да булып тора. Бу елларда ул теге яки бу язучы үз әсәрләрендә нинди генә вакыйгаларны тасвир итмәсен, аның иҗатында дөньяга карашы тәэсирендә формалашкан бер төп юнәлеш һәм иҗтимагый-политик максат булырга тиеш дигән нәтиҗәгә килә. Һәм мондый нәтиҗәгә килүе очраклы хәл дә түгел. Тәнкыйтьче әдәбият һәм сәнгатьнең асылын аңлауда ышанычлы позициягә баса. «Реальный әсәрләр генә түгел, иң мөхаль хыяллар да башка фәкать тышкы дөньяның тәэсире белән генә киләләр, — ди ул. — Сәнаигъ табигать вә хәятның туп-туры үзеннән мөтәэсир булырга да шуны махсус таланты белән кәгазь-

[1] «Йолдыз» газетасы, 1912 ел, 865 сан.
[2] «Аң» журналы, 1913 ел, 23 сан.
[3] «Казан утлары» журналы, 1971 ел, 12 сан, 159 бит.
[4] «Тормыш» газетасы, 1915 ел, 195 сан.

тә төшерергә тиешле»[1]. Бу юллар инде тәнкыйтьченең эстетик карашлары реализмга таба борылуы турында гына түгел, үзенең бөтен энергиясен тормышчан һәм реалистик әдәбият өчен көрәшкә багышлавы турында да сөйли.

Әдәби тәнкыйть өчен зур әһәмияте булган гүзәллек категориясен аңлауга да Г. Ибраһимов нигездә материалистик эстетика кысаларыннан чыгып якын килә. Әдәбият һәм сәнгатьтәге гүзәллек төшенчәсе тормыштагы гүзәллек белән турыдан-туры бәйләнештә һәм элемтәдә булса да, алар арасына тигезлек билгесе куеп булмый. Гүзәллек категориясенең шушы үзенчәлегенә аеруча җитди игътибар биреп килгән татар тәнкыйтьчеләренең берсе Г. Ибраһимов була. Тормыштагы гүзәллек сәнгатьтә инде сыйфат ягыннан бөтенләй яңа формада чагыла. Язучы һәм шагыйрь әдәби әсәрдә чынбарлыкны ничек бар шулай тасвирлап барырга тиеш түгелләр. Коры акыл сатудан, үгет-нәсихәттән торган дидактик шигырьләр белән килешә алмыйча, ул болай дип яза: шагыйрьдән «киңәш, рәһбәрлек көтелми, бәлки авызыннан хәсән, җәмал коелуы теләнәдер. Ул безгә назик вә мөәссир хисләр, гали моң, матур ләүхәләр түксен! Безгә гади күренгән нәрсәләрне бөтенләй башкача итеп күз алдыбызга салсын»[2]. Монда сүз күк галәмендәге хыялый матурлык турында түгел, ә бәлки, тәнкыйтьче үзе искәртеп киткәнчә, «безгә гади күренгән нәрсәләр»нең матурлыгы, реаль чынбарлык турында бара. Шуңа күрә тәнкыйтьченең талант һәм сәнгатьчәлек, әдәбият һәм сәнгатьнең спецификасы мәсьәләләрен күтәреп чыгуын идеалистик «сәнгать — сәнгать өчен» теориясенә авышу дип аңларга ярамый. Аның әдәби иҗат эшенең әлеге якларына аеруча әһәмият бирүе бик аңлашыла. Шул ук вакытта Г. Ибраһимов, әдәбият һәм сәнгатьтәге гүзәллек белән мавыгып китеп, тормыш матурлыгын икенче планда калдырды дип санау һич кенә дә дөрес булмас иде. Мисал өчен Ф. Әмирханның «Хәят» повестена багышланган рецензиясенә тукталып үтик. «Фатих әфәнде, — дип яза тәнкыйтьче, — сәнгать вә каләм йөртергә осталык илә, табигый агымны, каләмнең табигый барышын күмеп ташлый, ягъни сәнгать табигатьне җиңә. Бу исә реальныйлыкны дәгъвә иткән әдипкә мактаулы сыйфат түгел»[3].

Шулай итеп, Г. Ибраһимов фикеренчә, әдәбият һәм сәнгатьтәге гүзәллекнең кыйммәте, беренче чиратта, аның тормыш дәрәслегенә якынлыгы белән билгеләнә. Нинди генә әсәр язмасыннар, шагыйрь һәм язучы тормышка һәм реаль чынбарлыкка үзләренең эстетик идеаллары һәм гүзәллекне аңлау критерийларыннан чыгып мөрәҗәгать итәргә мәҗбүрләр. һәм, ниһаять, ул чын гүзәллекне тормышның үзеннән эзләргә кирәк дигән карашка килә. Бу мәсьәләне аңлауда Г. Ибраһимов бөек рус тәнкыйтьчесе Н. Г. Чернышевскийның «Чын гүзәллек — тормыш үзе» дигән концепциясенә бик тә якын тора.

Г. Ибраһимовның реализм өчен көрәшнең алгы сафында барырлык тәнкыйтьче булып җитлегүен аның әдәби типлар һәм типиклык турындагы карашлары да бик ачык раслый. Бу яктан әдипнең «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» дип исемләнгән мәкаләсе аеруча игътибарга лаек[4]. Тәнкыйтьченең типиклыкны аңлатуында В. Г. Белинский хезмәтләренең тәэсире сизелеп тора.

XX йөз башыннан татар әдәбияты һәм сәнгате үсешендә кискен борылыш һәм яңарыш чоры башлана. Мондый шартларда татар тәнкыйте һәм әдәби-эстетик фикере дә үз кабыгына гына төренеп, милли рамкалар белән генә чикләнеп кала алмый иде. Әдәби җәмәгатьчелек һәм тәнкыйть алдына дөнья әдәбиятының идея-эстетик байлыгын һәм прогрессив традицияләрен тирәнтен үзләштерү бурычы килеп баса. Ләкин бу мәсьәлә җиңел генә хәл ителми. Ул дәвердә кайбер тәнкыйтьчеләр Көнчыгыш (шәрык) һәм Көнбатыш (гарәп) әдәбиятларын бер-берсенә каршы куеп, аларның я берсен, я икенчесен генә кабул итәргә мөмкин дигән фикерне алга сөрәләр. Шулай да Шәрыкны Гарепкә каршы кую тенденциясе әллә ни зур яңгыраш

---

[1] «Йолдыз» газетасы, 1914 ел, 1158 сан.
[2] «Йолдыз», 1911 ел, 644 сан.
[3] «Йолдыз», 1911 ел, 757 сан.
[4] А. Әхмәдуллинның шушы санда басылган «Галимҗан Ибраһимов һәм татар драматургиясе» исемле мәкаләсен карагыз.

ала алмый. Дөнья әдәбияты классикларының һәм бигрәк тә рус реалистик әдәбиятының алдынгы традицияләрен һәм әдәби-эстетик фикерләрен кабул итүгә зур әһәмият биргән Г. Ибраһимов мәкаләләре безгә шул хакта сөйли. «Киләчәк көнебезнең яктыруы өчен Гарәп әдәбияты белән файдалануыбыз никадәрле лязим булса, шул нисбәттә үк, безгә Шәрыкның үткәне белән дә танышырга, Шәрык даһиларының хикмәт вә шигырьләре белән дә азыкланырга тиеш,— дип яза ул.— ... Гомер, Данте, Шекспир кебек Гарәп классиклары илә янәшә утыртып, алларына бердәй тезләнергә фарыз булган Шәрык даһиларын хәтергә ала башларга вакыттыр дип уйлыйм... Татар йөрәгенә «Илиада»лар, «Илаһи комедия»ләр белән бергә гарәпнең Мәгарри, Фирдәүсинең «Шаһнамә»ләре, Сәгъди белән Фозулиның «Гөлстан» вә «Ләйлә-Мәҗнүн»нәре кереп утырырга, шуңа күрә боларны тәрҗемә вә нашер кыйлырга... бик тиешледер»[1]. Дөнья әдәбиятыннан зур мәгълүматлы әдип буларак, Г. Ибраһимов Шәрык һәм Гарәп әдәбиятларын бер-берсенә каршы куюдан ерак тора. Ул татар әдәбиятының үсеше өчен боларның һәр икесен дә өйрәнергә һәм уңай якларын үзләштерергә кирәк дип саный. Рус һәм Көнбатыш әдәбиятлары аны үзләренең дөньяви һәм реалистик традицияләре белән кызыксындырса, Көнчыгыш поэзиясенең классик үрнәкләрендә тәнкыйтьче кешенең зурлыгына, гүзәллегенә дан җырлауны күрә. Шәрык һәм Гарәп әдәбиятлары чынбарлыкка мөнәсәбәтләре, фәлсәфи эчтәлекләре һәм сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләре белән бер-берсеннән нык аерылалар, билгеле. Ләкин шул ук вакытта алар бер-берсен тулыландырып та киләләр, дөнья әдәбияты дигән уртак төшенчәне тәшкил итәләр. Ибраһимов Октябрь революциясенә кадәрге чорда ук дөнья әдәбиятын, менә шул рәвешчә, бер бөтен итеп кабул итә. Аның, татар тәнкыйтендә беренчеләрдән булып, «дөнья әдәбияты» терминын кулллануын да билгеләп үтәргә кирәк. (Сүз терминны стихияле төстә генә түгел, ә аңлы рәвештә һәм үз урынында куллану турында бара.) «Безгә гакыл вә фикеребезне гомум бәни адәм офыгына таба юнәлдерергә...,— дип яза ул,— кыскача әйткәндә, татар әдәбиятыннан үтеп, **бөтен дөнья әдәбиятының** (курсив безнеке — Р. М.) тарихи агымнары белән дә танышырга лязим булачак»[2]. Болар татар әдәбиятының үсеше өчен дөнья әдәбияты казанышларын өйрәнүнең нинди әһәмияткә ия булуын тирән аңлап әйтелгән, Шәрык һәм Гарәп әдәбиятларын бер-берсенә каршы кую кебек зарарлы тенденцияләрдән югары торып әйтелгән сүзләр була.

Гомумән, дөнья әдәбиятын өйрәнү мәсьәләсе гамәлгә куелганда, барыннан да элек, милли әдәбиятның офыкларын киңәйтү бурычы күздә тотыла. Ләкин XX йөз башында рус әдәбиятына мөнәсәбәттә мәсьәләнең бу ягы икенче пландарак кала. Тәнкыйть рус әдәбиятын — тормышчанлык һәм халыкчанлык юлыннан үсеп килүче әдәбият һәм милли сәнгать өчен олы бер мәктәп итеп кабул итә. Прогрессив карашлы тәнкыйтьчеләр татар әдәбиятында реализм формалашуны, материалистик эстетика принципларының ныгуын рус әдәбиятын өйрәнү һәм рус революцион-демократик фикерләрен кабул итү белән бәйләп аңлаталар.

Рус әдәбияты дигәндә, Г. Ибраһимовның иң элек Пушкин, Гоголь, Тургенев, Лермонтов, Горький, Андреев кебек әдип һәм шагыйрьләрне күз алдында тотуы бер дә очраклы хәл түгел. Рус реалистик әдәбияты классикларына «ихтирам казандырган... нәрсә — фәлсәфә сату, ул кирәк-бу кирәк дип язу булмыйча, хакыйкый мәгънәсе илә язылган роман, хикәя, драм, шигырьләр идеге дә мәгълүм бит. Нигә без шул хәлне күрмибез?»[3] — дигән сорау куя тәнкыйтьче. Бу — татар әдәбиятының да, рус әдәбияты кебек үк, реализм һәм халыкчанлык юлыннан үсәргә тиешлеген яклап чыгу иде.

Г. Ибраһимов «Яңа әдәбият хакындагы тәнкыйтьләр мөнәсәбәте илә» дип исемләнгән мәкаләсендә әлеге мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайта, рус әдәбиятының үз эчендә берничә юнәлеш булуын искәртеп үтә. Менә шуңа күрә рус әдәбиятына мөнәсәбәт аңарга сукырларча табынуга кайтып калмаска, ә бәлки аңлы һәм планлы рәвештә өйрәнү һәм кабул итүдән гыйбарәт булырга тиеш, дип саный тәнкыйтьче.

Ибраһимовның «Каһарман шагыйрь» исемле мәкаләсе башка әдәбиятларга әлеге таләптән чыгып якын килүнең характерлы мисалы булып тора. Сүз анда, билгеле

---

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан, 1960 ел, 101—102 битләр.
[2] Шунда ук, 100—101 битләр.
[3] Шунда ук, 35 бит.

булганча, украин халкының мәшһүр шагыйре Тарас Григорьевич Шевченко турында бара. «Мин аны каһарман, дим. Шагыйрь генә димим... Ул — хөррият каһарманы»,— дип яза Г. Ибраһимов. Күрәсез, әдип Шевченконы, барыннан да элек, хөррият каһарманы, патша самодержавиесе тарафыннан изелгән һәм кимсетелгән халыкның тарихи идеалларын җырлаучы буларак күтәрә. һәм бу очраклы хәл түгел. Тәнкыйтьче каһарман шагыйрьнең һәм бөтен Украина халкының язмышында татар халкының тормыш шартларына зур якынлык күрә. «Ятимнәр бер-берен тиз аңлыйлар,— дип дәвам итә ул. — Шевченконың халкы белән безнең татарның язмышында күп уртак нәрсә бар. Шевченконың йөрәгендә кайнаган, әле бу көндәге малорус мөтәфәккирләренең җанын әрнеткән күп дәрт вә хәсрәтләр бездә, безнең татарда да бар...» Менә шундый охшашлыклардан чыгып, ул Т. Г. Шевченко иҗатын өйрәнүнең татар әдәбияты өчен зур әһәмияткә ия булуын раслый.

Бу елларда рус һәм башка халыклар әдәбияты һәм аларның эстетик фикерләрен өйрәнүдән чыгып, әдәбият алдында гына түгел, әдәби тәнкыйть алдында да конкрет, яңа бурычлар куела. Г. Ибраһимовның югарыда искә алынган «Рус мөхәррирләреннән мәшһүр интикатчы В. Г. Белинский җәнаблары хакында» дигән мәкаләсе — шуның матур бер үрнәге. Гомумән, ул рус әдәбиятын үзләштерүнең милли әдәбият һәм культураның үсеше, иҗтимагый-политик һәм әдәби-эстетик фикерләрнең формалашуы өчен котылгысыз бер шарт булуын тирән аңлый, әдәбият һәм сәнгать алдында торган практик мәсьәләләрне рус әдәбиятының реалистик традицияләренә таянып хәл итүне яклап чыга. Шул мәсьәләгә тукталып, тәнкыйтьче Бөек Октябрь революциясеннән соңгы хезмәтләренең берсендә болай дип яза: «Бу мәдәният (рус культурасы — Р. М.) бик күп яктан безгә остаз була килде. Безнең яңаруыбыз, безнең әдәбиятыбыз, безнең гыйлемнәребез, безнең революция хәрәкәтләребез һәммәсе бу рус мәдәниятенең бик нык тәэсире һәм мөгаллимлеге астында үстеләр. Икътисади, сәяси яктан без бөтенләй диярлек береккәнбез» [1].

Дөнья әдәбиятын өйрәнү мәсьәләсе, билгеле булганча, тәрҗемә эшен активлаштырудан башка карала алмый. Менә шул хакыйкатьне тирәнтен аңлап, Г. Ибраһимов татар әдәбиятында тәрҗемә эшенең торышына даими төстә игътибарын юнәлтеп килә. Ул 1910 елда ук «Йолдыз»да «Тәрҗемә һәм аның шартлары» исемле мәкалә белән чыга, әдәби тәрҗемәләрнең татар әдәбиятының үсеше өчен никадәр зарур булуын күрсәтә һәм, әдәби тәнкыйтебездә беренчеләрдән булып, тәрҗемәчеләр алдында конкрет бурычлар һәм таләпләр куя. Мәкаләнең заманы өчен нинди зур әһәмияткә ия булуын әйтеп тормастан, сүз уңаеннан шуны гына билгеләп үтәргә кирәк, Г. Ибраһимовның тәрҗемәләр алдында куелган югары таләпләре әле бүген дә үзләренең актуальлекләрен югалтмаган.

1914 елда С. Сүнчәләй тәрҗемәсендә Г. Гейненың «Әльмансур»ы басылып чыга. Шул уңай белән вакытлы матбугат битләрендә тәрҗемә принциплары турында җитди һәм файдалы бәхәс башланып китә. С. Сүнчәләй, әсәрне «миллиләштерәм» дип, урыны-урыны белән оригиналга үзгәрешләр кертә, төрле характердагы төгәлсезлекләр җибәрә. Берәүләр моны тәрҗемәченең кыюлыгы һәм уңышы итеп күрсәтергә тырыша (мәсәлән, З. Кадыйри мәкаләсе, «Тормыш» газетасы, 1914 ел, 22—23 саннар), икенчеләре исә, шуннан чыгып, әлеге тәрҗемәнең әһәмиятен бөтенләй юкка чыгарырга тырышалар (мәсәлән, Ф. Сәйфи-Казанлы, «Аң» журналы, 1914 ел, 5 сан.) Менә шундый шартларда мәсьәләгә Г. Ибраһимов ачыклык кертә. Тәрҗемәче, барыннан да элек, оригиналга тугры булып калырга тиеш. Авторның, «миллиләштерәм» дип, төрлечә үзгәртүләрен тәнкыйтьче гафу итәргә мөмкин булмаган зур хата дип саный. Ләкин шуның белән бергә, Ф. Сәйфи-Казанлыдан аермалы буларак, ул тәрҗемәчегә артык кискен бәрелүне дә кирәк дип тапмый. Монда Г. Ибраһимовның тәнкыйтьче буларак үзенчәлекле бер сыйфаты ачылып китә, ул башлап язучыларга мөнәсәбәттә таләпчәнлек белән теләктәшлекнең органик бөтенлегенә омтыла.

С. Сүнчәләйнең өметле яшь шагыйрь булуын истә тотып, Г. Ибраһимов «Әльмансур» тәрҗемәсенең (әсәр турыдан-туры немец телендәге оригиналыннан тәрҗемә ителгән) кичерергә мөмкин булмаган кимчелекләрен күрсәтү белән бергә, тәрҗемәченең уңышларын күрсәтүгә дә күп урын бирә һәм аңа тәрҗемә өлкәсендә

---

[1] Г. Ибраһимов. Кара маяклар яки ак әдәбиятлар. Казан, 1924 ел, 24 бит.

зур өметләр баглый. Тәнкыйтьченең ул өметләре тулысынча акланды дияргә була. Татар укучылары Пушкин һәм Лермонтовның күп кенә әсәрләрен беренче тапкыр С. Сүнчәләй тәрҗемәсендә укыйлар, безгә шулай ук аның Байронның «Шильон тоткыны» һәм А. М. Горькийның «Тормыш төбендә» әсәрләрен тәрҗемә итүе билгеле.

Г. Ибраһимовның тәнкыйть мирасы үзенең гаять киң колачлы булуы белән аерылып тора. Аның иҗатында әдәбият мәсьәләләре белән бер үк дәрәҗәдә милли театр, рәсем һәм музыка сәнгате, әдәби тел һәм вакытлы матбугат алдында торган проблемалар да күтәрелә. Әдипнең бу җитди хезмәтләре әле яңадан кайтып-кайтып өйрәнелергә лаек мирас булып тора.

Тәнкыйтьченең иҗат колачы турында сүз чыккан икән, аның даими төстә басылып килгән, еллык әдәбият һәм матбугатны анализлауга багышланган хезмәтләрен искә алмый үтү мөмкин түгел (Г. Ибраһимов башлаган бу матур традиция — әдәби ел йомгаклары ясау — әдәбиятыбызда бүген дә дәвам итә). Г. Ибраһимовның әдәби ел йомгаклары — татар әдәбиятының үзенчәлекле елъязмасын хәтерләтәләр. Алар белән эзлекле рәвештә танышып чыгу XX йөз башы татар әдәбиятының күп кенә үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итә, танылган язучы һәм шагыйрьләребезнең иҗат эволюцияләрен күз алдына китереп бастыра. Тәнкыйтьче ул мәкаләләрендә язучы һәм шагыйрьләрнең уңышын күреп чын күңелдән куана, ә җитешмәгән яклары өчен тирән борчуга төшә. Мәсәлән, М. Гафури иҗатының кара реакция елларында сүлпәнләнеп китүе 1911 елга йомгак ясаганда аны уйга калдыра. Критик реализм методын үзләштерә барып, бераздан М. Гафури укучыларны яңадан үзенең уңышлы әсәрләре белән куандыра башлый. Билгеле, бу күренеш тә тәнкыйтьче игътибарын читләп узмый. 1913 елга йомгак рәвешендә язылган «Матбугат вә әдәбиятыбызның барышы» дип исемләнгән мәкаләдә ул моңа үзенең куануын белдереп уза.

Г. Ибраһимов әдәбиятка килүче һәр яңа авторны үзенең тәнкыйть иләге аша уздыра тора. Әдәбиятның киләчәге яшьләр кулында булуны тирәнтен аңлап, ул яшь әдипләр, журналистлар иҗатына, бер яктан, югары таләпләр белән килсә, икенче яктан, аларга мөнәсәбәттә бик сак һәм яхшы теләктә булырга омтыла. Шул уңайдан 1915 елда «Йолдыз» газетасында басылган «Яңа әсәрләр, яңа имзалар һәм яшь куәтләр» мәкаләсе аеруча гыйбрәтле. Бу мәкаләдә, Ш. Камал һәм С. Сүнчәләй иҗатына ясалган принципиаль һәм объектив анализ белән бергә, тәнкыйтьче ике яшь журналист Г. Баймбәтов һәм И. Биккуловлар иҗатына туктала. Г. Ибраһимовка бигрәк тә Гыйлемдар Баймбәтовның киләчәге өметле тоела һәм ул аны «оригиналь каләме булган авыл журналисты» дип атый.

Г. Ибраһимовның әдәби тәнкыйть эшчәнлеге замандашлары тарафыннан да югары бәяләнә. Таләпчән замандашлары арасында аны «әдәбиятыбызның бердәнбер тәнкыйтьчесе» дип санаучылар була. Аның туры сүзле, принципиаль шәхес, тирән анализ остасы булуы матбугат битләрендә кабат-кабат билгеләнелеп үтелә. Аңарга хәтта, язучылыгын ташлап, бары тик тәнкыйть эшчәнлеге белән генә шөгыльләнергә киңәш итүчеләр дә була. Бәхәссез ки, болар һәркайсы — Г. Ибраһимовның әдәби тәнкыйтебез тарихында кабатланмас бер урын тотуы турында сөйли торган фактлар.

Г. Ибраһимовның Бөек Октябрьга кадәрге актив тәнкыйть эшчәнлеге нибарысы алты ел вакытны үз эченә ала. Ләкин тәнкыйтьченең эше еллар белән генә үлчәнми, аның иҗаты үзенең колачы, иҗтимагый активлыгы һәм фикер тирәнлеге белән хәйран калдыра.

XX йөз башы татар әдәбияты өчен зур әһәмияткә ия булып та, Г. Ибраһимов тәнкыйтендә ачык чагылмый калган мәсьәләләр, мөгаен, юктыр. Чөнки ул бөтен бер әдәбият язмышы өчен үзен җаваплы хис иткән олы җанлы, югары зәвыклы принципиаль тәнкыйтьче була. Менә шуңа күрә аның тәнкыйте конкрет заман рамкалары белән генә чикләнми, Г. Ибраһимов яклаган әдәби-эстетик карашларның төп өлеше бүген дә үзләренең әһәмиятен һәм актуальлеген югалтмый, аның мирасы, әдәби тәнкыйтебезнең үзәк тамыры буларак, һаман да яшәвендә дәвам итә. Биредә сүз Г. Ибраһимовның татар әдәби тәнкыйте формалашу чорындагы, Бөек Октябрь революциясенә кадәрге эшчәнлеге турында гына барды. Әлбәттә, революция Г. Ибраһимов алдында, язучы буларак кына түгел, тәнкыйтьче буларак та гаять зур мөмкинлекләр тудырды һәм ул татар совет әдәби тәнкыйтен башлап җибәрүче тәнкыйтьчеләрнең беренчесе иде.

Габделхәй Әхәтов,
филология фәннәре докторы



# ЯЗУЧЫ ФРАЗЕОЛОГИЯСЕНЕҢ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Язучы-художник, нинди генә әсәр иҗат итмәсен, халык теленең бөтен мөмкинлекләреннән киң һәм оста файдаланырга тырыша. Ул бигрәк тә сүзлек байлыгына, аның саф чишмәдәй чылтырап аккан, күңелләргә ятышлы сүзләренә, гасырлар дәвамында халык сөйләмендә чарланып шомарган канатлы тәгъбирләренә, мәкальләргә һәм әйтемнәргә, образлы фразеологик әйләнмәләргә мөрәҗәгать итә. Кыскасы, язучы тел өстендә эшләүгә әйтеп бетергесез күп көч түгә.

Чыннан да, ни өчен әдипләр телгә шулай нык игътибар итәләр, сүз сайлауга, яңа әйтемнәр куллануга зур әһәмият бирәләр соң? Бу сорауларга җавап табу, сәнгать әсәрләренең телен өйрәнү теоретик һәм практик яктан ифрат кыйммәтле бер эш санала.

Кызганычка каршы, татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган бөек язучыбыз Галимҗан Ибраһимовның тел-стиль үзенчәлекләре, шул җөмләдән фразеологик фонды кул тимәгән өлкә булып кала килә дип әйтерлек. Ә бит ул художник буларак татар әдәби теле лексикасы арсеналында булган бай чаралар белән искиткеч оста эш иткән, хикәя, роман төзелешенә яңа стиль керткән, яңа буяулар салган язучы! Туган телебезгә ул һәр вакыт ихтирам һәм хөрмәт белән караган, аңа саклык күрсәткән, халык теленең бай һәм күпьяклы сүзлек катламнарында энҗе бөртекләредәй яшеренеп ятучы кыйммәтле сүз һәм тәгъбирләрне үзенең хикәя һәм романнарында гаять дәрәҗәдә урынлы һәм, әйтергә кирәк, новаторларча файдаланган.

Телебезнең фразеологиясен иҗади куллану ягыннан Галимҗан Ибраһимовның романнары аерата игътибарга лаек.

Мәсәлән, мәшһүр әдипнең СССР халыкларының Үзәк нәшрияты тарафыннан 1924 елда Мәскәүдә бастырып чыгарылган «Казакъ кызы» романындагы фразеологик әйләнмәләргә генә игътибарны юнәлтсәк тә, без гаять кыйммәтле тел хәзинәсенә тап булырбыз. Бу роман Г. Ибраһимов иҗатында аерым урын били. Ул язучының башка халыкларның тормыш-көнкүреше, язмышы белән, интернациональ темалар һәм проблемалар белән турыдан-туры кызыксынуын күрсәтеп тора.

Мәгълүм булганча, романда XIX йөзнең ахыры һәм XX йөзнең башларындагы социаль-экономик үзгәрешләр җирлегендә күчмә казакъ кабиләләренең тормышяшәеше сурәтләнә. Автор дала тормышының киң панорамасын яктырта, реалистик картиналарда халык массаларының аңында барган тирән үзгәрешләрне ача, төрле социаль катлам вәкилләре образларының тулы бер галереясен тудыра.

Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» романы белән үзенең чын-чыннан классик язучы һәм олы сүз остасы булуын раслады. Романдагы образларны, вакыйгаларны сурәтләүдә ул телебезнең алтын фондыннан — фразеологиясеннән үрнәк булырлык оста файдалана. Берничә мисал китерик.

Карлыгач-Сылуның Арсланбайга булган саф мәхәббәте, аның эчке кичерешләре «йөрәк» сүзе белән ясалган фразеологик әйләнмә аша тасвирланып бирелә:

«Шул вакыт ишек ачыла, ялгыз бер егет килеп керә. Бүз балалар, сылулар арасында кайнашып йөргән бер акын, тора биреп, кунак егетне мактый башлый. Кыз аңа күз ташлый: озынча төз буй, яңа сызылып килгән куе кара мыек, маңгайга таба

бераз киңәеп килгән акыллы йөз, билдә кәмәр, кулда камчы. **Яшь йөрәккә ут төшә,** мәгәр танымады, кем дип сорарга кыймады, сүз әйтергә теле бармады...»[1]

Искә төшереп үтәргә кирәк, «йөрәк» сүзе белән ясалган фразеологик әйләнмәләр татар халкында элек-электән кешеләрнең интим кичерешләрен, гыйшык-мәхәббәт тоту, сөешүләрен сурәтләү чарасы буларак кулланылган: йөрәк яну, йөрәк ярсу, йөрәк өзелү, йөрәккә ут салу, йөрәк тилпенү, йөрәк серен серләшү, йөрәк ялкынлану, йөрәкне телем-телем кисү һ. б. Күренүенчә, Г. Ибраһимов «йөрәккә ут төшү» дигән яңа, эмоциональ-экспрессив яктан көчлерәк әйләнмә кулланган.

Байтүрәнең халыкны вәхшиләрчә изүе Биремҗан әкә авызыннан әйтелгән түбәндәге фразеологик әйләнмәләр ярдәмендә тәгъбир ителә:

«— Илчегә үлем юк, мин сиңа шелтә кылмыйм, мәгәр,— диде,— син Байтүрәгә әйт: адәм баласы кулы белән эшләгәнне муены белән күтәрергә тиешле! Илгә **таш чәчте, кан агызды,** әгәр болар бугазына утырса, үз чәчкәннәрем үсте дип белсен!!!» (279—280 битләр.) «Аңарчы дәшми утырган кунак егет Арсланбай да сүзгә кушылды:

— Байгышның туфрагы авыр булыр, үз **йөрәгенә күп адәмнең күз яшен йоткан иде!**— диде» (325 бит).

Китерелгән мисаллардагы **таш чәчте, кан агызды, йөрәгенә күп адәмнең күз яшен йоткан иде** кебек тәгъбирләр Байтүрәнең кем булуын, эчке сыйфатларын әнә шулай кискен һәм калку итеп күз алдына бастыра.

Җолкынбайның Сарсымбай йортында интегеп, кыйналып яшәве «аркам күп камчы ашады» (378), ә тукалның ял күрмичә көне-төне эшләве «күземә йокым керми» (326) дигән фразеологизмнар белән бик уңышлы сурәтләнә.

Романдагы фразеологик әйләнмәләр, образлы сөйләм стилен тудыру белән бергә, катлаулы мәгънәләр алып килләләр, персонажларны характерлауга булышлык итәләр.

Әдип үз әсәрендә, сүзтезмә калыбы белән ясалган фразеологик әйләнмәләрдән тыш, җөмлә тибындагы фразеологизмнардан да иркен файдалана. Мәсәлән, йөрәк кайнау, йөз кату, йөрәк парчалану, йөз суыну, күздә ут уйнау, тел бәйләнү, күзне кан басу, күңел кату, күңел сыну кебек әйләнмәләр әнә шундыйлардан.

Галимҗан Ибраһимов бер мәгънәне бирү өчен төрле урында төрле фразеологик әйләнмәләр куллана. Андыйларны синонимик фразеологизмнар дип атарга була. Мәсәлән, татар телендә «күз» сүзе ярдәмендә ясалган фразеологик тәгъбирләр йөзгә җитә. Романда да без бер үк тәгъбирнең кат-кат кулланылуын очратмыйбыз: «Ишектән аягын атлауга тирмәнең эчендәге байлыкка, кирәгә буйлап тезелгән буяулы сандыкларга, кат-кат өелгән атлас юрганнарга, хәтфә келәмнәргә **күзләрен йөртте...»** (271); «Тирмәдән далага **күз ташлауга,** аның алдына кайнап торган җәйләү килде: әйтерсең штаб тирәсен сырып алган миллионлы гаскәр!» (273); «...күршедән берничә казакъ, көпеләрен җилкәләренә салып, акрын, сабыр атлап, казаннан табакка сосылган итнең чамасына **күз төшереп,** уртадагы өлкән өйгә керделәр» (320); «Еракта ак таң беленә башлагач, үз урынына күчеп ятыр алдыннан, кызның үтенүе буенча, бәйләүдәге ала айгырга **күз салу** өчен чыккан иде» (331) һ. б.

«Сүз», «тел» төшенчәләре белән бәйләнешле әйләнмәләрне алып карасак та, шундый ук хәлне күрербез: **«Каршы әйтергә** йөрәгем җитмәде... Гомеремдә бер мәртәбә **авызым ябылды»** (285); «Куркып, агарып молла килеп керде. Нидер әйтмәк булса да, **теле бәйләнде»** (330); «Айбала һушыннан китә язы, **телен югалтты,** сердәшенең беләгенә тотынды...» (264); «Ләкин кунаклар **телләрен тешләделәр,** алар, үзләренең шәрәфен саклау белән бергә, гауга чыгармыйча бетерү ягындалар иде» (389); «Егет берничә мәртәбә сорарга дип **авыз ачса да,** өлкән адәм үзе әйтмәгәч, батырчылык кыла алмады» (285); «Каршы **тел әйтергә** ни амалым бар?» (328); «Эчүнең исәбе-саны булмады, кымыз күбрәк китерелгән саен, башлар җиңеләя, күзләрдә ут уйный, **телләр чәчәнләшә** бара иде» (350); «— Атлары Сарсымбайныкына охшый... Түрдә утырганы Биремҗан аксакал имәсме?— дип, **сүз ташлады»** (335); «Шуның белән **сүз киселде»** (292).

Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романында, фразеологик әйләнмәләрдән тыш, метафоралар, метанимияләр, синекдохалар, чагыштырулар, сынландырулар,

---

[1] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. Казан, 1956 ел, II том, 295 бит. Барлык мисаллар шул томнан алынды. Алга таба битләре генә күрсәтеп барылачак.

эпитетлар, мәкальләр һәм әйтемнәр, казакъ теле сүзләре, казакъ халкына гына хас әйтелмәләр дә киң урын алып тора. Аларны җентекләп өйрәнү язучының тел-стиль үзенчәлекләрен ачуда шулай ук әһәмиятле.

Фразеологик әйләнмәләр, халыкның образлы фикерләү дәрәҗәсен билгеләүче тел берәмлекләреннән берсе буларак, матур әдәбият әсәрләрендә тел-сурәтләү чараларының иң катлаулыларыннан һәм шул ук вакытта иң тәэсирлеләреннән, тойгылыларыннан, үткеннәреннән һәм үтемлеләреннән исәпләнәләр. Алар художестволы әсәр стиленә сәнгатьлелек бирүдә, фикерне ачыграк итеп җиткерүдә гаять әһәмиятле роль уйныйлар, образларны, вакыйгаларны сиземлерәк, тулырак итеп ачалар, әсәр теленең халыкчанлыгын, гадилеген, аһәңле яңгырашын тәэмин итәләр. Аларның мәгънә җегәрлеге теләсә нинди сүзнекенә караганда икеләтә-өчләтә көчлерәк була. Галимҗан Ибраһимов — бу мөмкинлекләрдән иркен файдаланган бөек язучы.

**Суфиян Поварисов,**
филология фәннәре кандидаты

## ТЕЛ ДИҢГЕЗЕ

Диңгезне беренче күргәч, хәйран калып, озак-озак карап торганым хәтердә. Эссе көн иде. Күккә карыйм — очсыз-кырыйсыз зәп-зәңгәр һава. Диңгезгә карыйм — очсыз-кырыйсыз зәп-зәңгәр җәймә. Җил юк. Диңгез тын. Серле. Күңелгә әллә нинди уйлар килә: ниләр бар икән аның төбендә?...

Телне дә халык әнә шундый очсыз-кырыйсыз диңгезгә охшата. «Тел дигән диңгез бар, төбендә энҗе-мәрҗән бар, эзләгәннәр чумып алыр, эзләмәгән коры калыр», ди.

Г. Ибраһимовның беренче томын тәүге тапкыр кулга алгач, тел диңгезе төбендәге энҗе-мәрҗән искә төште. Әдипнең теле бай булуы, әсәрләренең йөрәк ялкыны белән язылганлыгы хакында кем генә белми! Менә шуңа күрә бай тел диңгезенә тизрәк чумасы, дулкыннарына колач салып йөзәсе килә. Шундый хис белән «Яз башы»н ничек укып чыкканымны сизми дә калдым. Укып чыктым да томны янә күкрәгемә кыстым — тирән уйга чумдым: чыннан да, менә кайда икән тел диңгезе!

Юк, тел диңгезе әле халыкта. Халык аны баласыдай кадерләп үстерә, күренексез, тупас җирләрен шомарта; баладагы алама гадәтне гел-гел каккалап торган кебек, телдәге ятышсыз күренешләрне рәхимсез рәвештә алып ыргыта. Тел һаман инсафлана бара; халыкның үзенчә әйтсәк, диңгездәге энҗе-мәрҗәнгә әйләнә. Язучы шул диңгезгә чума. Энҗе-мәрҗәннәрне җыеп, әдәби әсәр иҗат итә. Г. Ибраһимовның беренче хикәясендә сүзләр әнә, ничектер, җай гына, диңгез дулкыны кебек тирбәлеп тора, алар бер-бер артлы синең күңелеңә шифа булып ятып бара кебек. Лексик-фразеологик состав та бай, язучының үзенә генә хас сурәтләү чаралары, поэтик бизәк тә күп. Гадәттә елганы зәңгәр тасмага охшаталар. Г. Ибраһимов үз авылы яныннан аккан елга агышын назлы кыз йөрешенә охшата: «Бу киң вә **дулкынлы үлән диңгезенең** нәкъ уртасыннан **назлы кыз йөреше кеби** боргаланып-боргаланып аккан елга үзенең **көмештәй ялтыраган тәсе** белән бөтен тирә-якның күркен әллә ничә кат арттырып җибәрә». Мәдрәсәдән кайткан малай туган авылының табигатенә әнә шулай йөрәге белән сөеп, яратып, гашыйк булып карый. Авторда шундый асыл сыйфат, кайнар хис-тойгы, табигатьнең эчке матурлыкларына мөкиббәнлек булмаса, елга агышын назлы кыз йөрешенә охшатып ләззәтләнмәс иде. **Табигать йөрәге** дигән фразаны Г. Ибраһимов күп кулланучан. Әдипнең үз йөрәге табигать йөрәге белән тоташ. Шуңа күрә талантның табигатьтән килүен әйтә дә ул: «Чын мәгънәсендә шагыйрь булу өчен анаңнан шагыйрь булып туу кирәк. Кеше үзе теләп шагыйрь була алмый, аны табигать ясый» [1].

[1] Г. Ибраһимов. Татар шагыйрьләре. Оренбург, 1913 ел, 72 бит.

Сыйнфый көрәш утыннан, революция дулкыннарыннан читтә йөрсә, политик хәлләр эчендә кайнамаса, вакыйгаларны күңеле, йөрәге аша үткәрмәсә, Г. Ибраһимов үзе дә табигый талант белән генә әдәбият мәйданында бу дәрәҗәгә үк күтәрелә дә алмас иде бәлки. Әдипнең иҗатын фәнни нигездә тикшергән Мансур Хәсәнов бу хакта болай ди: «Табигый талантның үзе генә художник алдына заман куйган иҗтимагый таләпләргә җавап бирерлек сәнгать әсәрләре тудыру өчен җитми әле. Талантның чын зур көчкә әверелүе өчен тагын әле прогрессив, дөньяга революцион караш белән коралланыуы да кирәк»[1].

Әмма шулай да, иң беренче шарт — табигый талант, тел осталыгы. Г. Ибраһимов тел диңгезендә иркен йөзә, аның мөмкинлекләреннән оста, иҗади файдалана. Тау күкрәгеннән бәреп чыккан чишмә елгага кушылып, аның суын тагын да арттырган, сафландырган кебек, әдип йөрәгеннән чыккан һәр образлы фраза әдәби тел диңгезенә җәүһәр булып барып кушыла. Романтик рухта язылган баштагы хикәяләрендә автор табигать эчендә әсәрләнә. Соңрак исә **яз**, **диңгез**, **дулкын** сүзләре тирән күчерелмә мәгънәләрдә кулланыла башлый. Мәсәлән, «Безнең көннәр» романында ул сүзләр бөтен Россия масштабында кайнаган революция ташкынын бер фразада әйтеп бирергә ярдәм итә: **«Олы Россия диңгезендә күтәрелгән куәтле революция дулкыннары; дөньяны каплаган ут диңгезе дулкыны; йөрәкләрне үз дулкыннары эченә суырып алды** һ. б.

Халык дулкын сүзен эчке кичерешне белдергәндә куллана. Мәсәлән, **йөрәгем дулкынлана**, ди. Ә Г. Ибраһимовта, күрүебезчә, **дулкын** әнә нинди революцион идеяләрне чагылдыручы эмоциональ-стилистик мәгънәләр белән баетылган. Бу инде кояш җир суларын алып парландырып, кире үзенә шифалы яңгыр итеп кайтарган кебек.

Әлеге фразаларда революционерның кырыслыгы, хис-тойгыны зур акыл белән аралаштырып, йөрәк ярсуы белән әйтү бар. Бу сүзләр эчендә хәтта революционер-язучының үз образы күзгә бәрелеп тора кебек.

Менә «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда авылдан җиде кыз китеп, тугыз килен төшәсе көннең бер картинасын ничек бирә язучы: «Бикъярлар һәммәсе, киенеп-ясанып, урамнарга агылдылар. Салам түбәле өйләр, кәкре-бөкре тыкрыклар, коймалар, текмәләр, читәннәр — һәммәсе бертуктаусыз **әле анда, әле монда йөгереп кайнашкан аллы-гөлле күлмәкләр, зәңгәрле-яшелле, кызыллы-сарылы шәлләр дулкыны** эчендә калдылар. Кара бишмәтләр, җиңсез камзуллар, кайсы оеклы-чабаталы, кайсы итекле **кырма бүрекле көяз егетләр** шул купшы шәлләр, яулыклар арасына **сибеләләр**». Игътибар итегез: **зәңгәрле-яшелле, кызыллы-сарылы шәлләр** дисәк, аерым-аерым кешеләрне генә күрәбез, ә инде **дулкын** сүзе аларны ишәйтә, бөтен бер массага әйләндерә. Ә менә кырма бүрекле көяз егетләрнең шул дулкынга барып сибелүе нинди образлы, җанлы картина тудыра! Биредә **дулкын** белән **сибелделәр** сүзен алып ташласаң, әлеге картинаны күз алдына ачык китереп булмас иде.

Башка урында әдип шундый ук кыска фразалар белән иҗтимагый хәрәкәтне, кешеләрнең йөз-кыяфәтләре аша аларның эчке хәл-әхвәлләрен тасвирлый. «Безнең көннәр» романының бер урынында Г. Ибраһимов шәкертләр хәрәкәтен менә ничек сурәтли: «Мәдрәсәнең һәммә катлавы туктаусыз **кайнап торган дулкынны** искә төшерә иде. һәммә бүлмәләрдә шау-шу бара. Ябык, саргылт йөзле, хәлсез карашлы, ач яңаклы, берәзы казаки, бишмәттән, кайберләре фуражка яки кара күлмәк өстенә бәйләнгән каештан, бик күбе җиту чәчле, ләкин һәммәсе диярлек начар киенгән шәкерт җәмәгате бүген **эш ташлау алдыннан завод эчендә кайнаган эшчеләргә яки бунтка әзерләнгән күп солдатлы казармага охшыйлар**, үзләре туктаусыз төркем-төркем булып сөйләшәләр, кычкырышалар, **каяндыр искән җил белән кузгалып торган диңгез кебек**, бүлмәдән коридорга, аннан түбәнгә, баскычка, тагы югарыга, тагы коридордан бүлмәләргә агып, гөрләп йөриләр».

Шәкертләр хәрәкәте — гомуми революцион хәрәкәтнең бер күренеше. Язучы моны әйтми. Художник буларак, тасвирлы сүзләр куәте аша күрсәтә. Вакыйганың мәгънәсен эш ташлау алдыннан завод эчендә кайнаган эшче, бунтка әзерләнгән солдат казармаларына чагыштырып сиземләндерә. **Каяндыр искән җил белән кузгалып торган диңгез кебек** дигән чагыштыру да характерлы. Ул җил, билгеле, мәдрәсә шәкертләренә теге олы Россия диңгезендә күтәрелгән куәтле революция дулкыннары белән

[1] М. Хәсәнов. Г. Ибраһимов. Казан, 1964 ел, 65 бит.

килеп кергән. **Кузгалган** түгел, **кузгалып торган** диңгез. Болай әйтү дә үзенчәлекле, чөнки бу — вакытлыча кузгалу. Өзекне дәвам итик. Язучы шәкертләрнең тышкы күренеше белән эчке дөньяларын яраштырып сурәтли, «Нәҗип Камалны күргәч, **ябык саргылт йөзле, ярым русча начар киемле, җитү чәчле, ләкин һәммә сугышка әзермен дип караган ялкын карашлы** шәкертләрнең бер төркеме, **шул уртак дулкыннан аерылып,** аңа таба каршы килделәр».

Г. Ибраһимов халык телендәге әзер тәгъбирләрдән гаять оста файдалана. Барлык иҗатында алты меңнән артык фразеологик әйтелмә генә бар. Мәкальләр дә җитәрлек. Ләкин ул бер урында әзер форманы кулланса да, икенче урында инде аны кабатламаска тырыша. **Чит җирдә солтан булганчы, үз җиреңдә олтан бул** дигән мәкальне Г. Ибраһимов бер биттә үзгәртми файдаланса, икенче урында, шуның эчтәлеген саклаган хәлдә, **Мисырда патша булганчы, Кәнгәнда гидай булу артык** дип ала. Сүзләрне дә кабатламаска тырыша ул. **Әйтте, сөйләде** дигән лексик берәмлекнең, мәсәлән, әллә ничә синонимын куллана: **тезеп китте, сүз куертты, сайрап китте, сызып чыга алды, сөйләп бирде, хикәя кылды, әйтә салды, сөйләргә тотынды, гәп куертты, калкытып үтте, йөгереп үтте, аваз салды. h. б.**

Г. Ибраһимов еш кына бер тәгъбир белән кешенең үткәне һәм бүгенгесен, бөтен уй-тойгысын күрсәтеп бирә. Бу да шул тел маһирлыгына бәйләнгән. «Кызыл чәчәкләр хикәясе»ндә, мәсәлән, Гыйрфан бай кызы революциядән соң авылга кайта. Тормыш аны шактый үзгәрткән. Элекке иркә, матур йөзендә хәзер җитдилек бар. Тирәякка уен-көлке чәчә, җиңеллек чәчә торган күзләрендә ниндидер уй катнаш акыл пәрдәсе капланган. Солтан аны шулай күрә. Ә сөйләшә башлагач, икенче бер дөнья ачыла: **«Ул иркәләнде, күзләрендә элекке заманның нуры, куштанлыгы ялтырап китте».** Язучы шушы бер метафора аша кеше психологиясендәге тирән катламнарны күрсәтә. Яки менә «Безнең көннәр»дәге Гәүһәр туташ образы: **нечкә зифа гәүдә, матур алсу ирен** аның чибәрлеген күрсәтсә, **зәһәрле караш** эчке дөньясын ачып сала. Әдип озак сөйләп тормый, аз сүз белән күп мәгънә аңлата.

Әсәр героеның нинди сыйнфый катлам кешесе булуына, иҗтимагый тормыштагы ролен карап, язучы кыска гына бер чагыштыру аша да аның характерын ачып салуга ирешә. «Безнең көннәр»дәге революционер Гәрәй — усал телле, ялкынлы йөрәкле, шашкын күңелле, дошманга аяусыз, тимер характерлы кеше. Аның кулына эләксәң, ычкыну мөмкин түгел. Моны әдип **тимер ыргак кебек кеше** дигән чагыштыру ярдәмендә раслый.

Шул ук әсәрдәге Шакир солдат хакында ул болай ди: **«... алпавытны суярга хәзерләнгән кеше кебек каты карый».** Башка бер сүз әйтми, шушы бер фраза революция дошманнарына йодрык төйнәгән корыч йөрәкле солдатларны күз алдына китереп бастыра.

Г. Ибраһимов конкрет бер образ аша киң гомумиләштерүләр ясау алымына еш мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, ул бер башкорт образы кыяфәтендә бөтен халыкның каһарманлык сыйфатларын чагылдыра: **«...кыяфәте белән дә чын башкорт иде. Майланып, ялтырап торган киң кара йөзе, кош йомыркасыдай зур уенчак күзе, башындагы чын камчат бүреге белән билендәге көмеш кәмәре — моның рус гаскәрләренең алгы сафында Парижга барып кайткан мәшһүр тарихи каһарманнарның берсе икәнен ачык күрсәтәләр иде».**

Күз карашы, елмаюы аша да кешенең ни уйлаганын әйтү, эчке дөньясын ачып салу оста психолог булуны таләп итә. Г. Ибраһимов әнә шундый кодрәткә ия. Югарыдагы кайбер мисаллар да моны раслап тора. Тагын берничә мисал: **җиңеп чыккан генерал елмаюы белән көлде; Сәлимов мыек астыннан мыскыллы елмаю белән Мефистофельчә көлеп утырды** h. б.

Аз сүз белән күп мәгънә аңлату, игътибар итсәң, әдип томнарының һәр битендә күзгә ташлана. Сүзгә саранлык (экономиялелек), әсәрләре теленең халык сөйләменә якынлыгы, сүзләрнең гаять нечкә стилистик-экспрессив мөмкинлекләрен эшкә җигә белү — болар барысы да әдипне күренекле тел остасы итеп таныта.

Төрле тарихи, иҗтимагый-политик һәм социаль күренешләрне сурәтләү язучыларны билгеле бер дәрәҗәдә публицистика стиле чараларын файдаланырга этәрә. «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр» романнарында да урыны белән публицистика стиле үзен сиздереп куя. Ләкин Г. Ибраһимов, оста художник буларак, ул сизелүне

һич тә озакка сузмый, матур сүз җепләре белән тизрәк чигүләргә ашыга. Кыскасы, матур әдәбият стиле белән публицистик стиль элементларын да яраштыра белә әдип. Кайнар хис, тирән тойгы, йөрәк җылысы белән язу аны прозада шагыйрь итә. Вакытында бу хакта күренекле әдәбият белгече П. С. Коган да әйткән иде. Г. Ибраһимов кешелек дөньясындагы иң яхшы шагыйрьләр семьясына башын югары тоткан хәлдә барып керергә хаклы, ди ул.[1]

Әдип теленең төп үзенчәлекләреннән берсе итеп, аның әнә шул прозадагы поэзиясен күрсәтәсе килә. Ул поэтик элементлар әсәргә җылы тын өрер өчен генә түгел, ә бәлки зур фикерләрне эмоциональ тасвирлау өчен кулланыла. Табигать күренешләрен дә зур уйланулар аша җанландыра ул: мәсәлән, күк белән диңгез сөешә... күк нурлы күзләре белән җир йөрәгенә карый... Язучының тасвирламасын укыганда син әллә нинди матурлык дөньясына кереп югаласың.

Бу мәкаләдә Г. Ибраһимов теленең кайбер үзенчәлекләренә генә тукталынды. Яки, икенче төрле әйтсәк, язучының тирән тел диңгезеннән тамчы-тамчы үрнәкләр алып күрсәтү генә булды. Ә инде **эзләгәннәр табып алыр, эзләмәгән коры калыр** дигәнне истә тотсак, Г. Ибраһимов теле диңгезенә кат-кат чумарга кирәклеге көн кебек ачык.

# ӘДИПНЕҢ ТАГЫН БЕР ХАТЫ

Журналның былтыргы 12 нче санында Гәлимҗан Ибраһимовның яшь тәрҗемәче Гайшә Шәриповага адресланган хатлары басылган иде. Укучылар хәтерлидер, күренекле әдип ул хатларда әдәби тәрҗемәнең нигез принциплары, әдәби әсәрдә тел-сәнгать чараларының әһәмияте турындагы карашлары белән уртаклаша.

Күптән түгел, Алма-Ата шәһәренә баргач, Казагыстан ССРның Үзәк дәүләт тарих архивында Гайшә Шәрипованың шәхси фонды белән таныштык. Анда әдәбият тарихы өчен әһәмиятле күп кенә материаллар саклана. Пөхтәләп төпләнгән кәгазьләр арасында «Безнең көннәр» романының русча тәрҗемәсе, М. Галәүнең «Бунт» («Ил өреккәндә») романы һәм хикәяләренең, шулай ук «Татар әкиятләре»нең русча тәрҗемәләре, Ф. Бурнаш хатлары һ. б. бар. Аерым папкада Г. Ибраһимовның Г. Шәриповага язган тагын бер хаты табылды (1956 фонд, 1 тасвирлама, 72 эш берәмлеге). Ул әдәби иҗат эшенең үзенчәлекле якларына язучының мөнәсәбәтен ачыкларга булыша. Форсаттан файдаланып, хатны матбугатка чыгарырга рөхсәт иткән өчен, Г. Шәрипованың кызы Асия ханымга рәхмәт белдерәсе килә.

**ИСКӘНДӘР АБДУЛЛИН,**
**филология фәннәре кандидаты.**

*20 март, 1936 ел. Ялта.*

Хөрмәтле Гайшә ханым,

хатыгызны алдым. Договор эшенең һаман тәмам булмавы әчне пошыргыч бер мәсьәләгә әйләнеп бара. Моны тизрәк өзеп, практик эшкә — тәрҗемәгә тотынырга кирәк иде:[1] кыйммәтле вакыт юкка китә бит.

Сез андагы шартлар буенча сатулашырга хаклысыз. Ләкин үзегезне Гослитиздатка каршы куеп, алар белән көрәшү хәленә керүдән сакланырга кирәк. Алар частный

[1] Кара: Вестник научного общества татароведения. 1928 ел, 8 сан, 5 бит.

нашир түгел. Сез үзегезне шул зур коллективның бер әгъзасы итеп карарга тиешлесез. Шулай каралса, бер урында алар, бер урында Сез уступкага барырга туры килер. Сез аларны үз кешегез, бу тәрҗемә эшләрен үз эшегез итеп уйласагыз, гонорарның бер тип әсәрләрдә артыграк, икенчедә кимрәк булу моментлары — **эшне ташлар** дәрәҗәдә кискенлеккә алып бармаска тиеш. Сезгә бу очраклы бер эш түгел. Сез — **профессиональ** тәрҗемәче, Сез — Союз **әгъзасы**; мондый эшләрдә санап алынган акча белән **бер дәрәҗәдә үк моральный авторитетны** күз алдында тотарга кирәк. Әдәби мәйданда моральный авторитет — **саф алтын** ул. Аның аркасында матди файда үзе тагы төплерәк нигезгә утырадыр.

Гонорар өчен сатулашканда, бу моментларны бер дә хәтердән чыгарырга ярамый. Мин үзем ач хәлемдә «Яшь йөрәкләр» кебек зур романны бөтенләй буш бирдем. «Казакъ кызы» өчен «Центриздат» табагына **35** сум түләде. Башка кайбер китапларымның III нче, IV нче басмаларына 400 тәңкә түлиләр. Мондый эш базарга чыгарып мал сату түгел. Хәзер исәпләп карасам, минем буш биргән романым яки 35 кә биргән «К[азакъ] к[ызы]» романы гомуми нәтиҗәләр буенча миңа матди тәэмин ягыннан да зуррак файда китергәннәр. Кыскасы, бу эшләрдә киңрәк, ераграк уйлап, гомуми нәтиҗә якларын күз алдында тотарга тиешлебез.

Мин бүген Асадуллаев[2] иптәшкә хат язып, Сезгә гонорар эшендә дә чара күрсәттем.

Яхшылап аңлашкач, алар анда Сезгә арттырырлар, мин реальный юлны әйттем аларга.

Җавабыгызны тиз языгыз.

Сәлам белән: **Галимҗан.**

---

[1] Сүз Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы хакында бара. Әдипнең 1935 елның 1 апрелендә язган хатыннан күренгәнчә, «Безнең көннәр» романын русчага тәрҗемә итеп, Дәүләт матур әдәбият нәшриятында чыгару эшен ул Г. Шәриповага тапшыра, нәшрият белән элемтәгә керә һәм кат-кат яза. Романның русча тәрҗемәсе (ул тәгәлләнмәгән һәм беркайда да басылмаган) шушы ук архив фондында 23 эш берәмлеге буларак саклана.

[2] Г. Ибраһимов Дәүләт матур әдәбият нәшриятында СССР халыклары бүлеге редакторы Асадуллаевка шул ук көнне язган хатында романны тәрҗемә итүне тәҗрибәле Г. Шәриповага тапшырырга кирәклекне дәлилләп чыга һәм тәрҗемәчегә гонорарны автор исәбеннән арттыруны тәкъдим итә («Совет әдәбияты» журналы, 1965 ел, 7 сан, 143 бит). Зур әдип өчен бу мәсьәләдә дә беренче чиратта мораль як өстенлек итә.

# Әхмәт Рәшитов

## Җалита... Җалита...

Җирле халык Ялтаны «Җалита» дип йөртә.
Утызынчы еллар азагында биредә Галимҗан Ибраһимов дәваланган.

Диңгезнең мәңгелек зарларын
Бүгенгә сөйләгән шикелле,
Дулкыннар капшана ярларда—
Кемнедер эзлиләр...
Тик кемне?..

Килгән дә, киткән дә күп булган —
Кайсы соң аларга яр икән?
Тик бер сүз тәкърарлый дулкыннар:
— Җалита...
— Җалита...
— Җалита...

Мин сезнең сүзләрне аңламыйм —
Туганмын еракта, Иделдә.
Бәлки бу ваемсыз халәттә
Инәлеп сүз катмас идем дә,
Мин әзлим Галимҗан абыйны —
Кайчандыр ул монда ял иткән...
Туктаусыз сулкылдый дулкыннар:
— Җалита...
— Җалита...
— Җалита...

Ул — Ленин гаскәре солдаты —
Давыллар тын торган арада
Бер шифа табыйм, дип, килгәндер,
Көрәшләр калдырган ярага.

Нигә соң әйтмисез, дулкыннар,
Шул хакта бер генә хәбәр дә...

Юнаннар [1] хыялы тудырган
Нихәтле исем бар мәрмәрдә!
Бәлки ул мифларның хикмәте
Тарихка сабакка ярыйдыр, —
Тик алар яшәеш серләрен
Безнеңчә сөйләми барыбер.

Галимҗан абыйга кирәккән
Яңа уй һәм хыял!.. Заманча!.. —
Яңа чор тудырган батырлар
Иң гүзәл дастанга салганча.
Дәверләр өстендә калыккан
Өр-яңа Антейлар, Алыплар.
Без шулар җырына кушылыйк,
Җалита...
Җалита...
Җалита...

[1] Юнаннар — греклар.

# ТАРИХТАН БЕР СӘХИФӘ

Урта гасырларда шәһәрләр, бигрәк тә башкала ролен үтәгәннәре, гадәттә икегә бүленгәннәр. Беренче өлеше кальга дип аталган һәм анда дәүләт башлыгы, хөкүмәт әгъзалары, югары дәрәҗәле руханилар урнашкан. Бистә яки шәһәр (русча «посад») дип йөртелгән икенче өлешендә һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һәм башка шуныңише «кара халык» яшәгән. XVI гасырда Казан шәһәрендә дә шундый бүленеш булган.

Кальга һәм шәһәр агач стеналар белән әйләндереп алынган. Кальга хәзерге Кремль мәйданыннан бәләкәйрәк урынны алып торган. Хәзерге көндә Татарстан АССР Верховный Советы һәм Министрлар Советы урнашкан бина һәм аның каршындагы бакча урынын хан сарае йорты биләгән. Йорт эчендә мәчетләр, хан нәселенең мавзолейлары урнашкан. Ул биналар матур итеп таштан эшләнгәннәр һәм, башкаларыннан аерылып торсын өчен, биек койма белән әйләндереп алынган булганнар. Кальга эчендәге яхшы ныгытылган бу цитадельгә тантана вакытларында, чит ил вәкилләрен кабул иткәндә һәм башка шундый очракларда биек манара астыннан үтеп йөргәннәр. Цитадель белән беррәттән Нур Гали мәчете урнашкан булган. Нур Гали Ширин ул вакытта Казанның зур дәүләт эшлеклесе, хөкүмәт башлыгы, ханнан кала икенче дәрәҗәдәге кеше саналган. Аның мәчете дә бик мәһабәт итеп эшләнгән.

Әйтелгәнчә, кальгадәге мәчетләр, мавзолейлар, хөкүмәт йортлары таштан төзелгәннәр. Казанны алуда катнашкан рус кнәзе А. Курбский: «Тау өстендә матур шәһәр тора, патша сарайлары һәм мәчетләр бик биек, таштан салынганнар... кнәзь һәм түрәләрнең өйләре сөйкемле, гаҗәпкә калдырырлык итеп төзелгәннәр», — дип язып калдырган. Иван Грозный үзе дә, елъязмачы әйткәнчә, Казан белән беренче танышканда, стеналарның биеклегенә, шәһәр ныгытмаларының матурлыгына, ныклыгына исе китеп йөргән.

Хан сараена якында гына кальганең һәм бөтен ханлыкның баш мәчете калкып торган. Сигез манаралы шушы мәчет янәшәсендә зур мәдрәсә, китапханә, Казан дәүләтендә ислам дине башлыгы булып саналган сәетнең йорты урнашкан булган. Башка чиновникларның, хәрби түрәләрнең һәм руханиларның өйләре кальгадә дә, шәһәрдә дә агачтан салынганнар. Кальга стеналарында барлыгы дүрт капка булып, рус елъязмалары хәбәр иткәнчә, алар Патша капкасы яки Олы капка, Алабуга капкасы, Нур Гали һәм Төмән капкасы дип исемләнгәннәр. Бу капкалар кереп-чыгып йөрү өчен генә түгел, ә бәлки оборона максатыннан да чыгып эшләнгәннәр. Капкалар өстенә манара рәвешендәге махсус ныгытмалар ясалган. Ул ныгытмаларда туплар, дары һәм ядрәләр сакланган, туп һәм мылтыклардан ату өчен торымнан-торымга уемнар эшләнгән. Шуңа охшаулы оя-амбразуралар стеналарда да ясалган. Мондый чараларның ханнар сарае урнашкан кальгане тышкы дошманнардан саклау өчен генә түгел, шәһәрдәге «кара халык»ка каршы тору өчен дә күрелгән булуы бик ихтимал. Чөнки халык чуалышлары Казан феодаль дәүләтендә шактый еш булып торган.

Әйтеп үтелгәнчә, кальга һәм шәһәр стеналары имән бүрәнәләрдән төзелгән. Ике рәт итеп өелгән параллель стеналар алты-сигез метр саен шахмат тәртибендә аркылы салынган бүрәнәләр белән бүленгән. Дүрт почмаклы мондый бураларның иңе сигез метрга кадәр җиткән. Аларның эченә таш, ком һәм балчык тутырылып, бетон кебек

итеп катырылган. Аларның калынлыгы һәм ныклыгы ядрә тишеп керә алмаслык, ә өстендә җигүле атлар йөрерлек булган. Сигез метр биеклектәге стеналар өстендә, сугышчыларны сакларлык итеп, икешәр метрлы коймалар торгызылган. Кайбер урыннарда исә махсус коймалар эшләмичә, тышкы як стенаны эчке ягына караганда биегрәк ясаганнар һәм ату өчен тишек-оялар уйганнар. Кирәк урында стеналар өстенә такта түбәләр ябканнар. Ул түбәләр астында һөҗүм итүчеләр өстенә тәгәрәтеп төшерү өчен юан-юан бүрәнәләр, зур-зур ташлар, кайнатып агызу өчен сумала, нефть һәм башка нәрсәләр торган. Стеналар почмак ясап борылган урыннардагы биек манаралар шәһәрнең оборона куәтен арттыру өчен хезмәт иткәннәр.

Шәһәр стеналары каршына тирән чокыр-канаулар казылган. XVI гасырның икенче яртысында язылган «Патшалык китабы»нда Арча кырындагы шундый бер канауның тирәнлеге җиде, иңе өч сажин булганлыгы әйтелә. Бу канаулар табигый күлләр, сазлык һәм елгалар белән тоташканнар. Канау-чокырлар аша һәр капка алдында күперләр салынган, ләкин алар күтәрелмәле булмаган. Күренгәнчә, Казан ул чорда көчле ныгытылган крепостьларның берсе булган.

Саф һавалы биегрәк урыннарда төрле феодаллар һәм бай сәүдәгәрләр яшәгән. Түбән җирләрдә, тау һәм ерганак араларында ярлыларның тәбәнәк өйчекләре бер-берләренә тәрәлеп, тыгызланып утырган. Болак буенда һөнәрчеләр мастерскойлары тезелгән. Монда шулай ук пристань да булган. Товарлар Иделдән Казан елгасы буйлап Болакның үзенә китерелгән һәм сәүдәгәрләрнең мал-мөлкәтен ишәйткән. 1523 елга кадәр Казаннан җиде чакрым читтә, Казан елгасы Иделгә койган урынга каршы утрауда (ул сәүдәгәрләр утравы дип аталган) һәр ел саен июнь аенда ярминкә уздырылган. Казанның үзенә һәм шул ярминкәгә килеп, бик күп илләрнең сәүдәгәрләре үзара алыш-биреш иткәннәр. Казан халыкара сәүдәнең зур үзәгенә әверелгән, Европа һәм Азия илләрен бер-берләре белән бәйләнешкә кертешкән. Шәһәрдә рус һәм әрмән бистәләре барлыкка килгән. Нугайлар һәр елны 20 мең баш ат һәм сарык сата торган булган. Казан татарлары үзләре дә чит шәһәрләр, илләр белән сәүдә мөнәсәбәтләрендә торганнар. Бохара йөртүчеләр, сәмәркандчылар дип шул шәһәрләр белән сәүдә итүчеләрне атаганнар. Казан сәүдәгәрләре Бөек Новгород, Дмитров, Нижний Новгород һәм башка рус шәһәрләрендә торып та сәүдә иткәннәр. Мәскәүдә, Мәскәү елгасының аръягында татарларның зур бистәсе оешкан. Академик М. Н. Тихомиров, татарлар Мәскәүдәге мөселман халкының зур өлешен тәшкил иткән, Казан белән сәүдә итү Мәскәүнең сату-алу эшен арттырган, дип яза.

Казанның үзендә ике базар булып, аларның берсе хәзерге Беренче Май мәйданын биләгән. Икенчесе аннан аста Болак буенда булган. Ул урын соңыннан Ташаяк дип йөртелә башлаган һәм анда ярминкәләр уздырылган. Шәһәрнең шундый зур сәүдә алып баруы аның үзендә дә һөнәрчелекнең алга китүен күрсәтә. Казанда Болгардан күчкән күнчелек, тире эшкәртү, аяк киемнәре тегү, бизәнү әйберләре ясау зур үсеш алган, ташчылар, тимерчеләр, металлчылар, коралчылар һәм башка һөнәр ияләре барлыкка килгән. Тора-бара алар, шәһәр халкының төп массасын тәшкил итеп, социаль яктан икегә — феодалларга бәйле һәм «ирекле» һөнәрчеләргә бүленгәннәр. Беренчеләре хан сарае мастерскойларында, аерым феодалларның йортларында балта осталары, чүлмәкчеләр, коралчылар, тегүчеләр, итекчекәвешчеләр булып эшләгәннәр. «Ирекле» һөнәрчеләр үзләре ясаган әйберләрне базарда үк сатканнар. Аларның мастерскойлары да базар тирәсенә салынган. һөнәрчеләрнең күбесе эре сәүдәгәрләргә бәйле булган. Шул ук вакытта алар хан власте һәм аның чиновниклары тарафыннан да рәхимсез рәвештә изелгән.

Кара халык арасында, һөнәрчеләрдән тыш, коллар аерылып торган. Алар феодаллар һәм байларның йортларында иң авыр эшләрне башкарганнар һәм бернинди хокукка да ия булмаганнар. Сугыш вакытында әсир төшкән һәм мөселман булмаган кешеләр күбесенчә кол дип исәпләнгән. Мөселман булган ярлы халык, кол дип саналмаса да, начар шартларда яшәгән.

Феодаллар, дөньяви эш белән шөгыльләнүчеләргә һәм дингә хезмәт итүчеләргә бүленеп, изүчеләр сыйныфын тәшкил иткәннәр. Дөньяви феодаллар, ханнан кала, солтан һәм әмирләрдән, морзалар, огланнардан торган. Алар дәүләт хезмәтендә, күбесенчә хәрби хезмәттә булганнар. Хәрби хезмәттәге гади гаскәриләр эчке казаклар дип йөртелгән.

Дини феодалларга, ислам дине башлыгы сәеттән тыш, төрле шәехләр, имам, ахун, муллалар, хәлфә, мәзиннәр һәм аларның балалары кергән. Болар халыкның иҗтимагый тормышында зур роль уйнаган. Сәет дәүләтнең бөтен эшләрендә катнашкан, хәтта хан үзе дә аның чапанын үбәргә тиеш булган.

Барлык феодаллар хезмәт иҗләре исәбенә яшәгән. Князьләр (солтан һәм әмирләр) үз колларында кораллы отрядлар тотканнар, дәүләтнең аерым өлкәләрендә үзләре теләгәнчә эш иткәннәр. Аларның күбесе зур җир мәйданнары биләгән, кайберләре тышкы сәүдә белән шөгыльләнгән. Дәүләттә төп көч булып әнә шулар саналган. Рухани феодаллар да халык җилкәсендә көн күргән.

Халык массалары һәртөрле феодаль изүләргә каршы өзлексез көрәш алып барган. Тарихи чыганакларның аз булуына да карамастан, ул көрәшкә бәйләнешле кайбер вакыйгалар турында сөйләргә мөмкин. 1496 елда Казан тәхетенә Себердән килгән Мамук Шейбани утыра. Күчмә кабиләләр гадәтенчә, ул ачыктан-ачык талау политикасы үткәрә башлый. Хәтта кайбер эре князьләрнең дә, үзләрен төрмәгә утыртып, малларын тартып ала. Аннан соң, үзенә буйсындырырга һәм таларга теләп, Арчага поход ясый. Моның белән килешеп торырга теләмәгән халык баш күтәрә. Арча кешеләре, Казан халкы белән бер булып, үзләренең шәһәрләрен ныгыталар һәм Мамук Шейбанины анда кертмиләр. Казанга кире борылып кайткан хан шәһәр стеналарында үзенә каршы төбәлгән туп көпшәләрен һәм коралланган баш күтәрүчеләрне күрә. Казан халкы кабат аны шәһәргә кертми, ә качып китәргә мәҗбүр итә.

Сафа Гәрәй ханлык иткәндә Казан халкы шулай ук берничә тапкыр күтәрелеп чыга. Елъязмаларда әйтелгәнчә, 1531 елда шәһәрдә «зур гаугалар һәм буталулар» башлана. Аеруча зур чуалыш 1546 елда була. Казан халкы, бердәм күтәрелеп, ханны шәһәрдән куа. 1549, 1551 елларда да властьларга каршы баш күтәрүләр турында мәгълүматлар бар. Тарихи чыганаклар «кечкенә»ләрнең, икенче төрле әйткәндә, гади кешеләрнең «зурлар»га, ягъни феодалларга, буйсынырга теләмәүләре турында сөйлиләр. Шулай итеп, шәһәрнең төп халкы ул вакытта ук инде феодаль изүгә каршы сыйнфый көрәш алып барган. Бу көрәш җәмгыятьнең иҗтимагый фикер үсешендә халыкчанлык идеяләрен тудырган. Шул чорда яшәгән шагыйрь Мөхәммәдъяр үзенең иҗатында гаделлек, барлык кешеләр арасында тигезлек, туганлык идеяләрен яклап чыккан. Ул халыкны җәберләүне илне һәлакәткә алып бара торган нәрсә дип караган, ханнардан гадел хөкемдар булуны таләп иткән.

Мөхәммәдъяр кебек шагыйрьләр Казанда байтак булган. Аның үзенең әйтүенчә, шәһәрдә кечкенәсе дә, зурысы да шагыйрьләр икән. Казан дәүләтендә гомумән культураның һәм әдәбиятның үсеше югары дәрәҗәдә булганлыгы башка мисаллар белән дә исбатлана. Мөхәммәдъярның замандашы, язучы һәм шагыйрь Мөхәммәд Шәриф, мәсәлән, повестьлар иҗат иткән. Аның бер повесте Төркиядә дә билгеле булган. Үзенең туган теленнән тыш ул гарәп, фарсы, чыгытай телләрен яхшы белгән.

Сигез манаралы хан мәчете янындагы зур мәдрәсә һәм китапханәдән тыш Казанда башка мәктәп һәм мәдрәсәләр дә булган. Кальга эчендәге зур мәдрәсәләрдә эре аксөякләрнең, шәһәрдәге мәктәпләрдә һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләрнең балалары укыган. Һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр, бигрәк тә аларның чит илләр белән бәйләнешкә кергәннәре өчен грамоталылыкның аеруча зарури булуы да Казанда уку-укыту эшләрен юлга салуны таләп иткән. Ләкин бу хакта бездә язма материаллар сакланмаган. Моның сәбәпләре күп, билгеле. Шуларның берсе — татар халкының мөстәкыйль дәүләте яшәүдән туктау.

1552 елның 2 октябрендә Казан Иван IV гаскәрләре тарафыннан алынгач, кальгага һәм шәһәрнең үзенә воеводалар, стрелецлар, князьләр, боярлар, руханилар килеп урнаша. 1565—1568 еллардагы «Язу дәфтәрләре»ннән күренгәнчә, шәһәрдә хәрби хезмәттәгеләр 1010, руханилар 100 чамасы, шәһәр халкы 765 кеше исәпләнгән. Бу саннарга, әлбәттә, ир җенесеннән булган йорт хуҗалары гына керә. Хезмәттәгеләр арасында яңа чукындырылган 24 керәшен, чукынмаган — 8, шәһәр кешеләре эчендә — 9, стрелецлар составында — 2, барлыгы 43 татар булган. Болардан кала Кабан артында оешкан татар бистәсендә 150 йорт булып, аларның һәрберсендә унар гаилә яшәгән. Шулай итеп, шәһәрнең барлык халкы унөч-унбиш меңгә җиткән. Ул вакыттагы Рус дәүләте шәһәрләре арасында Казан иң зурларыннан саналган. Чагыштыру өчен түбәндәге саннарны китереп үтү дә җитә: 1579 елда Бөек Новгородта 283 йорт була. Ә

XVII гасырның 20 елларында Казанда йортларның саны 1400 дән артып китә һәм ул зурлыгы ягыннан Россиядә беренче урынга чыга.

Шәһәр төзелешендәге үзгәрешләр беренче чиратта Кремльгә әйләнеп баручы кальгадән башланган. Ул үзгәрешләрнең берсе сигез манаралы төп мәчет урынына, шуның ташларын һәм стеналарын файдаланып, Благовещенский соборын төзүдән гыйбарәт булган. Ә хан сарае урынына архиепископ, соңыннан архиерей йорты дип аталган сарай салынган. Шул ук гасырның илленче елларында Спас-Преображенский һәм Троицкий монастырьлары эшли башлаган. Кальга-крепостька каршы яктагы Елан тавында Зилантовский, икенче якта Богородицкий хатын-кызлар монастыре ачылган. Казан Кремле төзелә башлаганчы ук инде, воеводаның хәрби-административ власте белән берләттән, монда руханилар власте да урнаштырылган. Мәскәүгә буйсынган барлык рус җирләренең православие руханилары Казан халкының рухи атасы итеп Гурий дигән берәүне сайлап куйганнар. 1555 елда аның Казанга килүе христиан диненең Көнчыгышка ясаган тәре походы төсен алган. Аның төп бурычы Казан ягы халыкларын, беренче нәүбәттә татарларны чукындыру һәм руслаштыру булган. Архиепископ Гурийның йорты үз канцеляриясе, төрмәсе, хуҗалык корылмалары булган дини учреждениегә әверелгән. Аның карамагына Казан тирәсендәге татар авылларының җирләре һәм ул авылларда яшәүче крестьяннар крепостнойлар итеп бирелгән.

1556 елда Казан Кремлен төзү башланган. 1555 елның 15 декабрендә махсус указ чыгарылып, «яңа шәһәр Казанны таштан эшләү» өчен Мәскәүдән «чиркәү һәм шәһәр төзү остасы» Постник Яковлев җибәрелгән. «Язу дәфтәрләре» раславынча, 60 нчы елларда Кремльнең шәһәр белән ике арасында 60 метр, Казан елгасы ягында 30 метр озынлыкта таш стеналары салынган. Калган өлешләре әүвәлгечә агач стеналардан торган. Таш стеналар кальгадәге җимерелгән сарай һәм мәчет ташларыннан төзелгән. Ләкин ак таштан эшләнгән бу стеналар сакланмаган. Һәртөрле ремонтлаулар, яңартулар аша безнең көннәргә кадәр килеп җиткән Кремль стеналары XVI гасырның 90 нчы елларында кызыл кирпечтән төзелә башлаган. Әмма ул вакытта да әле аның бер өлеше агачтан салынган көе калган. Кремльне таш стена белән әйләндереп алу эше XVII гасырда тәмамланган.

1558 елда Казанга килгән инглиз сәяхәтчесе Дженкинсон Кремль турында: «Казан, бик матур итеп, рус һәм татар җирлегендә төзелгән шәһәр, тау өстендә бик нык крепосте бар. Бу замок әлек вал һәм агач ныгытмалар белән әйләндереп алынган булса, соңгы вакытта рус патшасы иске стеналарны җимереп, ак таштан яңа стеналар төзергә боерды», — дип язып калдырган.

Кремльгә тоташкан шәһәрдә, ягъни посадта, стрелецлар, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һәм башкалар урнашкан. «Язу дәфтәрләре»ндә 100 дән артык һөнәрчелек һәм 644 сәүдә итү пункты теркәлгән. Сәүдә рәте хәзерге Татарстан Дәүләт музее урынында булып, анда таможня йорты эшләгән.

Казан халкы рус шәһәрләреннән күчереп утыртылган кешеләр исәбенә үскән. Иван Грозный үзенә ошамаган бояр-князьләрне дә бирегә сөргенгә җибәргән. Күчереп утыртылганнар арасында таза хәлле сәүдәгәрләр дә булган. Аларны Астрахань, Кавказ һәм үзләренең туган яклары белән сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга салу өчен күчергәннәр.

XVI гасыр ахырында Кабан артындагы бистә татарларның даими яшәү үзәгенә әйләнгән. Патша указларының тыюына да карамастан, алар шәһәр кырына ук китереп үзләренең мәчетләрен сала башлаганнар. Ләкин 1593 елда патша Федор Иванович, Казаннан җибәрелгән грамота-гаризага җавап итеп, татарларга үз теләкләре белән мәчетләр салуны тыярга, дигән боерык биргән.

Казан XVII гасырда да Көнчыгышта нык хәрби үзәк булып саналган. Ул халык массалары хәрәкәтен бастыру вазифасын үтәгән. XVII гасыр башында крестьяннар күтәрелеше елларында Казан идарә итүче үзәк булып кына түгел, баш күтәрүчеләрне бастыручы гаскәрләрнең җыелу һәм оешу урыны булып та хезмәт иткән.

Крестьян сугышларында Казан тирәсендә яшәгән халыклар актив катнашкан. Аларның бер өлеше Болотниковка барып кушылган, ә калганнары, үз җирләрендә баш күтәреп, хөкүмәт гаскәрләренә каршы сугышкан.

Изелүгә, талауга чыдамы беткән Урта Идел буе халыклары 1615 елда баш күтә-

рәләр. Аны татар һәм мари крестьяннары башлап җибәрә. Аларга чуваш, мордва, рус, удмурт һәм башкорт крестьяннары килеп кушыла. Восстание шактый зур территориягә — Сарапулдан алып Арзамаска һәм Муромга кадәр җәелә. Баш күтәргән крестьяннарның иң зур җитәкчеләреннән берсе йомышлы татар Җан Гали Вәлиулла улы була. Бу хәрәкәтне тарихта аның исеме белән Җан Гали яки Еналей восстаниесе дип йөртәләр дә. Крестьян отрядлары байтак кына шәһәрләрне камап ала, Казан, Нижний Новгород, Муром шәһәрләренә һөҗүм итә. Патша хөкүмәте аларга каршы күп санлы гаскәрләр, җәза отрядлары җибәрергә мәҗбүр була. Коралллы солдатлар Урта Иделнең төрле өязләрендә баш күтәргән крестьяннарны төрле яктан кысрыклый башлыйлар. Аларга татар морзаларының бер өлеше булышлык күрсәтә. Җан Гали восстаниесе берничә ел дәвам итә һәм ул 1619 елда гына бастырыла. Аның җитәкчеләрен Казанга алып килеп асып үтерәләр.

1646 елгы «Язу дәфтәрләре» Казанда йорт хуҗаларының саны 2540 кешегә җитүе турында сөйлиләр. Һөнәрчелек белән шөгыльләнгән йортларның саны исә 800 дән ким булмаган. Бу вакытта шәһәр инде Кремльдән төньяк-көнчыгышка һәм Болак буйлап көньякка таба үскән. Һөнәрчеләр арасында күнчеләр, итекчеләр, тимерче, тегүче, сабынчы һәм шәмчеләр арткан, күп санлы асламчылар (текстиль тукымалар белән сәүдә итүчеләр) барлыкка килгән. Сату-алу эшләре шактый алга киткән. Казан башка шәһәрләр белән экономик бәйләнешкә ныграк кергән. Шәһәр һәм авыл кешеләре арасында акча-товар мөнәсәбәтләре үсә, киңәя барган. Эчке сәүдә тышкысы белән тыгыз элемтәгә керә башлаган. Казанда чит ил сәүдәгәрләре күбәйгән. Монда илнең башка шәһәрләреннән дә бик күп сәүдәгәрләр яшәгән. Болар барысы да Бөтенроссия базарын төзүдә Казанның зур роль уйнавына китергән. Бөтенроссия базарының үзәк артериясе булып хезмәт иткән Идел — Кама магистрале Казан өчен шундый уңайлы шартлар тудырган. Сәүдәнең һәм һөнәрчелекнең үсүе үз чиратында шәһәрнең зураюына китергән. XVII гасырның икенче яртысында аның тирәсендә яңа бистәләр үсеп чыккан. Акрынлап шәһәр үзенең элеккеге чикләренә сыешмый башлаган.

XVII гасырда, башка бистәләр белән бергәттән, татар бистәсе дә зур тизлек белән үскән. Казан татарларының зур көчкә ия булуы Степан Разин восстаниесе вакытында ачык күренгән. Разинның якын көрәштәшләреннән берсе Хәсән Айбулат улы Карачурин аның исеменнән Казан татарларына чакыру-өндәмә хатлары язып, аларны восстаниегә кушылырга өнди. Шул ук вакытта ул Степан Разинны Казанны алырга чакыра һәм, анда барсак Казан татарларында яклау табачакбыз дип, аларның теләктәшлегенә ышана. Ләкин Казан, көчле хәрби крепость һәм Көнчыгышта алпавытларның үзәк шәһәре буларак, Разин восстаниесен дә бастыру вазифасын үти. Хөкүмәт гаскәрләре баш күтәргән крестьяннарга каршы берничә тапкыр походка чыгалар һәм Сембер янында Разин гаскәрләрен таркаталар.

XVII гасырда Казан төрле стихияле бәла-казаларга да дучар була. 1654 елдан 1656 елга кадәр чума зәхмәте шәһәрнең ун меңнәрчә халкын кыра. 1672 һәм 1684 елларда Казан тулысынча диярлек янып бетә. Ләкин бу бәлаләрдән соң шәһәр яңадан аякка баса, XVII гасыр ахырларына ул тагын да матуррак итеп төзелә. Халык массаларының кул көче дә, акыл көче дә аңа бөтенләй егылырга беркайчан да ирек бирми. Болай да авыр тормышта яшәгән халык бәла-казаларны да җиңә барган һәм шәһәребезнең данлы тарихын тудырган.

**СӘЛАМ АЛИШЕВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# ХӘМИТ ТӨХВИ ШИГЫРЬЛӘРЕ

*Укучыларыбызга тәкъдим ителә торган бу шигырьләр авторы Хәмит Төхфәтуллинның балалык һәм яшьлек еллары Кытайда, Шиңҗаң (Синцзян) — Уйгур автономияле өлкәсендә узган. Ул Кулҗа шәһәрендә татар мәктәбендә урта белем ала. 1944 елда булган уйгур милли-азатлык хәрәкәтенә катнашып, «Инкыйлаби Шәркый Төркестан», «Казакъ Шәркый Төркестан» һәм «Шиңҗаң газетасы» редакцияләрендә эшли, беренче шигырьләрен бастыра.*

*Хәмит Төхфи — Г. Тукайның сайланма шигырьләр китабын төзеп, кереш сүз белән 1947 елда Кулҗа шәһәрендә бастырып чыгарган. 1955 елда гаиләсе белән Ватанга кайту теләгенә ирешкәч, ул Ташкент шәһәрендә яшәп кала, андагы мебель комбинатында эшли...*

*Хәмит Төхфинең Татарстан Язучылар союзы каршындагы әдәби консультациягә килгән шигырьләрен сайлап һәм автор турында мәгълүмат белән журналга өлкән шагыйребез Әхмәт Исхак тәкъдим итте.*

●

Яр буенда Чистай шәһәре,
Бер карауга күзгә ташлана.
Яшеллеккә чумган шул яктан,
Шәҗәрәбез шуннан баш ала,
Минем нәсел шуннан башлана...

Бабай мескен ниләр күрмәгән?
Булганмы соң аның иркендә?
Бәхет эзләп киткән айкадан
Ак буранлы кышкы бер төндә,
Ач бүреләр улаган төндә.

Алтын таулар көтмәгән читтә,
Ят җирдә дә булмаган уңай.
Илдә табалмаган бәхетен
Горбәттә дә бирмәгән ходай,
Чит илдә дә булмаган уңай.

Кайда барсаң да бит бер кояш,
Кайда барсаң да бит үзеңнән.
Эш эшләсәң, ага тозлы тир,
Эшләмәсәң — ага күзеңнән,
Кайда да бит фәкать үзеңнән...

[1] Айка — төп йорт.

Заман аккан, шул заман кебек,
Чулман суы аккан да аккан.
Ачу белән давыл куптарып,
Дулкыннары ярларга каккан,
Чулман суы аккан да аккан.

Заманалар хәзер үзгәчә,
Һич тә түгел аһлар орырлык.
Эш эшләсәң бөтен нәрсә бар,
Тормышы — гел рәхәт торырлык,
Һич тә түгел аһлар орырлык.

Яр буенда Чистай шәһәре,
Күзгә шундый җылы ташлана.
Бу як минем атам мәкане —
Минем нәсел шуннан башлана.
Безнең нәсел шуннан башлана.

●

Шаулап куйды нарат урманы
Газаматлы, серле өн белән.
Әйт син миңа, әйт син, әй, урман,
Сөйләшәсең болай кем белән?
Серләшәсең болай кем белән?

Хәл-әхвәлем сорыймсың миннән?
Шушы яктан нәсел-нәсәбем.
Үзем исә гади бер татар,
Раушан көндәй уем-исәбем,
Шушы яктан нәсел-нәсәбем.

Бер күрергә килдем мин сине,
Сагышларда янып, җирсенеп.
Горбәтлектә гаять кыен бит,
Килдем сиңа, килдем илсенеп,
Бер күрергә сине җирсенеп...

Китмәс идем мөмкин булганда...
Шулдыр инде күңел тулганы.
Аңлагандай минем әхвәлне,
Шаулап куйды нарат урманы,
Шулдыр инде күңел тулганы.

●

Юкка рәнҗеттем, сөеклем, сине,
Шелтәлим инде, әрлим үземне.
Әгәр дә мөмкин булса шундый эш, —
Кайтарып алыйм әйткән сүземне.

---

[1] Мәкан — торган җир.

Кайтарып алыйм һәммәсен кире,
Нинди авырлык булса сүземдә.
Мөмкинме соң бу, мөмкинме инде?
Мөмкин түгелен беләм үзем дә...

Күңел күңелдән бизде бер сүздән,
Ком сахрасыдай инде арасы.
Әйтелгән сүз ул — кадалган хәнҗәр,
Хәнҗәрен алсаң, кала ярасы.

●

Бер төрле китапның һәр җөмлә, һәр сүзе
Нәкъ асылташ кебек.
Бер төрле китапның язганы гыйшыктан
Исергән баш кебек.
Бер төрле китапның яклаган фикере
Күз белән каш кебек.
Ә инде китапсыз уздырган көннәрем
Нәкъ тозсыз аш кебек.

------------

# ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕГЕ ТУРЫНДА ЯҢА ХЕЗМӘТ

Татарлар арасында иҗтимагый-политик һәм философик фикер үсеше тарихында мәгърифәтчелек хәрәкәте әһәмиятле урын алып тора. Узган гасырда һәм бигрәк тә аның икенче яртысында киң җәелгән бу хәрәкәт татар хезмәт ияләренең рухи ихтыяҗларын, аларның теләк һәм омтылышларын гәүдәләндерде. Мәгърифәтчелек фикере төп асылы белән урта гасырчылык тоңлыгына, дини обскурантизм һәм фанатизмга каршы юнәлдерелгән иде. Ул халык арасында үз вакыты өчен алдынгы булган идеяләр һәм фәнни белемнәр таратуга ярдәм итте. Соңга табарак Татарстанда иҗтимагый фикернең турыдан-туры рус революцион-демократлары йогынтысы астында үсеп китүе, татар халкының рухи культурасы тагын да баюы өчен мәгърифәтчелек зарури бер баскыч булды.

Шул рәвешчә, татар мәгърифәтчеләренең идея мирасын тикшерү прогрессив иҗтимагый-политик, философик-социологик, табигый-фәнни һәм тарихи фикер үсешен өйрәнүдә бик кирәкле буын тәшкил итә. Я. Г. Абдуллинның күптән түгел дөнья күргән монографик хезмәте[1] нәкъ менә шушы зур һәм әһәмиятле проблемага багышланган.

Татар мәгърифәтчелегенең кайбер мөһим мәсьәләләре, аның туу һәм үсеш тарихы, аерым мәгърифәтчеләрнең иҗади эшчәнлеге моңа кадәрге хезмәтләрдә инде шактый тирән өйрәнелгән иде. Бу эшкә, барыннан да элек, Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, М. Гайнуллин, Р. Нәфиков, К. Фасеев, Х. Мөхәммәтов, С. Михайловалар тарафыннан зур өлеш кертелгән булуын билгеләп үтәргә кирәк. Бу авторларның хезмәтләренә тиешле бәя биреп, Я. Абдуллин үзенең монографиясендә төп игътибарны татар мәгърифәтчелегенең аз өйрәнелгән өлкәсенә — мәгърифәтчеләрнең философик һәм социологик карашларын ачыклауга юнәлтә. Ләкин иң элек ул, методологик яктан бик дөрес килеп, мәгърифәтчелек хәрәкәтенең формалашу чорына һәм аның төп этапларына гомуми характеристика бирә; мәгърифәтчелекнең идея нигезләрен һәм чыганакларын ачыклый; татар һәм рус мәгърифәтчеләре, Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа фикер ияләренең карашларындагы уртак һәм аермалы якларны күрсәтә.

Табигый ки, иҗтимагый-политик фикернең шул исәптән мәгърифәтчелекнең формалашуында һәм үсешендә һәр халыкның милли тормыш шартлары хәлиткеч рольне уйный. Шуның белән бергә, монда башка халыклар идеологларының йогынтысы да зур булуын истән чыгарырга ярамый. Татар халкы гасырлар дәвамында һәм Көнчыгыш, һәм Көнбатыш халыклары белән тыгыз культура-экономика бәйләнешләре тота. Монографиядә күрсәтелгәнчә, татар мәгърифәтчеләре борынгы Көнчыгышның Ибн Сина, Әл-Фараби, Ибн Рәшид, Ибн Баҗҗа, Ибн Халдун, Фирдәүси кебек фикер ияләренең иҗат мирасын тирәнтен үзләштерәләр. Гарәп һәм фарсы телендәге чыганаклар аша алар Аристотель, Платон, Пифагор, Эвклид, Фалес, Сократ һәм башка борынгы грек галимнәренең карашлары белән танышалар. һәм, әлбәттә, татар

[1] Я. Г. Абдуллин. Татарская просветительская мысль. (Социальная природа и основные проблемы.) Татарстан китап нәшрияты, 1976 ел, 320 бит.

мәгърифәтчеләренең зур күпчелеге рус телен һәм рус культурасын яхшы беләләр. Алар В. В. Радлов, А. М. Казимбек, И. Ф. Готвальд, Н. Ф. Катанов, В. В. Вельяминов-Зернов кебек рус галимнәре белән бергә эшлиләр. Авторның үз сүзләре белән әйтсәк, «татар мәгърифәтчеләре рус иҗтимагый-политик һәм фәнни фикерендә бара торган үзгәрешләрдән хәбәрдар булып торалар» (33 бит). Бер үк вакытта рус телендәге әдәбият алар өчен Көнбатыш Европадагы фән, философия, иҗтимагый фикер казанышлары белән таныштыручы канал булып хезмәт итә.

Татар мәгърифәтчелегенең үзенчәлекле якларына тукталып, Я. Абдуллин бу үзенчәлекләрнең социаль-экономик мөнәсәбәтләр табигате, милли традицияләр характеры, хезмәт ияләренең аңына ислам дине тәэсире, милли-колониаль изү яшәп килүе һәм башка күп кенә материаль һәм идеологик, сыйнфый һәм милли, эчке һәм тышкы, тарихи һәм агымдагы факторлар белән билгеләнүен ышандырырлык итеп исбатлый.

Санап үтелгән факторларны анализлаганда, монография авторы партиялелек принцибын эзлекле саклый, татар мәгърифәтчелегенең социаль-сыйнфый табигатен, аның идея юнәлешен ачыклауга җитди игътибар бирә. Ул татар мәгърифәтчелеге үзенең төп сыйфатлары белән буржуаз характер йөртүе, чөнки аның вәкилләре, ихтыярлы рәвештәме, яки ихтыярсыздан-мы, җәмгыятьнең ул вакыттагы «алга таба үсеше белән бәйләнгән тенденцияләрне гәүдәләндерүчеләр булуы» турында яза (53 бит).

Алдарак әйткәнебезчә, Татарстанда мәгърифәтчелек нигездә феодализмга каршы юнәлешле иде. Гәрчә күпчелек мәгърифәтчеләр үзләре руханилар яки дини мөхиттән чыгучылар булсалар да, мәгърифәтчелек фикере ислам тәгълиматының ортодоксаль-фанатик агымнары белән көрәштә формалашты. Татар халкы яшәгән конкрет шартларда мәгърифәтчелек өченче сословие, шул исәптән хезмәт ияләре интересларына да җавап бирде.

Шуның белән бергә, татар мәгърифәтчелеге бердәм, бөтен һәм эзлекле бер хәрәкәт түгел иде. (Бу хакта монографиядә басым ясап әйтелә.) Аның эчендә, хәрәкәт тулаем антифеодаль юнәлешне саклаган хәлдә, философик һәм социологик проблемаларны аңлатуда, хезмәт ияләренең җәмгыятьтәге урынын һәм ролен бәяләүдә каршылыклы тенденцияләр яшәп килде. Мәгърифәтчеләрнең идеалларына тарихи чикләнгәнлек хас булуын онытырга ярамый. Алар социаль проблемаларны кешенең әхлакый камиллеккә ирешү, культураны үстерү, хезмәт ияләрен хуҗалык итүнең алдынгы формаларына, мәгърифәткә, фәнни белемнәргә тарту юлы белән хәл итәргә өметләнделәр. Кыскасы, татар мәгърифәтчелеге тулаем алганда прогрессив характерда булса да, ул үз чорының иң мөһим бурычларын чишә алмады.

Китапның татар мәгърифәтчелеге өйрәнүләрендә философик һәм дөньяга караш проблемаларын анализлауга багышланган сәхифәләре зур кызыксыну белән укыла. Автор Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Ш. Күлтәси кебек мәгърифәтчеләрнең хезмәтләрендә бу проблемаларның ничек хәл ителүенә тәфсилле туктала, аларның философик культурасы нинди дәрәҗәдә булуын күрсәтә. Материяне аңлату, аның атрибутларына (пространство һәм вакыт, чиклелек һәм чиксезлек, хәрәкәт) характеристика бирү, кешенең үзен әйләндереп алган мөхитне танып белүенең асылына төшенергә омтылу кебек катлаулы философик мәсьәләләрдә мәгърифәтчеләрнең нинди позициядә торганлыклары укучылар алдында шактый тулы ачыла.

Татар мәгърифәтчеләренең философик карашларындагы үзенчәлек шунда ки, алар үзләренең төп карашларына ислам дине догмалары һәм ышанулары системасын (кәлям) тәнкыйтьләү һәм мистикага бирелүне, суфичылыкны (дөньядан ваз кичү, язмышка буйсыну) кире кагу аша килделәр.

Әлбәттә, суфичылыкны, ортодоксаль ислам тәгълиматын тәнкыйтьләү ул әле атеизм позициясендә тору дигән сүз түгел. Татар мәгърифәтчеләре барысы да дөньяга караш мәсьәләләрендә теге яки бу дәрәҗәдә югары идеяне (алланы) тануга нигезләнделәр, исламның изге чыганаклары көрьән һәм сөннәтне кабул иттеләр. Аларның дингә тискәре карашы, әйткәнебезчә, ислам тәгълиматы системасын тулысы белән инкарь итмәстән, кешеләрнең дини догматларга сукырларча ышануын, схоластиканы, фанатизмны тәнкыйтьләү белән генә чикләнде. Я. Абдуллин бу чикләнгәнлек һәм эзлексезлекне мәгърифәтчелек фикеренең тарихи кысалары, шул чорның конкрет тормыш шартлары тудырганлыгын бик дөрес күрсәтеп үтә.

Татар мәгърифәтчеләре философиядә рационализм юнәлешенең кайнар тарафдарлары булдылар. Алар кешенең акыл көченә чиксез ышану белдерделәр, танып белүнең иркле булуын, фәннең һәм философиянең диннән бәйсезлеген яклап чыктылар. Моның шулай икәнлеген автор Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри һәм башка мәгърифәтчеләрнең хезмәтләренә киң таянып исбат итә.

Ш. Мәрҗани турында, мәгърифәтче буларак, әле соңгы елларда гына сөйләнелә башланды. Анда да тикшеренүчеләр алгы планга аның олы тарихчы-галим булуын куеп киләләр. Мәрҗани исә татар иҗтимагый фикер тарихында күренекле фикер иясе буларак та әһәмиятле урын тота. Ул үз заманының иң мөһим философик мәсьәләләренә җавап табарга омтылды, үз халкын урта гасырчылык чоңгылыннан чыгару, аны гомуми кешелек прогрессына тарту юлларын эзләде. Я. Абдуллин үзенең монографиясендә Мәрҗани шәхесен һәм иҗат мирасын менә шушы яктан ачуга зур игътибар бирә.

Алланы дөньяның башлангычы сыйфатында таныса да (ягъни, объектив идеализм позициясендә торса да), Ш. Мәрҗани табигатьнең һәм җәмгыятьнең **вакыт эчендә** барлыкка китерелүен турыдан-туры инкарь итте. Аның күзаллавы буенча, чынбарлык, алладан бәйле булса да, мәңгедән яшәп килә, ул — чиксез, ул даими һәм өзлексез рәвештә үзгәрү һәм яңару процессына дучар булып тора. Китапта басым ясап күрсәтелгәнчә, Ш. Мәрҗанинең алласы — ул һәркайда һәм һәркайчан барлык әйберләрнең һәм күренешләрнең нигезендә ята торган гомуми яшәеш принцибы. Табигать исә, илаһи асылның күренеше буларак, шулай ук мәңгелек һәм чиксез, бу мәңгелек һәм чиксезлек чикле әйберләрнең һәм күренешләрнең бертуктаусыз алмашынуы һәм яңаруы аркылы гамәлгә аша (103 бит). Шулай итеп, монографиядә Ш. Мәрҗанинең карашлары пантеистик идеяләр сыйфатында бәяләнә. Безнеңчә, бу фикер белән килешергә кирәк. Әмма Мәрҗани пантеизмының характерын билгеләүдә автор үзенең позициясен төгәл белдерми. Философик фикер тарихында билгеле булганча, ике төрле — идеалистик һәм материалистик пантеизм була. Әгәр китапта Ш. Мәрҗани пантеизмының шуларның кайсысына ныграк тартылуы ачык итеп күрсәтелсә, аның философиясенә бирелгән бәя тагын да тулырак булыр иде.

Ш. Мәрҗанинең философик карашларындагы эзлексезлек, аның еш кына дингә һәм идеализмга кереп китүе икенче бер мәгърифәтченең — Шәмсетдин Күлтәсинең (1857—1932) философик карашларын тикшерү фонында бигрәк тә ачык булып күзгә ташлана.

Ш. Күлтәси исеме соңгы елларга кадәр тикшеренүчеләрнең игътибарыннан читтә калып килде. Үз чорының шактый радикаль фикер иясе булган, реакцион ислам идеологиясен фаш итүгә һәм татарлар арасында фәнни белемнәр таратуга күп тырышлык куйган бу мәгърифәтче галимнең философик карашлары турында беренче булып Я. Абдуллин язып чыккан иде («Казан утлары», 1972 ел, 12 сан). Табигый ки, Ш. Күлтәси иҗатын анализлауга Я. Абдуллин үзенең монографиясендә дә киң урын бирә. Ул Ш. Күлтәсинең, философ буларак, деизм позициясендә торуын күрсәтә. Ягъни, Ш. Күлтәси галәмне башлап барлыкка китерүче итеп алланы таный, ләкин реаль чынбарлык соңыннан үз законнары буенча, үзен тудырган беренче сәбәптән бәйсез рәвештә яши дип аңлата. Күлтәси фикеренчә, материя мәңге яши. Хәрәкәт, өч үлчәнеш (озынлык, биеклек, киңлек) һәм вакыт материаль җисемнәрнең атрибутлары гына булып торалар. Мәгърифәтче материаль җисемнәрнең үзлекләре материянең үзенә кадәр һич тә яши алмавын катгый төстә әйтеп үтә.

Билгеле, бу карашларны чын мәгънәсендә философик материализм дип раслап булмый. Ни өчен дигәндә, Ш. Күлтәси материаль дөньяның ахыр чиктә, барыбер югары илаһи көч тарафыннан тудырылганлыгы мәсьәләсен куя.

Үзләренең философик өйрәтүләрендә татар мәгърифәтчеләре танып-белү мәсьәләләрен дә читләтеп үтмәделәр. Монографиядә күрсәтелгәнчә, алар кешенең танып-белү мөмкинлекләренә зур ышаныч белән карадылар, танып-белүдә объект һәм субъект мөнәсәбәтләрен күз алдына шактый төгәл китерделәр; күмәк тәҗрибә, теоретик һәм эмпирик белемнәрнең ролен дөрес аңлауга якын ук килделәр. Шулай да философиянең төп мәсьәләләрен хәл итүдәге эзлексезлек, дингә һәм идеализмга таба чигенешләре аларга чагылыш теориясен фәнни аңлау позициясенә басарга мөмкинлек бирмәде.

Монография авторының татар мәгърифәтчеләренең философик карашларына биргән гомуми бәясе белән тулысынча килешергә мөмкин. «Татар мәгърифәтчелеге философиясе, — диелә китапта, — гәрчә дөньяга дини-идеалистик караш белән араны кискен рәвештә өзә алмаса да, рационалистик философия булды, ул бер очракларда пантеизм, икенче очракларда деизм белән бәйләнгән иде һәм, дөньяга прогрессиврак караш буларак, урта гасырлар иррационализмына һәм мөселман схоластикасына каршы торды... Табигатьне, илаһи асылны пантеистик һәм деистик рухта аңлату дөньядагы әйберләрне һәм күренешләрне аларның үз табигатеннән һәм эчке закончалыкларыннан чыгып тикшерүгә һәм аңлатуга кучүдә зарури алгы шарт булды» (143 бит).

Я. Абдуллин үзенең хезмәтендә күп кенә социологик проблемаларны яктыртуга зур урын бирә. Татар мәгърифәтчеләренең игътибар үзәгендә кеше һәм аның бәхете проблемасы торды. Шәхеснең әхлакый камилләшүендә алар иҗтимагый үсешнең мөһим шартын күрделәр. Менә шушы гомум танылган фикерне дәвам иттереп, автор татар мәгърифәтчеләренең кеше табигатен, шәхеснең формалашу һәм әхлакый камилләшү шартларын ничек аңлауларын, бу мөһим социологик проблеманы хәл иткәндә аларның нинди теоретик-методологик юнәлештә торуларын ачыкларга омтыла. Моңа кадәрге тикшеренүләрдә тиешенчә яктыртылмаган, әмма татар мәгърифәтчеләрен үз вакытында нык дулкынландырган мөһим проблемаларның берсе — социаль прогресс проблемасы. Мәгърифәтчеләр аны ничек аңлаган, артта калганлыкны, торгынлыкны бетерүнең юлларын алар кайда күргәннәр? — Монографиядә бу сорауга да җавап эзләнә.

Дөрес, философик идеализм белән араны өзә алмаган татар мәгърифәтчеләре җәмгыять үсешенең социаль-экономик асылын аңлап бетермәделәр. Ләкин аларның идеяләре гуманизм, ирек сөючәнлек рухы белән сугарылган, гади кешенең кешелек намусын һәм дәрәҗәсен яклауга юнәлдерелгән иде. Мәгърифәтчеләр хезмәт ияләренең мохтаҗлыкта, хәерчелектә яшәүләрен күрсәтү белән генә чикләнмәделәр, бәлки тормышның мондый тискәре күренешләрен кискен гаепләделәр. К. Насыйри, З. Бигиев, М. Акмулла һәм башка мәгърифәтче язучыларның әсәрләрендә бу хәл ачык художестволы чагылыш тапты. Бер үк вакытта мәгърифәтчеләр табыш артыннан кууга, мал җыюга, акча властена каршы протест белдерделәр, әчкечелек, икейөзлелек, комсызлык, саранлык кебек әхлакый гариплекләрне рәхимсез фаш иттеләр.

Татар мәгърифәтчеләре милли үсеш һәм милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр мәсьәләләреннән дә читтә калмадылар. Аларның бу өлкәдәге карашлары һәм идеаллары чын-чынлап тәкъдир ителүгә лаек. Татар халкының иҗтимагый прогресс юлына басуы өчен аны башка халыклар, бигрәк тә алдынгы милләтләр культурасына һәм фәненә тарту кирәклеген дөрес аңлап, мәгърифәтчеләр милли-колониаль изү системасына, халыкларның үзара аралашуы юлында реакцион дин башлыклары тарафыннан тудырыла торган һәр төрле киртәләргә, чикләүләргә каршы чыктылар. Ш. Мәрҗани, мәсәлән, татар халкына Европа фәне, мәгарифе, культурасы, промышленносте кирәклеге, белем белән мәгърифәтнең милләт һәм тел чикләрен белмәве хакында турыдан-туры язып чыкты.

Мәгърифәтчеләр уртак ватанда уртак язмыш кичереп, бер җирнең икмәген ашап, гомер-гомергә күрше булып яшәгән, берберсенең гореф-гадәтләрен яхшы аңлаган рус һәм татар халыклары арасындагы дуслыкны үстерү һәм ныгыту кирәклеген кат-кат күрсәттеләр. Алар (бигрәк тә К. Насыйри) татарлар һәм руслар арасында иҗади һәм практик эшчәнлектә тыгыз бәйләнешләр урнаштыруга төрлечә булышлык иттеләр, татарларга рус теле укыттылар, рус тарихы һәм культурасы буенча материаллар хәзерләп бастырдылар. Ш. Мәрҗани, И. Хәлфин, Х. Фәезхановлар рус галимнәре белән даими элемтәдә тордылар, рус аудиторияләрендә фәнни докладлар белән чыгыш ясадылар.

Татар мәгърифәтчеләренең рус һәм татар халыклары арасындагы дуслыкны ныгыту юнәлешендәге тырышлыклары зур әһәмияткә ия булды. Шуны югары бәяләп, Я. Абдуллин бик хаклы рәвештә мондый юлларны яза: «Татар мәгърифәтчеләре эшчәнлеге татарлар арасында интернациональ карашлар һәм тенденцияләрне тарату һәм ныгыту өчен зур киңлек ачты. Бүген, совет җәмгыяте шартларында, татар халкының бу гүзәл улларының халыклар арасындагы дуслык һәм туганлык, культура

казанышларын үзара ирекле алмашу мөмкинлеге турындагы хыяллары чынбарлыкка әверелде һәм татар хезмәт ияләре совет халыкларының уртак сафында коммунизмның якты биеклекләренә атлыйлар» (241 бит).

Бер рецензия чикләрендә генә Я. Абдуллин монографиясендә күтәрелгән проблемаларның барысына да тукталу мөмкин түгел. Алай да, санап чыгу төсендә генә булса да, аларны телгә алып үтәсе килә. Китапта мәгърифәтчеләрнең хатын-кыз азатлыгы өчен көрәше, аларның дәүләт төзелеше, халык мәгарифе, укыту һәм тәрбия принциплары турындагы фикерләре, карашлары һәм практик эшчәнлекләре шулай ук киң яктыртылыш тапкан. Мәгърифәтчеләрнең эстетик карашларын тикшерүгә багышланган бүлекчә дә бик кызыклы. Анда Ш. Мәрҗани, К. Насыйри һәм башка мәгърифәтчеләрнең сәнгатьнең иҗтимагый роле, аның тарихы һәм теориясе буенча әйткән фикерләре тирән анализлана. Сәнгатьнең табигатен аңлатуда мәгърифәтчеләрнең материалистик позициядә торуларын, сәнгатьне шәригать чикләүләреннән һәм тыюларыннан азат итү, әдәбиятны, музыканы, скульптураны һәм рәсем сәнгатен үстерү өчен көрәшүләрен автор бик күп фактлар ярдәмендә ачыклый.

Шул рәвешчә, без Я. Абдуллин китабының төп эчтәлеген кыскача гына күздән кичереп үттек. Җитди фәнни тирәнлек белән һәм җентекләп язылган бу хезмәт татар мәгърифәтчелек фикерен өйрәнүгә әһәмиятле яңа өлеш булып тора. Татар халкының культурасы, иҗтимагый-политик һәм философик фикере тарихы белән кызыксынучылар бу китаптан үзләре өчен зур файда алачагын ышанып әйтеп була.

**М. САДЫЙКОВ,**
**философия фәннәре кандидаты.**
**Х. МӘХМҮТОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

-----------

# УКУЧЫ СҮЗЕ

*«Казан утлары»ның 1975 елгы 9—10 саннарында Әмирхан Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» дигән кечкенә романы басылган иде. Әсәр турында укучыларыбыздан редакциягә һәм автор исеменә күп кенә хатлар килде. Укучыларыбызга шул хатларның кайберләрен тәкъдим итәбез.*

*
* *

Әмирхан иптәш!

«Казан утлары»нда басылып чыккан «Гөләндәм туташ хатирәсе» дигән романыгызны бик яратып укыдым! Бу романны бөтен укытучылар коллективы укып чыкты һәм яратты.

Сезнең романда Салих абый бик акыллы, талантлы һәм чибәр кеше итеп күрсәтелгән. Моңа бик ышанырга була. Романыгызны пьеса итеп тә язарга булыр иде. Тик Салих абыйга охшаган артист уйнасын иде. Телевизордан карар идек. Безнең авыл зур, төзек, бай. Халкы культуралы. Зур клубыбыз, яңа мәктәбебез бар.

**НУРШИДӘ СӘЕТОВА,**
**Оренбург өлкәсе, Новомусино авылы.**

*
* *

Хөрмәтле Әмирхан ага!

Сез «Гөләндәм» әсәрегез белән Салих Сәйдәшевне дөньяга икенче кат тудырдыгыз.

Минем рәхмәтләр Сезгә «Гөләндәм» өчен!

**Укучыгыз СӨЕМБИКӘ ИХСАНОВА,**
**Пермь өлкәсе, Горшки авылы.**

*
* *

Кадерле редакция!

Мин үзем Ульяновск шәһәрендә яшим. Татарча газета-журналларга бик теләп языламын һәм аларны кызыксынып укып барам. Әле менә Әмирхан абый Еникинең «Казан утлары» журналында «Гөләндәм туташ хатирәсе» исемле кечкенә романы басылып чыкты. Аның башы журналның 9 нчы санында иде, ахырын түземсезлек белән көтеп алдым. Әсәрдә Гөләндәм туташның кемгә тормышка чыкканы ачык әйтелмәгән. Газиз әфәндегә тормышка чыккан диеп уйлыйсы да, ышанасы да килми. Шуны ачыклап әйтмәссезме икән? Сездән түземсезлек белән җавап көтеп, киләчәктә тагын шундый яңа романнар, хикәяләр басуыгызны үтенеп:

**МӨСЛИМӘ,**
**Ульяновск шәһәре.**

Кадерле редакция!

Без, сезнең укучыларыгыз, «Казан утлары» журналының 9, 10 саннарында басылган «Гөләндәм туташ хатирәсе» дигән кечкенә романны укып бик дулкынландык. Бу романда бөек татар композиторы Салих Сәйдәшевнең тормышы сурәтләнә. Күренекле композиторның көйләрен яратып тыңлыйбыз, ләкин аның хакында бик аз беләбез. Салих Сәйдәшевнең ары табан тормыш юлы хакында да язсагыз иде.

Зур хөрмәт белән:

ВЕНЕРА БАЯЗИТОВА,
НӘГЫЙМӘ СӘМИГУЛЛИНА,
нефтьчеләр.
Башкортстан, Дүртөйле эшчеләр
поселогы.

*
* *

Хөрмәтле Әмирхан Еники ага!

Әле генә «Казан утлары» битләрендә басылган «Гөләндәм туташ хатирәсе»н иптәшем Рәшидә белән бергәләп, тирән кызыксыну белән укып чыктык. Бу әсәр безнең күңелләрдә саф мәхәббәт турында бер моң булып урнашты, Салих Сәйдәшкә карата булган мәхәббәтебезне тагын да көчәйтте.

Русчага тәрҗемәсен биргәндә «Светлая любовь» дигәнрәк исем килешмәсме икән. Гафу итегез, монысы безнең фикер генә.

Тирән ихтирам белән әдәбият сөючеләр:

ЯКУБ ЗАНКИЕВ,
РӘШИДӘ ЗАНКИЕВА,
Түбән өлкәсе, Хуҗайлан авылы.

*
* *

Хөрмәтле Әмирхан Еники иптәш!

Сөекле композиторыбыз Салих абый Сәйдәшев турында язган романыгыз күңелемә бик хуш килде. Салих абыйның нәфисләгән һәм аңа гына хас булган башка яхшы якларын, шулай ук 16—17 яшьлек кызның нечкә хисләрен, саф мәхәббәтен шул кадәр матур итеп тасвир итүегез өчен Сезне чын күңелдән котлыйм.

Сезнең романны укыгач, Салих абыйның 1925—1928 елларда педагогия техникумында безгә музыка укытып йөргәне һәм яшь вакытларым исемә төште.

Салих абыйның 1922 елдан 1954 елга кадәр булган тормыш юлы хакында да язсагыз, бик шат булыр идем.

Ихтирам белән сәламләп:

ХИСАМОВА, Казан.

*
* *

Кадерле редакция!

«Казан утлары» журналында басылган «Гөләндәм туташ хатирәсе» романын укып чыктым. Ләкин журнал битен ябасым килмәде. «Шулай итсә ни булган, болай итсә ни булган» дип, Гөләндәм туташ өчен өзгәләндем. Геройларның үзләрен күргәндәй булдым, күренмичә генә артларыннан иярեп йөргән кебек хис иттем.

Гаиләбез белән әдәбият, музыка яратабыз. Журналда басылган әсәрләрне, башка әдәби китапларны ял көннәрендә әниемә кычкырып укыйм. «Гөләндәм туташ хатирәсе» өчен язучы Әмирхан Еникигә зур рәхмәт!

Яңа әсәрләр көтәбез.

М. ИСӘНЧУРИНА,
Оренбург өлкәсе, Иманкол авылы.

*

*   *

Хөрмәтле «Казан утлары» журналы!

Күңелемне кайтардыгыз «Гөләндәм туташ хатирәсе» турында язып... Гөләндәм туташ берәүнең бергенәсе, хезмәтче белән үсә...

Аның әнисе дә бер җирдә дә эшләми. Бер кызга ике хезмәтче, укучы күңелендә бу бит шик калдыра дип әзрәк уйлар идегез. Егет булсам, бер кич суыкта салкын тидереп, өч ай мендәр өстендә яткан сырхауны яратмас идем. Мин Сабираны яратыр идем.

**ТӘСЛИМӘ ӘХМӘТҖАНОВА,**
**Төмән өлкәсе, Стрежевой поселогы.**

*

*   *

Бу әсәрне мин, аерылмыйча диярлек, яратып укып чыктым. Миңа бу бик ошады. Көчле лирик әйбер... Уналты-унҗиде яшьлек бер кыз исеменнән генә язылган булса да, эченә күп нәрсә — тарихи вакыйгалар, тирән фикерләр сыйган... Ул Салих Сәйдәшевнең яшь вакыты белән таныштырып кына калмый, шул еллардагы хәлләрне, карашларны һәм татарларның милли тормышын да төрле яктан күрсәтә. Инде әсәрнең төп нигезе булган Гөләндәм белән Салих арасындагы саф мәхәббәтнең ничек үсүе оста язылганын әйтәсе дә юк.

**Р. ИЛЬЯСОВ,**
**Рига шәһәре.**

*

*   *

Ромен Роллан әйтә, әсәрнең художество кыйммәте — аның ихлас күңелдән язылган булуында, ди. Автор ихлас күңелдән язса, димәк, ул чын художник.

Әмирхан Еникинең бу кечкенә романы да әнә шундый саф, ихлас күңелдән язылган әсәр. Тормышны, кешеләрне, заманны тасвирлауда бернинди дә ясалмалык сизелми. Без анда чын, тере кешеләрне күрәбез. Менә бик самими, нечкә табигатьле яшь кенә кыз Гөләндәм. Музыкага булган сәләте аны талантлы музыкант, булачак композитор Салих Сәйдәшев белән якынлаштыра. Алар арасында табигый рәвештә саф, тирән мәхәббәт башлана... Бу мәхәббәтнең ахыры ни белән бетүе дә, минемчә, дөрес чишелгән. Кыскасы, барысы да бик ышандырырлык.

Аерым күренешләр рәвешендә генә булса да, шул заманның театр, музыка, әдәбият дөньясы да шактый тулы, җанлы итеп күрсәтелгән. Халыктан чыккан чая, үткер, шул ук вакытта самими, кече күңелле Сабира аеруча оста язылган.

Авторның бу кечкенә романы да, башка әсәрләре шикелле үк, укучылар өчен үзенә күрә бер бүләк булды диясем килә. Тик язучы әсәренең телендәге кайбер кимчелекләрне, мәсәлән, «генә», «гына», «кенә» кебек кушымчаларны киметә төшсә, яхшырак булмас иде микән?

**ӘМИНӘ ХАҖИЕВА,**
**Мәскәү.**

**Фәтхулла Абдуллин**

# КӨРӘШЧЕ ТИМЕРЛӘР ҺӘМ МИҢҖАМАЛ ҖИҢГИ

*Хикәя*



Миңҗамал җиңги көтте ул сабан туйларын, зарыгып көтте. Шулай булмыйча, үткән елгы сабан туйда оттырган өчен быел ничек тә үч алырга кирәк лабаса. Ел саен Тимерләр батыр калырга тиеш түгел бит инде. Сарыгын җәлләмәде, быел да ирен көрәшкә әзерләде. Менә, ниһаять, сабан туй! Яше-карты урман эчендәге аланга җыелды. Һәркайда җыр, музыка, уен-көлке яңгырый. Җиңгинең аларда кайгысы юк. Аның бөтен игътибары көрәш мәйданына юнәлгән. Малайлардан башланган көрәш әкренләп бабайларга таба үрләде. Гайрәтлеләр, осталар ега тордылар. Мәйдан уртасында көрәшчеләр саны азайганнан-азайды. Соңгы дүрт кеше арасында үзенең Нурлыгаяны да калгач, Миңҗамал җиңгигә канат үсеп киткәндәй тоелган иде. Әмма Тимерләрнең бәдәне тимердән ким түгел икән. Соңгы алышта Гаян абзыйны баш аркан чөйделәр. Шулай итеп, Миңҗамал җиңгинең өмете чәлпәрәмә килде дип уйлыйсызмы? Һич юк. Аның ачуы бермә-бер артты гына.

Менә бер заман ашау ярышлары башланды. Әйе, әйе, ашау ярышлары! Күрмәгән кешеләр булса, аңлатып китик. Ул менә болайрак була инде: каерып киселгән ипи телемнәрен ике таяк аркылы сузылган тасмага асып куялар һәм куллары артка бәйләнгән катнашучылар, команда булу белән, ашарга ябышалар. Үз өлешен кем алдан ашап бетерә, шул бүләк ала. Әмма быел, әз булса да яңалык керсен диптер инде, ипине ашап бетергәч, эчәргә бер савыт катык та куйганнар иде. Катнашырга теләүчеләр башта бик озак икеләнеп тордылар. Ничаклы мул киселгән булса да, ипиен ашап бетерерсең, ә менә катыгын эчеп бетереп булырмы?

Тәвәккәл таш йоткан дигәндәй, мәйданга җыелган халык арасыннан тәвәккәл кеше табылды бит. Иң беренче булып әле генә мәйдан токкан Тимергали чыкты. Шуны гына көтеп торгандай, төп кебек тәгәрәп, Миңҗамал җиңги дә Тимергали янына тәрәлеп басты. «Булдыксыз» иренә сулагай кулын селтәгән җиңги бу юлы үзе алы-

шырга исәп итте, күрәсең. Бер заман китте ярыш, китте чыр-чу! Ипи телемнәре икесе дә бертигез югарылыкта эленгән. Болай да кыска гәүдәле Миңҗамал җиңгинең ипигә рәтләп буе җитми — сикерә-сикерә байтак азапланды. Ә менә озын гәүдәле Тимергалигә, киресенчә, аска иелергә туры килә. Ипине кабыйм гына дисә, борыны тиеп китә дә ипи телеме аның башы тирәли әйләнергә тотына. Алыптай гәүдәсе белән Тимергали дә ипи телеме артыннан әйләнә. Халык гөр килә.

— Әйләнчек булдымы әллә сиңа, Тимергали? — дип кычкыралар. Көрәшче көрәшче инде, әйләнә-тулгана булса да үз өлешен сыпырып салды Тимергали. Моны күргән Миңҗамал җиңги калган ипиен әллә чәйнәп йотты, әллә чәйнәмичә, аннары тиз генә катыкка ябышты һәм, ничек итсә итте, тәки беренчелекне алды. Аңа бүләккә күлмәклек бирделәр. Ул да булмады, мәйданга энесенең җиңелгәнен күреп хурланган Тимершәех атылды. Эх, син! Көрәштә батыр калган егет, шул капка төләкәсенә бирешне бит. Шартласам шартлармын, мәгәр җиңелмәм, ди иде аның күз карашлары. Әйе, моңа ышанырга була иде. Авыл халкы белә, быел энесе батыр калса, икенче елга абыйсы мәйдан тота. Әтиләре Тимербулат агай да заманында көрәшче булган. Гомуман, көрәшче нәсел иде алар Тимерләр. Әмма, мәйдан халкын гаҗәпкә калдырып, бу юлы да Миңҗамал җиңги җиңде бит, шайтан. Халык гөр килеп кул чапты. Кайбер усал телләр генә:

— Әйтәм аны, хатыны ни әйтсә, Гаян абзый шуңа риза, татулыкның сере менә кайда икән, — дип көлештеләр. Ике агасы җиңелгәч, өченче туган Тимергази ярышка чыгарга базмады. Батырчылык итүче бүтән кешеләр дә күренмәделәр. Шулай итеп, ашау буенча гомуми беренчелекне Миңҗамал җиңгигә бирделәр. Тимерләрдән үч алынды. Ләкин бәйрәм уеннары бетмәгән иде әле. Иң соңыннан төпсез мичкәләр аша чыгып йөгерү башланды. Ике тапкыр рәттән җиңүгә ирешкән җиңги, канатланып китеп, монда да беренче булып язылды. Әллә агаларының җиңелүенә хурланып, әллә очраклы гына, икенче кеше булып ярышка Тимерләр нәселе Минзифа килеп кушылгач, безнең җиңги эшнең уен-муеннан түгеллеген сизенде сизенүен, ләкин соң иде инде. Алыптай абыйларын отып, сеңелләре алдында гына хур буласы килмәгән җиңги команда булу белән йөгереп килеп чирәмдә аунап яткан мичкә эченә кереп китте. Кереп китүен китте... әмма икенче башыннан килеп чыкмады: мичкә эчендә кысылып калган булып чыкты.

... Гаян абзый мичкәнең кыршавын салдырып хатынын сөйрәп чыгарганда, Тимербулат агайның төпчек кызы елмаеп бүләк алып тора иде.

# ГЫЙБРӘТЛЕ ДИАЛОГЛАР

## БАЛЫКЧЫЛАР

К — ичә нигәдер боз өстендә күренмәдең?

— Мин бүтән урында тоттым.

— Ничек соң анда?

— Шәп каба, малай, алырга гына өлгер. Бер чиләк тотып кайттым.

— Ышанмыйм.

— Ә кем ышана соң? Балыкчылар сүзе чын булса, безнең Казанкада инде күптән бер балык та калмаган булыр иде.

— Син нинди китаплар укыйсың?
— Нигә укырга, мин үзем китап язам.
— Мин синең китапларыңны укымаячакмын.
— Ни өчен?
— Чөнки беләм: үзе укымаган кеше китап яза алмый.

## КЕМ КЕМНЕ АШАТА!

— Колхозларда атлар бетеп бара.
— Бетәр шул. Атны бит ашатырга кирәк аны. Син дә механизатор, мин дә механизатор, кем ашатыр аларны?
— Механизатор булмаган агайлар да бар бит әле.
— Аларны механизаторлар ашата.

## БӘЛКИ

— Дисциплина, тәртип дибез. Ә тәртипне начальниклар үзләре боза.
— Дәлилләгез.
— Эшкә башкалардан ярты сәгать, бер сәгать алдан киләләр. Шактый соңга калып китәләр. Бала-чагалары, хатыннары янына соң кайталар. Шулмы тәртип?
— Алар турында олырак начальниклар нәрсә ди икән соң?
— Әлбәттә, аларның тәртипләре «бишле» яки хәтта «алтылы» куярлыктыр. Әмма күп кенә урыннарда боларның балаларының тәртипләре «биш»тән шактый түбән диләр.
— Бәлки алар да соңга калып кайта торганнардыр. Алма агачыннан ерак төшми бит.

## СЫНАТМАДЫ

— Сине бик саран кеше дип әйтәләр. Имеш, кыш көне дә кешегә бер уч кар бирмисең?!.
— Минме саран? Рәхим ит, мин сиңа хәтта җәй көне дә бер уч кар бирәм,— диде дә саран, холодильнигын ачып бер уч кар алып тоттырды кулыма. Акча сорарга өлгерми дә калдым.

## БАКЧАЧЫЛАР

— Көне-төне бил бөгеп эшлим. Ни рәхәтен күргәнем бар бу бакчаның,— дип зарлана ир, базардан кайтып кергән хатынына.
— Рәхәтен күрсәң, акчасын күрмисең аның,— дип, авызын томалый хатыны, акчаны оегына тыга-тыга.

*
* *

— Гомерең буе кибеттә сатучы булып эшлисең. Үзеңә кирәкне дә сатып аласыңмы?
— Юк, сатмый гына алам.

МӨМДИ

# КӨРД ХАЛЫК ИҖАТЫННАН

*Көрдләр—Төркия, Иран, Ирак, Сурия дәүләтләре территориясендә яшәүче халык. Телләре буенча алар иран группасына керәләр.*

*Көрд халкының авыз иҗаты белән галимнәр күптәннән кызыксыналар.*

*Советлар Союзында көрдләр Урта Азиядә һәм Закавказьеда яшиләр. Алар турында китаплар рус, француз, немец, инглиз телләрендә дөньяның бик күп дәүләтләрендә басылып чыга тора.*

*Ленинград галиме М. Руденко бернича елдан бирле җыеп килгән чындый үрнәкләр 1970 елда «Наука» нәшриятында аерым китап булып басылып та чыкты. Журналыбыз укучыларына шуннан кайбер өзекләр тәкъдим итәбез. Шунысы кызыклы, көрд халык иҗатында Идел буе татарларының авыз иҗаты белән бик күп уртаклыклар бар.*

##ҺӘРКЕМГӘ ҮЗ АЗЫГЫ

Өч дус бергәләп сәфәргә чыкканнар. Бер авылга кунарга кергәннәр. Кунарга керткән йорт хуҗасы күрә: өч егет — һәрберсе матур, әдәп белән генә сөйләшәләр, сокланып туймаслык.

«Тукта әле, мин боларны сынап карыйм,— дип уйлый йорт хуҗасы, — болар, чыннан да, шулай әйбәт егетләрме икән, әллә тыштан гына шулай күренәләрме?»

Егетләрнең берсе ишегалдына чыгып киткәч, хуҗа сорый:

— Бу иптәшең нindирәк егет? — ди.

Өйдә калган ике егет:

— Ә, ул — ахмак, ишәк,— диләр.

Егет бераздан өйгә керә. Хәзер тегеләре чыгып китә. Хуҗа йортта калган егеттән:

— Иптәшләрең нindирәк егетләр? — дип сорый.

— Теге, кара бүрек кигәне — этнең үзе!

— Ә икенчесе?

— Хайван!

Кичке аш янында хуҗа кеше болай эшли: ахмак, ишәк дип аталганының алдына арпа, хайван дип аталганының алдына бер кочак печән, эт дип аталганының алдына сөякләр һәм сынык-санак китереп куя. Егетләр аптырашып бер-берсенә карашалар һәм хуҗага сораулы караш ташлыйлар.

— Нигә аптырыйсыз? — ди хуҗа кеше. Сез үзегез бит әйттегез: беребез — ишәк, икенчебез — хайван, өченчебез — эт дидегез. Менә мин һәркемнең алдына үз азыгын куйдым...

## ИКЕ МУЛЛА

Бер мулланың ике хатыны бар икән, ә икенче мулланың — берәү генә. Ике хатынлы мулла һәр вакытта да манарага менәргә иртүк килеп җитә, бер хатынлысы соңга кала икән: күпме генә тырышмасын, теге мулладан иртә килә алмый.

Бервакыт ул ике хатынлы муллага әйткән:

— Син оҗмахлы булырсың инде, — дигән. — Күпме генә тырышсам да, синең артыңнан җитә алмыйм.

— Әй, бичара, синең бит хатының берәү генә. Ул хатын синең киемнәреңне табып китергәнче, ашарга әзерләгәнче көнең узып бетәр. Ә минем нәрсә! Берсе оекбашлар тотып килә, икенчесе кәвеш-

ләрне, берсе ашарга әзерли, икенчесе чалманы чорный. Менә шуңа күрә иртә киләм мин.

Теге мулла да, уйлап-уйлап йөргән дә, икенче хатын алып кайткан. Бер көнне кич өенә кайтып керсә, күрә — ике хатын сугышалар.

— Мулланың башына төкерим, — ди берсе.

— Ә мин сакалына төкерим, — ди икенчесе...

Төн җитә, тегеләр һаман талашалар. Мулла тора, мәчеткә килә һәм манарага менеп китә. Менсә — берәү дә юк. Бераздан күрә — теге мулла килә.

— Я ничек? — ди тәҗрибәле мулла, — ике хатынлы кеше һәрвакыт иртә тора дип әйтмәдемме мин сиңа?

— Һәй, дөмеккере! — дигән тегесе,— синең өеңдәге янгын минем өйгә дә күчте хәзер...

### АКЫЛЛЫ ТАЗ

Патша бер көнне үзенең вәзиренә әйтә:

— Менә сиңа табышмак, — ди, — кырык көн узганда җавабын тапмасаң, башың белән саубуллашасың. Миңа әйтеп бир: үзе ризык — ә ашарга ярамый, ул нәрсә? Үзе ат, ләкин ат дип саналмый. Үзе кеше, ләкин кеше түгел — ул кем?

Вәзир көннәр буе кара кайгыда яши, җавап таба алмый. Санап карый — нибары ун көн гомере калган.

Бервакыт ул юлдан бара, күрә: юл буенда Таз утыра. Вәзир Таздан җирәнеп читкә төкерә дә китеп бара. Ләкин Таз аны туктата.

— Тукта, кая ашыгасың? — ди аңа Таз. — Әллә син үзеңне миннән акыллырак дип исәплисеңме? Син бит патшаның табышмагына җавап таба алмыйча йөрисең. Ә үзеңнең ун көн гомерең калган.

— Кара әле, Таз,— дип ялвара башлаган вәзир.— Син ул табышмакка җавап таба алмассыңмы?

— Ә монда җавап эзләп торасы да юк, — дигән Таз. — Менә тыңла: үзе ашамлык, ә ашарга ярамый, ул — куләгәдә үскән кыяр. Кояш күрмәгәч, ул ачы булып өлгергән. Ат дип саналмаган ат шул: хуҗасы иярдән егылып төшкән очракта туктамыйча китеп барса, хуҗасын көтеп тормаса — ул ат ат түгел. Үзе кеше, ләкин кеше түгел — хатыны өенә кучеп килгән, йортка кергән кеше.

Вәзир шатланып патша янына йөгергән. Ләкин патша бу табышмакны кем чишкәне белән кызыксынган һәм Тазны сараена китерткән. Патша Тазны үзе дә сынап карамакчы булган.

Таз сарайга килеп керүгә патша аны күреп сакалын учлаган. Таз җавап урынына кулын үзенең чигәсенә куйган. Патша көлеп җибәргән һәм сораган:

— Таз, әйт әле, нигә син кулыңны чигәңә куйдың?

— Ә син, патша, нигә сакалыңны учладың? Син бит болай дип әйтмәкче идең: «Карасана, дөньяда мондый шөкәтсез адәм дә була икән!» Ә мин чигәмә кулымны куеп сиңа болай җавап бирдем: «Кешенең акылы сакалында түгел, башында».

Патша аңа үзенең кызын биргән.

### ЯВЫЗ ХАТЫН

Әхмәтхан исемле бер кеше булган. Хатыны бик явыз икән. Бервакыт кешеләр аңа әйткәннәр:

— Әхмәтхан, син үзең юньле генә кеше, ә хатының нинди явыз. Бөтен кеше белән талаша, йортына күрше-күләнне кертми, сиңа оят түгелме?

Бервакыт Әхмәтхан үзенең хатынын кырга алып бара. Зур чокыр янына килеп туктыйлар. Әхмәтхан хатынына әйтә:

— Мин, ди, узган ел монда бодай күмеп куйган идем, карап кара әле, калмадымы икән?

Хатыны чокырга иелүгә ире аны шунда төртеп төшерә. Үзе өенә кайтып китә. Ләкин төнлә йокыга китә алмый, вөҗданы газаплый. «Ничә әйтсәң дә еллар буе йортка хезмәт күрсәткән кеше бит ул,— дип уйлый Әхмәтхан,— ичмаса, ашарына илтеп бирим».

Иртән торуга ашамлык әйберләр ала да чокыр янына килә. Бауга бәйләп ашамлык әйберләрне төшерә дә бауны ала башлый. «Әһә, хатын чыга икән», дип уйлый. Тартып чыгарса — зур буар елан. Куркып кире ташлыйм дигәндә генә елан телгә килә:

— Зинһар өчен ташлама! — ди. — Кичә монда бер явыз хатын төште, — ди. — Мине үзең белән ал, кайчан да булса файдам тияр.

Әхмәтхан аны өенә алып кайта. Бервакыт елан моңа болай ди:

— Мин патша кызының муенына чорналырмын. Берәү дә аңа ярдәм итә алмас. Патша шунда: «Минем кызымны кем азат итә ала?» дип сорар. Шунда син килеп кызның муеныннан мине алырсың. Патша сиңа күп алтын бирер. Менә синең яхшылыгыңны мин шулай түләрмен.

Әхмәтхан риза була.

Патша кызының ятагына үтеп керә елан һәм аның муенына чорнала. Патша үз мәмләкәтендәге барлык акыл ияләрен, сихерчеләрне чакырып карый — берәү дә ярдәм итә алмый. Аннары шәһәр буенча хәбәр сала:

— Кем дә кем патша кызын еланнан коткарса, патша аңа бу кызны хатынлыкка бирә.

— Мин булдыра алам моны, — ди Әхмәтхан.

Аны сарайга алып киләләр. Кызның ятагына алып керәләр. Еланның Әхмәтханны күрүе була, кызны ычкындыруы була. Саубуллашканда елан әйтә:

— Икенче мәртәбә мин берәр кызның муенына чорналсам, якын киләсе булма, — ди. — Якын килсәң, үзеңне буып үтерермен.

Әхмәтхан патша кызына өйләнә. Җиде көн, җиде төн туй итәләр. Алар бәхет эчендә яши бирсеннәр. Әйдәгез, еланниләр эшләп йөргәнен күзәтик әле.

Елан күрше мәмләкәттәге патша кызының ятагына үтеп керә һәм кызның муенына чорнала. Ярдәмгә ташланалар, ләкин берәү дә бер эш чыгара алмый. Шул вакыт хезмәтчеләрнең берсе әйтә:

— Моны, ди, күрше мәмләкәттәге Әхмәтхан гына булдыра ала.

Әхмәтханны алмага җибәрәләр. Әхмәтхан уйга кала. «Нишләргә? — ди ул. Бармасаң — патша үч алыр, барсаң — елан буып үтерер».

Шулай да барырга була. Кызның ятагына керсә, күрә: елан кызны буып азаплый. Әхмәтханны күрүгә елан аңа ташлана. Ләкин Әхмәтхан аңа әйтә: «Мин, ди, кызны коткарам дип килмәдем, сине кисәтергә дип кенә килдем: минем хатын теге чокырдан чыккан, дөнья бетереп сине эзләп йөри, тапсам бетерәм, ди икән».

Моны ишетүгә еланны син күр дә, мин күр.

Менә шуннан соң «хатыныңа баш була алмыйсың» дип, ирләргә сүз әйтмәгез инде. Хатының явыз булса — аңа әмәл юк...

## Мкртич Корюн,

әрмән шагыйре

### Күп лыгырдау бәласе

Төнгә каршы берәү ишек шакыган:
— Кертмәссезме кунып чыгарга?..
Йорт хуҗасы шунда тиеш тапкан
Кем икәнен моның сорарга.

Иплəп кенә тезеп киткән теге:
«Ованесның якын туганы.
Матеосның кияве... Үзегез дә
Беләсездер Нарьян коданы...

Бажам Киракосны... Тевонесны —
Миңа кайниш була анысы»...
Һәм өстәгән тагын:— Улым Ашот,
Абыем Вартон сиңа танышмы?

Өнсез калган хуҗа:— Моннан, берүк,
Алып китә күр син җыенысын —
Шушы чаклы ишле кешене соң
Минем өем ничек сыйдырсын?

... Морале шул моның: авыз тутырып
Үз исемеңне әйтер урында
Лыгырдама ишек төбендә син
Бажаң... җизнәң... кодаң турында.

### Тегүче һәм энә

Сизми калган җөйче энәсенең
Төшеп киткәнлеген кулыннан.
Почмактагы чүп-чар арасыннан
Табып алган аны соңыннан.

Озын итеп кабат җеп саплаган,
Тавыш-тынсыз гына утырып.
Тик энәсе эшкә ярамаган,
Беткән булган тәмам тутыгып.

Тутыккан да булгач, энә, имеш,
Мәсәл өчен иске нәрсә ул.
Тик шулай да аяк өсте йоклап
Йөргәннәрне әйбәт чәнчә ул.

## Сәер курай

— Кураең,— ди хуҗа көтүчегә,—
Моң тарата ерак-еракка.
Ә мин якын килсәм, тавышы да
Ишетелмәс була колакка.

— Аптырадым инде мин үзем дә
Холкы аның сәер булганга:
Көй сузарга никтер теләми ул
Хайваннар бик якын торганда.

## Сүздә һәм эштә

Мактаныр ул кайчан барсаң да:
— Телим,— дияр,— ачыш ясарга.—
Марста да фикер ияләре
Булуы мөмкин,— диеп сөйләнер.
Ә фикергә ия җирдәшләрен
Җене сөйми аның нигәдер.

## Гаҗәпләнә күрмә

Карт эт Айга ялгыз өргән чакта
Гаҗәпләнә күрмә син шуңа.
Без дә калышмыйк дип, аңа тагын
Йөзәрләгән көчек кушыла.

## Акылы үзе белән

Аның хакында мин әйтмәс идем,
Акылы, диеп, алтын:
Ике ияр белән иярләгән
Арык кына атын.

## Алтыдагы алтмышка

— Арысланга тиң мин, дигән мәчедән
Кем батырлык көткән?!
Ул барыбер әүвәлгечә шулай
Куркып яши эттән.

РӘШИТ ГӘРӘЙ тәрҗемәләре.

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ ПЛЕНУМЫ

Узган елның 15—16 декабренда әдипләрнең Мәскәүдәге Үзәк йортында РСФСР Язучылар союзы идарәсенең чираттагы пленумы булды. Пленум «Россия әдәбияты тынычлык, халыкара киеренкелекне йомшарту өчен көрәштә» дигән мәсьәләне карады. Доклад белән РСФСР Язучылар союзы идарәсенең председателе С. В. Михалков чыкты.

Пленум эшендә Татарстан язучыларыннан С. Хәким, А. Расих, З. Нури, Г. Ахунов, Ә. Маликов, М. Шабаев, Р. Фәйзуллиннар катнашты.

## КАЗАНДА ЧИТ ИЛ ЯЗУЧЫЛАРЫ

Казанда Монголия, ГДР, Венгрия, Чехословакия, Төркия, Финляндия, Швеция һәм Норвегиядән башкалабыз Мәскәүгә совет әдәбиятын чит телләргә тәрҗемә итүчеләрнең IV халыкара очрашуына килгән бер төркем язучылар булып китте.

Казанның Актерлар йортында алар республика язучылары белән очраштылар. Кунаклар алдында Татарстан Язучылар союзы идарәсенең председателе Г. Ахунов, Татарстан китап нәшриятының баш редакторы М. Шабаев, әдәбият галимнәре Ә. Кәримуллин һәм Р. Мостафин, шагыйрь Р. Фәйзуллин чыгыш ясады.

Чит ил язучылары шулай ук шәһәрнең музейларында, истәлекле урыннарында булдылар, М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында Ә. Бакировның «Су анасы» балетын карадылар.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЛАРЫ

КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карарын республика язучылары хуплап каршы алдылар. Узган ел ахырында әлеге карар уңае белән республика Язучылар союзы һәм Татарстан китап нәшриятының берләштерелгән партия җыелышы уздырылды. Язучылар союзы идарәсенең председателе Г. Ахунов Үзәк Комитет карары яктылыгында Язучылар союзы алдында торган бурычлар турында сөйләде. Доклад буенча фикер алышуларда Ш. Маннур, З. Нури, М. Шабаев, Х. Сарьян, М. Зарецкий, Ә. Мәхмүдов һәм башка язучылар катнашты. Тикшерелгән мәсьәлә буенча конкрет карар кабул ителде.

*
* *

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының декабрь аенда уздырылган ачык җыелышында КПСС Үзәк Комитетының Октябрь (1976 ел) пленумы карарлары яктылыгында республика язучыларының бурычлары турындагы мәсьәлә каралды. Доклад белән «Казан утлары» журналының баш редакторы З. Нури чыкты. Фикер алышуларда С. Хәким, Г. Минский, Н. Дәүли, Г. Ахунов һәм Б. Камаловлар катнашты.

## ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫНА — 70 ЕЛ

Халкыбызның даны һәм горурлыгы булган иҗат коллективының олы бәйрәмен республикабыз хезмәт ияләре гаять тантаналы шартларда билгеләп үттеләр.

Театрның 70 еллыгына багышланган тантаналы кичә Академия театрында узган елның 22 декабренда үткәрелде. Тантанада, республиканың хезмәт ияләреннән тыш, Казагыстан, Үзбәкстан, Әзербәйҗан ССРдан, Башкортстан, Чувашстан АССРдан, Оренбург, Чиләбе өлкәләреннән килгән кунаклар да катнашты.

Тантаналы кичәне кыскача кереш сүз белән КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова ачты. КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев театр коллективына КПСС өлкә комитеты, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы һәм Татарстан АССР Министрлар Советының котлавын тапшырды. Татарстан АССР культура министры И. Н. Алиев театрның 70 еллык иҗат юлы турында сөйләде.

Республиканың сәнгать оешмалары, культура учреждениеләре, промышленность предприятиеләре вәкилләре һәм авыл хуҗалыгы эшчәннәре, шулай ук илебезнең төрле төбәкләреннән килгән кунаклар театрны данлы бәйрәме белән кайнар котладылар.

*

* *

Казанның Актерлар йортында Академия театрының 70 еллыгына багышланган ике көнлек фәнни конференция эшләде. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институты һәм Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге тарафыннан оештырылган конференциядә, Казан галимнәре белән бергә, Ленинград, Уфа, Чабаксар һәм башка шәһәрләрдән килгән театр белгечләре катнашты. Алар татар театрының данлы тарихы һәм бүгенге казанышлары, тугандаш театрларның үзара бәйләнеше, бер-берләренә йогынты ясаулары хакында сөйләделәр.

*

* *

В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсендә Татар дәүләт академия театрының 70 еллыгына багышланган күргәзмә ачылды. Күргәзмәгә С. Гыйззәтуллина-Волжская, Ф. Ильская, Х. Сәлимҗанов, К. Шамил һәм башка артистларның истәлекләре, «Сәйяр», «Нур» труппаларының эшен яктырткан документлар, театр коллективының бүгенге уңышлары турында сөйләүче газета һәм журнал мәкаләләре куелган иде.

*

* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1976 ел, 21 декабрь Указы нигезендә, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары Габдулла Нигъмәтҗан улы Фәтхуллин белән Наилә Хәким кызы Гәрәевага Татарстан АССРның халык артисты, Рауза Дәүләт кызы Әхмеровага, Барый Әшрәп улы Әшрәповка һәм Хәлим Бәдри улы Җәләловка Татарстан АССРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәр бирелде.

*

* *

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен шул ук театрның баянисты Рәис Шаһимәрдән улы Сафиуллинга, труппа мөдире Бикә Шакир кызы Шакировага Татарстан АССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исемнәр бирелде.

## АРТИСТКАНЫ ХӨРМӘТЛӘҮ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы Галия Булатовага 70 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсе булды. Язучы Ф. Хөсни артистканың тормыш һәм иҗат юлы турында сөйләде.

Юбилярны ТАССР Культура министрлыгы, культура работниклары профсоюзы өлкә комитеты, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге һәм башка оешмалар вәкилләре кайнар котлады.

## ЮБИЛЕЙ КҮРГӘЗМӘСЕ

Татарстан АССРның халык художнигы М. Сутюшевка 70 яшь тулды. Шул уңай белән Казанның Актерлар йортында аның әсәрләреннән торган күргәзмә ачылды. Күргәзмәгә танылган рәссамның төрле елларда иҗат иткән картиналары, сәхнә әсәрләренә эшләгән декорацияләрнең эскизлары куелган иде.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры тамашачыларга Д. Вәлиевнең «Язмышың хәл ителгәндә...» дигән драмасы буенча эшләнгән яңа спектакль күрсәтә башлады. Анда сүз кешенең әхлак йөзе, партияле намусы турында бара. Әсәрне сәхнәгә режиссер Р. Хаҗиәхметов куйган, декорацияләрне Татарстан АССРның халык художнигы М. Сутюшев ясаган.

## ФИЛЬМ-СПЕКТАКЛЬ

Казан телевидение студиясе Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының «Ир-егетләр» исемле спектаклен кино тасмасына алды. Рольләрне СССРның халык артисты Ф. Халитов, РСФСРның халык артисты Г. Шамуков, Татарстан АССРның халык артистлары Г. Камалова һәм Д. Ильясов, артистлардан Д. Нуруллина, И. Вәлиев башкара. Спектакльнең монтажын телевидение режиссеры Ә. Зарипов ясаган, операторы — В. Щеглов.

## ТАТАРСТАН КИТАП ПАЛАТАСЫНА — 50 ЕЛ

22 декабрьда КПСС өлкә комитетының политик мәгариф йортында Татарстан китап палатасының 50 еллыгына багышланган конференция булды. Конференция эшендә катнашучылар китап палатасы директоры Ә. Хисамованың «Татарстан АССР китап палатасына 50 ел», тарих фәннәре докторы, профессор Р. Таһировның «Татар библиографиясе үсешенең төп этаплары», В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсенең бүлек мөдире Ф. Гафурованың «Матбугат елъязмасы»нда информация-эзләнү системасы», культура институтының өлкән укытучысы Н. Гыйззәтуллинаның «Универсаль китапханәләрнең каталогларында милли культураның чагылуы» дигән темаларга докладларын тыңладылар. Докладлар буенча фикер алышу үткәрелде.

## ГОРЬКИЙГА БАГЫШЛАП

Узган ел ахырында СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында бөек пролетар язучысы А. М. Горькийга багышланган 19нчы фәнни конференция булып узды. Конференция эшендә Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми хезмәткәрләре, культура һәм фән эшлеклеләре, М. Горький һәм ТАССР Дәүләт музейлары работниклары, илебезнең зур шәһәрләреннән, тугандаш республикалардан килгән кунаклар катнашты.

Филология фәннәре докторы, профессор Б. Бяликның «КПССның XXV съезды карарлары һәм А. М. Горький мирасын өйрәнү өлкәсендәге бурычлар», филология фәннәре кандидаты Б. Пирадовның «А. М. Горький һәм грузин әдәбияты», филология фәннәре кандидаты Г. Мөхәммәдовааның «А. М. Горький һәм татар әдәбияты», Казандагы Горький музееның директор урынбасары Н. Турның «А. М. Горькийның Казан профессоры В. Н. Терновскийга хатлары» дигән докладлары тыңлаучыларда аеруча зур кызыксыну уятты.

## ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТЛАРЫНЫҢ VII СЪЕЗДЫ

Декабрь ахырында Татарстан Журналистлар союзының VII съезды булды.

Отчет чорында Татарстан Журналистлар союзы идарәсенең эше, КПССның XXV съезды һәм КПСС Үзәк Комитетының октябрь (1976 ел) Пленумы карарлары яктылыгында республика журналистларының бурычлары турында доклад белән Татарстан Журналистлар союзы идарәсенең председателе Ш. Х. Хамматов чыкты. Фикер алышуларда унга якын кеше катнашты. Съезд тикшерелгән мәсьәләләр буенча резолюция кабул итте. Ул шулай ук Журналистлар союзы идарәсен, ревизия комиссиясен һәм СССР Журналистлар союзының март башында уздырылачак IV съездына 6 делегат сайлады.

Оештыру пленумында идарә бюросына Ф. И. Әгъзамов, Ш. М. Вәлиев, Р. К. Зәкиев, Е. А. Лисин, Ф. Г. Надыйров, А. Ф. Хәсәнова, Г. Н. Шәрәфетдиновлар кертелде. Союз идарәсенең председателе итеп Ш. Х. Хамматов, җаваплы секретарь итеп В. Н. Михайлов сайланды. Татарстан язучылары исеменнән съездда Гариф Ахунов чыгыш ясады.

## КОНКУРС ЙОМГАКЛАРЫ

Татарстанда чыга торган китапларның художество оформлениесен һәм полиграфия ягыннан эшләнешен тагын да яхшырту, художниклар, оформительләр һәм полиграфистлар арасында иҗади ярышны киң җәелдерү максатында үткәрелә торган конкурска һәр елның азагында йомгак ясала. Күптән түгел конкурс комиссиясенең йомгаклау утырышы булды. Жюри 1976 елда чыккан китаплар арасында «Без туган бер җепкә бергә теркәлеп» (Г. Тукай) дигән китапны иң яхшы дип тапты. Бу китап I дәрәҗә диплом һәм 150 сум күләмендә премия белән билгеләп үтелде. «Идел — туганлык елгасы» һәм «Җырларым» исемле китапларга II дәрәҗә диплом һәм 100 әр сум акчалата премия бирелде. Абдулла Алишның «Нечкәбил», Мәхмүт Нигъмәтҗановның «Татар халык җырлары», Равил Фәйзуллинның «Шигырьләр» дигән китаплары III дәрәҗә диплом һәм һәркайсы 50 шәр сум акчалата премия белән бүләкләнде.

Болардан тыш, «Татарстан шәһәрләре буйлап» (яхшы оформлениесе өчен) һәм «Кызыклы зоология» (полиграфия ягыннан яхшы эшләнгән булуы өчен) дигән китаплар кызыксындыру дипломнары белән билгеләп үтелделәр.

## КОТЛЫЙБЫЗ

РСФСР Министрлар Советының әдәбият, сәнгать һәм архитектура өлкәсендә 1976 ел өчен РСФСР Дәүләт премияләре бирү турындагы карары нигезендә сынлы сәнгать өлкәсендә И. Репин исемендәге премия «Чаллы чибәрләре» һәм «Алдынгы терлекчеләр-көтүчеләр Н. Җиһаншин, Ш. һәм Г. Шәкүровлар» дигән картиналары өчен республикабызның танылган рәссамы, СССР Художество академиясенең член-корреспонденты Харис Якуповка бирелде.

*

* *

Совет матбугатын үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Татарстан коммунисты» журналының бүлек мөдире Сәлах Хәмзә улы Хафизовка РСФСРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӨТ БҮЛЕГЕНДӘ

*

* *

Язучылар һәм журналистлар «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры, СССР Верховный Советы депутаты Әгъзам Вәлиханов белән очраштылар. Ул аларга уңышчы бишьеллыкта нефтьчеләр алдында торган бурычлар турында сөйләде, тыңлаучыларны кызыксындырган күп төрле сорауларга җаваплар бирде.

*

* *

Әлмәттәге 1 нче номерлы татар урта мәктәбендә поэзия кичәсе булып узды. Әдәби түгәрәк членнары инициативасы белән оештырылган бу кичәдә шагыйрьләр С. Сө-

ләйманова, К. Булатова һәм яшь прозаик Ф. Гыйльметдинов катнашты. Алар үз-ләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

*
* *

Әлмәт шәһәренең 17 нче номерлы урта мәктәбендә «Кызыклы очрашулар клубы» эшләп килә. Унынчы класс укучылары төрле һөнәр ияләре — танылган нефтьчеләр, төзүчеләр, галимнәр, врачлар һ. б. белән әңгәмәләр уздыралар. Өлкән класс укучылары ноябрь аенда кунакка шагыйрә Сажидә Сөләймановaны чакырды. Ул татар поэзиясе һәм әдәби иҗат процессы турында сөйләде, яңа шигырьләрен укыды, укучыларның сорауларына җаваплар бирде.

*
* *

Ноябрь аенда Әлмәт татар дәүләт драма театры Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург Юныс Әминовның «Сөймим дисәң дә» исемле әсәрен тамашачыга күрсәтте. Спектакль девон нефтенә юл салучы бораулау осталарының фидакарь хезмәтен күрсәтүгә багышланган. Әсәрне сәхнәгә Татарстанның халык артисткасы Зәкия Туишева куйды.

*
* *

Фоат Садриев нефть якларындагы район газетасында эшли. Узган ел аның беренче пьесасы Татарстан язучыларының Әлмәт бүлегендә тикшерелеп, авторга әсәр өстендә эшләргә киңәш бирелгән иде. Пьеса шактый камилләшкәннән соң, Әлмәт татар дәүләт драма театры аны үз репертуарына кертте. Күптән түгел «Их, сез, егетләр» исемле шул спектакльнең премьерасы булды. Фикер алышуда катнашкан язучылардан Юныс Әминов, Сажидә Сөләйманова, Рафаил Төхфәтуллин һәм театр артистлары спектакльне уңай яктан бәяләделәр, шулай ук аерым кимчелекләрен дә күрсәттеләр.

Спектакльнең художество житәкчесе — театрның баш режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Гали Хөсәенов, режиссеры — артист Рөстәм Абдуллаев.

## Киләсе санда:

Журналыбызның 4 нче саны Рафаил Төхфәтуллинның «Китә казлар» дигән повесте белән ачыла. Әсәрдә Бөек Ватан сугышы елларындагы авыл яшьләре тормышы сурәтләнә.

Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы тәгәлләнә. В. Иваненконың Ленин темасына «Арча» исемле хикәясе тәкъдим ителә.

Апрель — татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай туган ай. Журналның үзәк сәхифәләре Габдулла Тукай истәлегенә багышлана: М. Хәсәновның «Тукай хакында сүз» дигән мәкаләсе, илебез әдипләренең Тукай турындагы фикерләре, И. Брагинскийның «Габдулла Тукай һәм Урта Азия әдәбиятлары» исемле чыгышы басыла.

Поэзия сөючеләр бу санда Р. Әхмәтҗанов, Ф. Шәфигуллин, М. Әгъләмов, Ш. Маннапов шигырьләре белән танышырлар. Ә публицистика бүлегендә КПССның Лаеш райкомы беренче секретаре Д. Дәүләтшинаның бүгенге колхозлар үсешен чагылдырган язмасы, И. Зариповның «Туган кыр батыры» дигән очеркы тәкъдим ителә.

Күренекле тәнкыйтьче, Җәлил исемендәге премия лауреаты Гази Кашшафның тууына 70 ел тулу уңае белән, Н. Юзиевның «Фидакарьлек» дигән мәкаләсе, мәрхүмнең моңарчы басылмаган «Журналистлык кайда бетә!» дип исемләнгән хезмәте урнаштырыла.

Болардан тыш әдәби тәнкыйть материаллары, китап күзәтү бирелә. Дүртенче санның кунагы — Чувашстанның «Капкын» журналы көлкеле әсәрләр тәкъдим итә. Гадәттәгечә, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары турында хроника урнаштырыла.

### ПОДПИСЧИКЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Укучыларыбызның күп санлы үтенечләрен искә алып, «Казан утлары» журналына язылу һәркайда дәвам иттерелә. Аңа елның теләсә кайсы аеннан башлап язылырга мөмкин. Бу хакта «Союзпечать»нең республика, өлкә, район агентлыкларына хәбәр ителгән. Журналга язылырга теләүчеләр подписканы үзләре яши торган урыннарда рәсмиләштерергә тиешләр. Редакция журналга яздыру эше белән шөгыльләнми.

«Казан утлары» журналының бөтенсоюз каталогындагы индексы — 73210.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210